# казан утлары

6
ИЮНЬ·1972



ФАТИХ ХӨСНИ

# КПСС өлкә комитетында һәм ТАССР Министрлар Советында

### 1972 ЕЛ ӨЧЕН ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре Комитеты тәкъдимен караганнан соң, 1972 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:

#### ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ

Язучы **Фатих Хөснигә** — «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» китабы өчен.

#### БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ ӘСӘРЛӘРЕ ӨЧЕН

Шагыйрь **Шәүкәт Галиевкә**—«Әти белән кабинада», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Котбетдин мәргән», «Шәвәли», «Тәмле йорт», «Кызык» исемле шигырь җыентыклары өчен.



ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**
ИЮНЬ
1972


## Бу санда


**Н. АРСЛАНОВ.** Кайтар мине. Шигырьләр . . . 3
**Н. СӘФӘРЕВ.** Каргышлы һәм өметле көн. Романнан бүлекләр . . . . . . . . . . . . 10
**З. НАСЫЙБУЛЛИН.** Безнең буын. Шигырьләр . . 33
**Ф. ШӘФИГУЛЛИН.** Диңгез эскизлары. Шигырьләр. 36
**Ш. БИКЧУРИН.** Каты токым. Роман . . . . . . 40
**Р. ВӘЛИЕВ.** Тормыш асылы. Шигырьләр . . . . 90
**Х. ГАТИН.** Әни искә төшкәндә. Шигырьләр . . . 93
**Г. АФЗАЛ.** Карабаш күлендә. Хикәя . . . . . 95

ОЧЕРКЛАР

**М. ХӘМИТОВ.** Бәхетле язмыш . . . . . . . . 97
**М. НАСЫЙБУЛЛИН.** Прокурор . . . . . . . . 101
**З. ӘХМӘТҖАНОВ.** Герой каберендә чәчәкләр . . 108

СӘНГАТЬ

**И. АЛЕКСЕЕВ.** Кинопублицистиканың сугышчан жанры . . . . . . . . . . . . . . . 114
**Л. ИХСАНОВА.** Замандашым турында . . . . . 122

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Х. МИННЕГУЛОВ.** Сәйф Сараиның яңа әсәрләре . 129

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

**С. АКБИЕВ.** Мәдәни бергәлек . . . . . . . . 140

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Үр артында яңа үрләр бар . . . 148

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.** Туган як яме . . . . . . . . 164
**Т. ГАЛИУЛЛИН.** Дөньям кызыксынды[illegible]са . . . 170



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

Н. ФӘТТАХ. Тарих битләрен актарганда . . . . 175

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

КОЛХӨСӘЕН ХӨСӘЕН ОГЛЫ. Тыныч йокла, балам. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . 179

ЮМОР-САТИРА

Ф. ХӨСНИ. Циклон. Хикәя . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 188

Х. ВӘЛИУЛЛИН, Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Акчарлаклар. Җыр . . . . . . . . . . . . . . . 192

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 10/III-1972 ел. Басарга кул куелды 28/IV-1972 ел. ПФ 04053. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тираж 87 446 экз. Заказ Г-181. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

## Нури Арсланов

# Кайтар мине

Каркаралның[1] күге — күчмә болыт,
Җире — биек таулар:
Әкияттәге кебек урманнары
Мәңге-мәңге шаулар!

Шунда, бала чакта, бер иртәдә,
Көтү куган төштә,
Әллә нәрсә булды кинәт миңа,—
Бүгенгедәй истә:

Бөдрә болытларның арасыннан
Фәкать миңа гына
Балкып торды Кояш, алып мине
Алтын михрабына.

Вәхый килгән чакта пәйгамбәр дә
Шулай булмагандыр:
Минем кебек бөтен җаны-тәне
Нурга тулмагандыр!..

Шул таңда, шул гаҗәп бер мизгелдә
Рухым ачты «мин»нән,
Мин матдәдән кинәт мәгънә булып
Күтәрелдем җирдән.

Бар табигать миңа баш игәндәй,
Буйсынгандай булды:
Фанилектән өстенлеген тоеп
Җаным оеп торды.

Кытыклады күкрәгемне шатлык,—
Сулкылдады күңелем:
Беренче кат шунда шигъриятнең
Күк капусын күрдем.

Кайтар мине, хәтерем, үткәннәргә,—
Кыя тауларыма,
Сабый җанга хикмәт нуры салган
Гаҗәп таңнарыма.

---

[1] Каркарал — Казагыстандагы шәһәр.

Элеккедәй пакьләп вөҗүдемне,
Кояш, нурыңны чәч!
Күтәр мине алтын михрабыңа,
Илһам күгеңне ач!

1971

## Асау атым

Туры килде атның иң асавы,—
Тәвәккәлләп мендем иярга.
Шуннан бирле форсат табалмады
Аякларым җиргә тиярга.

Ярышларда сынды өзәңгеләр,
Тезгеннәрем шартлап өзелде.
Чапкан шәпкә кинәт ялтарды ат,—
Егып китмәк булды үземне.

Заман аты юртак, әйдәүләрең
Кирәк түгел бер дә ул атка!
Мин үземне үзем камчыладым,
Тиң булыйм дип шушы пыракка [1].

Юк, ул атны явыз ният белән
Бирмәделәр,— белеп бирделәр,—
Исән килеш егылмас ул — батыр,—
Бабалары кебек, диделәр.

Шул асаудан күргән чыгымнарга,
Дулауларга тәмам өйрәндем...
Килә әнә моңы ил җырлаган
Борынгы һәм яңа көйләрнең.

Борынгыдан — гыйбрәт, яңадан — дәрт
Алып чаба минем аргымак.
Чап әйдә, чап! Үтсә үтсен гомер,—
Тик яшендәй калсын ялтырап!

1971

## Күкчәтау

Анау тауның башыннан күч [2] киләде,
Күч артыннан бер тайлак [3] буш киләде,
Төшкәндә син исемә, хайран илем,
Мөлдерәп ике күздән яшь киләде...

*Казакъ халык җыры*

Күкчәтау, күгең дә күк, күлең дә күк,
Күк далаң буйлап йөрдем яшьлектә күп.
Кояшым карарга да өлгермәде,—
Аерылдым, бала чагым, синнән иртүк.

---

[1] Пырак — канатлы ат.
[2] Күч — җәйләүгә күчеп баручы кәрван.
[3] Тайлак — дөя баласы.

Мәктәбем — яшел йортым, карасана,
Мөлдерәп тора миңа — баласына,
Искедән бер хатирә инде мин дип,
Сыенган биек йортлар арасына.

Җыелып килгән идек ишегеңә,
Кемнәр генә тирбәлмәде бишегеңдә!
Язмышлар, әйтәсе юк, булды хәйран...
Чыдаса чыдар безнең ише генә.

Күкчәтау, башларыңнан күч киләме?
Күч артыннан бер тайлак буш киләме?
Тайлагың булып эзләп кайткан саен
Мөлдерәп ике күздән яшь киләде...

Күгеңнең һаман кояш таңнарында,
Күлеңнең һаман җиләс ярларында,
Күңелнең һаман иләс-миләс чагы,—
Уяна узганнарым алларымда.

Хисләрнең унсигездәй уйнаганы,
Хыялның канат кагып туймаганы!
Кызлар!
Алар инде бездән башкаларга...
Нәфесне тыеп булмый, уңмаганны!..

Күкчәтау, күгең дә күк, күлең дә күк,
Җанга газиз хатирәләр күңелдә күп...
Кайткан саен каршы ала унсигезем,
Яшьлегем шул күлеңә күмелгән күк.

1971

## Шомлы төндә

Күңелгә шом салып бер эт улый,
Нинди борчу икән ул эттә?
Үз тавышына үзе исе китеп
Шыңшый да ул, карый өреп тә.

Таңда китәм, шуңа улый, дисәм,
Мин түгел бит аның иясе.
Ни шомлыкка икән тагын бусы,
Ничек юрап, нәрсә диясе?!

Әллә минем хисләремне сизеп,
Сагышыма кушылып улавы?
Томан баскан тонык айга карап
Җырлавымы, әллә елавы?

Мин урынымнан тордым чыдамыйча,
Әллә нигә сыкрап, пошынып:
Иэрәгемә җиңел булыр сыман
Бер уласам шуңа кушылып...

Туктатырга теләп бирәүләре
Таш атарлар эткә — тиярләр...
Ә мин — кеше, миңа туры карап:
«Сынаттың бит, Нури!» диярләр.

Гомер буе шулай сынатмыйм дип,
Чыгармаган идем өнемне,—
Сагыш тулган икән чиктән ашып,
Гарык кылган икән күңелне...

Ә теге эт улый шомлы итеп.
Аһ, әгәр дә улау киметсә
Эчләремә тулган сагышларны,—
Мин кушылыр идем шул эткә.

1971

## Бөртек булып

Гүзәл яшьлекне бизи дәрт,
Картлыкны — хикмәт.
Исәпләшми моның белән
Бу дөнья нишләп? —
Дәртсезләр дә, мәнсезләр дә
Яшиләр бик шәп:

Аларны да хатын-кызлар
Сөя-ярата,
Эшләреннән дә уңалар,
Абруй да арта,—
Фани дөнья тегермәне
Барын да тарта.

Тегермән ташына бодай
Коелган төштән,
Бер бөртек булып буага
Тәгәрәп төшсәм,
Агып чыгып, язлар саен,
Кырларда үссәм,—

Шул булыр иде хыялның
Бөек җиңүе:
Хикмәт белән дәртнең бергә
Туры килүе,—
Язмышыма үлемсезлек
Алып бирүе.

1972

## Гомер турында

Шагыйрь гомере кыска була, диләр,
Әйбәт кеше, диләр, гомерсез.
Әйтсәм әйтим, моны минем яшьтә
Ишетүе шактый күңелсез.

Хәер, әгәр чынлап шулай булса —
Үлгән булыр идем мин күптән.
Кургаш тәнем җиргә тарта мине,
Ә шигърият — төшерми күктән!

Бөек Сәгъди йөздән артык торган,—
Мең ел инде — яши һаман да:
Тел тидереп кара, күп яши, дип,—
Замандаш ул һәрбер заманга!

Яхшылыкка түгел — озаклады,
Дип әйткәннәр әйтер, ни чара?!
Тик Сәгъдиләр яшен яшәтмичә
Ясамый тор, үлем, ишарә.

1972

●

Килделәр дә керделәр,
Кереп түргә менделәр,
Уйнадылар, көлделәр
Шатлыклар йөрәгемдә!

Шатлык ул килә генә:
Олыга да, кечегә дә,
Дусыңа да, ишеңә дә
Яхшылык телә генә.

1971

## Дантон әйткән диләр

Дантон әйткән диләр эшафотта:
— Башым кискәч күтәр, әй, палач,
Чәчләремнән тотып югарыга,
Анлык кына тора,— дип,— бу баш!

Я киссәң кис син дә «беткән баш»ны,
«Эшафотка мендем» — каршыңда.
Тик төшермә җиргә! — Тузан-туфрак
Утырмасын күзем-кашыма.

Керфекләре сиңа мәхәббәттән
Дымлы аның, нурлы күзләре:
Бер — чиктән тыш бәхетлеләр алар,
Бер — сагышлы, моңлы үзләре...

Бу баштагы уйлар, хыял, җырлар...
Илһамланды синнән, серле каш!
Аунатма син аны аяк аста,
Анлык кына тора бит бу баш!

Синең хөкемең миңа тәкъдир хөкеме,
Бәхетемне тик шул хәл итә:
Бер ни кирәк түгел, әгәр булсам
Тик бер генә көнлек хәлифә!..

1971

## Кыз бала

Каш астыннан күзен сирпеп
Карый бигрәк серле итеп,—
Җанда дәртләр кузгала...
Яратса — яр итә белә,
Вәгъдә бирсә — көтә белә
Безнең чибәр кыз бала.
Кыз бала!
Хәтерләрен калдырырлык
Сүз әйтмәгез сез аңа.

«Ярар микән?» дия-дия,
Мини юбкалар да кия,
Калышмаска үзара:
Заманча атларга кирәк,
Әдәп тә сакларга кирәк,
Нишләсен соң кыз бала!..
Кыз бала!
Татар кызы бигрәк тыйнак —
Сәбәпсез дә кызара.

Казагы да, кыргызы да,
Үзбәге дә бик кызыга —
Татарлардан кыз ала:
Бигрәк матур татар кызы,
Гашыйк итә барчабызны...
Күз тидермик без аңа!
Кыз бала!
Ике бите — пешкән алма,
Кояш кебек кызара.

1971

## Юату

Каләмдәшем Ибраһим Салаховка

Кичерешләрдән авырып егылсаң да,
Авырулардан каушап егылма.
Безнең әле роман укыйсы бар
Имантаулы батыр турында.

Дагстанда йөзәр яшьле ирләр
Йөри диләр атлар өйрәтеп.
Ә безгә бит әле алтмыш кына,—
Өр-яңадан була өйләнеп!..

Ат асавы туры килә икән —
Килсен әйдә, дулап-котырсын,
Ега икән — ексын,
тик иягә
Ир яңадан менеп утырсын!

Бәйгеләрнең зуры алда әле,
Аз вакытта күп юл үтәсе.
Тылсым белән әгәр коткаралсам,—
Барыр идем... ни хәл итәсе!..

Авырып ятар вакытмыни хәзер,
Әле алда гаҗәп узышлар!
Килешми ул безгә, без бу җиргә
Озак яшәр өчен туышлар!

1971

## Рәхимсез таяк

Таяк була, диләр, ике башлы.
Хәят та шул таяк сыман нәкъ:
Бер башы — без туган чак дөньяга,
Икенчесе — дөнья куйган чак.
— Тотын! — диеп суза безгә элек
Ул бер башын, тәпи басарга,
Аннан суга икенчесе белән:
— Вакыт,— диеп,— йомгак ясарга!..

1972

## Бер селкенеп

Бәрәм-бәрәм йөзе ачыла бара
Тирә-юньдә йөргән затларның,
Һәр кайсысы тотына күрсәтергә
Һөнәренең төрле якларын:

Берәүләре, син тау өйгән чакта,
Бер уч туфрак ташлый — өлешен,—
Күз дә йоммый соңра әйтер өчен:
— Бу тауны,— дип,— мин дә өештем!

Авыр юлны ансат үтәр өчен
Берәүләре утыра арбаңа...
Ул гынамы әле!.. үз арбаңда
Аның җырын җырлап бар аңа!..

Үрмәлиләр шулай төрле яклап,
Сырышалар синең өстеңә,
Кызык иткән сыман бер җүләрне,
Тап булгандай дәрвиш-меские.

Бер селкенеп ташлыйм андый чакта —
Өстән төшә тегеләр шыбырдап:
Җан җиңеләеп китә арынганга,
Тик тән генә кала чымырдап...

1972

Нәзир Сәфәрев

# КАРГЫШЛЫ ҺӘМ ӨМЕТЛЕ КӨН

РОМАН

*Күренекле үзбәк язучысы һәм драматургы, Хәмзә премиясе лауреаты Нәзир Сәфәрев «Каргышлы һәм өметле көн» романында үзенең бала чагын, үзбәк халкының революциягә кадәр булган авыр тормышын зур осталык белән чагылдыра. Нәзир Сәфәревнең хатирәләрендә 1916 елгы Җиззах восстаниесе зур урын тота. Бу романда уйлап чыгарылган вакыйга юк, ул тарихи әһәмияткә ия.*

*СССРда яшәүче бик күп башка халыклар кебек, тугандаш үзбәк һәм татар халыклары да борын-борыннан ук дус булып, аралашып яшиләр, ике арада элекке заманнарда ук башланган әдәбият һәм сәнгать багланышлары совет чорында тагын да үсә, киңәя бара. СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән укучыларыбызга романнан бүлекләр тәкъдим итәбез.*

## БЕРЕНЧЕ АДЫМ



Әгәр дә мәгәр бу фани дөньяда мәңге яши торган берәр нәрсә булса, ул, мөгаен, безнең Җиззах базарыдыр. Аны җир йөзе яралганчы ук барлыкка килгән, диләр. Хәер, алай ук булмаса да, ул, һичшиксез, мин туганчы ук яшәгән. Сабый чакта без базарны күктәге ай-йолдызлар кебек мәңгелек дип уйлый идек. Ерактагы йолдызларның исем-җисемнәрен, ай-елларның рәтен-чиратын белмәсәк тә, базар көненең кайчан буласын тәгаен белә идек. Ул көнне базарга Җиззахның бар тарафыннан халык агыла. Урамда атлар кешнәве, сыерлар мөгрәве, сарыклар бәэлдәве, тәгәрмәчләрнең сыкранып шыгырдавы ишетелә. Базарда кешеләр шау-гөр килә. Сатучылар бертуктаусыз үз малларын мактап кычкыра. Менә шул тавышларга тимерче алачыгындагы чүкечләр такылдавы, ат дагалаганы, колакларны тондырып ишәк кычкыруы өстәлеп, барысы бергә бутала, корама юрган кебек чуар базар өстен соры тузан болыты каплап ала.

Бала-чага өчен базар көненең тагын бер кызыктыргыч ягы бар: базар ашы — назар[1] ашы дигәндәй, ул чакта ашханә белән чәйханәләрдә генә түгел, ишек алларында да тәмле ашлар пешә. Бар җирдә казан асыла. Бер урында ләгъман шулпасы кайнаса, икенче урында мәнте[2] яки сумса өлгерә. Безнең әнкәй базар көнне гадәттә пылау пешерә торган иде. Белмим, кем уйлап чыгаргандыр ул ризыкны? Әмма пылаудан да тәмлерәк нәрсә, ай-һай, бу дөньяда бармы икән?!

Мин сезгә Җиззах базарының кайсы көнне икәнен әйтмәдем бит әле. Ә ул алдагы вакыйгаларда зур урын тотачак. Бездә базар дүшәмбе белән пәнҗешәмбе көннәрдә була. Башка җирдә ничектер, анысы миңа мәгълүм түгел. Чөнки безнең дөньябыз ул чакта җир йөзендәге иң «гүзәл» калаларның берсе — бөек Җиззах шәһәре белән чикләнә иде.

Менә шул базар кичендә әнкәй безнең алга, зур табакка салып, кайнар пылау китереп куйды. Без Мансур абый белән дөньябызны онытып ашарга керештек. Тамак туйгач, ашыклы сөяк өчен әүмәкләшеп тартыша башладык. Шунда әнкәй йодрыгы белән башыма берне тамызмасынмы. Алай гына да түгел, шул сөяк аркасында мин тагын да зуррак бәлагә тарыдым.

Миннән сигез яшькә зур Мансур абыем үтә тискәре, ашык уены дигәндә өй түбәсеннән ташланырга әзер, ә мәктәптә укуны җене кебек сөймәүче, кире беткән бер малай иде. Әгәр озаграк югалып торса, ул, һичшиксез, берәр җирдә ашык уйнаучылар арасында булыр. Менә шуңа күрә абый һәр көнне диярлек бер түгел, бернича тапкыр әти-әнинең шелтәсен ишетә, ә кайчакта сыртына әткәйнең билбавы да төшә торган иде.

Яман чир тиз йога, яман гадәт тиз керә дигәндәй, дүрт-биш яшьтә булуыма карамастан, абыйның «чире» миңа да күчте. Ашыкка «гашыйк» булып, күземә ак-кара күренмәс булды. Бу «чирдән» котылуның бердәнбер дәвасы, әнкәй әйтмешли, көндез мине абыйдан аеру иде. Бер көнне әнкәй йоклар алдыннан әтигә әйтте:

— Моның өчен Нәзирколны Мансур укыган мәктәпкә түгел, кызлар мәктәбенә бирергә кирәк,— диде.

Әткәй, өнәмичә:

— Нәзиркол сабый бит әле. Укуның мәгънәсе булмас, бер елга сабыр итик,— дип караган иде дә, кая ул! Анам:

— Чыбыкны вакытында бөгү кирәк, үсә төшкәч соң була ул! Бала җанга газиз, тәрбияле булуы аннан да газизрәк. Мәктәптә белем алмаса да, тәртипкә өйрәнә торыр,— дип кырт кисте.

Әткәй бу сүзләрне тыныч кына тыңлап торгач, «мәйлең, теләсәң нишлә» дигәндәй, кулын селтәде.

Иртәгесен әнкәй мине таң тишегеннән уятты. Арыкта бит-кулымны юып, өс-башыма киенгәч тә, ай-ваема карамастан, җилтерәтеп мине Хикмәтай абыстай мәктәбенә алып китте. Барганда анам миңа нинди генә үгет-нәсихәтләр бирмәде! Янәсе: «Уку кешене күзле итә (әйтерсең минем күзем юк); укыган — үлмәс, укымаган — көн күрмәс (янәсе, мин көн күрмим); укыган ил — узар, укымаган ил — тузар» дип, әллә нәрсәләр тезеп китте. Әгәр ул уку кешене шул кадәр бәхетле итә икән, нигә соң абый ул «мәктеп» дигәннән уттан качкан кебек кача? Мин үземчә шулайрак уйлап бардым.

Исемдә — яз башы иде. Өрекләр чәчәк коеп, җимеше борчак кадәр булган чак. Мәктәп капкасыннан керү белән күзгә ташланган беренче нәрсә ишек алдындагы юан кәүсәле зур тут агачы булды. Аннары игъ-

---

[1] Күркәмлек.
[2] Үзбәк ашлары.

тибарымны айванда[1] бытыр-бытыр сабак кабатлаучы кыз-кыркыннар жәлеп итте. Әнкәй зур нәзакәтлек белән абыстайга нәрсәдер аңлата, ә минем күзем — бөгелә-сыгыла китаптан ниндидер аңлаешсыз сүзләр укучы кызларда. Күзем аларда булса да, күңелем мәһабәт тут агачында. Аның балланып агара башлаган җимеше зөбәрҗәт төсле яшькелт яфраклар арасыннан күңелне кытыклап тора. Ботактан ботакка сикерүче чыпчыклар, кызларга ияреп җыр җырлагандай, сайраша-сайраша өчлы томшыклары белән ап-ак тутларны чукып җиргә төшерәләр. Аларның бу «хезмәте» миңа бик тә ошый. Җирдәге тутларны алып авызыма кабудан үземне көчкә тыеп торам...

Мин тут җимешен хәзер дә бик яратам. Яз көне, тут өлгерү белән, без бакчадан кайтмый торган идек. Революциягә кадәр, Төркестан шәһәрләренең күбесендәге кебек, Җиззахның да мин туып үскән мәхәлләсендә каләндәрханә[2] бар иде. Аның зур бакчасын икегә бүлеп, уртадан киң аллея уза. Бакча түренә таш йорт салынган. Анда дәрвишләр имамы Дәдәбай хәзрәт тора. Урта Азиянең ерак кышлакларыннан килгән дәрвишләр гадәттә шул каләндәрханәгә туктыйлар. Базар көннәрендә башларына кызыл фәс киеп, урамга чыгалар. Дәдәбай хәзрәт артына тезелеп: «Я абла дуст, я абла!.. Бәһаветдин әүлия!..» ди-ди мәйданнан мәйданга тулганып йөриләр, тирә-юнегә халык җыеп, дини хорафат орлыгы чәчәләр. Кешеләрдән хәер сорыйлар. Базар беткәч, килгән табышларын уртага салып, каләндәрханә бакчасында аш пешерәләр, әфьюн тартып кәефләнәләр иде.

Каләндәрханә бакчасын мактамас җиреңнән мактарсың. Ул җанга дәрт кертә торган тыныч бер урын. Елның уникә аенда да суга интеккән, аерата җәй көннәрендә түзә алмаслык эссе булган Җиззахта андый салкын күләгәле урынны бүтән бер җирдән дә таба алмассың. Бакчаның уртасыннан уйнаклап Нәйман инеше ага. Уртада зур хавыз[3]. Аның буенда кәүсәсе кочакка сыймаслык юан, бөдрә карагайлар үсеп утыра. Менә шул төш Җиззах халкы өчен иң рәхәт урын санала иде. Анда бер чәйнек чәй эчәргә дип безнең мәхәлләдән генә түгел, тирә-як кышлаклардан да бихисап кешеләр җыела. Безнең иште малайларны күбрәк бакчадагы тут агачлары тарта иде. Яз башында аннан да иртә нәрсә өлгерә, я, әйтеп кара әле?.. Тут пешү белән каләндәрханә бакчасында балалар түгел, зурлар да балга җыелган корт кебек мыж киләләр. Бакча зур юл буена урнашканга, үткән-сүткәннең җәяүлесе-атлысы ихтыярсыздан шунда таба борылып китәр иде. Кайбер атлар каләндәрханә капкасына житү белән шып туктый. Камчыламыйча хәтта урыныннан да кузгата алмыйсың.

Агач башына менеп чүмәшкән малайлар бер-берсенә тоташкан ботаклар аша бер туттан икенчесенә күчәләр, көн буена шуннан төшмиләр иде. Мин әле буйга кечкенә булганга, өскә менә алмыйм. Үзем тут төбендә, ә күзләрем җимешендә. Җепкә тезелгән энҗе бөртекләре кебек, күзне камаштырып, авыз суларын китерәләр. Һай, әгәр кулым озынрак булса икән!.. Шуңа күрә, теләсәм-теләмәсәм дә, берәрсенең рәхиме килеп, ботак селеккәнен көтәргә кала. Яхшы әле, бәхетемә, ара-тирә чыпчыклар куныл, чукый-чукый тутларны җиргә төшерәләр...

Хикмәтай абыстай янында басып торганда, мин менә шулар турында уйландым. Бакчада тут өлгереп, авызым балланырга торганда, әнкәй мине ниндидер абыстайга биреп калдырмакчы. Минем ул чактагы кыяфәтем, мөгаен, капкынга эләккән җәнлек баласыныкы төсле булгандыр.

---

[1] Терраса.
[2] Дәрвишләр торагы.
[3] Инеш юлында ясалган сулы чокыр.

Бу берни дә аңламый торган томана малай булган икән дип уйлый күрмәгез тагын. Биш яшемдә үк инде мин ак белән караны аера башлаган идем. Оясында ни күрсә, очканда шуны куа, диләр. Шуның кебек, мин дә күп нәрсәне абыйдан ала идем. Мансур әкәнең мин, бер генә көн булса да, карышмыйча мәктәпкә киткәнен хәтерләмим. Бичара анам, абыйның букчасына икмәк белән кипкән өрек салып, капкага кадәр озатып куя. Ә абый, укырга бару урынына, бөтенләй башка якка китеп бара иде. Берәрсенең ишек алдына керә дә көн буе малайлар белән ашык уйный. Мәктәптән кайтыр чак җиткәндә генә, букчасын асып, өйгә кайтып керә. Ләкин безнең әнине алай җиңел алдап булмый. Ул хәтта күңел түрендәге яшерен уйларыңны да белә. Абый нинди генә хәйлә кормасын, әни барыбер аны сизә һәм мәктәптә булмаганы өчен ярыйсы ук пешерә торган иде. Ә әткәй андый чакта гел сукрана гына.

Менә шуның өчен, абыйдан күреп мин дә бүген сөрән салдым:

— Мәктәптә калмыйм!.. Өйгә кайтам!..— дип, әнинең итәгенә чатябыштым.

Ә Хикмәтай абыстай, ачулану урынына, зәңгәр күзләрен шар итеп, ягымлы елмайды:

— Карале, безгә нинди дәү егет килгән! Исемең кем әле?.. Ә, әйе, Нәзиркол бугай... Сине кемгә нәзер кылдылар соң?

Әни горур бер кыяфәт белән:

— Шаһизинд әүлиягә,— диде.

— Шундый зур кешегә нәзер ителгән егет, әлбәттә, укып мулла булырга тиеш. Юкса, изгеләрнең рәнҗүе бар! — дип, абыстай мине юатмакчы булды.— Әнә, дәү апаларыңа кара, нинди тырышып укыйлар... Адаләтхан, монда кил әле!..

Абыстай тавышына айвандагы укучылар арасыннан бер кыз торып, безнең янга килде. Бу озын буйлы, шомырт кара күзле, куе кашлы, конгырт йөзле апаны мин кайдадыр күргән идем кебек. Адаләтхан, кулларын күкрәгенә куеп, абыстайга текәлде.

— Бу егетне таныйсыңмы?

— Таныйм... Исеме Нәзиркол. Раһәтай апаның малае. Акыллы егет,— дип, ул минем башымнан сыйпады.— Какылың[1] бигрәк матур үрелгән!.. Кыз булсаң, аллы-артлы кырык толым җибәрер идең. Болай булгач, безнең кызлар белән бик тиз дуслашырсың инде...

— Бәрәкалла, Адаләтхан. Әйткәнең килсен. Газиземне сезгә, ә сезне аллаһы тәгаләнең үзенә тапшырам,— диде әнкәй, шатлыгы тавышына чыкты.

— Каяле, мин энекәшкә бүләк биримче,— дип, Адаләтхан кулын үзенең камзул кесәсенә тыкты.

Яулыгын маңгаена кадәр төшереп бәйләгән бу ят апа миңа беренче күрүдә үк ошады. Нәрсә бирер икән дип, күзләремне мөлдерәтеп карап тордым. Адаләтхан миңа өч-дүрт бадам белән чуклы конфет сузды. Мин, алыргамы-юкмы дигәндәй, кылтаебрак әнкәйгә борылдым. Карасам, янымда анам юк!.. Ул җил-җил атлап капкага таба китеп бара иде. Мин акырып елап җибәрдем. Беләгемнән кысып тоткан Адаләт апа, бер дә исе китмичә, әнигә кул изәде:

— Барыгыз, Раһәтай апа! Улыгыз өчен борчылмагыз! Дәрестән соң үзем илтеп куярмын.

Кыскасы, Адаләтхан тәмле теле белән алдап-йолдап, мине мәктәпкә бик тиз ияләштерде. Укучы кызлар аны хәлфә апа дип йөртәләр икән. Ул Хикмәтай абыстайның уң кулы саналып, балаларны укытырга булыша икән.

[1] Изгеләргә багышлап үстерелгән чәч толымы.

Бала чакта мин шикәр-конфет яратучан идем. Хәлфә апа минем тәмле тамак булуымны сизеп, ансат кына үзенә каратып куйды. Беренче айларда, көн саен диярлек иртән безгә кереп, шикәр яки бадам төше кушылган кара мәез[1] биреп, күңелемне таба, аннары җитәкләп мәктәпкә алып китә иде. Тора-бара мәктеп дигәне үземә дә ошап, бара алмый калган көннәремдә үземне кая куярга белмичә аптырап бетә торган идем. Миндәге бу үзгәрешне сизгән анам эчтән генә сөенеп йөрде. Мансур абый гына, һаман үз гадәтен куып, ата-анага көн саен көенеч китерә иде.

Көннәрнең берсендә кичкырын әнкәй:

— Бульрдай бозауның йөрүеннән билгеле. Бу Мансурдан мулла чыкмас, ахрысы,— диде.— Исән чакта итәгебезне җыярга кирәк булыр. Бала бөтенләй юлдан язганчы, Ашурмәт энеңә илтеп, берәр эшкә өйрәтәсе иде. Иртәдән кичкә кадәр тимерчелектә күрек басып, чүкеч сукса, үзенә бераз акыл кермәсме. Әле ул яшь. Баштан ук дөрес юлга бастырмасаң, бер-ике елдан безне санга да сукмас.

Безнең әнкәй сүзен җилгә ташлый торганнардан түгел иде. Иртәгесе көнне җепшек кар явуга карамастан, мине Ашурмәт әмәкене[2] алып килергә йөгерттеләр. Ул безгә килгәч, зурлар җылы сандал[3] янында бик озак гәп сатып, чәй эчеп утырдылар. Менә шунда абыйның да язмышы хәл ителде.

Мин сандал чокырына аягымны сузып, зурларның сөйләшкәнен тыңлап утырам. Үзем, саксаул күмеренең кызуына чыдый алмыйча, аягымны әле бер, әле икенче почмакка күчерәм. Анам сандал астына чәйнек куйган икән. Аягым ялгыш шуңа тиеп, чәйнекне аударып җибәрдем. Кайнар чәй үзәгемә үтәрдәй итеп аягымны пешереп алды. Мин ачыргаланып елап җибәрдем. Әнкәй: «Вай, мин үлмәсәм!»[4] ди-ди, дәррәү сандалның юрганын күтәрде. Мин аягымны тартып алдым. Ике балтырым да чиләнеп, кабырчыкланып чыккан. Мин, әрнүемә түзә алмыйча, дөнья куптарып акырам. Ашурмәт әмәке аягымдагы яраны күргәч: «Зыян юк. Тозлы су китер. Шул ярдәм итә», диде. Анам тиз генә тозлы су ясап китерде. Аннары кәсадагы суга чүпрәк манчып, балтырыма сөртте. Мин тагын да болайрак кычкырырга тотындым.

— Бәла аяк астында йөри дип тикмәгә әйтмәгәннәр. Башыма тай типмәсә, чәйнекне сандал астына куяммы соң?..— дип, әнкәй үз-үзен битәрләп алды. Атам:

— Борчылырлык берни дә юк әле, анасы. Өч-дүрт көннән төзәлер. Тиресен генә пешерткән. Чиләнгән җире купкач, яңасы чыгар,— дип тынычландырды.

Шулай да аяк газабы ике атнадан артыкка барды. Елан чаккан — баудан куркыр дигәндәй, шуннан бирле аягымны сандал чокырына тыкмас булдым. Ул чакны Адаләт апа, көн саен диярлек безгә килеп, бер-ике хәреф өйрәтеп китте. Акылбәк дустым да, һәр көн мәктәптән кайтышлый безгә сугылып, хәл белешеп торды. Әнисе аңа Хасиятханның тубыннан да тыгызрак итеп яңа туп тегеп биргән икән. Бер кергәндә шуны миңа сузып:

— Мә, Нәзиркол, бу синдә торсын, аягың төзәлгәч, бергә уйнарбыз,— диде.

Тупны күргәч, башым күккә тия язды.

— Болай булгач, Хасиятләргә ялынмыйбыз,— дидем.— Аягым гына төзәлсен, аның кирәген бирермен әле!..

---

[1] Киптерелгән йөзем.
[2] Абзый.
[3] Үзбәк миче, өстенә юрган капланган кечкенә өстәл астындагы чокырга утлы күмер салына.
[4] «Ай-һай, үзем гаепле» дигәнрәк әйтем.

— Куй, кызларга ачу тотма. Әгәр Хасиятхан ир бала булса, үзем дә карап тормас идем, синең өчен үч алыр идем,— дип, Акылбәк йодрыгын төеп күрсәтте.— Сабагыңны укыйсыңмы соң?

— Укыйм... Әлиф, би, ти, си, жим, хи, һи...— дип тезеп киттем.

Анам тандердән[1] нан[2] алып маташа икән, җавабымны ишеткәч:

— Бәрәкалла, улым, зур булып үс! Укыгач мулла булырсың,— дип мактады. Аннары кәрзингә нан тутырып бүлмәгә алып керде. Безнең алга кызарып пешкән берничә нан куйгач, каяндыр ачкычын алып, түрдәге сандыкны ачты. Йозак төрле тавыш чыгарып зеңгелдәп ачылды. Әни сандыктан бер уч конфет белән мәез алып безгә сузды.

— Мәгез, балакайлар, нанга кушып ашагыз. Хәзер кайнар чәй дә кертәм,— дип, чәйнекне алып, ишек алдына чыкты. Әнкәй кыштыр-кыштыр эшләп йөргән арада без сандал өстендәге конфетларны бетерә язган идек инде.

Аягымның ярасы төзәлмичә, өйдә утыру тәмам туйдырды мине. Безнең йорт урам ягына караганга, андагы шау-шу аермачык булып ишетелә иде. Көннәрдән бер көнне урамнан дәрвишләрнең сузынкы тавышы ишетелде:

«Диванаи Мәшраб мән булам!
Әүлиягә тиң булам!
Я, абла дуст, абла!
Хак тәгалә, абла...»

Бу — Кашкардан килгән дәрвишләр булса кирәк. Алар шулай, суза-суза, Мәшраб бәетен әйтергә яраталар. Үз тирәләренә кеше җыелгач, такмаклый-такмаклый биергә керешәләр. Минем атылып урамга чыгасым, дәрвишләрнең уенын карыйсым килде. Акрын гына урынымнан тордым, чалыш-чолыш атлап, ишек алдына чыктым. Көн күзне камаштырырлык аяз иде. Кар эреп, җир өсте кесәлгә әйләнгән. Таеп егылмас өчен, иплән кенә атлыйм. Балтыр итем бераз тартышса да, аягым элекке кебек авыртмый. Шулай биш-алты адым киткәч, шатлыгымнан кычкырып җибәрдем:

— Әни!.. Күр әле!.. Аягым төзәлгән... Менә үзем атлыйм!

Анам абзарда апара суын бутый икән, минем тавышка йөгереп чыкты: «Сак бул, улым, егыла күрмә!» — диде. Мин батырая төшеп: «Нишләп егылыйм, ди, күрмисеңмени, менә үзем атлыйм ич» дип, тагын бер адым алга атладым. Анам йөгереп килеп мине кочаклап алды. Урамга чыгыйм әле дип күпме ялынсам да, риза булмыйча, янадан урыныма илтеп салды.

Берничә көннән аягым төзәлде. Мин яңадан укырга йөри башладым. Иртәнге чәйдән соң абый Ашурмәт әмәке алачыгына, ә мин, хәлфә апаны да көтмичә, мәктәпкә барырга ашыга идек.

Хикмәтай абыстайның йорты каләндәрханә бакчасы артында иде. Анда барыр өчен башта зур урамны чыгарга, аннары ташландык ихата аша узып, тар тыкрыктан китәргә кирәк. Абыстайның ишек алды шактый зур булса да, анда туттан башка бер нинди агач та юк иде. Шуңа күрә җәй көннәрендә анда ми кайнарлык эссе була. Без зур йортның күләгәсенә кереп укысак та, янып-пешеп чыгабыз. Ә көз көннәрендә без кебек караңгы бүлмәгә күчә идек. Анда бер-беребезгә сыенып җылынабыз. Кышкы салкыннарда исә дәрес вакытында дер калтырап утырабыз. Дөрес, бүлмә уртасында, исеме өчен булса да, бер сандал куелган. Өстенә киндер тышлы зур юрган капланган. Без шул сандалга аркабызны терәп, калтырана-калтырана сабак укыйбыз.

---

[1] Көлчә пешерә торган мич.
[2] Көлчә.

Укучыларның күбесе кыз-кыркын булып, малайлардан без өчәү генә: әмәкемнең улы Мәлиҗан, яшьтәшем Акылбәк һәм мин. Кызлар укып арыгач, дәрес вакытында да курчак уйныйлар. Ә без үзебезгә уен таба алмагач, аларны ирештерә башлыйбыз. Бер көнне шулай Мәһри белән Хасияткә көзге чебен кебек бәйләнеп тенкәләренә тидем. Хасият түзмәде, кыргый мәчедәй битемне тырнады. Күзләремнән кайнар яшь атылып чыкты.

— У-у! Мәми авыз, хәзер абыстайга әйтәм! — дип, аңа йодрык күрсәттем.— Тубыңны бирәсеңме, юкмы?

Хасият минем сүзне колагына да элмәде. Хәтта борылып та карамады. Аның юрамалый санга сукмавына ачуым килде. Мин җиң очы белән битемдәге канны сөртеп алдым.

Шул көннән бирле Акылбәк белән без Хасиятнең тубын чәлдерергә йөрдек. Эченә йомшак йон тутырып, тышы зәнгәрле-кызыллы җеп белән тегелгән бу туп безнең күзгә шул кадәр матур булып күренә, уйнау түгел, кулда тотып тору да зур ләззәт булыр кебек иде.

Мәктәптән кайтканда без урамның астын-өскә китереп туп уйныйбыз. Эченә сыер йонын укмаштырып тегелгән безнең туп үтә йомшак булганга, ерак очмый. Хасиятнең тубы исә резина кебек сикерә иде. Шуңа күрә без аны ничек тә кулга төшермәкче булдык. Хасиятхан — кояш кебек чәчрәп торган мут кыз. Тубын безгә ансат кына бирмәячәк. Мин аны тагын ничектер куркытмакчы идем, Хасият керфек тә какмады. Сүземне ишетмәмешкә салышып, Мәһри белән сөйләшүендә дәвам итте:

— Өйдә минем моңардан да зуррак курчагым бар,— дип, кулындагы таш курчакны күрсәтте.

— Миңа да уйнарга бирәсеңме? — ди Мәһри.

— Безгә барсаң, бирәм.

— Баштa әнкәйдән рөхсәт сорыйк. Аннары бергә барырбыз, яме?

— Нигә ялынасың шул саран бакага! — дидем.

— Ә син, туң колак... җиңешкән булма!

— Мәһри синең кебек тәртипсез бала түгел. Бар, әтәчләнеп йөрмә монда! — дип, Хасият кашларын җыерды.

— Кем әтәч? Минме? — дип, тегенең курчагына барып ябыштым.

Ике кыз бер якка, мин икенче якка тартыша башладык. Нәтиҗәдә курчакның кулы өзелде, «Әфтияк»нең битләре ертылды. Үеннан уймак чыкты. Болай да чебен тимәс чер итәргә торган Хасият үкереп елап җибәрде:

— «Әфтиягем»не ертты, сугыш чукмары! Янасын табып китер!..

Хәлфә апа бездән сорашкан арада, бүлмәгә абыстай үзе килеп керде. Гаепнең миндә икәнен белгәч:

— Кызларны рәнҗетүдән башка, үзеңә берәр уен таба алмадыңмы? — дип, мине тиргәп алды.

— Ә ни өчен алар курчак уйный? — дип, мин дә кәпрәя төштем.

Абыстай кызларга ачулы карап:

— Дәрес вакытында уйнамагыз дип күпме әйттем сезгә?! — диде.

— Ә без уйнамадык! — дип, Хасият иреннәрен бүлтәйтте.

— Ә бу курчак кемнеке?

Хасият җавап бирү урынына яңадан елый башлады. Мин гаепсез кеше сымак тураеп басып тордым. Шул чакны абыстайның уртанчы улы кереп, кемдер килгәнен әйтте. Абыстай бүлмәдән чыгып барышлый:

— Адаләтхан, дәрестән соң өчесен дә алып кал! Ә сез бу сөзгәк тәкәдән сак булыгыз! — диде.

Кызлар абыстайның сүзен шунда ук эләп алып, мине «Сөзгәк тәкә! Сөзгәк тәкә!» дип үртәргә керештеләр.

Хәлфә апа «нан хөрдәк»[1] игълан итте.

Укучы балалар шау-гөр килеп урыннарыннан тордылар. Кайсы букчасыннан көлчә, кайсы сумса алып ишек алдына йөгерделәр. Хасият әле һаман бер почмакта балавыз сыга иде. Кызлар: «Елама, Хасият, хәзер без ул сөзгәк тәкәне акылга утыртабыз» дип, үзара пышын-пышын сөйләшеп алдылар. Ул көнне Акылбәк дустым мәктәпкә килмәгән иде. Димәк, миңа беркем дә ярдәм итмәячәк. Әллә битемдәге тырналган эзне күрсәтеп абыстайга әләкләргәме? Шулай уйларга да өлгермәдем, кызлар миңа өерләре белән ташландылар да йодрыклары белән башым, иңсәм, аркамны дөмбәсләргә керештеләр.

— Нигә кызларны рәнҗетәсең, апара корсак!

— Кулың сыныгры, мөртәт!

— Кыз бала малайларга тиң буламы?..

— Нишләп ул малай булсын, ди? Ир баланың баш түбәсендә чәч толымы буламыни?..

Мин алардан ничек котылырга да белмәдем. Берсе какылымны шул кадәр нык тартты ки, күземнән утлар чәчрәде. Ахырда тәмам ачуым килеп, аларны берәм-берәм бөтерә башладым. Ләкин кызлар өстен чыкты. Күмәкләшеп мине аяктан ектылар да, мәчегә ташланган карчыгалар кебек, бер-бер артлы әле колагым, әле какылымнан тартып, бәреп-төртеп качтылар. Бер-икесенә көчем җитсә дә, бергәләшеп тотынгач, билгеле, мин җиңелдем. Шуның гарьлегенә чыдый алмыйча, үкереп елап җибәрдем.

Минем тавышка хәлфә апа бүлмәдән чыгып, мине кызлардан аерып алды. Өстемдәге тузанны каккач, арык буена алып барып бит-кулымны юды. «Елама, Нәзиркол, малай кешегә күз яше килешми. Туктасаң, анаңа әйтмәм. Дәрес бетү белән өеңә кайтырсың», дип башымнан сыйпады. Мин, үкси-үкси булса да, елаудан туктадым.

Озын тәнәфес бетмәгән иде әле. Кызлар кайсы кая утырган килеш тамак ялгый. Берәвесе өрек тышын кимереп бетергәч, таш белән ватып төшен ашый, берәвесе каешланып каткан кавын кагы чәйни иде. Ашап туктаганнары ишек төбендәге чиләктән болганчык су эчә. Аннары беришесе яу куган кебек йөгерешеп ишек алдына сибелде. Алар шуклыгына башкалар да әлмәшеп китә. Кызлар качышлы уйный, бии, җиңнәрен сызганып, такмак әйтергә керешәләр:

Җәһидә көе чыккан, диләр,
Начар аты чыккан, диләр.
Атлас-ефәк күлмәкләрне
Кимәгәнен белмиләр.
Җәһидә-һү,
Җәһидә-һү,
Җәһидә! Җәһидә! Җәһидә!

Мин, ачуым килеп, айванда утыра идем. Мөслимә исемле бер кызның тәмләп кавын ашавын күргәч, минем дә ашыйсым килеп китте. Букчамдагы ярты нанны алып ашадым. Шунда Акылбәк дустым исемә төште. Без аның белән гел бергә утырып, бер мәезне икегә бүлеп ашый торган идек. Акылның бүген укырга килмәвенә көенеп куйдым. Ул булганда кызлар да болай хәтәр кыланмас иде.

Ниһаять, тәнәфес бетте. Хәлфә апа безне дәрескә чакырды. Барыбыз да айванга тезелеп, кошчыклар төсле, туктаусыз чебердәшә башладык. Кайсыбыз «Әфтияк», кайсыбыз «Чар-китап», кайсыбыз «Суфи аллаяр»[2]ны укый. Куйсын атлы бер кыз карый кебек сузып ниндидер бәет әйтә:

---

[1] Зур тәнәфес.
[2] Дини мәктәпләрдәге уку китаплары.

Тәмуг белән гөлҗәннәт
Әйтешә ди бер заман.
Җәннәт әйтер: син яман!
Миндә яшьләр гыйльман[1].
Тәмуг әйтер: син яман,
Миндә яшьләр елан.

Хасият исә кычкырып: «Иннә әгътәйнә кәл-кәүсәр, иннә әгътәйнә кәл-кәүсәр», дип кабатлый. Мин ул «аять»не яттан белсәм дә, авыз эченнән генә укыйм.

Дәрестән соң абыстай миңа нинди җәза бирер икән? Бәлки, бернидә булмас. Хәлфә апа, вәгъдәсендә торып, Хикмәтай абыстайдан гаебемне кичерүен сорар. Шул мәлне ишектән Адәләтхан үзе күренде: «Балалар, китапларыгызны җыештырып букчагызга салыгыз», диде. Билгеле, без моны бик тиз эшләдек. Тагын нинди эш кушар икән дип, барыбыз да аңа текәлдек.

Гадәттә, һәр пәнҗешәмбе көнне абыстай йортында өмә уздырыла иде. Дөрес, без көн саен диярлек дәрестән соң бүлмәләрне җыештырып, ишек алдын себереп китәбез. Шулай да җомга алдыннан мәктәптә зур өмә була. Андый чакта һәр укучыга бер эш тапшырыла. Үз башларына әле караңгылык бәласе — пәрәнҗә зәхмәте төшмәгән үсмер кызлар урамнын теге ягындагы арыктан чиләкләп тыз-быз су ташый, буйга җиткәннәре, ирләр күзеннән качып, ишек алдын себерә, бүлмәләр җыештыра, табак-савыт юа иде.

Бүген кызларның күбесе тырышып эшләсә дә, кайберләре вакыт уздырыр өчен ялкау гына кыймылдый. Ә мин, киресенчә, үз гаебемне аклар өчен җанымны Җәббарга бирдем[2]. Абыстай алдында ничек тә яхшы атлы булырга тырышам. Урамнан йөгерә-йөгерә су китерәм. Ике кыз күтәргән чиләкне берүзем күтәрәм. Алар бер тапкыр китергәнче мин икене китерәм. Хасият белән Мәһри мине узмакчы иде дә, кая ул!.. Бер чиләкне ике кеше күтәргәч, йөгерергә уңайсыз: суы чайкалып түгелә башлый икән. Куйсын атлы кыз: «Суны тутырып ташыгыз, шаярыр чак түгел, җомга алды. Тизрәк өйгә кайтасыбыз бар!» дип, тегеләрне тиргәп алды. Хасиятхан чиләкне үзе генә алып йөгергән иде, көлкегә калды: юеш җирдә таеп егылып, өс-башын пычратты. Шулай итеп, өмә бетте. Хәлфә апа барыбызны җыеп, эшебезгә бәя бирде. Берсен мактады, икенчесен хурлады. Минем турыда: «Нәзиркол бүген барыгызны да уздырды. Аңардан үрнәк алыгыз!» — диде.

Башым күккә тия язды. Каш астыннан гына Хасияткә караган идем, үчекләп телен чыгарды. Мин: «Ашыкма, арт сабагыңны укытырмын әле!» дигәндәй, йодрык күрсәттем. Хәлфә апа өйгә кайтырга рөхсәт итте. Без, читлектән котылган җанвар сыман, шау-гөр килеп, капкага йөгердек. Билгеле, беренче булып урамга атылып чыгучы мин идем...

## БЕРЕНЧЕ КӨЕНЕЧ

Көз көннәренең берсендә Хикмәтай абыстай мине үз бүлмәсенә чакырып алды да: «Иртәгә җомга, аның артыннан нинди көн килә?» дип сорады. Мин җомганы алып килүче пәнҗешәмбе белән җомганы озатып куючы шимбә көннәрен яхшы белә идем. Шуңа күрә шатырдатып:

— Берсекөнгә шимбә була! — дидем. Абыстай:

— Бәрәкалла! Акыллы егет икәнсең, синнән кеше чыгачак,— диде дә янадан миңа текәлде.— Ә хәзер, Нәзиркол, туп-туры өеңә кайт та

---

[1] Хур егете.
[2] Тырышып эшләдем (халык әйтеме).

анана әйт: шимбә көнне иртән мәктәпкә килсен, абыстайның сөйләшәсе сүзе бар икән, диген. Ярыймы?

— Ярамаган кая!..

Мин абыстай кушканча йөгерә-йөгерә өйгә кайтып киттем. Капкадан кергәч, сулышым кысылып, сүземне башлый алмыйча тордым.

— Әни... Җомгадан соң...

— И ходаем, артыңнан яу кумагандыр ич. Утыр. Ял ит,— диде анам.

— Шимбә көнне... иртә белән... абыстай сиңа мәктәпкә барырга кушты.

— Ни өчен?

— Анысын белмим.

— Сорамадыңмыни?

— Юк, сорасам да әйтмәс иде. Анаң белән сөйләшәсе сүзем бар диде.

— Әллә берәрсе белән сугыштыңмы?

— Юк, сугышмадым. Җир йотсын әгәр!..

— Анаңа эш өстәп йөрмәгән булсаң ярар иде инде. Сабагыңны хәзерләп барган идеңме соң?

— Абыстай хәтта синнән кеше чыгачак дип мактады.

Әнкәйнең йөзе яктыра төште.

— Чынлап әйтәсеңме?

— Начарлык эшләсәм, мактамас иде.

— Менә күрдеңме? Тырышып укысаң, үзеңә яхшы. Рәхмәттән башкасын ишетмәссең. Әгәр начар укып, тәртип бозсаң, үзеңә генә түгел, ата-анаңа да күңелсез булачак. Синеңчә, шуларның кайсысы яхшы?

— Әлбәттә, рәхмәте!

— Бәрәкалла. Ә хәзер букчаңны чөйгә эл дә касадагы ботканы аша.

Колагым әнкәйнең сүзен тыңласа да, күзем каләндәрханә бакчасындагы агачлар башында иде. Чөнки җил кузгалу белән очыргыч очыртырга дип сөйләшкән идек. Шул мәлне өй түбәсеннән Рәшитнең җил чакырып кычкырганы ишетелде:

— Шамал![1] Хатының үлде, китмәнеңне күтәреп йөгер-р!

Мин түбәгә менәргә дип торганда, капкадан Акылбәк күренде. Көн җиләс булуга карамастан, дустымның өстендә юка күлмәк. Мин шундук аны кисәтеп: «Тынынны чыгарасы булма, әни өйдә», дип ишарә ясадым. Ул, мине аңламыйча, аптырабрак як-ягына карады.

Безгә бу минутта әни күзенә күренмәү хәерлерәк иде. Аяк очы белән генә баса-баса аш өенә кереп, очыргычымны алып чыктым. Без башка көннәрдәге кебек таңдер өстеннән өй түбәсенә менәргә батырчылык итмәдек. Әни сизсә, очыргычымны алып, ботка ашарга кушачак. Хәер, дөге боткасын ашарга да була. Әгәр ул: Җил булмагач, очыргычыгыз барыбер очмас. Бала буларак синең дә бераз ярдәмең тисен», дип берәр эш кушса нишләрсең? Без тиз-тиз атлап урамга чыктык. Түбәгә бер Рәшит кенә түгел, башка малайлар да җыелган. Барысы да бербер артлы җил чакыра иде:

— Шамал! Хатының үлде, китмәнеңне күтәреп йөгер-р!..

Безнең өй түбәсе күршеләребезнеке белән тоташ булганга, очыргыч җибәрер өчен мәйдан киң иде. Әскә менгәч, очыргычымны Акылга тоттырдым да үзем урамга таба йөгердем. Очыргыч һавага аз гына күтәрелде дә түгәрәк ясап түбәгә төште. Моңа, билгеле, икебезнең дә кәефебез китте. Без җил бар микән дип яңадан тирәкләргә карадык. Ләкин агач башлары тыныч иде.

---

[1] Җил.

— Нәзиркол, әйдә, без дә җил чакырыйк! — дип кычкырды Акылбәк безнең өй түбәсеннән.

— Нигә акырасың, күзле бүкән!

— Акырса ни булган?

— Әнкәй ишетсә, икебезне дә түбәдән куып төшерәчәк. Исемемне әйтеп бүтән кычкырасы булма! Җилне үзең чакыр. Тавышыңны әни танымый,— дидем.

Акылбәк сагаеп кына кычкырды.

— Әнә, тирәк башы бераз селкенде! — дип кычкырдым кинәттән.

— Алайса, үзең дә акырма! — диде Акылбәк, агач башыннан күзен дә алмый тора бирде.— Күрдеңме, мин кычкыру белән җил кузгалды.

— Акылбәк, очыргычны алып, әнә тегендә барып бас,— дидем.

Дустым, мин күрсәткән җиргә барып, очыргычын күккә чөяргә әзерләнде. Мин «җибәр» дип кычкыруга, һавага атты. Мин, җепнең икенче башын тотып, түбә буйлап йөгердем. Очыргыч шактый өскә күтәрелгәч, һавада уйнаклап алды да яңадан килеп төште.

— Менә мактан инде! Син чакыргач, җил килгән, имеш.

— Шулай да җил хәзер юлга чыкты,— диде Акылбәк.— Ышанмасаң, әнә агач башына кара. Селкенәме?

Тирәк очлары сизелер-сизелмәс кенә селкенә башлаган иде.

— Җил исмәсә, агачларны селкетерсең, бар... Без җилгә кайгылы хәбәр ишеттердек. Ул хатыны үлгәнен белде, күрәсең. Шуңа әле көнчыгышка, әле көнбатышка карап йөгерә. Шул әкиятне ишеткәнең бармы? — дип сорады Акылбәк.

— Ә үзеңнең?

— Бар.

— Кемнән?

— Әткәй сөйләгән иде. Җил дә, кешеләр кебек, хатыны үлгәнен белгәч, юлга чыга икән. Ләкин аның хатыны кайда икәнен берәү дә белми. Бичара җил, үз карчыгын эзләп, әрле-бирле искән арада, без дә очыргычны җибәреп өлгерик.

Озак та үзмады, йомшак җил исеп, агач башларын селкетеп куйды. Без очыргычны һавага җибәргән идек, күз ачып йомганчы, өскә күтәрелеп, болытларга тия язды. Рәшитнең очыргычы, һавада елан кебек боргалана торгач, каләндәрханәдәге агачлар башына барып кадалды. Ул аты-юлы белән сүгенергә керешә. Безнең очыргыч өскә күтәрелгән саен кечерәя барды. Шатлыгым эчемә сыймыйча, жырлап җибәрдем:

Үзем ясаган ситарча[1],
Оч болытка җиткәнче!

Өй түбәсендә җил ул кадәр сизелмәсә дә, тагын да өстә нык исә бугай. Очыргыч күккә күтәрелгән саен, мин дә кәтүктәге җепне курыкмыйча җибәрә бирдем. Баш яулыгы кадәр очыргыч хәзер дәфтәр бите кебек кенә булып калды. Мин, күземне очыргычтан алмыйча, артыма чигенә торгач, соңгы адымымны түбә читенә атлап, аска мәтәлгәнмен...

Бераздан күземне ачсам, ни күрим! Урамга бер көтү халык җыелган. Күлмәк итәгем стенадан чыгып торган өрлек башына эләккән дә, мин асылынып калганмын икән. Астагы кешеләр шау-гөр килеп миңа таба кулларын сузган.

— Нәзиркол, кыймылдама!

— Берәрегез тизрәк түбәгә менегез!..

---

[1] Очыргыч.

— Мөэмин менеп китте инде.

— Нәзиркол, курыкма. Яхшы әле, күлмәгең нык икән.

Урамда әнинең ай-вайлаган тавышы ишетелде. Кемдер: «Раһәт апа, шаулама, баланы куркытасың... Әнә, Мөэминҗан түбәгә менде. Хәзер тартып алыр»,— дип, әнкәйне тынычландыра.

— Мөэминҗан, баланың күлмәгенә кагылма. Аягыңны өрлеккә куй.

— Сабыр ит! Умырзак, чапаныңны сал!.. Астан чапан җәеп тотарга кирәк!..

Кыскасы, кешеләр мең бәла белән мине үлемнән коткарып калдылар. Әни мине иркәләргә дә, ачуланырга да белмәде. Без өйгә кереп барганда, кемдер арттан:

— Раһәт апа, баланы битәрләмәгез! Аңа бүген болай да житәрлек эләкте. Моннан ары өй түбәсендә абайлап йөрер! — дип кычкырды.

Шунда очыргычым исемә төшсә дә, сорарга кыймадым. Соңыннан белешсәм, ул Туңкүпер мәхәлләсенә төшеп ертылып беткән икән.

Шулай итеп, жомга узып, шимбә килде. Без әни белән мәктәпкә киттек. Хикмәтай абыстай анам белән ягымлы гына сөйләшкән кебек тоелса да, минем өчен ул сөйләшүнең никадәр авыр булганын өйгә кайткач кына белдем. Ягъни, мин инде тугыз яшькә житеп, балигъ булганмын. Миңа моннан ары кызлар белән бергә укырга ярамый, шәригать кушмый икән... Укырга сәләтем булганга, абыйстай мине ир балалар мәктәбенә бирергә киңәш иткән икән.

Анам мине, әлбәттә, укытырга теләгән иде. Әткәй генә: «Мелла Сәфәрнең карыны мәзинлектән бер дә туймады. Укыса кем булыр дип беләсең? Берәр мәчеткә суфи булыр. Аның кемгә кирәге бар? Нәзирколны юньлерәк эшкә өйрәтергә кирәк. Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс» дип карышып караган иде дә, анам бу юлы да үз дигәнен эшләде. Иртәгесе көнне бер тандер нан пешереп, зур кәрзингә салды да, өстенә күлмәк-ыштанлык ак бәз куеп, мине мәхәллә мәчетенә алып китте.

— Дамелла, баламны укырга китердем. Ите сезгә, сөяге безгә,— диде.

Шуннан соң бер атна вакыт узгач, Акылбәкнең анасы да баш өстенә кәрзин күтәреп, мәчеткә килеп керде. Дустымны да инде кызлар мәктәбендә бүтәнчә тотмаганнар икән.

Шулай итеп, без янадан Акылбәк белән бер мәктәптә укый башладык. Хикмәтай абыстай үз укучыларына никадәр миһербанлы булса, мелла Миртаҗан рәхимсез, усал кеше иде. Булыр-булмас «гөнаһың» өчен дә җәзага тартып, укучыларның кан яшьләрен агыза иде.

Мәктәптә укыган өчен атна аралаш бәйрә[1] акчасы, өч-дүрт айга бер палас акчасы китерергә кирәк. Шулай да астыбыздагы җәймә саламнан гына булды. Түбәсе унбер өрлектән торган бүлмәгә алтмыш-житмеш бала көчкә сыябыз. Һәр көнне таң белән мәчеткә кереп, иртәнге намазны укыйбыз. Һәрбер яңа сабак, әйтик, корьәннең бер сүрәсеннән икенчесенә күчү зур «вакыйга» санала. Андый көнне дамеллага «азатлык» бүләге бирәбез. Ә инде «Һәфтияк»тән «Корьән»гә яки «Чар-китап»-тан «Хужа Хафиз»га күчкәндә баш хәлфә белән пишкадәмнәрнең дә авызын майлап, мелла Миртаҗанга өс-башлык китерергә кирәк була иде.

Ләкин моны эшләү барысының да хәленнән килми. Хәерчелек белән мохтаҗлык даими юлдаш булган ярлы-ябагайларга андый чыгым бик авырга төшә иде. Бирган — ходайга да ярагаи дигәндәй, монда да байбәтчәләр алдан чыга: һәр көн диярлек дамелланың авызын майлаганга, сабактан-сабакка күчмәгән атналары булмый иде. Мулла аб-

[1] Камыштан үрелгән чыпта (иске мәктәпләрдә балалар асларына җәеп утырган).

зый күбрәк аларга игътибар бирә. Шуңа күрә алар мәктәпне тизрәк бетерә; бай баласы унбишкә житсә — баш, ярлы баласы утызга житсә дә яшь булып кала бирә. Зур өметләр баглап, биш-алты ел буена алган «белемнәре» биш вакыт намаз уку белән берничә сүрә һәм аять өйрәнүдән артыкка бармый иде.

Мәхәлләдә берәр авыруның хәле мөшкелләнсә, аның янына гадәттә мулла абзыйны чакырталар. Сырхау кешене үлемнән «коткарыр» өчен кырык ясин чыгарга кирәк. Менә шул эшкә дамелла яраткан шәкертләрен жигә. Авыру дөнья куйса, ясин кыска була. Андый чакта: «Үләсе авыруның үлгәне яхшы, калган күңелнең тынганы яхшы», дип дога кылалар. Аның каравы, мәрхүмнең кием-салымы, түшәк-ястыгы мелла Миртажан белән пишкадәмнәргә өләшенә.

Хирыс мулла чыбык сөяр дигәндәй, Миртажанның кулыннан бер вакытта да чыбык төшмәде. Таяк белән теләсә кемне мулла итәргә була дип уйлаганга күрә, дәрес вакытында аның тал чыбыгы бертуктаусыз чыжылдап, әле бер, әле икенчебезнең аркасын сыдырып тора иде. Аерата бөйрә яки күмер акчасын, «азатлык» яки пәнжешәмбе бүләген китермәгән малайлар тал чыбыгының тәмен ешрак татый иде.

Иртән дәрес булмасена керү белән мулла абзый гадәттә, пишкадәм байбәтчәләрне чакырып, сабакларын тыңлый. Алар биргән бүләкне ефәк кебек чишелеп кабул кылгач, озак-озак итеп дога укый. Аннары гына яна сабакка күчә иде.

Дамелланың менә шул йомшак ягын сизгән бер байбәтчә аны гел мыскыл итә, хәтта шәкертләр алдында да көлкегә калдыра торган иде. Мулла абзый аны дәресен тыңларга дип чакырганда, бай малае кесәсенә кулын тыгып, бик озак капшанып маташа. Дамелла сабырсызланып уч төбен кашый: «Бу куллар юкка кычытмый торгандыр, байбәтчә!» дип, учын кат-кат үбеп, күз-кашын сөртә.

Көмеш тәңкәне кулына төшергәч, күңеле күтәрелеп, байбәтчәнең ата-анасына гына түгел, жиде буын әрвахларына кадәр дога кыла, хәтта бездән дә дога кылдыра иде. Аннары Ибраһим хәлфәгә борылып:

— Шәкертләреңә әйт, мелла байбәтчәдән үрнәк алсыннар. Һавадагы торнадан кулдагы чыпчык артык. Йөз тапкыр әйтелгән «сез-без»гә караганда бер тапкыр бирелгән жиз бездән артык. Моны барысы да ата-аналарына ишеттерсен! — ди.

Аның каравы, ярлы малайларын тыңлаганда, Миртажанның күзкашы жимерелә, бөлмәне кара болыт каплап алгандай була. Шәкертләр дер калтырап төшә. Бичара Хәмит белән Садыйк сабакларын кабатлаганда утка-суга керергә дә әзер торалар иде. Аптырагач, күзләрен мөлдерәтеп безгә карыйлар. Ләкин без нишли алабыз соң? Бу мәсхәрәдән хәтта котылыр әмәлең дә юк. Инсәләренә чыжылдап төшкән чыбыктан икесе дә калтыранып куя... Ә без, йөрәккә кан сауса да, моны күрмәмешкә салышып, бөгелә-сыгыла сабак укыйбыз. Мулла абзый тегеләрне кыйнап туйгач, чыбыгын ара-тирә безнең тарафка да сузгалый иде.

Хәмит бичара тешләрен кысып булса да түзә, сер бирмәскә тырыша. Аның үжәтлеге мулла абзыйның ачуын гына көчәйтә... Бер көнне дамелла, тәмам тугарылып китеп, Хәмитнең өстендәге бишмәтен салдыртты. Карасак, чыбык үтмәсен дип, ул өстенә өч-дүрт кат камзул киеп килгән икән!.. Менә шунда мулла абзый ярыла язды. Аның кушуы белән, Хәмитнең өстенә бер зур малай атланып, кулын артка каерды. Мулла абзый ярсый-ярсый Хәмитнең аркасын каезлады. Моңа хәтта чыбык та түзмичә берничә жиреннән сынып чыкты. Ибраһим хәлфә малайны кызганып: «Тәүбә диген, каһәр төшкере нәмәрсә!» дип кычкырды. Ә Хәмит һаман бер сүз дәшмәде. Шулай да сулы чыбыктан малай һушын жуйды. Тәнен телгәләп бетергән чыбык эзләреннән жылы кан тамчылары саркып чыкты.

Шуннан соң, берничә көн узгач, без тагын бер коточкыч хәлгә тап булдык:

Балалар арасында барыбыздан да ярлырак Сәфәр атлы бер малай бар иде. Аның сыртында көн саен диярлек чыбык уйный. Без аны Сәфәр Чекәнәк[1] дип йөртә идек. Бот буе чаклы гына булса да, үзе гаҗәеп өлгер, зиһенле, хәлфә биргән сабакларны тиз үзләштерә. Атасы Фәйзи оста камыт, ыңгырчак, ияр баулары тегеп көн күрә. Алар дүрт бала. Барысы да кечкенә, барысы да ашарга сорый.

Сәфәр Чекәнәк яңа сабакка күчәр алдыннан атасыннан акча сораган. Фәйзи оста: «Ашарыгызга булдырып, өс-башыгызны бөтәйтү дә бик житкән!» — дип, сүзен кыска тоткан. Шуннан соң Сәфәргә дә Хәмитнең язмышы эләкте.

Без иртә белән мәчеткә кереп, иртәнге намазны укыдык. Сәждәгә киткәндә кемдер байбәтчәнең табан астын кытыкламасынмы. Байбәтчә шуңа шаркылдап көлеп, намазын бозды. Мулла абзыйга шул житә калды. Аңа нәрсә: тәкә булса булсын, тик сөт кенә бирсен. Сәфәргә бөтенләй урынсызга бәйләнер өчен сәбәп табылды. Дамелла аның кул-аягын бәйләтте. Табан астына пәке белән сызып, ярасына тоз сипте. Сәфәр ачыргаланып, куркыныч һәм ят тавыш белән кычкырып җибәрде, ләкин аның тавышына колак салучы булмады. Миртаҗан, һаман да әле канәгать булмыйча, Сәфәрнең аякларына җәза калыбы кидертте. Аннары башын аска каратып, өрлеккә астырды. Моңа барыбыз да тораташ булып катып калдык. Сәфәр бераз тыпырчынгач, кинәт тынып калды. Йөзе күм-күк булып чыкты. Җан бирмәгәе дип без курка калдык. Күзләребез дымлана башлады. Беренче булып Ибраһим хәлфә телгә килде:

— Тәкъсир, Сәфәрнең гаебен кичерегез. Бу эшне ул түгел, мин эшләдем,— диде, аннары безгә таба борылды: — Әйдәгез, балалар, бөтен болай шаярмаска дамеллага сүз бирик!

Без нәкъ шуны гына көткән кебек бертавыштан:

— Сүз бирәбез! — дип кабатладык.

Мендәр өстендә таш сын кебек утыручы мулла абзый Сәфәр гәүдәсенә акаеп карагач, ваемсыз гына урыныннан торып, ямьсез тавыш белән:

— Төшерегез каһәр суккырыны! — диде.

Хәлфә иплән кенә бауны бушатты. «Җансыз» гәүдә җиргә төшерелде. Миртаҗан бүлмәдән чыгып китү белән, без Сәфәр янына жыелдык.

— Егетләр, ишекне капламагыз, һава керсен! — диде хәлфә, малайның йөзен җилпәзә белән җилләндерә башлады.

Сәфәр тиз генә аңына килә алмады. Тәне мәетнеке кебек агарып-күгәреп чыккан иде.

Бу хәлне Сәфәрнең ата-анасы ишеткәч тә, дамеллага бирни булмады. Киресенчә, анасы мәктәпкә килеп, Миртаҗаннан гафу үтенде: «Дөрес эшләгәнсез, тәкъсир. Бала-чага таяктан үлми, акылга гына утыра. Дамелладан да курыкмагач, ул кемнән курыксын? Улымның ите сезгә, сөяге безгә дип, баштан ук сөйләшкән идек бит. Тәртип бозгач, кирәгенчә җәзасын да алган. Һаман да әле аягына баса алмый. Инде гаебен кичерсәгез дә була. Шулай итсәгез, үлгәнче сезгә дога кылыр идем. Зинһар, баламны урамда калдырмагыз. Ярлы баласына ак-караны танытканыгыз өчен үзегезгә дә савабы булыр!» дип ялынды.

Менә шунда мулла абзый да түзмәде, күңелендәгесен ачып салды:

— Ярлы дисезме?! Дөньяда кем күп — ярлы күп! — дип, ярсып китте.— Яшермим, мин үзем дә бай түгел. Минем дә гаиләм, бала-чагам бар...

[1] Кечкенә.

— Беләм, тәкъсир, сезнең дә бай булмавыгызны,— дип, аның сүзен бүлде Хушруй түтәй.— Шулай да безнең көнгә калганыгыз юк әле. Бай булсагыз, чәчләремне чалартып, хатын башыма сезнең янга килмәс идем. Байга ялынганчы, ходайга ялын, диләр. Бай байга карый, ярлы ярлыны таный. Ярлы булгач, үз ишегезнең хәлен аңларга тиешсез. Моның сезгә дә савабы тими калмас.

Миртаҗан мыегы астыннан зәһәрле генә елмайды:

— Менә сез саваплы дисез! Коры савап белән тамак туймый икән шул. Яхшы әле, алтмыш-житмеш бала арасында өч-дүрт байбәтчә бар... Юкса, валлаһи, ачтан үләрсең. Аннары шәкертләрнең барысы да мулла булса, атка печән кем салыр? Игенне кем игәр? Сезгә киңәшем шул: улыгызны мәктәптән алып, берәр һөнәргә өйрәтегез.

— Киңәшегез өчен рәхмәт, тәкъсир! Алайса, мин дә башлаган сүземне әйтеп бетерим инде,— дип, Хушруй түтәй дә катгый бер карарга килгәнен сиздерде.

Ләкин Миртаҗан аны тыңларга теләмәде. «Өйлә намазына тәһарәтемне яңартасым бар» дип, урыныннан торып ишек алдына чыкты.

— Болай булгач, сез дә, дамелла, байлыкка сатылгансыз икән! Ач шәкерттән кач дигәннәре дөрес булса кирәк. Сез дә ярлы кешедән качарга булдыгыз. Мәйле, байбәтчәләрегездән аерылмагыз! — диде Сәфәрнең анасы, чәчваны[1] башы өстенә күтәрде.

Хушруй түтәйнең ябык йөзе саман кебек саргайган, күзләре дымлы иде. Ул, яулыгы белән яшьләрен сөрткәч, тезенә таянып аягүрә басты.

— И ходаем, бу дөньяга ярлы итеп яратканчы, яратмасаң ни булган! — дип, хәсрәтле көрсенеп, бүлмәдән чыгып китте.

## ГӘП-ГӘШТӘК[2]

Безнең ишек алды Уратүбә һәм Рәват мәхәлләләре белән чикләшеп, базар мәйданы безгә якын гына иде. Каршыдагы каләндәрханә капкасы янына биш-алты чәйханә урнашкан. Анда көндезен-кичен, аерата кыш көннәрендә кеше күп була. Җиззахның иске шәһәрендә чәйханәне гомумән санап бетергесез. Мәхәлләләрдә торучы халыкның бер өлеше һөнәр, вак сәүдә белән шөгыльләнсә, калган өлеше диһканчылык һәм бакчачылык белән көн күрә. Базарга якын мәхәлләләрдә сабын кайнаталар. Шуңа күрә аларны «сабынчылар» дип йөртәләр. Җиззах базарын һәм якын тирәдәге кышлакларны сабын белән шулар тәэмин итә инде. Безгә күрше ишек алларында күнчеләр яши. Алар тире иләп, менә дигән сәхтиян, шигерин күне ясыйлар. Аннары аларны итекчеләргә, кибетчеләргә һәм вак сәүдәгәрләргә саталар.

Җиззах халкына ташкентлылар йогынтысы бик зур. Базарга китерелгән малның күбесе шулар кулыннан уза. Шуңа күрә сәүдә дөньясы аларны «базар пычагы» дип йөртә. Төрле сбруй-дирбия, киез-келәм, кызыл мал, жеп, ефәк, чәй, конфет-прәннек кебек әйберләр шуларда була. Өстәвенә, шәһәрдәге кием-салым, читек-кәвеш тегүчеләрнең дә күбесе Ташкент кешеләре иде.

Без торган Уратүбә мәхәлләсе базар янында булганга, андагы халыкның күбесе тимер әйберләр, икмәк, тәм-том пешерү, хушбуй әзерләп сату белән шөгыльләнә. Базардан читтәрәк торган Аккурган, Рәват, Мулкалы, Төкчиле мәхәлләләрендәге кешеләр исә иген игеп, бакча үстереп, терлек асрап көн күрәләр иде. Пәнҗешәмбе белән җомга көннәрендә аларның барысы да базарга килә. Базар уртасы умарта күче

---

[1] Пәрәнҗә кигәндә йөзен каплый торган кара челтәр.
[2] Яшьләрнең күңел ачу мәҗлесе.

кебек гөжли. Ләкин моны читтән күзәтү ләззәтнең йөздән бер өлешен генә тату дигән сүз. Аны тулысынча тояр өчен базарның эченә кереп йөзәргә, кайнарга кирәк. Шуна күрә базарга, аерата пәнҗешәмбе көнне, олысы-кечесе, йомышы булганы-булмаганы да барырга атлыгып тора иде. Базар — арка-башыңны язар, дигәннәр. Анда барган кешенең күңеле көр. Берсе — атын сатып ишәк алса, икенчесе — үгез сатып бозау ала. Ә һөнәрчеләр атна буена теккән чапан, түбәтәй, читек-кәвешләрен сатып, киләсе базарга кадәр җитәрлек итеп кирәк-яракларын булдыра.

Миртаҗан дамелла шәкертләрен исә базар үзе түгел, ә җомга көне күбрәк кызыксындыра. Ыштансызның төшенә ике аршин бәз кергән дигәндәй, без җомганы зарыгып көтеп ала идек. Чөнки ул көнне мәктәпкә бармыйбыз. Күзгә зиндан булып күренгән дамелла йорты урынына, кичкырын гәп-гәштәктә булабыз. Безгә уен-көлке булса, шул җиткән. Киләсе атнада кичәнең кайда буласын алдан ук сораштырып беләбез. Һәм ул көнне, тышта таш яуса да, гәштәк буласы йорт янына барып, ишек төбен сагалый идек.

Ул елларда гәп-гәштәк уздыру үзбәк халкының бер гореф-гадәте иде. Кайсы гына мәхәлләне алма, кешеләре аерым даирәләргә бүленгән. Егерме-егерме биш яшьтәгеләр бер даирәгә, егерме биш белән кырык арасындагылар икенче, аннан да өлкәнрәкләре өченче даирәгә җыела иде. Гәштәккә яңа кеше керергә теләсә, моны барысы бергә җыелып хәл итә. Әгәр ул кеше берәр ягы белән даирә шәрикләренә ошамаса, аны гәштәккә алмыйлар.

Һәрбер гәштәкнең даирә башы, ягъни егетләр агасы була. Аңа теләсә кем сайланмый, буй-сыны килешкән, үткен зиһенле, үз фикерен, әйткән сүзен уздыра алырлык кеше сайлана. Егетләр аның әйткәнен теләсә нинди шартта да үтәргә тиеш була. Гәштәктә аракы эчеп кәеф-сафа кору тыела. Әмма алларындагы дәстәрхан буш булмый, аш-су, җиләк-җимеш мул куела.

Минем башка чыккан өй-каралтылы ике абыем бар иде. Зурысының исеме Насыйр, кечесенен — Касыйм. Икесе дә бер ана балалары булуга карамастан, холыклары бөтенләй башка иде. Касыйм абый кара күзле, кара кашлы, коңгырт йөзле, сакал-мыегы үзенә килешеп тора. Өстенә пөхтә киенә. Тимерче булып эшләгәнгә, кешеләр аны «оста Касыйм» дип йөртәләр. Үзе юкта хәтта «Касыйм фарән»[1] дип тә әйткәлиләр. Чөнки аның кулыннан килмәгән эш юк. Аерата тимер-томыр, корыччуеннан замананың кирәкле нәрсәләрен барысын да ясый; өстәвенә, үзе кырык егеттән торган гәштәккә даирә башы булганга, иптәшләре аны «Касыйм аксакал» дип тә атыйлар иде.

Зур абыем Насыйрга килгәндә, аның бер түгел, өч төрле һөнәре бар. Ул оста музыкант: замананың мәшһүр җырчысы, шагыйре, шул ук вакытта комарлы уеннарын да яратучы бер кеше иде. Ул «Садыр» көенә даирә[2] уйнап, «Рахәт» белән «Мөнаҗәт» көйләренә дөтәр[3] чиртеп җырлаганда тыңлаучыларның күзенә яшь килә торган иде. Насыйр абыйсыз туй-мәҗлес кызмый. Абый аларның түрендә була. Бер көнне чәйханәдә чәйләп утыручы сәнгать осталарының берсе: «Насыйр кулында даирә телгә килеп, сайрый башлый» дигәч, икенчесе аны куәтләп: «Дөтәр уйнавын кая куясың! Үзе дөтәр чиртеп, «Рахәт» көен җырлап җибәрсә, кеше түгел, кош та очуыннан туктап тыңлый. Ә инде «Тургай» көен җырлаганда, дөтәр колагына сандугач үзе кунардай була!..» дип

[1] Талантлы оста.
[2] Шөлдерле барабан.
[3] Чиертеп уйнала торган музыка коралы.

мактады. Аннары мине иркәләп: «Нәзиркол, син Насыйр акән кебек җырчы буласыңмы, әллә комарчымы?» дип сорагач, мин: «Комарчылык начар нәрсә, атам ачулана!» дип ычкындырдым. «Алайса, кем булырга телисең?» дигәч: «Мин Касыйм әкәм кебек фарән булам», дидем. Барысы да шаркылдап көлеп җибәрде. «Дөрес эшлисең, энекәш. Касыйм әкәнә охшасаң, начар егет булмассың... Насыйр әкәң дә болай уңган кеше, тик комарлыкка бирелеп кенә харап була. Комарлык начар нәрсә. Аның белән берүк мавыга күрмә. Ул егет кеше эше түгел!» — диделәр.

Безгә якында гына кечкенә бер чәйханә бар иде. Кыш көннәрендә яшьләр җыелып, буш вакытларын шунда уздыралар. Җәй көне урамдагы туфрак тезгә кадәр җитсә, кыш көне ул йөри алмаслык баткакка әйләнә. Яңгыр яуганда аннан ат-арба да уза алмый. Атлар, елга кичкәндәге кебек, ыңгырчак бавына кадәр кереп бата. Хәтта зур тәгәрмәчле арбаларны да арбакәшләре[1] чыгара алмый интегә торган иде. Менә шул чак чәйханәдәге егетләр арба тирәсенә җыела; берсе ат башыннан тарта, икенчесе арбаны этә, өченчесе тәгәрмәчен күтәрешә. Бергәләшеп тотынгач, шау-гөр килеп, ат-арбаны баткактан тәкъ тартып чыгаралар. Егетләрнең өс-башы пычранып бетә. Озак та узмый, шул ук урынга тагын икенчесе кереп бата... Эшсезлектән кая барырга, көчләрен кая куярга белмәгән диһканчы яшьләр дүшәмбе көннәрен үзара акча җыеп күкмә[2] уздыралар. Анда төрле уен-көлке белән күңел ачалар.

Безнең ишек алды, шул замандагы бар кешеләрнеке кебек, алгы кура, арткы курага бүленгән. Алгы курада зур миһманханә[3] бар. Тугыз өрлектән торган бүлмәнең ике як стенасы алебастр белән сыланып, аңа зур тәкчә[4] уеп ясалган. Җир идәненә салам түшәлеп, өстенә казакъ киезе җәелгән. Урта өрлектә егермеле лампа асылынып тора. Ишек төбендәге кечкенә чуен мичтә ташкүмер уты дөрли. Стена буйлап җәелгән тар кәрпәгә мәхәллә егетләре тезелешеп утырган. Түбәтәе өстеннән ефәк яулык урап, җиннәрен сызганган Насыйр абый мич янында даирә күнен кыздырып маташа. Ишек төбендә кунакларны каршы алучы егетләр басып тора.

Мин алар күрмәгән арада бүлмәгә кереп, бер почмакка постым. Даирә агасы кунакларны урнаштырып, кичәгә хәзерлек белән мәшгуль. Ул ишеккә таба борылган арада мин бер егеткә: «Әкәҗан, мине тәкчәгә утыртчы!» дип әйткән идем, Насыйр абый мине шәйләп:

— Тагын килдеңме, кыстыбый! Бар, өйгә кер! — дип ачуланды. Яхшы әле, Урдушмәт дигән егет мине яклады:

— Сабыйга алай каты кагылырга ярамый. Бала күңеле нечкә була. Әйдә, ул да бераз күңел ачсын,— дип, култыгымнан тотты да ике куллап тәкчә төбенә күтәреп утыртты.

Насыйр абыем миңа күзенен агын күрсәтте.

— Бала чактан ук начарлыкка өйрәнмәсен иде. Кичә дә афьюн исенә исереп, мәтәлеп төште.

— Ә мин бүген исермим. Күземне дә йоммам! — дидем.

Моңа барысы да көлешеп алды:

— Исермәгәч, безгә иптәш буласың икән. Болай булгач, сине дә гаштәккә тиң итеп алабыз. Үзең ничек уйлыйсың, Нәзиркол? — диде Урдушмәт әкә, көлемсерәп. Егетләр барысы да миңа, ә мин Насыйр әкәгә текәлдем. Шул мәлне кичәге исерүем, иртән башым авыртып мәктәпкә бармыйча калуым кылт итеп исемә килеп төште.

---

[1] Арба йөртүче кучерлар.
[2] Кыш көннәрендә уздырыла торган яшьләр кичәсе.
[3] Кунак өе.
[4] Юрган-ястыклар куяр өчен стенага уеп ясалган куыш.

Ә Урдушмәт әкә миннән җавап көтә:

— Я, ник дәшмисең? Әллә гәштәк акчасын бирәсең килмиме? Хәер, безгә иптәш булсаң, анысын сорап тормабыз,— диде.

Мин кыяр-кыймас кына:

— Иптәш булсам, әфьюн белән шаярмассызмы соң?? — дип сорадым.

Егетләр тагын шаркылдап көлеп җибәрделәр. Шул мәлне таза гәүдәле Корбанбай пәһлеван:

— Егетләр, тынычланыгыз! — дип кул күтәрде. Бүлмә эче кинәт тынып калды. Барысы да даирә агасының авызына карады:

— Нәзирколның Урдушмәткә биргән җавабын ишеттегезме?

— Ишеттек.

— Юк.

— Нәзиркол бала булса да, Урдушмәтне төпсез чуманга утыртты бит,— дип, Азизхан дигән егет авызын ерды.

Ләкин даирә агасы көлмәде. Ул кашларын җыерып, салмак кына сөйләвендә булды.

— Нәзирколның кинаясе бер Урдушмәткә генә түгел, барыбызга да кагыла,— диде ул.— Бу—улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигән шикелле. Чынлап та безнең арада әфьюн белән мавыгучылар күбәеп бара. Бава-бәнге йортында җанын әфьюнга саткан кешеләр дә менә шулай башлаган. Безнең гәштәк егетләренең берсенең дә әфьюн өммәте булганын теләмәс идем! Даирә башы Касыйм аксакалның да фикере шулай.

Бүлмәдә шылт иткән тавыш та ишетелмәде.

Корбанбай пәһлеван билендәге зәңгәр билбавын чишеп, аны аркан кебек ишә башлады. Мин егетләр агасының ачуы яман, Урдушмәтне кыйнап ташламагае дип курыктым.

— Я, Урдушмәт! — диде ул, тыгыз ишелгән билбавын учына сугып куйды.— Егетләрнең колагы синдә. Нәзирколга ничек дип җавап бирәбез?

Урдушмәт, чөгендер кебек кызарып, бүлмәдәгеләргә күз йөгертеп чыкты. Аннары миңа таба борылды:

— Ярый, дускай, шартың кабул ителә. Җаның тыныч булсын, бүген әфьюн тартмабыз! — диде.

— Бүген дә, моннан соң да! — дип өстәде егетләр агасы.

— Алдагысын күз күрер, Корбанбай әкә, исән булыйк,— диде Урдушмәт, бүтән сүз көрәштермәде.

Аннары даирә егетләре дәстәрхан өстендәге җимешләрне, тәмле ризыкларны каба-каба чәй эчтеләр, мәзәк сөйләделәр. Мокыйми, Фиркать, Навои шигырьләрен искә алып уздылар. Яңа бәет, җырулар, риваятьләр укылды. Шигырьләрне яттан белеп, матур итеп сөйләүче Урынбай әкә аерата зур чәчәнлек кылды. Аның артыннан Урдушмәт шаян җыр җырлап җибәрде.

Ул җырлап бетерүгә, Насыйр абыйның шөлдерле даирәсе телгә килде. Аңардан: «Бака-баң, ум бака-баң!» дигән тавыш яңгырады. Бүлмәдәгеләр, без уенга әзер дигәндәй, җайлашыбрак утырдылар. Башкалар да җыйнаулашып әмин тоттылар. Дәстәрхан җыештырылды. Ишек төбендә җырчы егетләр күренде. Корбанбай шуларга борылып:

— Бәрәкәназар кая? — дип сорады.

— Урамга чыккан иде. Әнә, керә бугай,— диде берсе.

— Әй, Бәрәкәназар! Борча кебек кая югалдың?!

Шул арада бүлмәгә йөнтәс кашлы, мут күзле Бәрәкәназар үзе дә авыз ерып килеп керде. Бүлмәдәгеләр кул чаба-чаба, һа-һа-һайлап кычкырырга кереште. Бу «Борча» уенының башлануы иде. Шул мәлне уенга катышмыйча утырган Азизханның иңсәсенә Корбанбайның «камчысы» шап итеп төште. Азизхан да, кинәт уянгандай, башкаларга кушылып кычкырырга тотынды: «һа-һа-һай!».

Барысы да даирә тавышына ияреп, «Җан борча»ны җырлый башладылар. Ишек төбендә басып торучы Бәрәкәназар кинәт артына чүкте дә, тез башына чапан чабуларын суга-суга, борча кебек, егетләр өстеннән сикереп уртага чыкты. Аннары каяндыр «борча» тотып алып, аны «суя» башлады. «Итен» кисәкләргә бүлеп, дусларына өләште. Яраткан кешеләренә «итле-майлы» җирен, калганнарына «баш-аягын», «эчәк-бавырын» бирде. Бәрәкәназарның әкәмәт кыланышыннан көлә-көлә, егетләрнең эчләре катты. Алар шау-гөр килеп, кул чаба-чаба уенны җанландырып, Бәрәкәназар башлаганны тәмамлый тордылар:

Бәрәкәназар. Көне бетте борчаның.
Хор. Җан борча, уңган борча.
Бәрәкәназар. Суючысы үзем булдым.
Хор. Җан борча, уңган борча.
Бәрәкәназар. Алтмыш батман ит чыкты.
Хор. Җан борча, уңган борча.
Бәрәкәназар. Башы мәзингә калды.
Хор. Җан борча, уңган борча.
Бәрәкәназар. Эчәк-бавыры сиңа булды.
Хор. Җан борча, уңган борча.

Менә шуның кебек уен-көлке, шаян җырлар башланып китте. Егетләр арасында Түләчә исемле шук бер егет бар иде. Тышкы кыяфәте болай да йомраннык кебек. Ә инде битенә корым сөртеп, борын тишекләренә чыбык тыгып, икенче очын ирене белән теш арасына терәтеп куйса, борыны өскә күтәрелеп, нәкъ йомран була да кала. Менә шул егет, Корбан тинтәк аркасына атланып, йомранча кылана башлады. Шуңа шаркылдап көлгәндә, мин чак кына тәкчәдән шуып төшмәдем. «Йомран» идәнгә тез чәнчеп утырган хәлдә Корбан тинтәкнең аяклары арасына «оя» корды. Аннары йөгереп уртага чыкты да, тирәякка карана-карана «бодай» башакларын йолкып, яңадан «оясына» кереп китте. Барысы да: «Йомран аман, йомран, һай!» ди-ди, аны дәртләндереп тордылар. «Йомран» янә үзенә җим эзләргә чыкты...

Аннары «Арка сугыш» уены башланды. Ә минем үлеп эчәсем килә. Моның өчен баштa тәкчәдән төшәргә кирәк. Берәрсеннән төшертер идем, абый күреп калып, тамашадан мәхрүм итәр дип куркам.

Исәбем — Гали чәчәннең хикәясен тыңламыйча китмәү. Шуңа күрә ничек тә түзәргә булдым. Миңа Галинең «Телеграф баганасы», «Килен төште», «Йөзем карагы», «Зират» дигән хикәяләре бик ошый. Бүлмәдә мең кеше булсын, чәчән барысын да үз авызына каратып куя иде. «Хатынның угыл тапкан!» дисәләр дә, аның сөйләгәнен тыңлап бетермичә, бер кем китә алмас иде. Чөнки ул кешене тәмам сихерләп куя. Бүлмә эче чебен очса да ишетелерлек булып тынып тора да, кинәттән барысы кычкырып көлеп җибәрә, аларның тавышы аргы очка кадәр җитә яза иде.

Мин гәштәк егетләре арасыннан Гали чәчәнне эзләдем. Ләкин ул юк иде. Насыйр абый даирә уйнап шактый арыган булса кирәк. Шабыр тиргә баткан. Ул ара-тирә миңа күз салып куя. Ә мин күрмәмешкә салышам... Бер тапкыр ул миңа усал итеп карап: «Өйгә кайт!» дигән ишарә ясады. Мин аны аңламаган булып башымны икенче якка бордым. Их, Гали чәчән тизрәк килеп, хикәясен тизрәк башласын иде. Аннан соң бәйләп куйсалар да калмас идем.

Ишек төбендә басып торган егетләрнең берсе:

— Гали чәчән бүген килмәс, ахрысы! — диде.

Бүлмә эче бөркү булганга, һәммәсе тирләп-пешеп чыккан. Бер почмакта нәүбәтләшеп чилем тарталар. Хурхур [1] көпшәсен суырганда, аның төбендәге тәмәке көле кызара төшә. Аннары тартучының авызыннан

[1] Көнчыгышта тәмәке тарту әсбабы.

зәңгәр төтен бөркеп чыга. Аның эфьюнneке кебек тәмсез исен яратмасам да, түзәргә мәҗбүр булам.

Кемдер ишек алдыннан:

— Корбанбай әкә, пылауга дөге салсыннармы? — дип сорады.

Егетләр агасы иптәшләренә сораулы караш ташлады. Нәкъ шул мәлне күршедәге кетәктән әтәч кычкырды.

— Мәйле, салсалар да була! — диде Корбанбай пәһлеван.

Насыйр абый, урыныннан торып, минем янга килде:

— Тамаша бетте. Бар, йокларга кайт! — дип, мине күтәреп ишек төбенә китереп куйды. Мин теләр-теләмәс кенә ишек алдына чыгып, арткы курага кердем. Төн шактый салкын иде. Бүлмә ишеген ачканда, ялгыш төчкереп җибәрдем. Шуна уяныпмы, әллә мине көтеп йокламыйча яткангамы, әнкәй:

— И юньсез. Тагын салкын тидергәнсең бит! Ул гәп-гәштәкләргә йөрүдән кайчан туктарсың икән? — дип сукранып алды.

Мин дәшмичә генә юрган астына кереп йокларга яттым.

## НӘҮРҮЗ[1]

Кыш аеның соңгы көннәре иде. Тышта җепшек кар ява. Әти белән әни сандал янында чәй эчәләр.

— Кайчан җылытыр икән инде, юкса, ягарга угын да калмады,— диде әнкәй.

— Кыш ае бетмәде бит әле,— дип, атам тәрәзәгә карады. Елның дүрт фасылын яхшы белгәнгә, шул турыда сүз чыкса, аңлатып үтми калмый иде: — Кышның кырык көне чиллә булса, кырыгы һиллә. Чилләсе узды, һиллә бетәргә берничә көн калды. Әҗүз карчык[2] көннәре дә көйсез була. Аның алты көне кайвакыт җидегә дә сузыла. Шулар узып, ләкләк кары яугач, көннәр җылыныр.

— Быел кыш та бик салкын килде. Берсенең өс-башына булса, берсенең юк дигәндәй.

— Кышның кырыгына түзгәнне, кырык беренә ничек тә түзәрбез әле,— диде атам.— Күбе узып, азы калды. Акман-тукман артыннан синең сәвереӊ[3] килер.

Атам сәверне ни өчен әнинеке дигәндер. Әмма ул айны мин дә яратам. Чөнки сәвердә болыннар чирәмгә төренеп, лаләләр чәчәк ата. Шуна күрә мин дә:

— Их, тизрәк яз килеп, сәвер яңгыры яусын иде!..— дип ычкындырдым.

— Өлкәннәр сөйләшкәндә кечкенәләр дәшми тора иде,— дип кисәтте анам.

Мин тәлемне тешләрдәй булып юрган астына постым.

— Сәвернең бер ае хәмәлнең[4] икесенә тора. Сәвер яңгыры диһканны ел буена туйдыра,— дип, атам сүзен дәвам иттерде.

— Амин, әйткәнең килсен,— диде әнкәй, яктыра тәшеп.— Хәмәлне әмәл дип картлар юкка әйтми. Алла боерса, тиздән яшьнәп нәүрүз килер. Дөньяга ямь керер.

Нәүрүз дигәч, минем дә күңелгә җан кергәндәй булды. Чөнки нәүрүздә дөнья яңара. Кыш буена йокымсырап яткан җирләр кибеп, умырзаялар чыга. Күк йөзенә кошлар күтәрелеп сайрый башлый.

---

[1] Яз бәйрәме.
[2] Кышның соңгы атнасын үзбәкләр «карчыклар көне» дип йөртәләр.
[3] Апрель ае.
[4] Май ае

— Бигрәк матур чакта була шул нәүруз бәйрәме!— диде анам.— Бичара хатын-кыз, бер генә көнгә булса да, өй эшләреннән бушанып ял итә, күңел ача. Кыш буена өй эчендә тутыга башлаган күңелләр саф һавада булып, туйганчы сулыш ала, йөрәкләр талпынып куя. Ничек шуңа алланың рәхиме килде икән?

— Син тагын алланы катыштырасың.— диде әткәй.— Аңа карап фикер йөртсәң, ул, киресенчә, хатын-кызның йөз күрсәтүен зур гөнаһка саный.

— Алай булгач, хатын-кызга бер генә көнгә дә иректә булырга ярамыймыни?

— Һы... Адәм баласына ул ирек дигәнең артык нәрсә. Аерата хатын-кызга. Ирек өчен күпме җан кыярга, җәфа чигәргә туры килә.

— Дөрес түгел. Кеше кайчан да булса, хәтта бер генә көнгә булса да, канат җәеп, сулыш алырга тиештер бит.

Әнинең болай кабынып сөйләвен минем элек бер дә күргәнем юк иде. Димәк, гәп-гәштәк, күңел ачу мәҗлесләреннән тыш, дөньяда кешене бәхетле итә торган ирек дигән нәрсә дә бар икән.

Революциягә кадәр үзбәк хатын-кызларының язмышы аерата кызганыч иде. Аларның гомере эчкәрегә якның кысан читлегендә узып, йөзләре иртә саргая иде. Урамга чыкканда башларыннан пәрәнҗә төшмәде. Шуның өчен кешелек хокукыннан мәхрүм ителгән хатын-кызларга бер генә көнгә булса да ирекккә чыгу, уен-көлке белән бәйрәм иту Сөләйман дәүләтеннән дә зуррак[1] булып күренә иде. Шуның өчен алар нәүрүз бәйрәмен таң яктысын көтеп алган кебек сагынып каршы алалар, аңа багышлап җыр җырлыйлар иде.

Башка якларда ничектер, бездә яз айлары яшьнәп, шаулап килә; ул көз белән кыш кебек астыртын гына шуышып килми. Яз башында күк йөзен күе болыт каплап ала. Күк күкри, яшен яшьни. Яз бөтен нәрсәгә тереклек сулышы өрә. Җылы яңгыры уҗым һәм чирәмнәрне юа, җир кочагында йоклаган җәнлекләрне уята. Далаларга яшел юрганын җәя... Җиззахлылар нәүрүз бәйрәмен уздыра торган Котырбулак тавы итәгендәге Хуҗа газен бакчасы аеруча ямьле була. Анда өрек, алмагачлар чәчәк атып, болындагы бихисап лаләләрдән тирә-як алсу төскә керә иде.

Нәүрүз бәйрәме гадәттә март аеның соңгы атнасында, чәршәмбе көнне була. Бала-чага аны гарәфә көнне[2] үк башлап җибәрә. Алар, карлыгач балалары кебек йорт борынча йөреп, яз килгәнен, иртәгә бәйрәм буласын хәбәр итәләр. Ул көнне бар йортларда да табын төрле конфетпрәннек, чәкчәк-бавырсаклар белән тула. Бәйрәмне котлап килгән балаларны, рәхмәтләр яудырып, тәмле әйберләр белән сыйлыйлар.

Безнең мәхәллә кешеләренең күбесе чәйрекәр[3] булганга, бәйрәм алдыннан алар, гадәттә, икмәк өлгергәч түләү шарты белән, байлардан акча, бодай, дөге ярмасы алалар. Һәр кайсысы, үз хәленә карап, гарәфә көнне өс-башын яңарта. Әнкәй безгә күлмәк-ыштан, түбәтәй тектерсә, әткәй базарга барып читек-кәвеш сатып алып кайта иде.

Ул көнне бар ишек алдында да бәйрәмгә хәзерлек бара. Җиткән кызлары булган гаиләләр аерата нык әзерләнәләр иде. Алар кызларына ефәк күлмәк, хәтфә камзул тектерәләр. Алка, йөзек, беләзек, мәрҗән муенса юнәтәләр. Билгеле, болары да төрлечә була. Хәлле кешеләрнең кызлары өстендә атлас, ефәк, муеннарында алтын-көмеш булса, ярлы кызлары ситсы күлмәк, бикасап[4] яки киже-камзул киеп, арзан гына муенса тагалар иде.

[1] Халык әйтеме.
[2] Бәйрәм алды көне.
[3] Элекке заманда уңышның бер өлешен түләү шарты белән җирне арендага алучылар.
[4] Кулдан тукылган ефәк.

Әнә, бүлмә түренә җыелган кыз-кыркын, бердәнбер көзгегә чиратлашып карый-карый, битләренә кершән, кашларына сөрмә тарталар. Моңа да осталык кирәк. Кызларның һәр кайсы үз кыяфәтенә карап буяна. Берсе киң кашына сөрмәне нечкә итеп сызса, икенчесе нечкә кашын киңәйтеп җибәрә, кашлары бер-берсенә тоташа яза. Өченчесе кершән сөрткән бит алмасына бәләкәй генә миң утырта. Шул мәлне тәрәзә төбендә егетләрнең җырлаган тавышы ишетелә:

Кара кашлы нечкә сөрмә,
Җаныйга сүз әйтә күрмә.
Чибәр кызга юк сүз әйтсәң,
Елар кашындагы сөрмә.

Бүлмәдәге кызлар, лачыннан курыккан күгәрчен кебек чыр-чу килеп, бер почмакка җыелып йөзләрен яшерәләр. Кыюраклары сагаеп кына тәрәзәгә карый. Кайсысының егете шулай, койма яки карагач артына яшеренеп, үз сөйгәнен күзләде икән? Ләкин ишек алдында беркем дә күренми. Кызлар тынычлана төшеп, яңадан көзге янына җыелалар. Гашыйкның тавышы яңадан кабатлана.

Сөрмәсез дә матур күзләрең,
Балдин татлы әйткән сүзләрең.

Кызлар инде, урыннарыннан кубып, көлешә-көлешә ишек алдына чыгалар...

Ә бәйрәм көнне мәхәллә урамнарына таңнан ук халык тулган була. Барысы да матур итеп киенгән, йөзләрендә шатлык булыр. Төрле яктан кәрнәй, сорнай тавышлары яңгырый. Күп тә үтми, Уратүбә, Нижан, Рәват, Аккурган, Такчи, Мөлкә, Һавас мәхәлләләреннән җыелган халык төркем-төркем булып тау итәгенә таба агыла башлый. Арбаларга келәм, палас, казан-табак, азык-төлек төяләә. Кайберәүләре атка, ишәккә, дөягә атланган, ә күбесе җәяү генә бара. Малайлар, тузан туздырып, әрле-бирле чабалар.

Читән арбага тезелеп утырган кыз-кыркыннар «Яр-яр»[1]ны җырлыйлар. Кыскасы, халык язгы ташкын кебек дулкынлана-дулкынлана Хуҗа газен бакчасына таба агыла.

Ә күк йөзе чалт аяз. Анда бер генә болыт әсәре дә күренми.

— Кичә генә әле чиләкләп яңгыр койган иде, ә бүген көн нинди матур! — ди чәчәванын башы өстенә күтәргән бер хатын.

— Әйе, Җиззахлылар бәхетенә, алланың кодрәте белән, көн үзгәрде дә куйды! — ди янәшә атлаучы икенче хатын.

Чынлап та кичә күк йөзен кара болыт каплап, яңгыр яуган иде. Ә бүген яңгырдан соң кырдагы чирәмнәр, яфраклар тагын да яшелләнә төшкән. Юлда тузан басылган. Арыктагы сулар ярларыннан чыгардай булып ашкынып ага.

Мин халык арасында узган елны гына әле кияүгә бирелгән күрше кызын күрдем. Уныч-уникүрт яшьтә генә булуына карамастан, ул инде кулына бәби тоткан. Ә йөзе кипкән яфрак төсле саргайган. Арттан килүче хатыннар шуны сөйләп алдылар:

— И бичара, йөзек кашы кебек матур кыз иде. Хәзер — карарлыгы да калмаган. Буйга җитмичә кыз баланы иргә бирү әнә нишләтә. Бер бала табуга ук кипкән, мескенем,— ди берсе.

— Мыжгылдык кайнана типкесе дә тими калмагандыр. Болай булгач, озак тормас инде. Нәүрүз бәйрәмен соңгы тапкыр күрүедер мескеннең,— ди икенчесе көенечле генә.

[1] Килен озатканда җырлана торган халык җыры.

Бу сүзләрдән мин калтыранып киттем. Адымымны кызулый төшеп, күрше кызның йөзенә карадым. Чынлап та аның кыз чагындагы чырае сүрелгән. Матур кара күзләре эчкә батып кергән. Узган елны тагып чыккан алкалары да юк. Күрәсең, алар хәзер яшь анага шатлык китерми. Ул моңлы күзләрен җиргә төбәгән... Бу бит шәригать кануннарының хатын-кызларга карата булган коточкыч гаделсезлеге. Мөселман дөньясында күпме кызлар шулай, чәчәк атмыйча, якты дөньяны күрмичә, бала гына көенчә кияүгә бирелеп, харап булалар! Табигать бүләк иткән бөек мәхәббәт тойгысыннан мәхрүм ителеп, күрмәгән-белмәгән кешегә, атасы, хәтта бабасы кебек картларга бирелеп, йөрәкләре кайгы-хәсрәт кичергәнгә, бик иртә дөнья куялар. Шуңа күрәдер инде, хатын-кызга нәүрүз бәйрәме аерата кадерле. Алар елына бер генә тапкыр булса да иреккә чыгып, дөнья кайгыларын онытып торалар. Яз аеның саф һавасында табигать хозурына чумалар, язгы йомшак җил йөзләрен сыйпап иркәли.

— Һай, бигрәк матур да соң бүген көне! — ди тагы бер хатын.— Нәүрүз бәйрәменә исән-сау җиткергән аллаһы тәгаләгә шөкерләр булсын!

Янәшәдә генә баручы яшьләр арасыннан кемдер шөлдерле даирә уйнап җибәрде. Калганнары шуның тавышына ияреп җырлый башладылар. Ике-өч егет, алга чыгып, биергә керештеләр. Җиде-сигез чакрымлык юл уен-көлке белән узылганга, сизелми дә калды. Хуҗа газең бакчасында ирләр бер төркемгә, хатын-кызлар икенче төркемгә бүленделәр.

*Дәвамы бар*

Зиннур Насыйбуллин

# Безнең буын

Яшь үсенте,
Мин сокланам сиңа:
Ташны тишеп чыга алгансың,
Ләкин үзең шундый назлы булып,
Шундый нәфис булып калгансың.

Без — дөньядан иртә киткәннәрнең
Җиргә бүләк иткән буыны;
Дөнья шулай сугыш, үлем белән
Каршылады безнең тууны.

Асыл ирләр авып җан биргәндә
Әле яңа безгә җан кергән,
Инде без ул — йортка өмет биргән,
Тормышка ямь биргән, җан өргән.

Дөньяга без ялкын ярып шыттык,
Мең үлемгә тудык үч итеп.
Җир яраткан безне бу заманга
Үлемнәрне җиңәр көч итеп.

Штык белән языла һаман тарих,
Атышларның бармы тынганы?
Чорыбыздан дары исе килә,
Җилләтергә иде дөньяны.

Күпме каннар акты, күпме күз яшь,
Чыланмады һаман дарылар.
Мин ышанам:
Төтәп яткан бикфорд шнурларын
Безнең тешләр өзә алырлар.

Мин ышанам:
Үлемнәрне җиңәр бер көч итеп
Җир яраткан безне — улларын,
Шуңа безнең нерв җепләренә
Тоташтырган заман Җир шарын!

## Тынлык телим!

Тынлык телим!
Кирәк миңа шундый тынлык:
Колакларны чыңлатырлык,
Акрын сөйләп, ихлас сөйләп
Күңелемне аңлатырлык;
Сабыйларның йөрәк тибешен
Планетага тыңлатырлык
Тынлык кирәк.

Ә ничек кыштырдый икән
Яңа шытып яткан орлык? —
Ишетәсем килә шуны.
Тынлык кирәк миңа, тынлык!
Кирәк миңа шундый тынлык:
Бар хәвефне онытырлык,
Җирне бөтен бәлаләрдән
Азат диеп хис итәрлек,
Галәм гизгән хыялымның
Кайтавазын ишетерлек
Тынлык кирәк.

Тынлык телим.
Җимерелү авазлары
Тынсын, тынсын!
Акыл тавышын һәрбер чукрак
Ишетерлек тынлык булсын!
Тынлык телим!
Шул тынлыкта
Шатлыгыма чәчәп көлим! —
Бар дөньяга ишетелсен,
Кайгы челпәрәмә килсен!

Тынлык телим!
Йөрәгемдә
Илаһи бер моң барында
Симфония уйныйм әле
Кайнар кояш кылларында!
Тынлык телим!

## Кояш чыкты!

Кояш чыкты!
Кояш чыкты!
Баш очында яңа кояш!
Бу — кичәге кояш түгел,
Башка кояш, яңа кояш!

Безнең кояш!
Руда килеш
Җир куеныннан тапкан кояш;
Домналарда чуен булып,
Корыч булып аккан кояш,

Кояш чыкты!
Эшчән куллар
Җылылыгын җыйган кояш,
Безнең кояш!
Төн буена
Без үзебез койган кояш.

Кояш чыкты!
Станокта
Без үзебез кырган кояш;
Безнең йөрәк җылысыннан,
Күз нурыннан торган кояш.
Кояш чыкты.
Ул кояшны
Безнең куллар күккә чөйде,
Юкса, кояш бу кадәрле
Нурлы, көләч булмас иде.

●

Янар өчен тугач, ян син, йөрәк,
Утта гына корыч туа.
Кыйна, язмыш,—
Сандал белән чүкеч арасында
Кылыч туа.

●

Без икебез ике кеше икән.
Ни беркетсен безнең араны?
Хәтта күзләр ике төрле күрә:
Мин — гел акны, ә син — караны.

Без икебез ике кеше икән.
Уртаклыклар эзләү кирәкме?
Уңын түгел, тискәресен карап
Бәялисең һәрбер бизәкне.

Шуңа синнән бәхет бик еш кына
Яшерәдер көләч карашын:
Акны эзләгәннәр акны таба,
Кара эзләгәннәр — карасын.

## Ишәм-сүтәм

Ишәм-сүтәм, ишәм-сүтәм...
Мин дә, имеш, дөнья көтәм.
Ишкәнемне сүтә-сүтә,
Күпме гомер әрәм үтә!

Үз ишкәнен әрни-әрни
Сүтмәгәннәр сирәктер ул,
Әйбәт итеп ишәр өчен
Сүтә белү кирәктер ул.

Фаил Шәфигуллин

# ДИҢГЕЗ ЭСКИЗЛАРЫ

## Америка самолеты

Каракоштай кара самолет
Эзәрлекли безне туктаусыз.
Яшергәнбез гүя бомбалар,
Төягәнбез гүя туплар без.

Очып үтә хәтта кайчакта
Мачталарга тия язып ул.
Каракоштай кара самолет
Гел кисәтә: хәтәр сезнең юл!

Я атылып керә болытка,
Я түбәнгә төшә кадалып...
Аккош кебек кораб өстендә
Каракоштай кара самолет.

## Давыл алдыннан

Нейтраль дә монда сулар,
Җилләр алай түгел.
Диңгез никтер авыр сулый
Көне буе бүген.
Кабарына бара һаман
Дулкыннарның ялы.
Күксел яр соры томанга
Томаланып калды.
Кайда хәзер Америка
Һәм Азия кайда?
Улап-улап очкан иде
Самолетлар бая.
Төшерделәр микән ялгыш
Алар суга атом;
Кыйтгалар Атлантида күк
Әллә суга батты?
Җил тели ачып карарга
Гүя диңгез төбен.
Нейтраль дә монда сулар,
Илләр алай түгел.

## Беринг диңгезе

Беринг диңгезенең кәефе киткән —
Чүп урынына чайкый корабны.
Ерак гасырларны каплап торган
Томаннарны давыл таратты...

Мең чакрымлы юлдан, карлар ерып,
Еллар буе олау сөйрәлә...
Чит-ят илдә яшь-яшь командорга
Җиңел булган дисезме әллә?!

Арып-талып, туңып, җирләп, ачыгып,
Кыенлыклар күреп мең төрле,
Килеп җиткән олау диңгезгәчә,
Буйдан буйга кичеп Себерне.

Балкып киткән көтмәгәндә генә
Офыкларга җәелеп чал диңгез.
Үзе серле, үзе иксез-чиксез,
Үзе мәгърур, үзе исемсез.

Иле көткән аны...
Ул кайтмаган...
Бунтарь җаны кушкан шул аңа,
Яшьлек хыялларын дулкын итеп,
Мәңге диңгез булып шауларга...

## Йокысыз төн

Якын инде, шундый якын
Материклар бер-беренә.
Уңда маяк, сулда маяк —
Бер кабына да бер сүнә.
Уң ярда да, сул ярда да
Маякларның уты яшел.
Дөнья тыныч. Ләкин кинәт
Сызылып китә күктә яшен.
Кабыналар прожекторлар
Уң якта да, сул якта да.
Аяз күкне телеп-телеп,
Утлы кылычлар айкала...
Сәгать тек-тек вакыт саный,
Сигналлардан эфир кыза.
Баш очыннан Америка
Самолеты очып уза.
Ераклаша кара шәүлә,
Сәгать һаман вакыт саный.
Йокламагач Америка,
Азия дә йоклый алмый,

# Аяз көндә

һаваларда болыт каурый-каурый,
Мамыкларын ефәк җилләр тарый.

Акчарлаклар төяп ага бозлар,
Салда гүя ак күлмәкле кызлар.

Боз атауга йөзеп баралармы
Боз каекта тюлень балалары? —

Җем-җем итеп кояш нурларында
Терекөмеш ага туннарыннан.

Нәрсә сизә күңел, ник борчыла?..
Ах, шул аваз тагын баш очында.

Исеп узды шомлы афәт җиле —
Самолетлар... дүрт, биш, алты, җиде..

Уйнап кына, ахры, берсе шунда
Ут яудырып китте тып-тын суга.

Күтәр инде, күтәр аналары —
Кан эчендә тюлень балалары.

Кем үтерде, ничек?.. Тик офыкта
Күренеп калды дүрт-биш кара нокта.

# Аляска

Алясканы 1867 елда патша
хөкүмәте Америкага сата.

Кургаш офыклар
Күзне талдыра.
Бөтен тирә-як
Боз да кар гына.
Сулда — Чукотка,
Аляска — уңда.
Аңа карагач
Күңелләр тула.
Романтиклар соң
Түзсеннәр ничек —
Кемдер эзләгән
Океаннар кичеп.
Кемдер эзләгән
Дөнья читеннән,
Кемдер табалмый
Кире чигенгән.
Кемдер адашып,
Кем туңып үлгән,

Эзләрен салкын
Бураннар күмгән...
Кемдер эзләгән,
Һәм... Кемдер тапкан.
Аның шатлыгын
Кемнәрдер саткан...

## Төньяк балкышы

Диңгез никтер уйга талган,
Дөм кара төн.
Мачталарын шыгырдатмый
Җил корабның.
Күзне камаштырып кинәт
Күк читендә
Уйный башлый сихри балкыш,
Төн чигенә.
Җем-җем, гөлт-гөлт,
Зәңгәр,
яшел,
кызыл,
сары...
Дөньядагы бар илләрнең
Байраклары
Җилферди күк, бер карасаң,
Бу балкышта.
Бу балкышта — яз да, көз дә,
Җәй дә, кыш та.
Байраклары белән шулай
Җилфер-җилфер,
Илләр, бәлки, берсен-берсе
Сәламлидер.
Тын балкышка чал мәңгелек
Башын ия.
Йоклый әле Америка
Һәм Азия.
Планетаның кыйбласына
Туры карап,
Әкрен генә йөзеп бара
Безнең кораб.

Шамил Бикчурин

# КАТЫ ТОКЫМ

РОМАН[1]

## 6

Язтургайның беренче атнасы мәшәкатьле булды. Мәшәкатькә бирешми, борынны салындырмый нык кул белән эшләделәр. Буровойда девон тирәнлегенә беренче йөз метр төшелде. Разведчиклар яна урыннан яна токым үрнәкләрен дә тапшырырга өлгерделәр — геологларның әйтүләренә караганда, Язтургай мәйданы бик үзенчәлекле, моннан унайгамы, кирәгәме, ниндидер хикмәтләр көтелә икән. Әлбәттә, бораулаучылар аны зур нефть запасы ачылуга гына юрадылар.

«Чатырлар шәһәрчегендә» дә тормыш үз урынына утырды кебек. Кешеләрнең баш өстендә куыш кына түгел, хәтта Кадермәт «проекты» белән жир мунча да, үзенә күрә кер юу, аш пешерү урыннары да булдырылды. Бораулаучылар чатыр тирәләрендә юллар, сукмаклар ясадылар, кызыл комачларга һәм фанер такталарга язылган лозунгларны, плакатларны элделәр. Хәзер аланның бөтен почмагыннан: «Бораулау планын срогыннан алда үтәү өчен көрәшик!», «Елга 7 мең метр бораулау өчен көчебезне куйыйк!» кебек өндәмәләр кычкырып тора иде. Боларның барысын да бригаданың танылган рәссамы Миргазиян язды.

Миргазиянның рәсем ясарга һәвәслеген бригадага килгәч тә күрделәр. Сөйләшеп торганда булмасын, җыелышларда катнашмасын, ул кулына һәрвакыт блокнот алыр һәм эче пошканнан гына карандаш белән аңа сызгалап утырыр. Карап торсаң, минут эчендә кәкре-бөкре ыргакларга, әкәмәт йортларга, пирамидаларга, чиркәү манараларына охшаган төрле хикмәтләр белән тула иде блокнот битләре. Шул арада икенче битне ала да, җыелышта чыгыш ясаучыларның, йоклап китүчеләрнең сурәтләрен төшереп куя. Монда Зөбәеровның карчыкларныкы төсле алга чыгып торган иягеи дә, Мотгәрәйнең түбәтәй кигән кабак башын да, Саакянның бөркет башын да күрергә була.

Бер бит тулысы белән Валентин вахтасы бораулаучыларына багышлана. Тин-Тиныч үзе кечкенә башы белән иләк кадәрле безкозыркасына чумып утырган. Ленталарда язу: «Тихоокеанский флот». Аның

[1] Башы 5 нче санда.

янында кабан тешләре белән Фәрхетдин елмаеп утыра — авызы колагына житкән. Сапарбайның кысык күзен бирү өчен Миргазиянга ике сызык сызу да житкән — коеп куйган Ускенбаев килеп чыккан. Ә верховой Нәжип карга кыяфәтендә вышка башында кунаклаган — художник көләр урын тапмаган булса кирәк.

Миргазиян үзе комсомолда түгел иде, шулай булса да бер көнне бригаданың комсоргы Валентин аны жыелышка чакыртты. «Кулың тик тормаганны яхшы беләбез,— диде ул,— син ул талантыңны юккабарга әрәм итәргә тиеш түгел, чатырлар шәһәрчеген бизәүне сиңа тапшырабыз,— диде. Шул көннән башлап Миргазиян стена газетасының художнигы да.

Аена бер генә мәртәбә чыкса да, Миргазиян катнаша башлаганнан бирле газетаның йөзе дә, эчтәлеге дә танымаслык булып үзгәрде. Газета булудан бигрәк, сатирик рәсемнәр һәм дусларча шаржлар белән бизәлгән «чәнечке» иде ул. Рәсемнәр астына шигырьләрне Тин-Тиныч үзе язды. Шигырь-такмак чыгарырга, һәр жөмләне рифмалаштырып алырга ана гына куш инде.

Бүген буровой вагонына бикләнеп, хәтта анда мастерның үзен дә кертмичә, Тин-Тиныч белән Миргазиян «Чәнечке» чыгару белән мәшгуль булдылар. Кызыклырак бер рәсем һәм аның астында үткенрәк шигырь барлыкка килгән саен вагон эче көлү тавышларыннан яңгырап торды. Сохари ашаган кебек кетер-кетер көлүчесе Миргазиян, кинәткинәт хахылдап жибәрүчесе Валентин иде. Алар үз ижатларыннан бик канәгать иделәр булса кирәк.

Буровойдагы егетләр үткәндә-сүткәндә вагон ишеген берничә мәртәбә шакып та килделәр:

— Әй, сез, жен балалары, безгә дә калдырыгыз көләргә!

Нәкъ вахта алышынган вакытны туры китереп, «Чәнечке»не чыгарып элделәр. Бораулаучылар ашыгыч эшләрен ташлап, вагон янына жыелды. Яңа газета һәрвакыт кызыксыну уята иде, хәтта үзенең герләреннән башканы белмәгән Еланский да карарга килә иде аны.

Вагон стенасының яртысын диярлек биләп торган чаршау кадәр кәгазьдә беренче булып Репинның «Бурлаклар Волгада» картинасы күзгә ташлана иде бу юлы. Якыннанрак карасаң, бурлаклар Волгада түгел, ә нефть мәйданында икән. Тагын да дикъкатьләбрәк баксаң — бурлаклар түгел, ә барысы да үз кешеләр — Зөбәеров бригадасы членнары икән, алар тарта торган нәрсә дә, баржа булмыйча, буровой вышкасы икән.

— Дуңгызлар, Репинны ничек бозганнар! — дип куйды үзен тану белән Зөбәеров. Елмаюын ничек кенә яшерергә тырышса да, булдыра алмады.

Иң алда бөтен гәүдәсе белән нелеп, әлмәккә Зөбәеров жигелгән иде. Аның тирәсендә өч ярдәмчесе — мыекларын тырпайтып трубка капкан ябык, озын гәүдәле Кадермәт бара, арган, тирләгән кыяфәттә безкозыркасын кулына тотып Тин-Тиныч килә, ә әлмәген күкрәгенә кадәр төшереп, янбашы белән диярлек тартып бөкре борынлы Саакян атлый.

— Каныктылар инде шул танауга! — дип чыелдап кычкырып жибәрде Сергей, барсын да көлдереп.

— Сапарбайны карагыз әле, Сапарбайны!

— Мотгәрәйгә генә күз салыгыз! Үзе кая соң әле Мотгәрәй?

— Фәрхетдин, туган, бу син бит? Әлмәгеңне бик бушаткансың түгелме?

— Бер караңгы почмакта очрап әле ул художник кисәге!

Рәссам чыннан да бик килештереп ясаган иде «бурлакларны». Һәркем үзенең буровойда тоткан урынына карап жигелгән, холкына, хезмәтенә карап бирелгән.

Мотгәрәй, мәсәлән, тартсам ярый, тартмасам ярый, дип кенә атлый. Фәрхетдиннең, кечәнгән булып кыланса да, баулары буп-буш. Сапарбай берьюлы ике элмәк кигән, ләкин көче шуның кадәр генә — ул иң арттан сөйрәлә.

Миша Кубракның да, Нәҗипнең дә, Еланскийның да элмәк тартуда үз өлешләре бар, тик бик аз.

«Чәнечке»нең калган урыннары аерым бораулаучыларны тәнкыйтьләп ясаган рәсемнәрдән һәм шигырьләрдән тора. Анда әле һаман Ык буендагы вакыйгалар сурәтләнгән иде. «Чәнечке»дән һәммәсенә диярлек өлеш чыккан: кайсын тырнап кына узган, кайсына энәсен яхшы ук кадаган, кайсын, һич кызганмыйча, кара канга батырган.

Менә арбада башы белән түбәтәе һәм аракы шешәсе күренеп торган Мотгәрәй. Астында бер генә куплеттан торган шигырь:

Юк бригадага кирәге,
Юк буровойда эше.
Онытылып калган арбада
Мотгәрәй дигән кеше.

— Шәп әйткәннәр, имансызлар! — дип тел шартлатты Еланский.

— Үзеңне кара, үзеңне.

Еланский үзен күрергә өлгермәгән иде әле, аны алгарак тартып керттеләр. Рәсемдә җиде гер күтәреп батыр Геннадий Еланский басып тора иде.

Гер дигәндә күтәрә ул
Җидесен дә исә.
Ә эштә ул гайканы да
Борып куярга ирене.

Еланский оятыннан мыштым гына китеп бара. Хәзер бораулаучылар гөр килеп Фәрхетдиннән көлә башлыйлар. Төлке итеп ясалган Фәрхетдин капчык асып буровойдан кайтып килә, капчык авызыннан төрле-төрле хатын-кыз башлары күренеп тора. Анда шигырь түгел, тик бер генә җөмлә белән: «Фәрхетдиннең чираттагы корбаннары», дип язылган иде.

— Арттырганнар! Күперткәннәр. Берьюлы бу кадәр хатын-кыз минем төшемә дә керәсе юк! — дип акланмакчы була Фәрхетдин. Аннан яный: — Ну, карангырак почмакта очрар әле ул, Миргазиян дигән уйнаштан туган нәрсә!

«Чәнечке»нең аскы өлешендә, гадәттәгечә, табышмаклар китә. Аларның җаваплары да әзер: «Үзе буровойда, күзе акчада. Бу кем? Аста киреле-башлы төшерелгән Сапарбай сурәте. Аның бер күзе буровойга, икенче күзе кассага карый. «Өрми дә җибәрми дә. Бу кем? Бу — кешеләргә икешәр ел отпуск бирми йөртүче мастер Зөбәеров. «Буровое бар, кешесе юк. Бу нәрсә? Бу — өч кешедән генә торган Кадермәт вахтасы». Шунда ук сорау куелган: «Мастер кайчан бораулаучы табарга уйлый икән?»

Зөбәеров «Чәнечке»нең бу өлешен яратып бетермәсә дә, табышмаклардан канәгать калды.

Стена газетасы белән юанып туйгач, бораулаучылар чатырларына кайтып киттеләр. Төнне йокысыз үткәргән Кадермәт ашап та тормыйча урынына ятты. Йокымсырап китеп, кайдадыр Белоруссия урманнары эчендә сазлыкларга бата-бата адашып йөри башлаган гына иде, чатыр янына гөрелдәп машина килеп туктады. Колакка ят булган яшь баланың елап җибәрүе, аны юаткан хатын-кыз тавышы ишетелеп китте.

— Чү, кызым, чү, килеп җиттек ич инде, килеп җиттек...

— Рәйсә ич бу! — Кадермәт Рәйсәнең көйләп сөйләвеннән танып алды, тиз генә урыныннан торып чалбарын, күлмәген киде дә тышка чыкты.

Зөбәеров чатыры алдында таныш булмаган иңиндидер яшькелт буяулы йөк машинасы тора, аның әрҗәсенә бер ир кеше менеп баскан (шофер булса кирәк), җиргә зур-зур чемоданнар төшерә иде.

Машина канатына бөкшәеп бала имезергә утырган сары башлыклы хатын чыннан да Зөбәеровның хатыны Рәйсә иде. Хәбәр-хәтерсез генә ничек килеп чыкмак итте икән әле ул?

— Исәнме, Рәйсә? — диде Кадермәт, аңа шактый ук якын килеп.— Исән-сау килеп җиттегезме, бик кыен булмадымы юлда?

— Бик яхшы, бик яхшы, Кадермәт,— дип сайрап алды каушап калган Рәйсә. Түшләре чыгып торганга читенсенеп, изүен каплап куйды.

— Ә мачтыр кая? — Ул Зөбәеровны, бораулаучылар кебек, кайчак «мачтыр» дип кенә җибәрә иде.

— Мачтырмы? Буровойда инде! Хәзер кайтыр. Ишетсәме килгәнегезне! Телендә соңгы вакытта гел кызы да син генә иден,— дигән булды Кадермәт.

— Булыр, булыр, ышанам.— Рәйсә сизелерлек дәрәҗәдә авызын кыйшайтты: — Шуңадыр инде ике айга бер генә кайта!

— Кыз ничек соң, кыз? Ләлә үсәме?

Кызын кулына алып сикертә башлады Рәйсә.

— Үсәм, диген кызым, бик зур булдым инде диген! Бүген-иртәгә унынчы айны тутырам инде диген. Ә үзеңнең хәл ничек соң, Кадермәт?

Кадермәт кулын селекте:

— Сорама инде, Рәйсә...

Машинаны күреп башка чатырлардан да бораулаучылар чыктылар. Рәйсә килгән дә Рәйсә килгән.

Рәйсәдән исәнлек-саулык сорашу, кечкенә Ләләне кулдан-кулга йөртүләр, елата-елата сөюләр китте. Ул арада Миргазиян буровойга Зөбәеровны алырга йөгерде. Саакян вахтасыныкылар әйберләрне кертү, юлчыларны чатырга урнаштыру белән шөгыльләнделәр. Кемдер алан уртасында учак көйрәтеп, казан асып җибәрде.

Үзен бу кадәр хөрмәтләүгә Рәйсә бераз читенсенә, бу кадәр мастерлары хакына гына эшләнәдер дип уйлый иде. Әмма бораулаучы егетләрнең Рәйсәгә илтифат күрсәтүләре буровойга килгән бердәнбер хатын-кыз булганга, җитмәсә, врач булганга һәм аңардан шүрләгәнгә дә иде. Кыска гына вакытта, азга гына килгән арада да Рәйсә бу «ир-ат өерен» тәртипкә салып киткәли иде.

Егетләрнең кайберсе инде чатырына кереп яшерен генә үзенең тузылган ятагын җыештыра, тумбочка эчләрен рәтли башлаган. Әнә, Мотгәрәй ашыга-ашыга сакалын кырып утыра. «Рәйсә килде — хәзер тәртип-режим кертә инде»,— диләр егетләр.

Инде селкенеп килүдән арган кызын йокларга салган арада Зөбәеров кайтты. Шатланып, шаулап керде ул чатырга:

— Кая минем кызым? Нигә каршы йөгереп чыкмый минем Ләләм? Нигә эти дип кычкырмый?

Рәйсәнең авыз каплап тавышланмаска кушуын күргәч, шып булды эти кеше, аяк очларына гына басып кечкенә Ләләсе йоклаган караватк янына килде. Кызына сокланып бераз карап торгач, борылып хатынын кочаклап алды.

— Нигә килдең?

— Әллә ярамый идеме, Фазыл?

— Көтмәгән идем... Хәбәр итмәдең ич...

— Көтмәгәнгә килдем дә,— диде Рәйсә, үпкәләгән сыман.— Һаман кайтмыйсың, һаман юк... И Фазыл!..

— Курәсең бит, Рәйсә, эш. Күчену мәшәкате. Буровойны көйләп җибәрү. Беренче атнаны ук авария белән азап чиктек. Борылырга да вакыт тими...

Шулай да Зөбәеров түзмәде. Рәйсәнең ай-ваена карамастан, йоклап яткан кызын караваттан җилтерәтеп алып елата-елата битләреннән, кулларыннан, аякларыннан үбәргә кереште.

## 7

Зөбәеров чатырының күршедә булуы шәп булып чыкмады Кадермәт өчен. Бер яктан, көндезләрен мастер янына йомыш белән килеп туктаган машиналарның гүләве, шаулашып, кешеләрнең кереп-чыгып йөрүләре комачауласа, икенче яктан, озак күрешми торган ир белән хатынның сагынышып гөрләшүләре, көлешүләре тынгылык бирми иде. Вахтадан кайтып яттымы, Кадермәтнең колагына, ирексездән, Рәйсәнең сайрап-сайрап ирен иркәләгәне ишетелә: «И Фазылым минем, и сары алтыным, и энәм минем...»

Ир белән хатынның бу кадәр төчеләнүеннән эче пошып һәм читенсенеп Кадермәт икенче якка әйләнеп ята, башына мендәр каплап куя иде.

Алай да тиз генә йоклап китә алмый. Рәйсәнең Фазылына әйткән сүзләрен кабатлап, үчекләп ята: «Сары алтыным, имеш. Җенем сөйми кешеләр кәнфитләнсә!» Сары алтыны аңлашыла да инде — Зөбәеровның чәчләре сары, шуңа әйтә торгандыр. Ә менә ни өчен «энәм минем», «энем минем» дигән кебегрәк тә ишетелеп киткән төсле иде башта, яхшылабрак тыңлап караса «энәм минем» ди икән Зөбәеровка. Чын-чыннан кием тегә торган энә? Керпе кебек, «йомшагым» диюеме? Анысын һич тә төшенә алмады Кадермәт. Бәлки Рәйсәсе янына озак кайтмыйча, хатынының йөрәгенә энә булып кадалгандыр ул, я булмаса энә кебек, күз алдында югалып йөргәндер? Ни булса да хатыны янында олы гына Зөбәеров энәгә әверелде дә калды.

— Тату торалар, чукынган! Нәкъ менә егет белән кыз инде,— дип соклана иде аларга Кадермәт.— Шулай да әкренрәк үбешсәләр яхшы булыр иде...

Бу әле чәчкәләре генә булган икән, җимешләре алда икән әле...

Килеп атна-ун көн үтүгә кызлары Ләлә авырый башлады. Көйсезләнеп төннәрен бала елавы Кадермәтләр чатырына гына түгел, ары баштагы Тин-Тинычларга кадәр барып ишетелә, берсенә дә ял итәргә, йокларга ирек бирми иде.

Кадермәтнең тәмам теңкәсенә тиде бала тавышы. Төннәрен ул кесәсенә папирос белән шырпысын тыгып, кулына одеялы белән мендәрен алып чатырдан чыгып китә һәм, әллә кая ерак китеп, Сагындык елгасы ярына ук барып ята иде. Ә яшьләр йоклыйлар — суеп ташлаганнармыни! Була икән ваемсыз кешеләр дөньяда...

Берничә көннән Зөбәеров чатырында бала елавы тынды. Иртәләрен бораулаучылар Рәйсәнең, куанып, тирә-яктагы агач ботакларына бала чүпрәкләре элеп йөрүен күрәләр һәм килеп сорашалар иде:

— Терелде, ахры, сабый, еламый башлады.

— Тернәкләнеп килә инде. Кызамык чыгарды бит, балакай...

Фәрхетдин, гаҗәпләнгәндәй, бот чабып куя:

— Врач кызы белән мастер кызы була торып, авыруын гына әйт инде син!

— Ай көр тавышлы! Зөбәеровка охшаган,— дип көлә Кадермәт.

— Бәлки үземәдер? — дип елмая Рәйсә.— Сез әле минем тавышны ишеткәнегез юк!

— Ишеттек, ишеттек! Ничек кенә сайрыйсың! «Алтыным» да, «энәм» генә! Зөбәеров филдән энә булды да калды!

— Әллә ишетелде?

Рәйсә оялуыннан чатырына кереп китә.

Бала елавы басылып өч-дүрт көн үтмәде, иртә-кичләрен Кадермәтләр чатырына икенче төрле авазлар керә башлады. Башта моны Кадермәт, электәгечә, сагынышкан парның шаярып сөйләшүләре генә дип уйлаган иде, колак салса, Зөбәеров белән Рәйсә тавышланып ята икән. Менә сиңа егет белән кыз!

Зөбәеров. Әйтәм бит, син моннан китәргә тиеш!

Рәйсә. Сиңа урын тармы әллә?

Зөбәеров. Хезмәт урыны бу — аңлыйсыңмы? Без курортка килмәгән!

Рәйсә. Бөгелмәдә миңа нәрсә калган? Синең елына бер кайтуыңны көтеп, квартира саклап ятаргамы? Җитәр. Күп каравылладым инде!

Зөбәеров. Тиле син! Монда бала белән чатырда ничек яшәмәк кирәк?

Рәйсә. Теләсәң нәрсә диген, мин китмим!

Кадермәт өчен бу көтелмәгән яңалык иде. Менә әкәмәт, ял вакытында бер айга кунакка килгән Зөбәеров хатыны бала белән буровойда калырга җыена!

Зөбәеров исә Рәйсәсен һаман үгетләүдә иде:

— Башың булса уйлап кара, Рәйсә: монда калып бит син миңа бер файда да китермисең. Башкаларга үрнәк кенә күрсәтәсең ич син. Бездән күреп алар да өйләнә башласа, хатыннарын буровойга алып килеп тора башласа? Аннан бит разведка балалар бакчасына әвереләчәк!

Рәйсә нык торды: «Китмим булгач китмим!»

Уйлап карагач, Кадермәт тә дөрес дип тапты Рәйсәнең карарын. Нигә, ире була торып, тол хатын кебек аерым яшәсенмени? Тиздән салкын яңгырлар башланыр, разведчиклар, гадәттәгечә, авылга күчәрләр. Анда инде җылы өй генә түгел, йомшак урын да булачак. Түзәсе күп калмады. «Ә эш мәсьәләсендә ни эшләргә уйлый икән соң әле Рәйсә? Ул бит врач кеше»... Юк, ни генә булса да Кадермәт хатынын аерым яшәтмәс иде... Булсын иде әле аның Рәйсә кебек ире өчен җаның бирергә торган хатыны...

Шул чак, сызланып, Кадермәт хатыны Зөмәрәне искә төшереп алды. Сагынудан түгел, болай гына...

Иң авыр вакытта ташлап китте бит ул Кадермәтне. Ләкин Зөмәрәне гаепләми ул. Гаепли дә алмый. Үзенең гаебен әйтми өйләнде бит ул аңа. Ләкин без капчыкта ятамыни?..

Өйләнү белән Бакуда бер генә атна да тормады Кадермәт. Әтисе, пенсиядәге Баку нефтьчесе Имаметдин карт, җайлап, әдәп белән генә әйтте: «Улым, син лутчы моннан кит. Әнә Башкортстанда яңа нефть чыганагы ачылган икән, хәзер син үзеңне шунда танытсаң гына танытырсың».— диде. Кадермәт шунда ук төшенде: Бакуда, исәпсез-хисапсыз таныш-белешләр арасында, аның әтисенә дә, улына да көн булмаячак иде.

Зөмәрәсе белән Кадермәт Башкортстанга килеп, бер конторада бораулау мастеры булып урнашты. Ләкин яңа җирдә шатлык озакка бармады — төрле юллар белән, төрле сәбәпләр табып аны бу эштән читләштерделәр. Бәйләнер-казыныр нәрсәсен дә таба алмады яшь мастер. Шунда Кадермәт хатынына үзенең әсирлектә булуын чиште. Зөмәрәнең күзләре шар булды. «Нигә аны башта әйтмәдең, нигә аны миннән яшердең?» — дип, чәчләрен йолкый-йолкый елады.

ШАМИЛ ВИКЧУРИН ◆ КАТЫ ТОКЫМ

«Ярый, эш бер монда гына түгел, исән булсак табылыр»,— дип, иркә хатынын иртеп, Куйбышевка китте Кадермәт. «Мастер урынымы? Һо, туган, ул бездә тулып ята!» — дип каршы алдылар аны дипломын карагач. Ләкин «шәхси учет карточкасы» тутыргач һәм Кадермәтнең документлары белән танышкач, бөтенләй башкача сөйли башладылар. «Ике көннән соң килерсең». Ике көннән соң килгәч: «Сиңа дип билгеләнгән урын бушамый бит әле». Ул урын бушагач: «Анда институттан яшь белгеч җибәрделәр» һәм башкалар.

Көн саен «бүген эшкә башлыйм» дип вәгъдә итеп тә, башын иеп яңадан кайтып кергәч, Зөмәрәнең кәефе тагын да бозылды, шиге күперде. Елаудан шешенеп беткән күзләр, караңгы чырай белән каршы ала башлады ул. Җитмәсә, фатирга түләрлек акча, тычкан күзенә сибәрлек азык калмады. «Әйт әле, Кадермәт,— диде ул бер көнне истерикага бирелеп.— Син мине шулай гомер буена алдап йөрергә уйлыйсыңмы?» «Тынычлан, дөнья гел болай тормас әле»,— дип юатып караса да, Зөмәрә, чәчен-башын йолкып, үксүендә булды.

Кадермәтнең ниндидер мастер, бораулаучы урыннарын көтәргә мөмкинлеге дә, түземлеге дә калмаган иде — якындагы бер складка трубалар бушатучы, трубалар төяүче булып эшкә керде. Ул көнне Кадермәт тузанга баткан комбинезон киеп кайтты.

«Барысы да аңлашылды,— диде Зөмәрә, сүнгән, эчкә баткан күзләре белән иренә карап.— Бәхил бул, мин киттем...»

Кадермәт ләм-мим бер сүз әйтмәде — башын игән хәлдә урындыкка утырып, соңгы мәртәбә хатынына карады. Зөмәрә ашыкмый гына әйберләрен җыйды, тыныч кына аларны чемоданына тутырды һәм песи кебек әкрен генә өйдән чыгып китте...

Хәзер бик сирәк искә төшерә хатынын Кадермәт. Анда да Зөмәрәне сагынудан түгел, бүгенге көнгә кадәр буйдак булып калуыннан әрнешеп, җитмәсә, паспортында да уч төбе кадәр никах мөһерен йөртүенә карганып кына. Барысы да шул гөнаһсы аркасында...

«Шушы Рәйсә кебек ачык, уңган хатын очраса, һичсүзсез өйләнер идем»,— дип уйлый иде Кадермәт, Зөбәеровның хатынына кызыгып.

Караңгы төшәр алдыннан гына буровойдан Зөбәеров кайтты. Аның артыннан ук Валентин белән Фәрхетдин Зөбәеров чатырына Сапарбайны култыклап китерделәр. Рәйсә белән Зөбәеров ашап утыралар иде, өстәлне дөбер-шатыр күтәреп, сикереп тордылар.

— Ни булды Үскенбаевка?

— Ни булганын шайтан белсен! Бара да төртелә, килә дә абына! — Тин-Тиныч кулларын җәеп җибәрде.

Сапарбай күзен чет-чет йомып, хәрәкәтсез басып тора иде.

— Сукыр ул, бөтенләй күрми! — дип кычкырды Фәрхетдин.— Мин аңа торба ачкычы сузам, ә ул сукыр ябалак кебек күзен текәгән дә каткан!

— Алайса, аңарда тавык күзе,— диде Рәйсә.— Их, бетерә бит бу буровой кешеләрне!..

8

Сапарбай даласын, туган кышлагын ташлап яхшы көннән чыгып китмәде. Башка казакъларныкы кебек, саман йортлары да бар иде аларның, бик ишле булмаса да, куйлары, башка мал-туарлары да. Тик әтисенә тазалык бирмәде дә Сапарбайга бәхет бирмәде «кодай». Сугышта яраланып, бик авыр хәлдә кайтып кергән Үскенбай озак яшәмәде. Вафат булыр алдыннан әкәсе Сөенбайны чакырып кертте. «Үпкәмдә снаряд кыйпылчыгы утыра, көнем санаулы,— диде ул аңа.— Сапарбайны рәнҗетмә, тәрбияләп үстер. Опытма, Карал-Төбәдә Җаксыбайның кызы белән ярәшелгән, өйләнергә булыш».

Үскенбай әле җан бирмәгән иде, Сөенбай йорт борынча кереп кешеләргә кабер казырга әйтеп йөрде. Тирмәсенә көрәк тотып кергән авылдашларын күргәч, Сапарбайның атасы торып утырды һәм шундук түшәгенә авып җан бирде. Аның битен ак кәфенлек белән капладылар.

Ун яшьлек Сапарбайның хәтерендә күп нәрсә калмаган. Тик шунысы йөрәген өтеп тора: икенче көнне үк Сөенбай әкәсе үз малларын болар утарына куып кертте дә, Сапарбайның әнисен елатып, абзар һәм сарай ачкычларын үзе белән алып чыгып китте. «Мина васыять ителгән!» дип, чалыш авызын зур ачып кычкырганы хәтердә. Нәрсә ул васыять, Сапарбай аны аңламый иде.

Сөенбай әкә аннан соң көн саен ике араны таптый башлады — иртәсен үзендә ашаса, кич кунарга боларга керде. Сөенбай хатыны Нурбану җиңгинең елаганыннан тагын бер нәрсә төшенде: Сапарбайның әнисе дә Сөенбайга васыять итеп калдырылган, имеш. Бу нәрсә? Сөенбай әкә Сапарбайның үги атасы да була түгелме соң?

Сапарбай унике яшенә чыккач, Сөенбай әкәсе аны үзе белән җылкы көтәргә алып йөри башлады. Туып аягына басканнан бирле ат өстендә чапкан Сапарбай өчен бу уен гына иде. Бер хәбәрсез малай чак шулай үтте дә китте. Инде Сапарбай күрше авылда — Карал-Төбәдә — Җаксыбай токымында үзе тугач та ярәшеп куйган Рәйхана исемле кызы барлыгын да белә иде.

Яше унсигез тулар-тулмаста ук юрга ат иярләп, кызын бакмага да барып кайтканы булды аның. Рәйхананы ул читтән генә, елгадан су күтәреп кайтканда күрде. Ошатмады. Ике кашы бергә кушылып торган озын буйлы, нечкә балтырлы кыз иде бу. Күрше кышлакта үзенең шундый озын буйлы кәләше барлыгын авылда бер генә егеткә дә сөйләмәде. Өйдә дә Рәйхана турында сүз кузгатмады. Тик Сапарбайның әбисе — сиксән яшьләрендәге карчык кына — кама бүрек өстеннән шәл бөркәнеп, киез өстендә утырган җиреннән: «Малым йок — калым йок. Киленем Рәйхананы күрә алмам, яз көне гүр иясе булырмын»,— дип сөйләнә иде. Шушы сүзләрне ул дога укыган шикелле, көннәр буе тоташтан кабатлап утырды һәм чыннан да бер язда үлеп китте.

Икенче елны ат уеннары — кыз куыш вакытында тагын күрде ул Рәйханасын. Дөресрәге, бу юлы Сөенбай әкәсе кымыз эчәргә алып кергән булып күрсәтте аны. Җамаяк белән кымызны Рәйхана үзе китерде боларга. Юк, һич тә бу кыз былтыргы Рәйханага охшамаган иде. Зифа буйлы, озын кара чәчле, тулып пешкән кыз иде Сапарбай алдында. Хәтта бергә кушылган кашлары да, очып барган карлыгач канатлары кебек, икесе ике якка ташланып торалар иде!

Тирмәдән чыккач, Сөенбай әкәсе:

— Күрдеңме, без сиңа нинди сылу кыз төбәп куйдык! — дип, Сапарбайга күз кысып, чалыш авызын кыегайтып алды. Бу чакта аның җен суккан авызы да ничектер сөйкемле булып китте Сапарбайга. Егет түземсезләнеп сорады:

— Ә нигә алып кайтып китмибез соң аны, Сөенбай әкә?

Сөенбай әкәсе хикмәтле итеп тел шартлатты:

— Бер нәмә дә төшенмисең, гой!.. Калым җитмәйде, калым! Калым булса, бүген үк алып кайтыр идек! Җаксыбай токымыннан бездәге мал белән генә котылып булмайде, гой!

Менә нәрсә өчен генә алып кайтмыйлар икән Рәйхананы Сапарбайлар тирмәсенә. Кыз алып кайту өчен кызның атасына бик күп терлек, акча, кием-салым, тагын әллә нәрсәләр бирергә кирәк икән. Шунда гына төшенде Сапарбай мәрхүмә әбисенең «малым йок — калым йок» дип сөйләнгән сүзләрен. Саташмаган икән ул.

Ләкин шул ук вакытта бер нәрсәне аңлый алмый азапланды: менә монда ике кышлак арасындагы далада ел саен ат белән кыз кудыралар. Өйләнмәгән олы-олы егетләр катнаша ул уенга. Ат өстендә килеш егет

кызны тотып үбә алса — кыз аныкы була, имеш. Калымсыз-нисез биреп жибәрәләр микән кызны, әллә алардан да бик күп калым сорыйлар микән?

Сапарбай кыз куу уенын бик дикъкать белән карап торды ул көнне. Үзенең дә шулай олы егетләр кебек ярсып торган атларда Рәйхананы куасы килде. Куып тотса, кызын калымсыз гына биреп жибәрер иде микән Рәйхананың атасы? Ә тота алмаса? Рәйхананың аты да җилле булып, үзе дә Сапарбайдан остарак йөрсә? Рәйхананы башкалар куып тотса?

Сапарбайның күзенә бу егетләр Рәйхананы куалар булып күренә башлады. Башы әйләнеп китте Сапарбайның.

Икенче ел көз армиягә каралып, солдатка алынмый калгач (аны врачлар яссы табанлы диделәр), Сөенбай әкәсе аны үз тирмәсенә чакырып, болай диде: «Солдаттан калуың яраган. Хәзер инде яшең дә житкән, өйләнү хәстәренә керешергә вакыт. Ә өйләнү өчен, үзең беләсең, акча юнәтергә кирәк, бик күп акча... Калымны монда җылкы көтеп кенә җыеп булмый...»

Акча табуның ысулларын өйрәтә башлады Сөенбай әкә.

Шәһәргә, Алма-Атага китеп берәр жиргә эшкә кергәндә акча төшереп була икән, Җизказганга барып шахтага урнашканда да акчаны күп ясап була икән, далада су эзләүчеләргә ияреп йөргәндә, акча юнәтү тагын да җайлырак икән. Әйе, әйе. Улыста Сөенбайның танышы Хыялетдин дигән берәүнең баш баласы далада су эзләүчеләргә ияреп киткән һәм шунда эшләп бер елдан соң капчык тутырып акча алып кайткан. Житмәсә, шул акчага улыста бер дигән чибәр кызны сайлап алган. Баю өчен Сапарбайга да күп кирәкми, имеш. Су эзләүчеләр адресы белән Хыялетдин малае урынына эшкә барырга кирәк, имеш.

Сапарбайны ерак юлга әзерләделәр. Китәр алдыннан Рәйхананы күреп сөйләшеп кайту өчен, атка атланып Карал-Төбәгә чапты егет.

Жаксыбай тирмәсен ике мәртәбә юртып әйләнгәннән соң, Сапарбай күбеккә баткан атын бәйләп эчкә керде. Бәхеткә каршы, Жаксыбай үзе өйдә юк иде — Сапарбайны тагын Рәйхана каршылады. Егетен күргәч, оялды да, шатланды да ул.

— Мин бит сине беләм,— диде ул, чаршау артына поскан жиреннән йомшак кына итеп.— Син Сапарбай буласың. Син инде безгә ике мәртәбә килдең...

— Мин китәм, Рәйхана,— диде Сапарбай. Әллә нәрсәгә генә күңеле йомшарды, Рәйхананы кочаклап үкереп-үкереп елыйсы килде.

Рәйхана түр якка чыкты.

— Кая китәсең?

— Үзем дә белмим... Мин тиз кайтам.— Беркатлыланып, Сапарбай үзенең ни өчен китүен дә әйтмәкче булган иде дә, Рәйхана аны үзе дә сизгән икән.

— Беләм... Атайдан ишеттем... Ә син калым дип торма,— дип киңәш итте аңа Рәйхана.— алып кит мине үзең белән...

— Ни сөйлисең син, Рәйхана?

Рәйхана, тезләнеп, Сапарбайның сырма итәгеннән тотты.

— Алып кит син мине, качыйк без моннан! Юкса, атай мине башкага бирә... Ишеттем...

— Бирмәсләр. Мин әкәмә әйтеп куярмын... Атаең көтәр. Мин тиз кайтам... Күп акча белән...

Рәйхана ишек төбендә елап калды, Сапарбай гүя моны күрмәс өчен, атын камчылый-камчылый, авылына чапты.

Әкәсе биргән адрес белән тапты ул су эзләүчеләрне. Бораулаучы итеп тә алдылар, ләкин артезиан коесы бораулап та аннан төче су чыкмагач, гидрологларны үз конторалары Алма-Атага чакырып алды.

Сапарбайга кире кайтырга юл юк һәм акчасыз кайтып керү мөмкин дә түгел иде — гидрологлар кинәше белән ул Татарстанга нефть эзләргә китте.

Шуннан соңгысын разведчиклар үзләре дә беләләр. Сапарбай буровойга Зәй буенда эшләгән чакта, хезмәт хакы алган көнне килеп төште. Бер нәрсә кызык булып күңелгә кереп калган: акча бирергә контораның кассиры «тетя Маша, сумка ваша, деньги наша» дип йөртелгән ябык һәм чәрелдек хатын килгән иде. Аның сумкасындагы төргәк-төргәк акчаны йотардай булып карап торган Сапарбайдан шикләнеп сорарга мәҗбүр булды ул:

— Нинди ач күз бу?

— Яңа кеше ул, тетя Маша, эшкә килгән.

Бораулаучылар берәм-берәм килә торды, кул куеп акча ала торды, ә Сапарбай касса янында терәлде дә катты.

— Нигә китми инде ул? — диде тетя Маша бораулаучыларның колагына.

— Сиңа гашыйк булган ул, тетя Маша! — дип шаярттылар кассирны.

— Ай-һай, акчага түгел микән?

— Бәлки, икегезгә дәдер? Акчалы хатынны кем яратмый? — дигән булдылар аңа.

Соныннан Сапарбайның «холкына» тетя Маша да, бораулаучылар да төшенделәр: акчага бер дә битараф карый алмый икән бичара казакъ баласы. Хезмәт хакы алыр көн җитә башласа, йокысы кача иде Сапарбайның. Ә кассир килеп акча бирергә керешсә, Сапарбай ведомостька кул куя алмый азаплана, калтырый, алган акчаларын төшереп җибәрә.

— Ашыкма, санап ал! — дип чәрелдәп кычкыра тетя Маша, Сапарбайны тагын да каушатып.

Ике арадагы бу кәмитне бораулаучылар бик кызыксынып күзәтәләр.

— Ялгыш санадың түгелме соң, Сапарбай?

— Әз бирде бит сиңа тетя Маша акчаны! — дип ирештерергә тотыналар. Сапарбай касса янына килеп акчасын яңадан саный башлый. Кассир белән икәүләп ялгышып, буталып бетәләр.

Сапарбайның тагын да сәеррәк гадәтләрен күрәселәре булган икән әле бораулаучыларның. Бригада кешеләре акчаларын тумбочкаларда, я мендәр асларында саклаганда, Сапарбай аларны билбавына төреп, бәйләп йөри башлады. Эшкә дә шул билбавы белән бара, йокларга ятканда да чишми. Бер вакыт бик арып кайтып йоклагач, егетләр шаярып билбавын чишеп алганнар иде, ник эшләдем көненә төштеләр — Сапарбай уянгач акылыннан язардай булып кычкырып җибәрде:

— Ай-вай, акчамны алганнар! Урлаганнар!

Акчасын биреп көчкә тынычландырдылар үзен.

Шул көннән соң ул үзенә ипилек-тозлык кына калдырып, акчасын туган иленә салып җибәрә башлады. Болай да чандыр, яңак сөякләре калкып торган егет, ачлы-туклы яшәп, тагын да бетеренә төште.

— Тамагыңны кысма, Сапарбай туган, үлеп китәрсең дә акчаң калыр билбавыңда! — дип, уенын-чынын бергә кушып шелтәлиләр иде аны иптәшләре.

Сапарбай я көлеп куя, я дәшми иде. Мондагы кырык мир баласы беләмени Сапарбайның хәлен? Аңа бит әле Сөенбай әкәсенең әйтүенчә Рәйхананы алу өчен кимендә кырык мең тәңкә акча кирәк. Кырык мең! Туй үткәрү, кодаларны чакыру, кунак җыю өчен тагын да ун мең чыгачак. Өйгә ай саен ике мең тәңкә салганда да егерме биш ай эшләргә кирәк дигән сүз. Ике елдан артык бит бу. Ә Сапарбайга алай озак торырга ярамый. Рәйханасы китә аның. Димәк, акча салуны мөмкин кадәр арттырырга, кавышу көннәрен якынайтырга кирәк. Сөенбай әкәсе дә хатта шулай дип яза.

Буровой эшчесе, разведчик буларак, Сапарбай хезмәт хакын аена ике мең сумлап ала иде. Ләкин күрә: буровойда акчаны тагын да күбрәк ясарга мөмкинлек бар. Бригадада кеше житми. Икенче сменага калып эшләргә теләүчеләр юк. Мастер бораулаучыларга ялынып-ялварып, ә кайчагында аларны мәжбүр итеп эшләтә. Мондый чакта Сапарбай: «Куй мине, мастер! Үзем барам!» — дип атлыгып кына тора иде. Хәтта аны Зөбәеров тырышлыгы өчен бер жыелышта мактап та чыкты.

Гайбәтенә кереп булмый, эшкә дигәндә Сапарбай — уңган егет. Вазифасы смена буе буровойга авыр-авыр торбалар китерү, берсе-берсе яртышар центнерлы инструментлар күтәрү, скважинага кудыру өчен балчык әзерләү белән бәйле булса да, зарланмас, ардым дип әйтмәс. Бер смена эшләп, ике смена ял итәргә тиеш булса да, ул буровойга бер вахта аша ук чыга, тагын шундый мәшәкатьле, авыр хезмәткә тотына, сер бирми.

Хезмәт хакы да инде аның икеләтә диярлек күтәрелде. Хәзер ул ерак Казагыстандагы әкәсенә акчаны өч мең тәңкә итеп сала.

Сөенбай әкәсеннән дә бу айларда берсеннән-берсе күңеллерәк хатлар килә. Ул Жаксыбай кодаларга барып, Рәйхананы гел белешеп тора икән. Рәйхана сәлам әйткән. Түземсезлек белән кавышу көннәрен көтә икән. Ә соңыннан һәрвакыттагыча Сөенбай әкәсенең имзасы: «Пуштыны аз саласың».

Тагын ике йөзгә арттыра Сапарбай «пушты» салуны. Унбиш-егерме көннән янә хат килеп төшә: «Рәйхана туй көннәрен санап кына тора, тик пуштың гына аз килә».

Бу айда ашавын коры икмәк белән суга гына күчереп, Сапарбай кышлак адресына акча салуны өч мең биш йөз сумга житкергән иде...

Нәтиҗәсе: кичә аны буровойдан житәкләп кайттылар.

## 9

Сапарбайга «тавык күзе» булгач, Рәйсә бораулаучыларны уйлап йөри башлады. Нинди халык бу разведчиклар, кемнәр алар — үзләренә күрә романтиклармы, кыланчыклармы, әллә ваемсыз бәндәләрме? Ничә мәртәбә Рәйсәнең Фазыл янына килеп, чатырда кунганы булды, фатирда торып китте, менә хәзер бер айга якын монда яши, ләкин аңлый алмый ул аларны. Кеше төсле ял да итә белмиләр, адәм рәтле йокы да, күңел ачу да юк. Хәтта көн белән төн төшенчәсен дә онытканнар. Кыргыйлар шикелле яшиләр. Көн саен буровойларына чыгып китәләр дә эштән соң чатырларына кайтып авалар. Анда да ял иткәне ял итә, ял итмәгәне — юк, ашаганы ашый, ашамаганы ач йөри. Киемне инде әйтеп торасы да түгел — кыяфәтләре сукбайларга охшаган.

Тәртип, режим дигән нәрсәне, хужа була торып, Фазыл үзе дә белми. Төннең, көннең теләсә кай вакытында чыгып китә дә югала. Үз рәтендә ашау-эчү юк, йокы юк, семья юк. Болай разведкада күпме йөрербез, дөньяда күпме яшәрбез дип уйлыйлар болар?!

Сапарбайның хәлен белеп кайтышлый Рәйсә туп-туры буровойга китте, ирен чакырып алды.

— Фазыл дустым,— диде ул, житди сөйләшкәнен белдереп,— син бит мастер, бригаданың житәкчесе. Бу буйдаклар өерен бер тәртипкә китерәсе иде бит...

— Нәрсәсе тәртипсез? Аллага шөкер, эш әлегә ярыйсы бара. График та үтәлә...

Анысы яхшы, ләкин алар үзләрен корбан итеп бетерәләр ич! Организмның да бит бер чиге бар...

— Аңламыйм, нәрсә әйтмәкче буласың, иптәш доктор? — диде Зөбәеров, «доктор» сүзенә басым ясап.

— Аларның эшләү, яшәү шартларын уйларга кирәк. Даими рәвештә азык-төлек кайтартуны, вакытында пешереп ашауны булдырырга. Икенчедән, ял итәсе урында теләсә кайда буталып йөрүләрне тыярга. Аннан, икешәр смена тоташтан эшләүләрен бетерергә кирәк. Кешеләрең аяктан егыла бит хәзер!

— Син Сапарбайны әйтәсең инде?

— Аның мисалы факт түгелмени? Чиктән тыш эшләүдән, ару-ялыгудан булган бит ул!

— Беләсең икән! — дип кычкырды Зөбәеров Рәйсәгә.— Ашамый ул. Бар акчасын өенә салып бара! Монысына да мастер гаепләме?

— Ә нигә бар акчасын?

— Анысын инде үзеннән сора! Комсызлык бәласе!

Моңа кадәр Үскенбаевның авыруын бары тик киеренке эштән һәм азыкта витамин житмәгәннән дип күргән Рәйсә ашыга-ашыга янадан Сапарбай чатырына китте. Менә сиңа, Үскенбаевның ни белән тукландуын да белмичә, Рәйсә аңа витаминга бай булган кузгалак, кычыткан кебек үләннәр кушарга, кишер, кыяр, күп итеп суган ашарга тәкъдим иткән иде. Чынлыкта исә Сапарбай «суган суы» суырып утыра икән!

— Сапарбай, жаным, мин бит сиңа ялгыш рецепт биргәнмен,— диде гафу үтенгәндәй Рәйсә.— Сиңа кузгалак, кычыткан кебек нәрсәләрне ашарга бөтенләй ярамый икән. Кишер дә, кыяр да, суган да зарарлы! Ит ашарга кирәк сиңа! Әйе, әйе, ит, сөт, йомырка!..

— Ит, сөт, йомырка! — дип үчекләп көлде Сапарбай.— Аларны алырга акча кирәк бит...

— Акча? Әй, Сапарбай, юкны сөйләмә инде! Сине бит бик күп акча ала дип сөйлиләр, ике смена эшлисең ич.

Сапарбай, бик зур кайгысы бар кешедәй, башын түбән иде.

— Әйт, килештекме? — дип, Рәйсә Сапарбайның беләгеннән тотты.— Ит, сөт, йомырка! Авылга барсаң, саталар...

— Булмайде.

— Ни өчен булмый?

— Акча юк.

Рәйсә Сапарбайны оялтырга тырышты.

— Ничек булмасын инде, әле кичә генә алдыгыз түгелме соң?

— Ул акчаны пуштыга салам.

— Салмый тор син аны. Нәрсә, әти-әниең бик фәкыйрь яшиме?

— Сез, нугайлар, бер нәрсә дә белмисез,— дип көрсенде Сапарбай...

Рәйсә тагын да кызыксына төште:

— Шулай да...

Бераз жавапсыз утырганнан соң Сапарбайның карачкыл-соры йөзенә елмаю чыккандай булды.

— Минем өйләнәсем бар...

— Өйләнә соң, кем сине тота!

— Әй, Рәйсәхан! Төшенмисең! Акча тота, акча!

Шуннан Сапарбай, ачынып, күңелендә булганнарның барысын селекте дә салды. Беркемгә дә сөйләгәне юк иде әле бу хакта. Кешеләрне кайгыртып йөргәнгәме, әллә «духтыр» булгангамы, Рәйсәне бик хөрмәт итә иде ул, берсен дә яшермәде. Илемдә минем ярәшеп уйган кызым бар, диде, мине көтә, диде. Хәзер инде күп калмады, калымлык акчамны тутырам да далама — Рәйханам янына кайтып китәм, диде. Аның исәбе буенча, Сөенбай әкәсе сораган кырык мең тәңкә акча тулган булырга тиеш, тагын туй чыгымнарына һәм кунак-төшем алу өчен ун мең сумлап кына жыясы калган икән.

Сапарбайның фажигасен кайтып сөйләгәч, Зөбәеров ышанырга да, ышанмаска да белмәде:

— Бу заманда — атом һәм электрон чорында авыз күтәреп «калым» дип утырамы? Ахмактыр ул! Я булмаса башындагы шөрепләре ычкынгандыр!

— Алай димә, Фазыл. Андый искелек галәмәтләре һәр җирдә дә бар ул. Теләсәң әйтим: бораулаучыларында да, синең үзеңдә дә тулып ята.

— Юк инде, Рәйсә. Ни әйтсәң дә Сапарбай кебек яшь кешегә ата-бабадан калган йолаларны тоту килешми! Ул үзе көрәшергә, сугышырга тиеш алар белән!

— Җибәрәсе акчаларын җибәргән, эше беткән инде. Тиздән калымны тутырам да, кыз минеке дип утыра хәзер. Тик шунысына борчылам: кызын да күрә алмый аягын сузуы бар...

— Алай, алай,— дип, картларча сузып торды Зөбәеров, һаман да әле гаҗәпләнүен баса алмады.— Билләһи, без аның калым җыйганын белмәдек! Акчага хирес, комсыз бер бәндә дип кенә уйлый идек...

— Минемчә, комсызлык чире яманрак. Ә Сапарбайның бу авыруы өйләнгәч тә бетәр...

Зөбәеров кулын селекте:

— Әй, икесе дә бер шайтан!

Рәйсә Зөбәеровның ачуы басылганын көтте дә мондый тәкъдим ясады:

— Әллә, мин әйтәм, Фазыл, ялга җибәрәсеңме үзен. Күрсен иде кайтып Рәйханасын. Икенче отпускам җитә дип сөйли бит инде...

— Килми ул аннан.

— Килер. — Бераз уйлап торгач бер фикер килде Рәйсәнең башына:— Ә сез акча җыйнап җибәрсәгез аңарга? Алып килсен Рәйханасын, ә?

Рәйсәсе бригада эшенә тыгыла башласа, жене котыра иде Зөбәеровның — бу юлы каршы килмәде.

— Әйдә! Хәзер барыбер Үскенбаевтан рәт чыкмый, терелеп килер,— диде.

Үзара сөйләшеп, бригадада һәркемнән өчәр-дүртәр йөз сум акча җыйдылар. Моны Сапарбай белергә тиеш түгел, үз акчам дигән булып аларны яшертен генә Рәйсә тапшырырга тиеш иде.

Рәйсә нәкъ шымчыларча эш йөртте.

— Мин врач буларак әйтәм, Сапарбай, сиңа ял кирәк,— дип үгетләүдән башлады сүзен.— Туган илеңә, далаңа кайтырсың, Рәйхананны күрерсең...

— Йок, ял алмыйм! — дип каршы төште Сапарбай.— Кайтсам бөтенләй кайтып китәм, ял алмыйм!

— Ике еллык отпуска акчаң бар бугай, шулай булгач калымың да җитә торгандыр. Рәйханага өйләнерсең дә монда килерсең...

— Йок, калым җитмәй...

— Җитмәсә, үзем биреп торырмын! Күпме кирәк! Биш мең җитәме?

— Җитә! — дип кычкырып җибәрде Сапарбай. Тик Рәйсәнең сүзләренә ышанмады булса кирәк.— Яхшы түгел сездән акча алу...

— Ә син килгәч бирерсең! Тот, тот!

Сапарбай Рәйсә биргән акчаларны ике кулы белән күкрәгенә кысып, җүләрләнгән шикелле сикерергә, әйләнергә, биергә кереште.

— Ой, рәхмәт, Рәйсәхан! Мин сезне мәңге онытмам!

— Син өйлән дә алып кил Рәйхананы!

— Болды! Алып киләм! Уй, сез күрсәгез иде Рәйхананы! Ул бит дөньяда бер кыз!..

Шул сәгатьтә үк Сапарбай юлга җыена башлады.

Нинди дә булса жыелышка, киңәшмәгә һәм отчет бирүләргә килүдән тыш, ерак Ромашкинодагы бораулау конторасына Зөбәеров аена тагын ике мәртәбә — разведчикларга аванс һәм хезмәт хакы алу өчен бара. Билгеле, акчаны мастер кулына бирмиләр, машинага хуҗалык сумкасын дыңгычлап тутырган акчасы белән тетя Маша утырып килә.

Конторада йомышларын йомышлап, кассир белән Язтугайга кайтырга йөри Зөбәеров. Бүген палучка көне, якты күздән чыгып китәргә кирәк. Тетя Маша да сумкасын акча белән симертеп кабинага утырган, Зөбәеровны ашыктыра.

Ләкин Зөбәеров һаман ишек алдында бутала, жыелып торган бер төркем кеше тирәсендә кайнаша. Ул төркемдә ике-өч хатын-кыз бар, шуларның берсе Тин-Тинычның Валясына охшаган. Чын менә, кулына кәйлә тоттырып, аркасына рюкзак астырсаң һәм хәзер чуалып беткән чәчләрен күпертеп косынка да бәйләтсәң — нәкъ журналда күргән геолог кыз була да куя!

Әллә, югыйсә, дөрестән дә Тин-Тинычның Валясымы?

Валентин бригадага килгән көннәрдә егетнең хыялына бирелеп, Зөбәеров та, бәлки Валяны табып булыр, дигән өмет белән яши иде. Тин-Тинычның үтенүе буенча, ул барган бер жирендә Валя дигән кызны сораша, күренгән бер геолог янына китеп бара иде. Хәтта шул хәлгә килеп житте: Тин-Тиныч кебек үк, ул да очраган бер хатын-кызның алдына чыгып карый торган булды.

Тин-Тинычның журналда күргән геолог кыз белән танышуы, ерак диңгезгә йөзәргә чыгып китеп ул кызны югалтуы һәм хәзер Сак белән Сок кебек адашып, кавыша алмыйча яшәүләрен бригадада һәркем белә, бәхетсез Тин-Тинычка кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә тырыша иде. Чыннан да, тау белән тау гына очрашмый бит! Ләкин ничә ел үтте, беркайда да, беркемгә дә журналдагы Валяга охшаган геолог кыз күренмәде.

Бичара Валентин кызны эзләү дәртеннән шушы көнгә кадәр суынмады. Буровой күченгән бер урында авылларга барып Валясын кешеләрдән сорашты, хәтта нефтькә бернинди мөнәсәбәте булмаган конторaларга, учреждениеләргә, йортларга кереп йөрде, көн-төн телефоннан шалтыратты. Ул һаман кызның кайдадыр килеп чыгасына ышана, табыласына, кавышасына инана иде.

Моның булмастай нәрсә, юк белән мавыгу икәнен төшенгәч, Зөбәеров Валяны эзләми башлады, «сораштырам, караштырам» дип, Тин-Тинычны тынычландырып кына йөри иде.

Бүген нишләптер әнә шул төркемдәге кызга күзе төште. Авызын ачты да катып калды — нәкъ журналдагы Валя! Тик эндәшергә кыймады — ул булмаса уңайсыз хәлдә генә калуың бар...

— Әй, Тин-Тинычка ияргән мин җүләр! — дип, тиз генә машинасы янына китте. Җитмәсә, тетя Маша да кабинада кычкырып һаман аны чакырып утыра иде.

— Әйдә, киттек! — диде Зөбәеров, тетя Маша янына кабинага кереп кысылгач. Гүя ул ашыга-ашыга Валядан кача иде.

Әгәр дә Валя булып чыкса, Зөбәеров ни эшләр иде? Кайтып: «Валяны күрдем», дисә, Тин-Тиныч нишләр иде? Һушыннан язар иде. Ул гынамы? Буровойны ташлап, Валя артыннан китәр иде. Аннан кем бораулар ул скважинаны? Авылын уйлап йөргән Мотгәрәйме? Бүген-иртәгә кайтып китәм дип торган Саакянмы? Янсә акча эшләргә генә килгән Сапарбаймы? Юк. Валя булуы дөресме, түгелме, бу турыда Тин-Тинычка әйтмәскә кирәк. Ләм-мим.

Яшерсә дә яхшы түгел. Бичара егетнең бөтен өмете, канаты шул күрер күзгә әллә ни искитәрлек булмаган көлтә чәчтә. Аннан башка

яшн алмый. «Ярый, ни булса шул» дип эченнән генә бер карарга килде Зөбәеров һәм шоферга Ромашкинодан шактый ерак китәргә өлгергән машинаны кире борырга кушты.

— Тагын конторагамыни! — дип чәрелдәп кычкырды кассир.— Әй, шушы мастерларны!..

— Бер генә минутка, тетя Маша, эшем калган...

Тик алар килгәндә ишек алдындагы төркем юк иде инде. Зөбәеров ары чапты, бире чапты, андагы кешеләрнең берсен дә очрата алмады. «Юл уңаенда гына кергәннәр. Машиналарына бензинмы, маймы салып чыкканнар икән. Инде алардан җилләр искән. Кемнәр алар, кай якка китеп барганнар — берәү дә белми.

— Бетте. Иомарга кирәк.— дип, Зөбәеров кайтканда күңеленә бер-кетеп куйды.— Юкса, бригада егетләре күзне ачырмас...

Чатырлар каршына машина туктау белән: «Акча кайтты! Тетя Маша, деньга наша!» дип кычкырышып, разведчиклар урамга сибелде. Акчадан бигрәк тетя Машаны сагынганнар, аны үртиселәре килә иде.

Кул куйдырып хезмәт хакын биргәндә тетя Маша, «вагы кирәкми» диюгә карамастан, акчаны тиенен тиенгә санап тоттырып, өстәвенә, акчаны әрәм-шәрәм итмәскә үгет биреп китәр.

Зөбәеров, кассирны автобус янында акча бирергә калдырып, чатырына кереп китмәкче иде, аны Кадермәт туктатты:

— Очрамагандыр инде, Тин-Тинычның Валясын әйтәм?

— Андыйлар күренмәде.— Аннары үзенең тупас җавабын болай дип төзәтте:— Гомумән, бернинди хатын-кыз очрамады.

— Очраса да танымыйсың инде син аны,— дип, өметсез нәтиҗә ясады Кадермәт.— Тин-Тиныч бүген ни өчендер аеруча көтте. Әле сез кайтыр алдыннан гына телефонга киткән иде.

Фазылны каршы алырга чатыр янына кызын күтәреп Рәйсә чыккан иде. Исәнлек-саулык белешүдән алда, ул да Кадермәт соравын кабатлады.

— Нәрсә сез бүген барыгыз да! — дип җенләнеп алды Зөбәеров.— Әйтерсең мин шуны гына карап йөрим! Башка эшем беткән!..

— Болай гына әйтүем, Фазыл... Кем белә, очрап куюы да мөмкин. Тин-Тиныч телефоннан белешкән: имеш, шушы тирәләрдә генә ниндидер геологлар йөри, ди...

— Күп булыр монда геологлар...

«Мин килгәнгә кабарынып йөри,— дип фикер йөртте Рәйсә.— Нәрсә ул мине гел шушылай чатырда тик ятыр дип уйлыймы? Әнә, авылга фельдшер-акушерка кирәк диләр, тотам да эшкә керәм!»

Фазылның күңелсезләнеп калуын килеп тора башлаганнан бирле сизеп йөри иде Рәйсә. Ире аның хәзер сөйләшми, көлми, елмаймый, кайтып ашый да я буровоена ашыга, я машинасына утырып контора-сына китеп бара. Бу борчылуларны башта Рәйсә буровойдагы кыенлыкларга бәйләп юрый иде. Фазылы да күп вакытта шуннан зарлана иде. Соңгы атналарда эшләре дә җайга салынды кебек, тик Зөбәеров һаман үзгәрмәде.

— Нигә син болай ачулы йөрисең әле, Фазыл?

— Юк ла, сиңа түгел! — Зөбәеров кызын кулына алып, теләр-теләмәс кенә сөйләп китте:— Син инде моны Тин-Тинычка, башкаларга әйтә күрмә... Бәлки ул да булмагандыр... Охшаган гынадыр ул... Мин бит Тин-Тинычның Валясын күрдем!

— Күрдең? Кайда? — Рәйсә иренең алдына төште.

— Юк, күземә генә шулай күренгәндер ул...

Зөбәеров, тотлыга-тотлыга, контора ишек алдындагы хәлне, машина белән яңадан килүләрен, ул килгәндә инде теге кызның китеп баруын сөйләп бирде.— Юк, күземә генә шулай күренгәндер ул!

— Кызык! Моны, һичшиксез, Тин-Тинычның үзенә әйтергә кирәк!

— Шашма!

— Яшерү бит кешелек түгел. Син үз иптәшләреңне, кул астында эшләгән кешеләреңне сөймисен булып чыга.

— Куй әле!

— Ә мин әйтәм.

— Әнә шуның өчен яратмыйм да мин синең монда торуыңны! Мастер эшенә тыгыласың!

— Алайса, мин иртәгәдән эшкә керәм! Иркенләп яшәрсең берүзең!

Зөбәеров, бер нәрсә дә төшенмичә, барган җиреннән туктап калды.

## II

Тирбәлеп торган тоташ арыш дулкыны арасында утырып йөрүдән башы әйләнә башлагач, бишенче уратуда Мотгәрәй комбайнны туктатып Камил янына төште, шунда ук чалкан китеп саламга ауды.

— Ардыңмы, абый? — дип сорады Камил.

— Нигәдер баш әйләнә. Элек күпме эшләп болай булганы юк иде, гаҗәп!

Үзе шунда ук баш авыртуның хикмәтен дә төшенде: эштән генә килде бит, бөтенләй ял итмәгән...

Ләкин Мотгәрәйнең моннан һаман да китәсе килми иде. Теге көндәге кебек арыш арасыннан, кызыл яулыгын болгый-болгый, пешекче хатын килеп чыкмасмы дип көтте ул. Камилдән читләтеп кенә сораша торгач, аның исеме Фәридә икәнен дә белде, Камилнең сөйләве буенча, бик уңган хатын икән, ашларны тәмле пешергәнгә, механизаторлар ел саен урак өстендә пешекче итеп аны куялар икән.

— Соң, кайчан килә инде ул Фәридәң? — дип, түземсезләнеп сорау биргәнен үзе дә сизми калды Мотгәрәй.

— Карын ачтымыни?

— Әйе... Булмаса, кайтырга кирәк. Төнлә вахтага чыгасы бар.

«Вахта» сүзен ишетү белән, Камил, серле бер нәрсә тотарга тырышкандай, алга омтылып куйды.

— Ә анда вахтада ничек, кызыкмы?

— Эшләп кара, белерсең!

— Барсам, анда мине алырлар микән? Мин кибет ишегенә ябыштырылган белдерүне укыган идем. «Комбайнчы булса да ярый», диелгән анда.

Авызга керердәй булып, алга сөрлегеп утырган бу егетнең сүзләрен Мотгәрәй ошатмады. «Менә бит, саташкан җан, кеше буровойдан ничек качарга белми йөри, ә ул нәрсә белән тилереп утыра!» Тиргәп ташлыйсы килде егетне Мотгәрәйнең, ләкин түзде.

Кузгалырга дип кенә торганда, арыш арасыннан, савыт-сабаларын күтәреп, Фәридә килеп чыкты.

— Бигрәк ерак киттегез, имансызлар, килеп җитәр хәл юк! — дип ачуланган була үзе.

Фәридәне күрүгә Мотгәрәйнең битләре кызышып китте. Гел көлеп, елмаеп торуы беләнме, юан ботларын як-якка ташлабрак атлавы беләнме, әллә шулай шелтәле сөйләшүе беләнме Мотгәрәйгә ошый иде Фәридә. Җитмәсә, шелтәләгәндә аның алсу иреннәре матур булып бүлтәеп чыга һәм, «егет булсаң — шуны үп!» дигәндәй, Мотгәрәйне үчекли сыман иде.

Теге көнне аның белән бергә ашарга калмавына да үкенеп бетә алмады Мотгәрәй. Ничек кыстады бит Фәридә, хәтта таза куллары белән беләктән дә килеп тотты. Бүген инде Мотгәрәй алай ялындырып тормас, бер әйтү белән табынга килеп утырыр. Әллә берәз генә кыланып торырга микән? Әйдә, тагын беләгеннән килеп тотсын әле Фәридә...

— Бүген инде мин сине җибәрмим! — дип, алдан ук кисәтеп куйды Фәридә дә.— Безнең колхозга шушы кадәр эш эшләшеп соң! Моны бит, җүләр, Камил булса биш көн ура!

Шул арада Фәридә салам өстенә ашъяулык җәеп, хәзинәдә барын чыгарып тезә башлады. Күпереп торган ак күмәч куйды, тәмле ис таратып торган ямь-яшел кыярлар куйды, савыты-савыты белән катык, сөт куйды. Аның өстенә калай тәлинкәләргә шулпа салды, кисәге-кисәге белән ит салды. Табынга бизәкле, ялтырап торган агач кашыклар да китергәч, Мотгәрәй хәтта кулын уып алды. Болар барысы аның туган авылын, өен, кырларын искә төшерә иде.

Табын әзерләгәндә Фәридә алсу иреннәрен ялый-ялый туктаусыз сөйләнде:

— Аптырадык бит теге көнне синең кемлегеңне белә алмыйча. Камилен әйтер идем: комбайныны биргән, кемлегеңне сорамаган. Кешегә эшләшеп йөри торган нинди изге җан икән дип тә, нинди эшсез бәндә дип тә юрыйбыз. Ахырда искә төште бит, Баланлы Төбәгенә килгән бораулаучылар! Камил әйтә, булмас, ди, ничек бораулаучы башы белән комбайнда утырып йөрсен, ди. Мин әйтәм, нигә утырмасын, алар да бит әллә кем түгелдер әле, крестьяннан азган кешеләрдер, дим. Менә ялгышмаганмын булып чыкты. Сезне чатырларда торалар дип әйтәләр, ничек соң, суык түгелме?

— Суык булса, авылга кайтабыз без, Язтургайга.

— Озакка килдегезме соң?

— Кайчан нефть чыга бит. Кыш урталарына кадәр бораулавыбыз да ихтимал. План шундыйрак.

— Озак бораулана икән. Нефть шулай бик тирәндәмени соң ул? Булмас, булмас, безнең Язтургайда нефть чыгамы соң? Гел шулай чатырларда да кеше өстендә яшисезме?

— Нишлисең, башыңа төшкәч.

— И-и, бичаралар. Авырдыр инде. Фатир ягы да кыендыр. Әгәр алай-болай авылга кайтырга туры килсә, үземә генә керегез. Хәер, сезгә йортның иркенрәген дә табарлар...

Инде кулга кашык алып кабам дигәндә генә табын янына ук тарантаслы ат килеп туктады. Аты күк туры, биек тәгәрмәчле читән тарантаска яшел печән салынган иде. Усал гына «тр-р» дигән тавыш ишетелде, адәмчә сүз башлаганчы ук чыбыркы сабы белән тәгәрмәчкә сугулар китте:

— Син монда, иптәш, безнең комбайннар тирәсендә буталып йөрмә, булдымы?! Килеп безнең кешеләрне агитлап йөрергә ничу, аңладыңмы! Без шпионнардан башка да бик яхшы яшибез, белдеңме! Белсәң шул: моннан соң бу тирәдә эзең булмасын, төшендеңме!

Атлы абзый ничек килгән булса, шулай тарантасында келтерәп китеп тә барды. Әмма аның килүеннән-китүеннән Мотгәрәй дә, Фәридә дә, Камил дә берни аңламадылар. Телендә бар белгәне «ничу» да «ничу», «белдеңме» дә «төшендеңме», кем шпион, ничек ул шпион, кемне кем котырта, нәрсә дип котырта — шайтан белсен.

Мотгәрәйне Фәридәнең кыставы да, Камилнең ялынуы да туктата алмый иде инде хәзер. Мотгәрәй китте. Авыр, ямьсез тәэсирләр белән китте ул Язтургай басуыннан. Аның бөтен юанычы шушы кырлар иде, күңел өчен генә булса да ара-тирә эшләп китү иде — өметен өзделәр. Кешенең һава суларга, кул яздырырга килүе дә кызганыч микәнни бу бәндәгә?

Бигрәк тә Фәридә белән сөйләшә алмавына әрнеште Мотгәрәй. Элек яп-якты йөзле хатын, чыбыркылы абзыйны күргәч, әнә ничек алыштырып куйгандай булды.

Фәридәнең арыш арасыннан килеп чыгуларын, юан ботларын якякка ташлап кыланып атлауларын һәм иренен бүлтәйтеп юри шелтәләү-

ләрен күз алдына китерә-китерә, Мотгәрәй Баланлы Тәбәккә кайтып житте.

Чатырлар тирәсендә беркем дә күренми, тик читтәрәк, карт имән күләгәсендә, Рәйсә генә тагаракта кер юып маташа иде. Шул, һаман да бер игелекле жан Рәйсә, иреннән яшерә-яшерә, бораулаучыларның өс-башларын юа торгандыр инде.

Мотгәрәйне күрүгә, кулындагы керләрен дә куярга онытып, Рәйсә аның янына йөгереп килде.

— И, Мотгәрәй жаным, кая югалдың? Сине хужаң эзләде бит! — диде ул борчылып. «Инде нинди жәза бирер икән мастеры аңарга?» дигәндәй уйланып калды.

— Буровойга чират буенча Сапарбай барырга тиеш булган икән. Ул отпускага китте. Сине жибәрмәкче булды мастерың. Эзли — син юк. Тапмагач, дөнья бетереп холыксызланды.

Зөбәеров үзе килеп чыкса яхшы булмаячагын төшенгән Мотгәрәй чатырына кайтып өстен алыштырырга, спецовкасын киярга тотынды. Арыганлык шул кадәр көчле иде — аяклар чалбар балакларын, куллар брезентовка төймәләрен тапмый азапландылар. Тапкач та ул төймәләрне каптыра алмый интекте Мотгәрәй.

Буровойга житкәнче үк каршы очраган Зөбәеров Мотгәрәйне эттән алып эткә салды: «Жаның юк синең, диде, башың юк, диде, булса аз гына бригадаң турында уйлар идең, һич кирәкмәгән урында буталып йөрмәс идең»,— дип жикеренде. Кулындагы ачкычларын атып бәрде дә: «Тагын бер мәртәбә югалып йөрсәң, үзеңә үпкәлә!» — дип китеп барды.



## 12

Бу көннәрдә Камил кабык арбасындагы бензин-керосин мичкәләре, арба төбенә салынган төрле машина частьләре белән дангыр-донгыр килеп буровой аша узып йөри башлады. Арыш басуын тәмамлап, ул бодай басуына күчкән иде һәм комбайн янына турыданрак та барырга була иде, ләкин егетне һаман әнә шул Сагындык аръягындагы могжиза булып һавага күтәрелгән буровой вышкасы, вышка башында төннәрен жемелдәгән тылсымлы утлар, тәүлекләр буе бер дә туктамый дөбердөбер килеп торган хикмәтле тавышлар тарта иде.

Июль урталарында көтмәгәндә генә Баланлы Тәбәккә килеп утырган бу буровойны инде авылда барып күрмәгән кеше калмагандыр. Тәпи йөри башлаган балалардан алып, таякка таянган картларга, бөкрәйгән карчыкларга кадәр булып кайттылар анда. Шатланып та, кайгырып та сөйләделәр авылда. Имеш, Баланлы Тәбәк астында нефть диңгез булып ята икән, имеш, бораулаучылар ул урында жирне тишәргә дә куркалар, тишсәләр — жир мае ургып чыгып Сагындык елгасына агачак, Язтургайны йортлары-ниләре белән күмеп китәчәк. Чынлапмы, саташыпмы, Камилнең атасы Сабиржан карт хәтта өен тау башынарак күчерү турында да сөйләнә башлаган иде.

Кайберәүләр монда нефть чыгачагына бөтенләй ышанмадылар. Ул хакта сүз чыккач, «һәй, безнең Язтургайга тагын нефть!» — дип, ирен кырые белән елмаеп кына куйдылар.

Ләкин андыйлар авылда аз иде. Халыкның күбесе Шөгер, Баулы, Ромашкино якларында күпләп-күпләп «кара алтын» чыга башлавы турында кешеләрдән ишетеп тә, газеталардан укып та белә иде инде. «Язтургай бит алланың ятим баласы түгел, анда нефть чыкканны ни өчен монда чыкмаска тиеш?»

Камил үзе, мәсәлән, жирнең ничек бораулануын, нефтьнең ничек фонтан булып атуын, ул фонтанга шырпы сызып жибәрсәң, буровойның галәмәт зур ялкын белән янып китәргә мөмкин булуын инде әллә кай-

чан, бишенче класста вакытта ук, «Горизонт» дигән китаптан укып белә иде.

Разведчиклар килгәч тә ул, башкалар кебек, абруен төшереп Баланлыга торып йөгермәде, үзен белдеклегә санап, урамда басып калды. Хәтта буровойга эшче кирәклеге турында кибет ишегенә ябыштырылган белдерүне укыганда да тиз генә кабынып китмәде, иптәшләре алдында сер бирмәде.

Ә менә ялгызы гына иртә таңнан комбайн янына барганда инде ул «Безгә тракторчылар, шоферлар, комбайнчылар һәм техника белән таныш булган башка кешеләр дә мөрәҗәгать итә ала» дигән сүзләрнең мәгънәсе турында уйлана башлый, ирексездән атын Баланлыга таба бора, юл уңаенда вышкага сокланып карый-карый, буровой янынннан узып китә. Китап китап инде ул, үзең барып күрү икенче нәрсә...

«Теге белдерүдә язылган «буровой эшчесе» дигәне кем була икән, нәрсә эшләргә тиеш икән ул анда?»

Ала биясен туктатып, бер генә минутка булса да буровойның үзенә кереп чыгарга иде, эшләгәннәрен карап торырга иде, юк бит, вакыт та тими, аннан Камилнең каһәр суккан мин-минлеге дә кушмый. «Син бит әле комбайнга да быел гына утырдың»,— дисәләр, алмасалар?..

Кеше табу мәсьәләсендә Язтургай авыл Советына барган Зөбәеров җәяүләп, әкрен генә буровойга кайтып килә иде, аны аты белән Камил куып җитте.

— Утырт әле, егет,— диде Зөбәеров, атлы үзе белән тигезләшкәч, һәм, Камилнең рөхсәтен дә көтеп тормыйча, арбага менеп утырды.

Сагындык елгасына җиткәч, ат, суга керергә куркып, чыгымчылап торды.

— Бир әле үземә! — Зөбәеров дилбегәне алмакчы булып үрелгән иде, ләкин егет аны ычкындырмады.

— Үзем!

Кечкенәдән ат тотып үскән егетнең, олыларча сүгенеп, каты итеп дилбегәне кагуы җитә калды — ат корсак астыннан диярлек чумып, минут эчендә аларны теге як ярга чыгарды. Зөбәеров чалбар төбенә су кергәнен сизде, дәшмәде.

— Син болай үзең карап торуга ничево! — дип әйтеп куйды ул.

— Ә нәрсә, малай-салай түгел лә!

Шуннан соң инде Зөбәеров та егет белән үз тиңедәй сөйләшеп китте:

— Ерак барасыңмы?

— Комбайн янына.

— Ягулык ташыйсыңмыни?

— Ягулык ташып йөрергә әллә мин малай-салаймы!

— Кем соң син?

— Комбайнчы.

— Шулай укмыни? Син болай үзең карап торуга гына бәләкәй икән! — диде Зөбәеров.

— Әллә сез буровойданмы, абый?

— Әйе, мин мастер булам, буровой хуҗасы...

Шулайдыр дип уйлаган идем аны...

Калган юл инде Камилнең буровой турында, вышкалар, бораулаучылар, аларның эшләре турында сорашуы белән узды. Зөбәеров егетнең беркатлы, кызык-кызык сорауларына көлемсерәп кенә җавап биреп барганнан соң, болай дип әйтеп куйды:

— Кара әле, үскәнем, буровойда эшләргә теләмисеңме?

— Теләр идем дә...— дип кычкырып җибәрде Камил.— Аннары күнелсезләнеп: — Алмассыз шул, юри генә әйтәсез,— диде.

Алар инде буровой турына ук килеп җиткәннәр иде. Арбадан төшкәндә, Зөбәеров егетнең ябык җилкәсенә кулын куйды.

— Иртәгә минем янга кил әле. Үзеңне яхшы бер бораулаучыга бирермен,— диде.

Язтургайда буровой өчен бераүнен дә артык түгеллеген, бигрәк тә колхозның механизаторларга мохтажлыгын авыл Советына баргач аңлады Зөбәеров. Авыл Советы председателе Хафизов, мастер белән танышканнан соң, Язтургай кырында скважина салуның бик күркәм, бик мөһим нәрсә икәнен әйтте, нефтьнең халык экономикасын яхшыртуда зур адым булачагын, илебездә материаль байлыклар тудыруда прогресс ясаячагын, СССР да коммунизм төзүдә нефтьнең зур этәргеч бирәчәгеп — һәркем өчен билгеле нәрсәләрне сөйләп китте. Авылның промышленностька, промышленностьның авылга ярдәм итүдәге ролен күрсәтергә дә онытмады председатель, тик сезгә бирергә кешеләребез генә юк, диде. Сүзен исбат итү өчен булса кирәк, колхозның партоешма секретаре, шул ук вакытта мәктәп директоры Дәминовны да чакырып китерде.

Анысы да бер сүздә икән: «Юк бездә андый кеше. Ышанмасагыз, әнә колхоз председателеннән сорагыз»,— дип, Галләмне күрсәтте.

Колхоз башлыгы мәсьәләне бик кискен куйды, хосусый милекче булып сөйләште. «Басуымны алдыгыз, суымны алдыгыз, печәнлегемә хуҗа булдыгыз,— миннән шунысы да бик җиткән!» — диде.

Икенче көнне Камил буровойга бик иртә, караңгылы-яктылыда килеп җитте. Шуңа да карамастан, монда гөрләп эш барганын күреп читенсенеп куйды: «Соңга калганмын икән... «Ул әле бораулаучыларның өч смена эшләүләрен, яңгыр яуса да, кар-буран булса да, бер генә минутка да туктамауларын белми иде. Җитмәсә, кичәге буровой хуҗасы да бирегә икән. Камилне күреп буровойдан чыкты.

— Килдеңме? — диде ул, Камилне танып алгач.— Димәк, эшлибез? — Аннан, кечкенә малайны житәкләгән кебек, Камилнең кулыннан тотып, такта җәелгән сөзәк басмадан буровойга алып керде.

— Менә, Кадермәт, сиңа ярдәмче.

Кадермәт эшне туктатты да, кулыннан рычагларны җибәреп, егет янына килде.

— Күптән кирәк иде. Бик яхшы. Исемең ничек?

— Камил.

— Камил. Бик яхшы. Мин Кадермәт абыең булырмын. Буровойны күргәнең бармы?

Камил өчен мастер үзе җавап бирде:

— Ул моннан, Язтургайдан... Комбайнда ярдәмче булып эшлим, ди...

— Бик әйбәт! Техника белән таныш, алайса.

Бораулаучы ярдәмчесе Геннадий Еланскийның кашлары җимерелде:

— Нишләп инде, иптәш мастер, булган-булган, олырак кеше таба алмадыгыз?

— Өйрәтерсең!

— Монда бит бораулаучылар мәктәбе юк! Үзегез әйтмешли, метрлар кирәк безгә, метрлар!

— Үзең соң, үзең, белә идеңме эшкә кергәндә буровойны? — дип туктатты аны Зөбәеров.— Мин аптырыйм, нигә бу кеше дигәнеңнең хәтере начар икән? Компрессия эзләп складка чапканыңны оныттыңмыни?

Зөбәеров китәргә җыенды.

— Менә нәрсә: егет бүген буровой белән танышсын. Карасын, күрсен, ошатса үзе әйтер...

Камил килгәч, вахтаның беренче эше забойга инструмент төшерүдән башланды.

Иләмсез зур әмбар йозагына охшаган тали блогы дигәннәре әҗгырып бер аска, бер өскә йөреп торды — беләк юанлыгы корыч арканга

элгән ыргагы белән торбаларны сөйрәп менгерә-төшерә торды. Колак тондыргыч тавышы белән әледән-әле чыгырлар арасыннан һава атылып чыкты. Буровой пошкыра, уфылдый, кырык биш метрлы гәүдәсен калтырата. Торбалар, бораулаучы әмеренә буйсынып, берәм-берәм җир астына чумалар. Камил өчен болар могҗиза кебек иде.

Егет бораулаучыларга ярдәм дә итмәкче була, ләкин нәрсәгә барып тотынырга белмичә, аптырап кала. Еланский исә, түзә алмыйча, тешләрен кысып мыгырдана: «Таптылар эшче! Аяклы каза!»

Яна эшченең һәр адымы Кадерматкә көлке дә, кызганыч та.

— Үземнең дә шундый чакларым бар иде,— дип уйлый ул үткәннәрен. Алар инде сугыш алдыннан булган хәлләр һәм хәзер әллә кайда, томан эчендә күмелеп калганнар...

— Нәрсә, Камил дус, әллә төшенеп булмыймы?

— Булмый шул...

— Тотып тор әле, Гена.— Кадермәт тормоз рычагын Еланскийга бирде, платформадан төшеп ротор янына килде.— Ачкычларны ничек корырга дисеңме? Менә, кара!

Тәҗрибәле бораулаучы имән бармагы белән ачкычны торбага китерде, сул кулы белән чак кына этте дә йозакны торбага каптырды. Ачкыч каты итеп торбаны кысты. Бары тик бер бармагы белән генә эшләде моны Кадермәт. «Бер бармак белән ачкыч кору» — оста бораулаучылар телендә ул шулай дип йөртелә дә икән.

Аннан Кадермәт бораулаучы ярдәмчесе булып инструмент төшереп күрсәтте. Моны ул шул кадәр җитез эшләде, әйтерсең аның кулында тимер түгел, ә резин туп. Кайсы нәрсәне кая куярга, нәрсәгә тотынырга, нәрсәне алырга икәнен ул уйлап та тормый, куллары, автомат кебек, үзеннән-үзе эшли.

Ике йөз метрдан артык корыч торба боравы-ние белән җир астына төшеп бетте.

— Менә хәзер бораулый башларга да була!

Кадермәт үзен алыштырган Еланскийның кулыннан канәгатьлек белән рычагын алды.

Стенадагы приборның теле сул якка авышты.

— Борау забойда,— дип аңлатты моны Кадермәт.

Вышканы селкеткән дөбердәү тавышы тирәндә бораунын каты токымны кимереп төшүен белдерә иде. Хәер, стенадагы приборлар болай да яхшы күрсәтеп торалар икән бораулау нәтиҗәсен. Индикатор дип аталган прибор хәтта кәгазьгә дә язып бара икән. Эшләгәненне дә, тик торганыңны да яза. Шуңа күрә бораулаучылар аны провокатор дип тә йөртәләр.

Кадермәтнең куллары тормозда булса, күзләре гел шул приборларда һәм Камилдә булды. Егетнең белергә, төшенергә тырышуы, ихластан йөрүе аны куандыра иде.

— Бу егеттән бораулаучы чыга! — диде ул, Еланскийның үзенә генә ишетелерлек итеп.

Ләкин вахта алышыныр алдыннан гына җир астыннан пәйда булган кебек кинәт кенә Галләмнең килеп чыгуы бөтенесенең кәефен алды да куйды. Ул, камчысы белән итегенә суга-суга, туп-туры буровойга керде. Бер кемгә, бер нәрсәгә дә игътибар итмичә, күзен тутырып Камилгә карап торды.

— Син, малай актыгы, нишләп йөрисең монда?

— Эшкә килдем.

Камил Галләмнең кулындагы камчысына карап куйды да, сыптырып җибәрмәгәе дип, артка чигенде.

— Ну-ка, марш комбайның янына! — дип кычкырды Галләм.

— Бармыйм.

— Марш, диләр сиңа!

Кадермәт бораулауны туктатты да, идарә пультеннән төшеп, «чакырылмаган кунак» белән Камил арасына төште.

— Тукта әле, абзый, син кем? Ни эшләп йөрисең монда? Кем сиңа буровойга керергә рөхсәт итте?

— Мин синең белән сөйләшмим! Мин үз эшчем белән сөйләшәм!

— Син сөйләшмисең, ә кычкырасың. Кем ул сиңа, колыңмы әллә?

Кадермәтнең тыныч кына әйтелгән сүзләре Галләмне тәмам чыгырыннан чыгарды:

— Эшкә аяк чалучылар! Саботажниклар! Минем кешегә тотынырга не имеете право! — Кадермәтнең җилкәсе аша үрелеп, Камилгә бармак янады.— Кайтмый гына кара, эшне генә өзеп кара!

— Бармыйм,— диде Камил, тискәре малай кебек үҗәтләнеп.

Итек балтырына камчы белән суга-суга, Галләм йөгереп диярлек буровойдан чыгып китте.

## 13

Зөбәеровның күңеленә аеруча хуш килгән бер нәрсә бар — ул да булса, юл уңаенда хатлар алып кайту. Бу юлы да шулай булды.

Буровойга туктаганны да көтмичә, кешеләр мастер машинасына ташланды.

Зөбәеров кайсын биетеп, кайсыннан биергә вәгъдә алып, хатларны өләшеп чыкты.

Соңгы хат Кадермәткә иде. Зөбәеров конверт тышындагы эре хәрефләр белән басылган адреска карап торды да хатны иясенә сузды.

— Бу хат биетеп бирә торганнардан түгел... Мәхәббәт хаты,— дигән булды.

Кадермәткә килгән бу хикмәтле хат белән бораулаучылар да кызыксынмакчы булганнар иде, ләкин госпиталь мөһере сугылган конвертны ачып, кечкенә кәгазьдәге бер-ике җөмләне уку белән Кадермәт аны ертты да читкә атты. Кискен борылды, аксаклап чатырына китеп барды.

— Холыкларын сатып алырсың акчага! — диде Зөбәеров аның артыннан.

Кадермәт Имаметдинов исеменә шулай һич көтелмәгән урыннардан «мәхәббәт хатлары» килгәләвен һәм алар хат иясен яман борчуга салуын беләләр иде инде бораулаучылар. Бригадада Кадермәт эшли башлаган көннәрдә аны прокурор, тикшерүче янына чакырган ниндидер кызыл тышлы хатлар килде. Имаметдинов начальнигын кыйнаган булган, имеш. Судтан котылып, акланып кайтты. Күңелле, тыныч кына эшли башлаган иде — хатыны аерылышу өчен судка бирде. Кияүгә чыкмакчы була икән, имеш. Хәләл җефете белән никахны өзеп кайтуга госпитальдән хатлар яза башладылар. Дәваланырга кирәк икән Имаметдиновка...

Моңа кадәр дә үзенең вахта житәкчесеннән куркып, аңарга төрле шикләр белән карап йөргән Еланский, Кадермәт чатырына кереп киткәч, Миргазиянның кабыргасына төртте:

— Сиздеңме? Әллә тикмәгә генә кызыл печатьле хатлар язалар дип уйлыйсыңмы? Әйтәм бит, нинди булса да гаебе бар!

— Авызын ачса, үпкәсе күренеп тора, нинди гаебе булсын аның?

— Булмаганга шулай төн буе йөренеп чыга кеше! Ишетеп торабыз бит караватында ничек бәргәләнеп ятканын!

— Я, баш ватма. Киттек йокларга... Үзе теләп алган чир түгел бит. Сугышта контузиядән шулай калган...

— Спорт белән шөгыльләнсен иде ул, бәлки, бетәр иде чире... Честное слово, куркам мин аңардан...

Еланский белән Миргазиян озак кына сөйләшеп, чатырга соң гы күшегеп кайтып керделәр. Керделәр дә, ут та алмыйча, тиз генә ятак рына чумдылар.

Еланский одеял астыннан, куркып, караваттагы Кадермәт шәүләсе карап ятты. Кадермәт хәрәкәтсез генә уйланып утыра иде. Торып экр генә чишенә башлады. Озак чишенде ул. Фуражкасын салды да тәмә кабызды, ботинкаларын салды, графиннан су агызып эчте. Чишен беткәч тә карават тирәсендә нәрсәдер эшләп йөрде.

«Гимнастика ясасын иде, һич булмаса...»

Күрше чатырда яшәгәч, Зөбәеров белән Рәйсә дә Кадермәтн сулышына кадәр ишетеп торалар. Кадермәт, бичара, кайчакта төнн бүе борсаланып, уфылдап, йөреп чыга. Кайбер төннәрне, әллә саташь әллә авыруы шундый булып: «Мин әле исбат итәчәкмен!», «Күрсәте мен әле мин!» яки «Безнең урамда да бәйрәм булыр!» кебек сүзл сөйләнеп йөргәнен дә ишеткәннәре бар.

Кем нәрсәгә юрый бит. Сапарбай: «Бума чире булмагае, гой, д Авылдан берәр им-томчы карчыкны алып килеп өшкертеп кара га кирәк»,— дип киңәш итә. Еланский аның бу кыланышларын спо белән шөгыльләнмәүдән күрә. Фәрхетдин исә: «Кызлар белән танышт рырга кирәк Кадермәтне. Хатын-кыз күрмәгән кешедә теләсә нинд авыру барланырга мөмкин»,— ди. Кем ничек уйлый бит.

Рәйсә Кадермәттәге нерв галәмәтләрен килгәч бер күрүдә үк сизг иде. Утырганда аякларын тик тота алмый — селкеп тора. Кулын кә куярга белми — гел кесәсендәге папиросын капшый. Бармаклары д гармунда уйнаган төсле итенәләр. Сөйләшкәндә еш кына тотлыга, ирс читләре калтырый.

Икенче килүендә (разведчиклар Ромашкинодан Карабаш кырын күченгән иделәр) Кадермәтнең күптән түгел судта булуын ишете гаҗәпләнде Рәйсә. «Участок начальнигын кыйнаган өчен», диделә Фазыл да булган судында. Кыйнамаган, якасыннан гына алган икә «Мин булсам, биллаһи, тукмар идем әле»,— дип сөйләде Фазыл.- Бригадасына кеше туплый бу, өйрәтә, ә тегесе алып китеп башка брига даларга бирә икән». Ни генә булмасын, Кадермәт акыллы эшләмәгән кызган. Сугыштагы контузиясен исәпкә алып, штраф салганнар Кадер мәткә. Җитмәсә, «хезмәт дисциплинасын бозган өчен» дигән пункты да, ни өчендер, көчендә калдырганнар.

Кадермәтнең холкы тагын да начарлангач, бер килүендә Рәйсә боль ница белән киңәш иткән иде. Врачлар Имаметдиновны хәрби госпиталь гә җибәрергә булдылар.

Бу башбаштаклыгы өчен Фазыл Рәйсәне ачуланды. Һич кирәкмәгән гә бригада эшенә тыгылып йөрисен, диде. Кадермәтсез мин нәрс эшләрмен, кем белән бораулармын, дип тиргәде.

Менә хәзер Кадермәтне госпитальгә чакырып язалар. Бармый, кире беткән нәрсә. Рәйсәнең яхшылык итәргә теләвен дә үзенчә аңлаган. Бер көнне трусик белән майкадан калган Кадермәт чатырыннан чыкты да күкрәгенә суга-суга:

— Син мине бригададан төртеп чыгарырга исәпләденме! — дип, ажгырып Фазыл өстенә килә башлады. Килеп тә житте, кисәк борылып тирән җәрәхәт эзләре калган сыртын чәбәкләргә тотынды: «Бу снаряд, пуля эзләрен эштән куылу өчен алдыммы мин! Я, әйт! Я, әйт!»

Төрле хәрәкәтләр ясап, кемнәрнедер каты сүгеп, усал янап бер-ике минутлар котырды Кадермәт. Палаткасына кереп Миргазиян белән Еланскийны куркытып торгызды, аларның баш очында өзлексез йод рыкларын уйнатты, истерикларча кычкырып төкерекләрен чәчте.

Бераздан басылды үзе. Караваат башына элгән чалбарын алып кидс, кесәсендә йөреп таушалган папиросын алып кабызды. Шунарчы эндәш-

ми тору яхшы — моны егетләр бер генә түгел, әллә ничә сынаганнары бар икән.

Иртән үзе гафу үтенергә кергән.

— Әйттем исә кайттым, госпитальгә бара күрмә, сиңа бары тынычлык кына кирәк, дип, Рәйсә үз тәкъдименнән үзе үк ваз кичте.

Һай, катлаулы да соң бу кеше дигәнең! Аның холкына, аның гадәтләренә бер генә ачкыч та табып булмый икән. Институтта ничә еллар кеше организмы турындагы фәнне укып, кеше психологиясен өйрәнеп тә бернәрсә белмәгән икән Рәйсә. Әллә авыр табигый шартларда аңлармынмы дип уйлаган иде — анда да төшенеп булмый икән бу адәм баласына!

Ерак барасы түгел: бу көнгә кадәр бергә торган үзенең Фазылын да аңлап бетерә алганы юк әле Рәйсәнең. Ромашкинога килеп, Фазылның эшен күргәч коты очты. Декабрь суыгында, чатлама салкында җир астыннан фонтан булып су бәрә. Бораулаучыларның да, Фазылның да киемнәре бозланып каткан, өсләре пыяла кебек ялтырап тора. Ә яка, бүрек асларыннан болыт кебек пар бәреп чыга... Фазыл чыдамас, бу эшне ташлап качар, дип, өметен җуйган иде Рәйсә. Ни әйтсәң дә, ул интеллигент баласы, нәзберек һәм юка иде. Студент чагында тамакка тия дип бер вакытта да ул салкын су эчмәде, морожный-фәлән ашамады. Күршегә кибеткә чыкканда да колагын өшетмәс өчен бүреген төшереп кияр, шарфын урар һәм пальто якасын күтәреп куяр иде.

Кызык соң бу кеше дигәнең. Бернинди медицина законнарына да, тормыш кануннарына да буйсынмый икән бу шәхес. Кайчан, нинди шартларда ничек булырга кирәк икәнен үзе генә белә, үзе генә хәл итә ала икән кеше.

Шунысы гаҗәп: бер буровойда эшләп, бер аланда, рәттән тезелеп киткән бер чатырларда яшәсәләр дә, разведчикларның барысы бергә җыелган чагы сирәк була. Сменалы эш шулай. Бер вахта буровойга килгәндә икенчесе кайтып ял итәргә, дөресрәге — сигез сәгать буена йокларга, бу чакта өченчесе торып, юынып, тамак туйдырып вахтага әзерләнергә тиеш. Асылда шул өченче вахта гына буталып йөри лагерьда. Аның кешеләре эш юктан авылга да барып кайталар, урман-кырларда булалар, җыелып карта уйныйлар, үз кирәкләре белән дә шөгыльләнәләр. Әгәр дә вакыт-вакыт скважинаның тирәнлеген яки юнәлешен үлчәргә килүче геофизиклар булмаса, бораулаучылар барысы бергә очраша да алмаслар иде.

Биш йөз метр тирәнлеккә җиткәч, мастерның чакыруы буенча, скважина көпшәсен тикшерү һәм разведчикларга күрсәтмә бирү өчен геофизиклар килде. Келәт кадәр машиналарындагы кеше биеклеге кәтүкләрен сүтеп, чыбык белән приборларын скважинага төшергән арада аландагы лагерь гөж килде. Бораулаучылар бер-берсен бүген генә күргәннәр диярсең: сөйләшеп-көлешеп, шаярышып туя алмыйлар.

Чатыр алдына Сергей — гитарасын, Габбас хромкасын алып чыккан, Мишаны урталарына кысканнар да икесе ике яктан көй сайлыйлар. Тиешле кылын тапмаган булып, җырга сусаган Кубракны Сергей юри интектерә. Ниһаять, Миша калын көр тавыш белән җыр башлый:

Взяв я бандуру
Тай заграв, що знав,
Через ту бандуру
Бандуристом став.

Бу баштa егетләр учак янына, Валентин тирәсенә җыелганнар. Ул күптән түгел генә телефоннан Ташлыярга шалтыраткан икән, анда геологлар нефть эзләргә килгән, имеш. Валентинның әйтүе буенча, араларында хатын-кызлар да бар икән, шуларның берсе, һичшиксез, Валя булырга тиеш...

— Ташла, зинһар, Тин-Тиныч, юк белән хыяллануыңны,— диләр ана.— Ничә ел эзлисең бит инде!

Валентин утка коры чыбык-чабык ташлый, кулындагы озын агач кашыгы белән пешәргә куйган шулпасын бутап ала.

— Ташламый торсын! Иртәгә вахтадан соң Ташлыяр мәйданына китәм. Валя шунда. Бүген төшемдә дә күрдем хәтта...

— Шулай да кызлар белән заочно танышу эш түгел инде! — ди Тин-Тинычның бу гадәте белән килешмәгән Фәрхетдин.— Син аның өчен янган, көйгән буласың, бәлки, ул тишекле бер тиенгә дә тормыйдыр?

Тин-Тиныч үпкәләми, күккә башын ташлап, һаман бер сүзне кабатлый:

— Юк, белмисез! Аның күзләренә бер карау — бер гомер...

— Ярый, күзләре матур да булсын, ди. Ә чукрак булса? Анысын рәсемгә төшереп булмый бит!

— Чукрак кеше геолог булмый...

— Ә холкын каян беләсең? Бәлки, ул аждаһадан да яманрактыр?

Фәрхетдин Тин-Тинычка кул селти дә башкаларга карап сөйләп китә:

— Менә мин хезмәттә чакта шушының кебек хыялый бер бәндә бар иде. Таныштыр да таныштыр авылыгыздагы бер кыз белән дип, һәр солдатның теңкәсенә тиеп бетә торган иде. Аптырагач, ахырда бер карт әбинең адресын биргәннәр мона. Бу: «Җаным, сине сөям, синнән башка тора алмыйм»,— дип тегенә сырлап-сырлап хат язган. Бераздан җавап килеп төшә моңа. «Рәхмәт, балакаем, хатыңны алгач илле яшькә яшәргән кебек булып киттем. Тагын яз, җавап көтәм»,— дип язган ди теге әби... Белеп булмый, бәлки, синең Валя дигәнең дә берәр әбидер.

Бу сүзләргә инде Тин-Тинычның чыдарлыгы калмый, җәһәт кенә тора да чатырына кереп китә, аннан таушалып беткән «Огонек» журналы алып чыга. Фәрхетдиннең борынына төртә:

— Менә кара, кыз булмыйча атаң башымы бу?

Җыелганнар барысы да рюкзак аскан, косынка бәйләгән кызны карарга тотыналар. Журнал кулдан-кулга күчә. Һәркемнең мактау сүзе әйтәсе килә:

— Шәп кыз бу. Янып-көеп йөрсәң дә урынында.

— Тормышларын гына әйт! Минемчә, бу затлы нәселдән.

— Карасана, башны ничек текә тота!

Верховой Нәҗип авиациядә булган егет, ул үз күзлегеннән бәя бирә:

— Фаралары шәп моның! Шассилары да нык булай... Фюзеляжы да ярыйсы күренә...

— Анысы ул кемгә ничек бит...— Фәрхетдин үзен унайсыз хәлдән чыгару өчен тагын бер мисал таба.— Читтән торып танышуның да үз тәме бардыр, күрәсең. Шулай, хезмәттә чакта минем дус танышты бер кыз белән. Газетада күргән дә исемен, хат язган моңа. Нигә танышмаска: теге алдынгы тукучы, комсомолка, житмәсә, бер үк шәһәрдә яшиләр икән. Киләчәге дә бар бит әле аның! Шулай итеп, хат языша башладылар болар. Тора-бара бер-берсен яратышып та киттеләр бугай. Рәсемен җибәрде егет. Моның да фотосын соратты. Килде хат. Хат эчендә фото да бар иде. Алып караса! Һуштан таеп егыла язды егетем. Күрсәгез менә кызның кыяфәтен! Бите табак, борыны чөгендер, чәчләре мич пумаласы, авызы иләк. Ә күзләре! Берсе мәгърибка карый, мин сина әйтим, икенчесе — мәшрикъка! Шуннан тынды хат язудан бу. Нәрсә дип сорагыз сез: бер елдан соң отпускага кайтып килгән иде бу солдат. «Киногa барган идем, бер кыз туктатты,— дип сөйли.— Туктатты да: фәлән-фәләнов сез буласызмы? — дип сорады,—

ди. «Мин булам», дип әйттем,— ди.— Алайса, сезнең белән хат алышкан кыз ул мин булам инде»,— дип әйтте ди теге кыз. Әйтте дә, ди, китеп тә барды, ди. Тагын һуштан таеп егыла язган солдатым. Шундый да чибәр, кашыкка салып йотарлык ди бу кыз. Аргыннан йөгергән. Куып җиткән, бер генә минутка булса да туктап сөйләшүен үтенгән, әмма кыз әйләнеп тә карамый икән. «Мин сине сынар өчен җибәрдем ул фотоны, сиңа кеше кирәкми, сиңа таш курчак кирәк икән, алайса, эзлә инде», дип әйтә ди». Менә, дуслар, шулай да була бит ул дөньяда!

Фәрхетдиннең бу хикәясеннән соң Тин-Тинычның күңеле күтәрелеп китте. Үзе дә абайламастан:

— А как же! — дип куйды.— Минем Валям да нәкъ шулай эшләр иде...

Бу вакытта Зөбәеров, үз чиратында, Тин-Тинычның үтенүе буенча, телефоннан Ташлыяр белән сөйләшә, ә Кадермәт, күршесендә күлмәген ямарга утырган килеш, тегүеннән туктап, аны тыңлап тора иде.

— Алло, Ташлыяр? Ташлыярмы бу? Кем әле бу? Авыл советы председателе? Сездә анда геологлар тора, диләр, дөресме? Валя исемле кызны белмисезме? Ничек инде председатель була торып белмисез?

Фазыл янында баласын күтәреп Рәйсә басып тора, иренең сүзләренә куәт биргәндәй, селкенеп-селкенеп ала, йөзе, авызы белән ишарә ясый.

— Син анда берәр геологны таптыр,— дип пышылдый, Зөбәеровның колагына иелеп.

— Геолог-фәлән күренмиме ул тирәдә? Юк? Аларның берәрсен чакыртасы иде бит. Ерак?

— Чакыртсын, чакыртсын! — ди Рәйсә, боерык биргәндәй.

Зөбәеров холыксызланып трубканы куя.

— Син команда биреп торма әле!

— Ничек инде, бирмә! Кешенең язмышы хәл ителә! Мин синең урыныңда булсам, машинамны биреп, эзләргә җибәрер идем Тин-Тинычны.

— Ә аның өчен кем бораулар? Синме? Үземме? Сапарбайны ялга җибәрүче дә син!

Күлмәгендәге ямавы белән энәсен асылындырып чатырга Кадермәт килеп керде. Керде дә ишек төбендә туктап калды. Рәйсәдән оялып, йонлач күкрәгенә карап алды.

— Гафу итегез. Әгәр кирәксә, Тин-Тиныч өчен вахтага үзем чыгам. Җибәрик аны Ташлыярга.

Кадермәтнең керүен дә, аның мондый сүзләрен дә көтмәгән Зөбәеров каушап калды.

— Нәрсә дисең?

Кадермәтнең шәрә күкрәге калтыранып китүдән шуны сизде Зөбәеров: теге көнне Валяны күрүен Рәйсәгә сөйләгән иде бит, димәк, Кадермәт тә аны ишеткән. Менә бит ул кая китә хатыныңа чатырда сер сөйләү!

— Юк, Кадермәт, күрмәдем мин ул Валяны. Шуңа охшаттым гына. Бәлки бөтенләй ул түгелдер... Мин үзем дә геологларны эзләп шалтыратып ята идем әле...

— Соң, барып кайтсын инде. Сиксән-туксан километр ара нәрсә тора?.. Машинаның эче төшеп калмас.

Дөресен әйткәндә, Валя булмадымы икән? дигән уй Зөбәеровның үзенә дә тынгы бирми иде.

— Барсын,— дип кул селтәде мастер.— Ул Тин-Тинычтан котылып та булмас...

Кадермәт, энәсе бар икәнен онытып, ямалып бетмәгән күлмәген киеп куйды.

— Хәзер чакырам мин аны.

Ул арада бораулаучылар арасына кереп кысылган хәлдә, ни йөгерә, ни атлый алмый Валентин да килеп җитте. Ул үз аягы белән дә килә алмады бугай — аны кайсы култыгыннан, кайсы чалбар каешыннан тотып очыртып алып килделәр.

— Менә нәрсә,— диде Зөбәеров.— Син ишеткәнсең дә икән. Анда Ташлыярда ниндидер геологлар йөри, ди. Барып кайт әле син анда. Бәлки Валяң да шундадыр...

— Валямы? Ташлыярдамы? Барып кайтыргамы? — дип мәгънәсез сораулар тезеп китте Тин-Тиныч. Шунда ук мазутлы киемнәре белән чатыр янында торган машинаның кабинасына керә дә башлады.

— Дегетле киемнәрең белән бармыйсыңдыр бит, Тин-Тиныч? — дип туктатты аны Рәйсә.

Секунд эчендә Тин-Тиныч җирдә иде:

— Төшәргәме? Киенергәме? Яхшыракны дисеңме? — Ут капкандай чатырына йөгерде, машинаны кабызганчы, безкозыркасындагы тасмаларын җилфердәтә-җилфердәтә, диңгезче формасыннан чабып килде. Рәйсә моны да ошатмады.

— Кит, Тин-Тиныч, башка кием тапмадыңмы?

— Бу бит минем парадный форма, Рәйсә!

— Булса соң? Ничә ел эшләп кием дә ала алмаган, булдыксыз дияр... Әнә, үзеңнеке юк икән — Фазылныкын ки!

— Юк, аннан Валя танымас! Мин бит аңа рәсемне шушы киемнән җибәрдем...

— Ярый инде, алайса, юлчының юлда булуы хәерле!

Фәрхетдин үтә ялагайланган булып Валентинга машина ишеген ачты, баш иде дә аны тупас кына кабинага төртеп кертте:

— Кара аны, Тин-Тиныч, Валяны тапмыйча кайтып керәсе булма!

— Иртән сәгать алтыда монда булырга! — дип кисәтте шоферны Зөбәеров.

Чатырга кергәч, Рәйсә көрсенеп алды:

— Таба алса гына ярар иде...

— Хыял! — дип кул селтәде Фазыл. Өстәл янына килеп утырды, сумкасыннан язуларын алды.— Ярый инде, күңелегез булсын...

Тин-Тинычның Валяны табуына бик үк ышанмаса да, ул киткәч, Зөбәеровка җиңел булып калды. Ни өчен икәнен үзе дә төшенмәде. Бәлки кешеләргә яхшылык эшләү шулай күңелдә рәхәтлек тудырадыр? Ә бит әле аның күпме яшәп кешеләргә бер изгелек тә иткәне булмады. Теләде, ләкин итә алмады, тормыш гел кирегә генә сукалап торды. Тәпле, нигезле кешеләр туплап, бригадасын иң алга чыгарырга, бораулаучыларын данга күмәргә ничә ел хыялланды — булмады. Ул гынамы? Эштән куылган икәнен белә торып Кадермәтне эшкә алды. Комбайнчы икәнен күрә торып Мотгәрәйне алды. Ни тоҗырды мастер? Буровой дип бер пошынып караганы бармы аның? Һиһаять, Сапарбайдан ни файда чыкты? Менә хәзер көйләп-чөйләп Тин-Тинычны утыртып җибәрде кызы янына. Валясын тапса кайтыр дисеңме аны? Изгелек эшлим дип яманлык ясый түгелме соң Зөбәеров?

Мондый тәртипсезлекне, башбаштаклыкны күреп Ибраһим-Задә ни дияр иде икән? «Син мастер түгел — син арыш боламыгы,— дияр иде.— Әгәр син мастер икәнсең, таудан биек, кыяддан каты, диңгездән киңрәк колачлы бул!»

Фазылның борчулы уйларын Рәйсә бүлдерде:

— Син һаман күңелсез, Фазыл. Нәрсә уйлап борчыласың?..

— Болай гына...

— Юк, Фазыл. Син элек мондый түгел идең. Ярарга дип әйтмим, кемгә булса да охшарга тырышуыңмы бу... Әйе, әйе, Фазыл, чиновникларга охшарга тырышу!

— Юкны сөйләмә!

— Хәтерлисеңме студент чагыңны? Беренче тапкыр кичәгә килгән көнеңне, безнең торакны? Син анда чын Фазыл идең. Хәзер дә кайчакта ул Фазыллыгың чагылып китә — шаярганда, көлгәндә, бергә эшләгән иптәшләрең белән аралашканда...

Зөбәеров көлеп куйды. «Анда Фазыл идең, монда Фазыл түгел». Карап-күзәтеп кенә йөри бу очлы күз Рәйсә. Бер кайгысыз, хәсрәтсез булганга студент диләр аны. Ә Рәйсә бит үзе дә ул чакта болай акыллыланып мораль укымый иде...

Фазыл Рәйсә хәтерләп үткән кичәне искә төшереп алды. Күп еллар үзды бит аңа...

Нәрсәдән килеп чыккан иде соң әле бу очрашу? Әйе, нефть институтының тулай торагы белән медицина институтының торагы урам аша, кара-каршы гына иде. Медицина институтында бөтенләй диярлек кызлар, боларныкында егетләр генә торганга, торакның берсен студентлар «хатын-кыз монастыре», икенчесен «ирләр монастыре» дип йөртәләр иде. Кызлар белән егетләр биш ел буена тәрәзәдән генә карашып яшәделәр. Бер-берсенә керешеп йөрү, ходай сакласын, ике институтның тарихында да юк. Кызлар торагында шундый кырыс вахтерлар тора — бусагаларын атлауга якадан гына йолкып чыгаралар. Берниндн мылтыклы сакчың да, явыз мәэмәең да кирәкми!

Яңа ел көнне шулай да үттеләр кызлар торагына Фазыллар. Ничек диген әле: янгынчылар булып!

Ул көнне институтта «Кыз урлау» комедиясен куйганнар иде. Анда янгынчылар булып уйнарга кирәк. Студентлар бу кичне янгынчылардан кием алып тордылар. Спектакль әкәмәт яхшы чыкты. Бигрәк тә пожарник Мифтахны уйнаган Зөбәеровны ошаттылар тамашачылар. Шунда үз уеныннан үзе кәефләнеп киткән Фазыл иптәшләренә мондый тәкъдим кертмәсенме: «Әйдәгез, шушы киемнәр белән кызлар монастырена үтәбез!» Идеяне хуп күрделәр. Сайларга дип алып кайткан кием берничә иде — киделәр дә кереп киттеләр. Вахтерлар янында туктап тору да юк. «Тикшерәбез!» — янәсе.

Фазылның биш елга якын кичләрен күзәтеп утырган тәрәзәсе, шул тәрәзә каршына гына куелган караваты, ул караватта һәрвакыт укып утырган кызы да бар иде инде. Кайвакыт кыз да тәрәзәгә килә, һич тарсынмыйча Фазыллар ягына карап тора иде. Хәтта аларның күзләре дә очраша сыман тоелып китә иде Фазылга. Ул бүлмәдә торучы биш-алты кыз арасында иң зифа буйлысы һәм ачык күренеп бетмәсә дә, иң чибәре дә шушы кыз иде бугай.

Егетләр, ишек шакып, туп-туры шушы бүлмәгә керделәр. Керсәләр — бер төркем кыз нәкъ балаларча кулга-кул тотынып, чыршы тирәли әйләнеп, биешеп-җырлашып йөри. Бизәнгәннәр-ясанганнар — ак күбәләкмени!

Башта — егетләр ләм-мим. Чыршыны караган булалар, чыбыкларын, лампаларын тикшергән булалар — ут-күз чыгарлык түгелме, янәсе.

Ә Фазылның күзләре теге зифа буйлысында. Тәрәзә аша бик ачык күренмәгән иде — төскә-биткә дә ярыйсы гына икән. Тик борыны бәләкәйрәк.

— Нигә үзегез генә бәйрәм итеп ятасыз? Нигә егетләрегез юк? Ут чыкса, кем җавап бирер? — дип бәйләнгән була Фазыл.

— Безнең торакта юк шул алар! — дип, беркатлы җавап бирәләр күрсенеп кызлар.

— Каршыдан чакыртырга кирәк! Анда егетләр җитәрлек!

— Чакырыр идек тә бит, абый, кертмиләр аларны! — дип зарланырга тотына кызлар.

— Димәк, булдыра алмыйсыз! Ир-аттан башка ут һәм электр белән шаяру катгый тыела! Штраф сезгә!

Фазыл кесәсеннән блокнот чыгара да кызларның исем-фамилияләрен яза башлый. Аңа, әлбәттә, үзе тәрәзәдән күзләгән кызның гына исемен белү кирәк.

— Синең исемең ничек?

— Рәйсә,— дип куркып кына җавап бирә элеге кыз.

Башкалар да куркуга төшәләр.

— Абзый, язма, штраф сала күрмә, без белмәдек, моннан соң алай эшләмәбез, каршы торактагы егетләрне чакыртырга тырышырбыз...

Тыела алмыйча көлеш китә егетләр арасында. «Менә без инде ул каршы торак егетләре»!

Баштан авыр тимер каскалар, өстән калын брезент курткалар салып ташлана, ирен өстеннән мыеклар кубарыла. Яп-яшь студент булып кала «пожарниклар».

Кара син аны, Фазыл да ул вакытта бөтенләй бала-чага, җилбәзәк бер егет булган икән лабаса! Аңламый: шуның өчен яратканмы аны Рәйсә? Юк, Фазыл хәзер ничаклы гына тырышса да, алай була алмас инде. Мастер кешегә җилбәзәкләнеп йөрү килешми...

Фазылның уйларын дәвам иткәндәй, Рәйсә әйтә куйды:

— Син яшь чакта күңелле, җор егет идең. Институт бетереп, мастер булып алгач та жен алыштырып куйгандай булды үзеңне!

Өстәлгә аш әзерләп куйды Рәйсә, сүзсез генә үзе дә килеп утырды, ләкин кашыкка кагылмады.

— Ә син? — дип сорады Фазыл, хатынының ашамый утырганын күреп.

— Пешекче ашның исеннән үк туя,— дигән булды Рәйсә. Бригаданың уртак казаныннан аерылып, үзләре өчен генә пешерә башлаганнан бирле йөрәгенә ятмый иде бу аш. Кешеләр шаярыша-көлешә табында бергә утыра, ә алар, кемнәндер курыккандай, яшереп ашыйлар. Эшчеләре белән бергә утыру Зөбәеровның авторитетын төшерә. Ярый әле моны бораулаучылар үзләренчә аңлыйлар. Рәйсә аларга: «Фазылның ашказаны авырта, диета кирәк»,— дип зарланган булган иде.

Күрәсең, ялгыз ашау Зөбәеровның үзенә дә күңелсез, ул тәлинкәдән шулпаны бутап, чемченеп кенә утыра.

Алдындагы ашны ничек кенә ашап бетерергә тырышмасын — булмады. Урыныннан торып, ишек төймәсенә эленгән курткасына үрелде мастер.

— Буровойга киттем. Геофизиклар эшләрен төгәлли торганнардыр.

## 14

Төшке аштан соң лагерьга көтмәгәндә Сапарбай кайтып төште. Буровойга торба ташучы машинага утырып кайтты ул һәм, иптәшләренә күренмәскә тырышып, чатырына да арт яклап, яшертен генә керде.

Егетләр, бәхеткә каршы, вахтага киткәннәр иде. Чемоданын куеп, Сапарбай чишенмичә генә караватына ятты, башыннан ук одеалы белән төренде. Болай ул үзен беркем дә яшәми торган далада, төнлә ялгызы кебек хис итә иде. Әйе, хәзер аның беркеме дә юк һәм аңа беркем кирәкми дә. Алдадылар Сапарбайны. Мәкерле Сөенбай шушындый караңгы дала уртасында утыртып калдырды аны. Сөенбайның кем икәнен белә торып алданды. Ишеткәне дә бар иде. Сапарбайның мәрхүм атасы исән чагында әйтә торган иде: «Сөенбайга ышанмагыз. Аның авызын җен суккан, ул дөрес сөйләми»,— дип. Хак икән...

Күп нәрсәне элек аңлап бетермәгән икән Сапарбай: бертуган энесе фронттан яраланып кайткач, ни өчен Сөенбай иртәле-кичле боларга керен, энесенең хәлен белешеп йөргәнен дә, энесе үлмәс борын ук кешеләргә ни өчен кабер казырга әйтеп йөргәнен дә, Сапарбайның этисе

үлгәч, ни өчен ике семьяның малларын бергә кушканын да, куйлар көткәндә үзе урынына Сапарбайны калдырып, базарга киткәннәрне һәм киткән чакта чыпта капчыкка ни өчен колхоз куйларын тыгып китүләрен дә — берсен дә төшенмәгән икән...

Ул чакта малай гына иде Сапарбай. Ә менә үсеп буйга житкәч, Сөенбай әкәсенең сүзенә карап, ни өчен читкә чыгып китте икән Сапарбай, ни өчен аңа акча жибәреп яткы икән? Нәрсә дип хатны турыдан-туры Рәйхананың үзенә язмыйча, Сөенбай әкәсенә жибәрде икән?

Яшьтән үк Сапарбайның күңеленә Сөенбай әкәсе кабатлап торган «васыять» сүзе кереп калган иде. Ул васыять дигәннәре изге, бер дә бозарга, үтәми калырга ярамый торган нәрсә икәнен белә иде, шул васыять хакына эшләде боларны Сапарбай...

Эштән кайткач, Фәрхетдин белән Нәжип Сапарбай караватында башыннан төренеп яткан кешене күреп, кем дип әйтергә дә белми тордылар. Кычкырып сөйләшеп кергән жирләреннән шып булдылар, карават янына әле берсе, әле икенчесе килде:

— Сапарбай дисәң...

— Булмас. Аның киткәненә бер атна да үтмәде түгелме соң?

— Кем булсын, Сапарбай инде! Әнә, мәче баласы кебек бөгәрләнеп йоклавын гына кара! — Фәрхетдин иплән кенә одеялның почмагын күтәрде.— Билләһи, Сапарбай! Ышанмасаң, килеп кара!

Томаланып ятудан саташып торды Сапарбай. Имеш, ул дөм-караңгы далада жылкы көтә, аның янына атка атланып Васыять килгән. Сөенбай әкәсенә дә бик охшаш, имеш, ул: аның кебек кыек авызлы, эре тешле. Әйтә: «Синең Рәйханаң миндә, куып житә алсаң, бирәм»,— ди. Һәм үзе Сапарбай тирәсендә ут уйнатып чаптырып йөри. Уянып киткәндә шул Васыятьне куып йөрүе иде Сапарбайның. Ул манма тиргә баткан.

— Нихәл, исән-сау гына кайттыңмы, Сапарбай?

Сапарбай әле һаман йокысыннан айный алмый тора иде.

— Аманмы сез? Аманмы? — дия-дия, башын селкеп утыра бирде.

— Нәрсә, Сапарбай, әллә даланңы таба алмый кайттыңмы?

— Дала урынында, кая китсен...

Хәлен Сапарбайның сөйлисе килми иде. Нәрсә юкка тел әрәм итәргә? Алар соң аңлыйлармыни аны? Көләргә, үртәргә генә беләләр.

— Ни булды соң, Сапарбай, әллә авырып кайттыңмы?

— Юк, бернәрсә дә булмады,— диде Сапарбай чатырның караңгы почмагыннан. Ләкин тел төбеннән үк аның белән күңелсез хәл булганы сизелеп тора иде.

Фәрхетдин үпкәләгән булды.

— Сөйләргә теләмисең — димәк, дус итмисең... Ә без монда синең өчен ут йотып торган булабыз...

— Нигә кайгырырга?

— Алай димә, Сапарбай,— дип, үзенчә мораль укып китте Фәрхетдин.— Синең язмышың, синең кызыңның язмышы, кем әле исеме? Рәйханамы? Әллә аның язмышы безне кызыксындырмый, борчымый дип беләсеңме? Әнә, Тин-Тиныч хәтта китапта укыган Онегин өчен дә кайгырып ятты. Ә кем соң ул Онегин! Бер дворян баласы! Ә Татьянасы кем? Борынгы бер дворянның иркә бер кызы!

— Минем кызым юк инде,— диде Сапарбай, көрсенеп.— Бетте инде ул Рәйхана... Поездда кайтканда ук күңелем сизгән иде. Нәрсәгәдер менә йөрәк әрнеде. Юк, әле аңа кадәр үк, моннан киткәнче үк туган ягымда яман эш барлыгы тоела башлаган иде...

Чишенеп урынына яткан Нәжип тә торып утырды.

— Шуннан, шуннан?

— Үзегез күреп тордыгыз, мин, дивана, кышлакка ай саен күпме акча салып тордым. Ашарга да калдырмый идем бит кайчакта. Көлде-

гез, уртәдегез, мине «комсыз», «җайдыгыш» дип атадыгыз. Түздем, барысына да түздем... Я, нәрсәгә сөйләп ятам соң мин боларны! Барыбер берни аңлыйсыгыз юк!
— Бер башлагач сөйлә инде...
Сапарбай тирән итеп көрсенеп алды да тагын дәвам итте:
— Ә нигә салдым ул акчаларны — берегез дә башына китерә алмады. Калымга дип салдым мин ул акчаларны!
Нәҗип бүлдерде:
— Нәрсә соң ул «калым»?
— Әйтәм бит — белмисез! Юк андый җола сез нугайларда! Карал-Төбәдә минем ярәшкән кызым бар иде. Рәйхана исемле. Шуңа дип җыйдым мин аны. Әтием урынына калган Сөенбай әкәмә сала бардым. Ә явыз Сөенбай алган да ул акчаны туздырган! Ух, ул җәлладны!..
— Кая туздырган соң шул кадәр акчаны?
— Сигез бүлмәле таш йорт салдырган, мал-туар алган...— Сапарбай башын тотып кычкырып җибәрде:— Ичмаса, бер генә тапкыр Җаксыбай катына барып Рәйхананы күрсә иде! Йок! Мин язган хатларны да бирмәгән! Ә үзе һаман хат язган була: «Рәйханаң сагына, зарыгып көтә. Калымга акчаң гына җитеп битми!» дип. Ә мин, дивана, аның саен арттырам акча салуны!
— Нык алдангансың икән, туган, нык!
— Ә кәләшең Рәйхананы күрдеңме соң? — дип кызыксынды Фәрхетдин.
— Бардым Карал-Төбәгә...— Сапарбайның төшенке тавышыннан ук юлы уңмаганын аңладылар.— Бардым. Туп-туры тирмәләренә кердем. Тып-тын. Тирмә эче шып-шыр. Тик Җаксыбай карт кына утыра бер почмакта моңаеп... Йөрәгем өзелеп төшкәндәй булды. «Рәйхана кая?» — дип сорыйм. «У-у, Рәйхана китте!» — ди. «Кая китте?» «У-у, ерак китте. Безне ташлады. Кияү Алма-Атага алып китте!» — ди. Соңыннан мәгълүм булды. Рәйхана мине көткән, көткән дә, хәбәр-хәтер булмагач, моннан бер ел элек, ялга кайткан офицерга ябышып чыккан...
— Менә сиңа калым! — диде Нәҗип, шаккатып.
Чатыр эче беразга тын калды; күрәсең, бичара Сапарбайның хәсрәтен уртаклашып яттылар. Егетнең хәлен җиңеләйтергә теләп булса кирәк, Фәрхетдин шаяруга күчте:
— Ахмак син, Сапарбай. Миңа әйткән булсаң, биллаһи дип әйтәм, бер тиенсез дә сиңа менә дигән кыз табып бирә идем! Күп булса бер ярты куяр идең...
— Рәйхана бит ул минем ярәшкән кызым иде...
— Азмыни дөньяда ярәшүләр дә сөйләшүләр? Һай, бичара! Минем, мәсәлән, бер кечтә икешәр-өчәр кызга вәгъдә биргәнем булды. Аларга өйләнә китсәң!..
Фәрхетдиннең бу сүзен Нәҗип килештермәде:
— Бар да синең кебек алама булмый! Я, Сапарбай, кайгырма, без сиңа менә дигән татар кызы табып бирербез!
Сапарбай борылып ятты. Хәзер аның кызлар турында сөйләшәсе дә, ишетәсе дә килми иде бугай.
— Тин-Тиныч кайда? — дип сорады, Валентинның юклыгын әле генә күргән кебек.
— Ул, дустым Сапарбай, синең кебек җил куып йөри инде... Кызын эзләргә китте. Кайдадыр Валя исемле бер кыз бар ди бугай.— Моны ачыктан-ачык үртәп әйтте Фәрхетдин.— Тин-Тиныч урынына Кадермәт эшләде, синең өчен Нәҗип белән миңа көчәнергә туры килде. Тәмам тузылды вахта...
Нәҗип әкрен генә гырылдап китте, Фәрхетдиннең дә күзен әчеттереп йокы тырный башлады, ә Сапарбай, төн кунагы төсле, һаман сорау артыннан сорауны яудырып кына торды, гүя ул монда еллар буе бул-

маган иде: «Сергей аманмы?.. Миргазиян ни хәлдә?.. Еланский һаман гер белән йөгереп йөриме?.. Мачтырның кәефе ничек?»

Сапарбай капыл гына торып утырды:

— Рәйсәхан минем турыда бер нәрсә дә сөйләмәдеме?

Сапарбайның тел төбен аңлый иде Фәрхетдин. Рәйсәдән алып торган акчалары өчен борчыла, аны белгәннәрдер, иптәшләре көләрләр дип курка.

— Юк, сөйләмәде. Йоклыйк булмаса...

Инде Фәрхетдин тәмле итеп изрәп бара иде, Сапарбай тагын уятты:

— Буровой ничек соң? Яхшы эшлиме? Ничә метр төштегез?

Бу сораулар Фәрхетдиннең күзен шар ясадылар. Нинди яңалык бу? Тора салып Сапарбай буровой белән, метрлар белән кызыксына башлаган, үләрсең! Элек аның беркайчан да метр дип авыз ачканы булмады. Буровой эшләсә: «Ничә сумлык бораулан ды?» Ә тегенди-мондый сәбәп белән туктап калса: «Ничә сумлык тукталды?» Башка сорауны хәтерләми Фәрхетдин.

— Мастер гына ясап куясы бар хәзер сине, Сапарбай! — диде дә башыннан ук бөркәнеп ятты.

«Иртән Рәйсәханга бурычны түләргә, бик күп итеп рәхмәт әйтергә булыр,— дип уйланып ятты Сапарбай.— Ә менә Рәйхана турында нәрсә дияргә икән?» Сапарбай иртәгә Рәйсәнең иртүк Язтургайга фельдшер булып китәсен белми иде әле.



## 15

Зөбәеров бригадасы Язтургай мәйданында меңенче метрга житеп бара. Эшнең көтелмәгәнчә уңышлы атлавына, бу тирәнлеккә кадәр хәвеф-хәтәрсез төшүгә геологлар да, мастер Зөбәеров та, бораулаучылар үзләре дә ышанмыйлар иде. Бригада иң артта сөйрәлгән жиреннән конторада кинәт кенә беренчеләр рәтенә күтәрелде дә куйды. Зөбәеров исеме газеталарда күренә башлады, радиоларда телгә керде. Хәтта Кадермәт кебек аерым кешеләрне, Сергей Саакян, Тин-Тиныч вахталарын конторада үрнәк итеп күрсәтә башладылар.

Зөбәеровның алга чыгуын башка бригада кешеләре үзләренчә юрадылар. Имеш, директор Язтургай кебек жайлы мәйданны Зөбәеров бригадасына бүләк итеп биргән. Имеш, кешегә гел тәмуг кына димәгән, оҗмах та булырга тиеш.

Чыннан да яхшы мәйданга юлыктылармы, әллә вакытлы гына күренешме бу — геологлар һаман үз сүзләрен әйтергә ашыкмадылар. Алдан тикшеренүләрнең нәтиҗәләре бу мәйданда төрлечә булды бит. Мәсәлән, кыр разведкасы, җир кабыгының өске өлешен өйрәнеп, «Мәйдан продуктлы булырга тиеш, ул Ромашкино нефть ятмасының дәвамыдыр» дигән мәгълүмат бирде.

Алардан соң килеп, тау токымын төрле ысуллар белән геофизик разведка тикшерде. Гравиметрик ысул гаять сизгер приборлары белән катламның җир астында нинди формада ятканлыгын билгеләп, нефть юк, диде. Булса да аның запасы промышленность өчен әһәмиятсез икәнен, бораулаган чыгымнарын капларга да житмәячәген әйтте.

Магнитометрик метод кулландылар. Җиде кат җир астындагы хәлне аерата тиз тоя торган махсус приборлар тирәндә магнит массаларының бериш түгеллеген ачты. Димәк, нефть бар.

Ә менә сейсмик прибор үзен сәеррәк тотты. Коелар казып, ясалма шартлатулар белән үткәрелгән бу алым, җир асты дулкыннарын өскә актарып чыгарып, язып бирде: нефть булуы шикле.

Бар ышаныч электрик эзләнүләр ысулында гына иде. Геофизиклар,

токымнарның токны ничек үткәрүен кат-кат сынагач кына: «Нефть бар!» — диделәр.

Тикшеренүләрнең шушы икеле-микеле мәгълүматларыннан чыгып, геологларга Язтургай мәйданын «борауларгамы, юкмы» дигән нәтиҗә ясарга кирәк иде. Бораулаучылар өчен генә түгел, ил каршында гаять зур җаваплылык иде бу. Чөнки бер скважинаны бораулау гына да миллион сумнар белән бәйле. Ул миллионнар күпме мәшәкатьтән, күпме кеше көче, күпме энергия, күпме механизм сарыф ителүдән тора. Бораулаургамы, бораулмаскамы дигән мәсьәләне хәл иткәндә бер тәвәккәллек кенә җитми, монда күбрәк акылыңа, ышанычыңа һәм үзеңнең ниндидер бер эчке сизгерлегеңә дә таянырга кирәк.

Ниһаять, Язтургай мәйданының җир асты катламнарын киселештә күрсәткән геологик картасы да төзелде. Ләкин әле нефть бармы-юкмы, булса аның запасы күпме? дигән сорауга җавапны тирән скважинага җентекле разведка ясаучы шушы бораулаучылар әйтергә тиеш иде. Геологларны бигрәк тә Ромашкино нефть ятмасының чикләре кызыксындыра иде.

Бораулау вакытында алынган токым үрнәкләре, бораy астыннан су белән юдырылып өскә чыккан шлам һәм скважинага төшерелгән геофизик приборлар техник нарядның нигездә дөрес төзелгәнлеген раcладылар. Алар күрсәткәнчә, катламнар төрле-төрле булды, каты һәм йомшак токымнар аралашып килде, күпләп-күпләп известь чыкты, хәтта өч йөз метр тирәнлектәге җитлекмәгән ташкүмер ятмасы да өскә күтәрелде.

Әмма шунысы кызык: геологлар искәрткән җир куышлыклары, су чыганаклары һәм газ конденсатлары һаман күренмәде. Бораулаучыларны бу хәл тоташ хәвеф эчендә тота, һәрвакыт сагаеп эшләргә мәҗбүр итә иде.

Шул хәлдә меңенче метрга җиттеләр. Бу — проектта күрсәтелгән тирәнлекнең яртысы кадәр иде.

Мона кадәр скважиналарны тоташ авырлыклар, мәшәкатьләр белән бораиларга күнеккән бригада членнары хәзер дә эшнең шома гына барасына ышанмыйлар, эчләреннән ут йотып, табигатьнең яңа бер капризын көтәләр иде.

Һәм килде ул көннәр.

Сергей Саакян үз вахтасында соңгы сәгатен бораулый иде. Смена башыннан бирле каты токым белән интеккән Сергей, бораyның йомшакка кергәнен тоеп, басымны арттыра төште — бераз гына булса да метрлар санын куарга кирәк. Җиде сәгатькә якын эшләп, бүген аның вахтасы бары тик дүрт метр гына төшә алды. Дүрт метр! Хурлык. Гомумән, бу ункөнлектә Сергейныкылар әллә ни алдыра алмадылар. Үч иткәндәй, нәкъ аның вахтасына каты токым туры килде, җир астындагы торбаларны сүтеп чыгарып, тешләре ашалган бораyларны алыштыру белән гомер узды. Шуның аркасында аны Кадермәт вахтасы куып җитте, инде Тин-Тиныччлар үкчәгә басып килә...

— Кызурак, егетләр, кызурак селкенегез! — дип куалый башлады Саакян үз бораулаучыларын.— Сизәсезме, аяк йомшакка тиде!

Сергей тормоз рычагын бер күтәреп, бер төшереп акрен генә забойны капшый. Җиде ел эшләп ул шушы рычагларның калтыравы аша да йөзләрчә метр тирәнлектәге җир токымын сизәргә, аңа бәя бирергә өйрәнеп беткән. Бораy каты чуерташ катламын үтеп, техник нарядта геологлар күрсәткән вак кварц катламына керде. «Юаш токым» дип атыйлар аны бораулаучылар. Тик кайчакта юаштан юан да чыгып куя... Әллә су белән бораулауны туктатып, балчык измәсенә күчәргәме?

Балчык белән мәшәкатьләнеп тормыйча, Сергейның су белән генә үткәне булмадымыни андый катламнарны? Булды. Хәзер бөтен бер скважинаны су белән бораулаган бригадалар да юк түгел инде. Быел балчык модадан төште — бораулау тизлеге бермә-бер артты.

— Әйдә, бер нәрсә дә булмас! — дип карар кылды Сергей һәм, борауның балавызга кергән кебек җиңел баруына куанып, аңа тагын да ныграк басым ясады. Кайчакта синең атналар буе бораулаганыңны йомшак токымда әнә шул санаулы минутлар да каплый.

Бораулауның гадәттән тыш тизлеге помбур Мотгәрәйне дә шиккә салды хәтта: «Юньлегә түгелдер бу». Ул, буровой тавышын җиңәргә теләп, Сергейга кычкырды:

— Әкренрәк маташ!

— Әйдә, эшеңне бел!

Сергей Саакян бинһая көнче, артта сөйрәлүне һич тә күтәрә алмый иде. Үзен узып китә башласалар, йокыдан, ашаудан кала. Беренчелекне кайтару өчен ниләр генә эшләми! Вакытка экономия ясыйм дип, эшкә тотыныр алдыннан вахта җиһазларын карауга да, эш урынын хәзерләүгә дә, буровойны чистартып куярга да әһәмият бирми. Алай да булдыра алмагач, алдашу юлына басты. Бригаданың тәҗрибә бораулары урлап, шулар белән бораулаганда тоттылар. Бригада җыелышында Сергей гаебен танырга теләмәде: «Мин урлап сатмадым ич! Күршеләр скважинасын да барып борауламадым, үзебезнекен борауладым!» — диде. Бу җыелышта Сергейга каршы Валентин да каты чыкты. Төпсез көймәгә утыртып киткән Саакян Тин-Тинычны. Сер түгел, хәзер дә вахта тапшырганда бораулаучылар вакытны әрәм итмәскә тырышалар, буровойны кешенең намусына ышанып кабул итәләр. Вахтага килгәч, Тин-Тиныч сорый Саакяннан: «Бар да тәртиптәме?» «Бар да урынында». Сергей китеп аяк эзе суынырга да өлгермәде, Валентин тормозның начар эшләвен сизеп алды. Караса, ленталар бандажларга кадәр ашалып беткән, уралган. Метрларны ансат юл белән җыярга керешкән Сергей, фактлар белән китерел кыскач, ниһаять, гаебен таныды.

Шушы җыелыштан соң Сергей иптәшләрен бервакытта да уңайсыз хәлгә калдырмады, алдынгылыкны башкалар хисабына табарга тырышмады. Хәзер ул бораулаучылар алдында үтә дә игътибарлы: смена килүгә инструментларны хәзерләп, эш коралларын карап, буровойны әзерләп куя. Рәхим ит, кил дә бораулый башла!

Үзгәрде дигәч тә, билгеле, Сергей үзе бораулаганны кешеләргә бирергә әзер тора торганнардан түгел. Ул ярышта һаман да көнче. Кайсы да булса вахта бер-ике метр артык бораулаunion, Саакян күлмәгенә сыймый, Кавказ кызулыгы белән баш киемен атып бәрә, ярдәмчеләрен тирги башлый:

— Булдыксызлар, җебегәннәр! Кеше эшләгәнне эшли алмыйсыз!

Борауның бүгенге көпшәк катламга килеп керүе һәм котырынып аска төшүе Сергейның дөньясын онытырып җибәрде, ул соңгы сәгатьләрне ярсып бораулады һәм аста забойда яшеренеп, көтеп яткан хәвефне сизмәде.

Кадермәт вахтасы килгәндә буровой тынган, Сергей башын тотып күперчектән төшеп килә иде.

— Мастер кайтмадымы? — дип сорады ул арыган, карлыккан тавыш белән.

— Ни булды?

— Инструмент забойда калды.

Аста, бер километр тирәнлектә кысылып калган инструментны азат итү теләге белән Кадермәт сәгатьләр буе азапланды. Трубаларны чыгыр белән тарттырып карады, ротор белән әйләндермәкче булып маташты — җир астындагы колонна кымшанырга да уйламады.

— Әйе, Сергей туган, каты утырткансың...

Буровойдагы авария турында телефоннан ишеткәч, конторага йомыш белән киткән Зөбәеров та бик тиз әйләнеп кайтты.

— Эх, егетләр, харап иткәнсез бит скважинаны!..

Кулына әле бер дә тотылмаган өр-яңа бияләен кия-кия Зөбәеров буровойга керде, платформага менеп, рычагларны үзенә алды. Роторны уңайга да, кирегә дә әйләндереп, трубаларны селкеткәләп караганнан соң, эшчеләрне буровойдан куып чыгарды да инструментны йолкытырга кереште. Кырык бер метрлы вышка ыңгырашып сыгылды, трубаларның башын эләктергән беләк юанлыгы корыч баулар өзелерлек булып тартылдылар, ләкин җир токымы корбанын җибәрмәде.

— Мин синнән моны көтмәгән идем, Саакян! — Зөбәеров кулындагы рычагларны ташлады.

— Авариянең сәбәбе ачык,— диде Кадермәт тыныч тавыш белән. Әйтерсең аның өчен буровойда бернинди искитәрлек хәл булмаган, әйтерсең бу бик гади нәрсә иде.— Көпшәк токым ишелеп төшкән һәм борауны кыскан.

— Дөрес, токым ишелгән, борауны кыскан,— Зөбәеров Кадермәт янына килеп басты.— Журналга да һич икеләнмичә шулай дип язып куярга була. Ләкин авариянең төп сәбәбе балчык измәсе кулланмауда!

— Юк, измә генә коткара алмый скважина ишелүләрне! Практикада күрдек бит: Нелин бригадасы бөтен бер скважинаны су белән тәмамлады, ә Габдуллинныкылар измә кулланып та аварияда утырдылар.

— Билгеле, су белән бораулау яңа нәрсә, бәхәсләшмим. Ул арзанлы, мәшәкатьсез, прогрессив алым. Урынлы кулланганда су ифрат яхшы нәтиҗәләр бирә, анысы мәгълүм. Ләкин су дип балчыкны оныторга ярамый.

— Измә ул, Кадермәт туган, борауны әйләндерү өчен генә кулланылмый, бер үк вакытта скважина көпшәсен сылап, ныгытып баручы материал булып та хезмәт итә.

— Син миңа, Зөбәеров, нотык укыма. Беләм мин измәнең нәрсә икәнен, гомер буе шуның белән баш катырган. Без монда гаеп эзләргә килмәдек. Син әйт: нәрсә эшлибез? Нинди чара табабыз моннан котылу өчен?

Күп мәртәбәләр аварияда булган, җир асты ишелүләрен, инструмент кысылып калуларны, су йотылуларны күреп уздырган Зөбәеровның гадәтенә бер нәрсә сеңгән: ничек кенә булса да буровойны авыр хәлдән чыгару, скважинаны саклап калу. Ә бу скважина бөтенләй өметсез. Моны ташлап икенче урыннан бораулый башларгамы? Бу кадәр тирәнлеккә җиткәч, бер километр озынлыгындагы металл колонналарны җир астында күмеп калдырудан да кызганычрак, үкенечлерәк нәрсә бармы? Аңа күпме көч куелган, күпме тир түгелгән!

Бәлки, электәге берәр алым ярап куяр дип, Зөбәеров үзе моңа кадәр эшләгән буровойларны, андагы аварияләрне күңеленнән үткәрде, ләкин бер авария икенчесенә, икенчесе өченчесенә охшамый.

Бердәнбер юл: борауны турбинасы белән җир астында өзеп калдыру һәм шул урыннан читкә таба бораулый башлау иде.

Озак кына баш ватып, киңәшеп утырганнан соң, Зөбәеровның фикере белән килештеләр. Труба аша забойга торпедо төшерергә һәм колоннаның аскы өлешен шартлатырга карар кылынды.

## 16

Язтургайда фельдшер-акушерка булып эшли башлаган көннәрдә авылда авырулар да, бәбәйләүчеләр дә юктыр кебек тоелган иде Рәйсәгә. Район башкарма комитеты боерыгы буенча, алай да зур каршылыклар белән яулап алынган шушы медпунктта — колхозның чебиләр үстерә торган шактый иркен, ләкин бик тә иске бер бинасында көннәр буе авырулар көтеп утырган чаклары да булды Рәйсәнең.

Дөрес, әлегә хуҗалык эшләре дә житәсе иде биредә. Авыл осталарыннан тәрәзәләрдәге ватык өлгеләрне куйдырып, ишекләрне рәтләткәч: «Калганын үзең кара инде»,— диделәр. Бу аларның: «Башка ярдәм көтмә бездән, монысы да кирәгеннән артыграк булды»,— дигән ишарәләре иде.

Кулына сулы чиләк белән мунчала тотып, бинаны түшәменнән башлап идәненә кадәр юып чыкты Рәйсә. Аннан акбур белән стеналарын агартты, буровойдан зәңгәр буяу алып кайтып, тәрәзә рамнарын буяп куйды. Тәрәзә пәрдәләре юк иде, аларын әлегә марлядан гына тегеп элде.

Инде эш бер өстәл, дарулар шкафы, авыруларны карау өчен кушетка, кирәк чакта аларны салу өчен койка һәм бер-ике урындык кына табасы калган иде.

Аларны юнәтү дә ул кадәр авыр булып чыкмады. Күп теләнә торгач, авыл Советы председателе Хафизов абзый үзенең архивлары өчен дип саклана торган иске, авыр кием шкафын керттерде. Почтадагылар «духтыр» апаларына бер аягы аксаган өстәлләрен бүләк иттеләр. Урындыкларны, рәхмәт төшкере, мәктәп директоры Дәминов укучы балалардан үзе керттерде. «Врач апагыз күбрәк сезгә кирәк булачак»,— дип әйткән, имеш.

Ә менә койка белән кушетка мәсьәләсенә килгәндә, аларны булдыру кыенгарак төште. Койканы кешедән табу мөмкин түгел, сатып алырга кибеттә юк иде.

— Тукта әле, чатырда безнең караватлар икәү иде бит,— дип уйлады Рәйсә. Ләкин бирегә килер алдыннан Фазыл белән булган ызгышны искә төшереп, чатырга кайтырга куркып йөрде.

Уйлап карасаң, нинди көнгә калды бит Рәйсә. Фазыл аның институт тәмамлаганын да көтмичә өйләнде. «Мәхәббәт өчен бернинди киртә юк. Кавышырга, бергә яшәргә теләгән кешеләрне һичкем аера алмый»,— дип кенә жибәрде ул мәхәббәттән исереп йөргән көннәрдә. Ләкин шулай килеп чыкты: Рәйсә белән Фазыл беренче көннәреннән үк рәтләп бергә тора алмадылар. Гомер буе ирен куып йөрергә насыйп булган икән Рәйсәгә.

Фазыл институт бетереп, Бөгелмә шәһәренә эшкә билгеләнгәч, Рәйсә дә үзен эшкә жибәрүләрен сорады. Билгеле, «ирем янына» дип горурланып әйткәч һәм мактанып паспортындагы ЗАГС печатен дә күрсәткәч, каршы килмәделәр. Бөгелмә больницасында эшләргә язу тоттырдылар. Ләкин ул Бөгелмә дигәненде нефть бөтенләй юк, шулай да нефть берләшмәсе — иң зур оешма — анда урнашкан иде. Фазылның эшли торган урыны нинди Тимәш авылында икән. Үзе эшләячәк больницага кереп тә тормастан, Фазылның итәгенә диярлек тагылып, Рәйсә Тимәш дигәненә китте. Әмма бу авылда кая больница-мазар булу, мунча кадәр медпункт та юк иде! Фазыл үзе дә фатирда торырга, кырга барып эшләргә тиеш иде. Имеш, монда нефть чыкса, Тимәш бик шәп үсеп китәчәк, зур шәһәргә әвереләчәк, имеш, биредә әллә ничәшәр катлы больницалар да, поликлиникалар да булачак. Вәгъдәләр күп, тик барысы да киләчәктә, булачакта, төзеләчәктә икән әле...

Яшь ир белән хатын, утырып киңәшләшкәннән соң, мондый карарга килделәр: бераз түзәргә. Аерым торулар авыр булса да, түзәргә. Рәйсә Бөгелмәсенә кайтып, билгеләнгән больницасында эшләп торырга, ә Фазыл монда «кара алтын» эзләргә тиеш. Эзләргә һәм бик тиз табарга. Тимәшне тизрәк шәһәр ясарга, Рәйсә өчен тизрәк больница, поликлиника салдырырга. Чүкердәшеп бергә яшәү көнен шунсыз якынайтып булмый.

Бер-бер артлы көннәр, айлар үтте. «Кара алтын» да тапты Фазыл Тимәштә. Зур-зур йортлар да, больница да, поликлиника кебек биналар да салынды анда, тик Рәйсә белән Фазыл гына «чүкердәшеп бергә яши» алмадылар. Яшь мастер Зөбәеров яңа бригада оештырып, яңа нефть чыганаклары эзләп, тагын да ераккарак китте. Анда-санда берәр кечкә

кайтып килүләрен исәпләмәгәндә, күрергә дә, табарга да юк иде Фазылны.

Ире белән яшәүгә бернинди өмет калмагач, Рәйсә Бөгелмәне ташларга да Фазыл янына китәргә дип карар кылган иде. Анда кайда торырга, ничек яшәргә, нәрсә эшләргә, бу турыда уйламады.

Китәргә талпынган бер чакны Рәйсәнең авырлы булуы тотып калды, икенчесендә яшь бала булу ирек бирмәде, өченче мәртәбәсендә...

Өченче мәртәбәсендә бернинди сәбәпкә дә карап тормады Рәйсә: больницасы белән исәп-хисапны өзде дә, кызы Ләләсен алып, Язтургайга — Баланлы Төбәктәге чатырга килде.

Фазылга турысын әйтергә дә куркып йөрде Рәйсә. Отпуск алып кунакка килдем дип ялганлады. Чөнки аның ире җитәрлек сукбайланган иде, аны әле күндерәсе, «кулга иләштерәсе», хатын белән торырга, семья белән яшәргә өйрәтәсе бар иде. Беренче көннән үк бөтенләй килгәнне белсә, ни кыланган булыр иде икән Фазыл?

Ни генә булмасын, Рәйсә үзенекен итте — озак еллар аерым яшәгәннән соң ире белән тору хокукына иреште. Хәзер инде менә, җайлы гына эше дә табылды...

Рәйсәнең лагерьга кайтуы койка сорау өчен генә түгел иде, әлбәттә. Ниһаять, Фазыл суынгандыр, аның белән яхшы гына аңлашырга, чатырда эшсез яту туйдырганын һәм гомумән эшсез тору мөмкин түгеллеген төшендерергә кирәк иде.

Фазыл буровойдан кайткан, сызгырына-сызгырына бәрәңге әрчеп утыра иде. Чатырга Рәйсәсе килеп кергәч, шатлыгыннан ни эшләргә дә белмәде, урыныннан сикереп торып, хатынын кочаклап алды. Кичәге ачуының эзе дә калмаган. Шулай инде ул —ерактагы кояш җылы була.

— Я, ничек Язтургайда, Рәйсә? Кызны кая калдырдың? Ләлә мине искә аламы? Медпунктның кайда? Еракмы? — дип, бер-бер артлы сораулар тезеп китте һәм аларга җавап биргәнне дә көтеп тормыйча, һаман сорауларын яудырды.

Фазылның «акылга» килүенә ышанып бетә алмады Рәйсә. Аның бит әле йомышы да бар иде иренә.

— Җаным, Фазыл,— дип төчеләнеп кенә башлады ул сүзен,— син әйт әле, без икебез бер караватка сыябызмы?

Фазыл, күрәсең, моны Рәйсәнең сагынып иркәләнүе дип аңлады булса кирәк:

— Әлбәттә, сыябыз! — дип кочакларын җәйде.

— Алайса, син бир миңа ул караватыңны. Медпункт өчен һич кенә дә койка таба алмыйм бит...

— Менә кая таба аударасың икән! Ә син беләсеңме аның дәүләтнеке икәнен?

— Беләм. Ләкин бит медпункт та дәүләтнеке!

— Икесе ике министерство: здравоохранение һәм нефть промышленносте!

— Булса соң. Без һәр икесенә дә хезмәт итәбез. Авырсаң бит нефть министрына бармассың!

Зөбәеров көлеп җибәрде.

— Сиңа җавап табып буламы соң, качкын! Ал, ләкин бөтенләйгә түгел!

— Тукта әле, тукта, үзең кайда йокларсың соң? — диде Фазыл.— Әллә бөтенләй кайтмаска дамы исәбең?

— Сагынсаң үзең кайтырсың минем янга. Кунак ашы — кара каршы, мин күп йөрдем сине эзләп...

Кушетка да булды. Пычкысы белән балтасыннан башка коралы булмаса да, оста икән Мотгәрәй, буровойдагы такталарны җыештырып, менә дигән ятак ясап бирде.

Шулай йөри торгач, бинаны җиһазлап бетерде Рәйсә. Район аптекасыннан кирәкле даруларны һәм инструментларны сатып алды, хәтта пыялага «Язтургай медпункты» дигән язу да язып элде, тик аның бусагасын атлап керүче булмады. Медик өчен моннан да күңелсезрәк, моннан да авыррак нәрсә юктыр.

— Язтургайда кешеләр бер дә чирләми микәнни? — дип гаҗәпләнде Рәйсә. Хезмәт хакы алып, айлар буе шушылай кул кушырып утыра башласаң ни эшләрсең?

Ышанмаслык хәл: бер вакыт хәтта шуңа барып житте Рәйсә — кешеләрнең авыруларын тели башлады.

Тора-бара язтургайлыларның да әүлия түгеллеге, авылда авыруларның да, бала табучы хатыннарның да шактый булуы беленде. Тик алар мондый «медпункт» дигән нәрсәгә йөрергә гадәтләнмәгәннәр, чирлеләр им-томчы карчыклардан өшкертеп «дәваланалар», бәбәйли торганнары кендек әбиләрен чакырталар икән. Малай туса, үзенә күрә сөннәткә утыртучы карт та бар.

«Нинди дарулары бар, нинди «ысуллар» белән дәвалый икән?» — дип, им-томчы карчыкның өенә барды Рәйсә. Нәрсә күрде: сәке өстендә дисбе тартып, кибеп-корышып беткән бөкре карчык утыра. Ким дигәндә сиксән яшьләрендә булыр. Начар ишетә, начар күрә, ләкин сорашкач, «табиплык» тәҗрибәсе белән бик теләп уртаклашкан булды. Янында ак мыеклы кара мәчесе йоклап ята — кешенең хәле бик мөшкел чакларда суга шуның койрыгын бутап эчертә икән. «Шифасы тия дисеңме? Тимәгән кая, зәхмәтне кул белән алып ташлагандай итә!»

Матчага, ишек-тәрәзә башларына, киштәгә төрле-төрле үләннәр, тамырлар киптерергә элгән. Анда бака яфрагын да, кычытканны да танырга була, аксыргак, абага белән андыз тамыры да бар. Авыруларга шуларның кайсын төеп, кайсын кайнатып эчәргә биреп җибәрә икән. «Инде һич булмаса, тәбәнәк әрем белән бөтнек үләне дә ярый»,— ди карчык. Шешкә яба торганы да, җәрәхәткә каплый торганы да шушы ук үләннәр, тик аерма шунда: зәхмәтенә карап кайсын өшкереп, кайсына төкереп бирә икән. Ә дәвалау догаларын беркем дә белә алмый, сырхау килгәч, хәерен-сәдакасын биргәч, аллаһе тәгалә аны күктән иңдерә икән.

Кайтышлый бабачыга керде Рәйсә. Яше алтмышлар тирәсендәге күе кара сакаллы, кара мыеклы, чиртсәң каны тамардай абзый иде әле бу. Авылга «духтыр» килгәнен ишеткән. Ак халатлы Рәйсәне күргәч, хезмәттәшен каршылагандай, ике куллап килеп күреште, итагатьле генә итеп утырырга урын күрсәтте, карчыгына чәй куярга боерды.

— Бик шат, бик мәгъкуль,— дип сөйләнгәләп, өстәлгә чәшкә-чынаяклар тезде.

— Безнең авылга кирәк иде ул медицина. Нишлисең, хәзер укымышлылар заманы.— Аннан кинәт кенә әйтеп куйды: — Инде, боерган булса, сөннәтне дә үзегезнең кулга аласыздыр?

Аның бу сүзләрендә өстенлек итү дә, ачыктан-ачык каһкаһа да сизелә иде.

— Сөннәтләү булмаячак, бабай.

— Булмаячак? Нәрсә булачак соң? Әллә медицина бер-бер яңа ысулын уйлап тапты мы?

— Сөннәтләү бетереләчәк!

— Анысына ышанмыйм, духтыр, билләһигазим, ышанмыйм! Беренчедән, мөселман өммәтенә сөннәт фарыз. Моны аллаһе тәгалә үзе кушкан. Икенчедән килеп, халык нәрсә әйтер бит әле? Безнең илдә демократия! Хәер, анысын сез беләсез инде, шәхес иреге...

Белдекле булып кыланган бу карт Рәйсәдә ачу уятты:

— Алайса, менә шул: мин бүгенге көннән үк бу эшегезне туктатуны таләп итәм!

— И-и духтыр, духтыр! — дип көлде бабачы, кара сакалын сыйпап.— Мин бик туктатыр идем дә бит, халык сорый. Ат белән, машина белән килеп алалар, җитмәсә! Әле нәчәлник була торып нәчәлникләр күрше авыллардан легковой җибәртәләр! Миңа нәрсә: бик гозерләнеп үтенгәч барам.

— Моннан соң бармассыз!

— Ярый, тырышырбыз. Ул бит әле, духтыр, без дигәнчә генә түгел!..

Бабачы Рәйсәне озата чыкты. Капка төпләренә җиткәч, карт серле генә итеп Рәйсәнең колагына иелде дә: «Бәлки, мәхәлләгә бүлешербез, ә? — диде.— Сез югары очны алсагыз, мин түбән очка да риза...

Әллә чынлап әйтүе, әллә мыскыл итүе булды бабачының — Рәйсә аңламады, алдына-артына карамыйча, урам буйлап китеп барды.

— Тәмам узындырганнар икән боларны. Юк, болай булмый, халыкны җыярга, аңлатырга кирәк...

«Бер чыккан көе кендек әбиләрен дә күрик инде»,— дип, Рәйсә, аның өен кешеләрдән сораша-сораша, түбән очка төшеп китте.

Карчыкларның акушерлык ысуллары Рәйсәгә билгеле иде инде. Бер уйлаганда, аларны гаепләп тә булмый. Авылда акушерка булмагач, ни эшләсен бала табучы хатын — ярдәм сорап тәҗрибәлерәкләргә мөрәҗәгать иткән. Шуннан «кендек әбисе» дигән вазифа барлыкка килгән. Медицина таләпләреннән ерак торган бу кендекчелек гасырлар буена шулай барган — бәбәйли алганы бәбәйләгән, бәбәйли алмаганының баласын «ходай» тартып алган, «насыйп итмәгән». Хәзер кендекчелекне чик куярга, акушерлыкны үз кулына алырга кирәк иде Рәйсәгә.

Кендек әбисенә керүнең төп максаты соңгы биш елда бала табучылар санын алу, баладан үлүче хатыннарны һәм туа алмаган сабыйларны белү иде. (Мондый саннарны Рәйсә авыл советыннан тапмады.) Лекция ясый-нитә калса, акушерка өчен бик мөһим иде алар.

— Кайлардан белеп бетермәк кирәк андый нәрсәләрне! — диде кендек әбисе, хәтереннән зарланып.— Гомеремдә мин кабул иткән балаларның исәбе-хисабы юк инде аның! — һәм ирләр тавышы белән мактанып та китте, әйтерсең аларны үзе тапкан:— Беренче кабул иткән балаларым — хәзер үзләре бала атасы. Кайсы агроном, кайсы менә синең кебек духтыр, кайсы әфисәр, рәхмәт төшкерләре. Бер балам хәтта генерал. Ялга — кунакка кайтсалар менә инде «әби» дип үлеп торалар... Миңа бүләк артыннан бүләк, күчтәнәч артыннан күчтәнәч... Кендек әбисе булу бик күркәм, бик саваплы эш ул, балам...

— Үлүчеләр булдымы?

— Андыйлар да булды, кызым. Ходайдан узып эш итә алмыйбыз. Бер елны бәбәйдән Чәүкә Миннисаның кызы вафат булган иде, менәтерәк быел язда кибетче Сәлимә дөнья куйды. Былтырларда Кырлавык Зәйтүнәнең баласы дөньяга килә алмады, быел ураза аенда югары оч Зәйтүнәнең сабыен ходай тартып алды... Аллаһе тәгаләдән узып эш итә алмыйбыз шул...

Икенче көнне, өченче көнне дә аяк өстендә булды Рәйсә. Йорт саен кереп, авыруларның, инвалидларның исемлеген төзеп йөрде, кайткач, аларны анализлап утырды. Фактлардан күренгәнчә, Язтургайда үлемҗитем шактый булган. Алар арасында өч хатын баладан үлгән, ике сабый дөньяга килә алмаган.

Авыруларга килгәндә, Язтургайда хәл бик үк начар түгел кебек. Трахома, корчаңгы кебек йогышлы чирләр юк, туберкулез билгеләре берничә кешедә генә. Ә менә йөрәктән, баш авыртудан зарланучылар байтак. Сәбәбе Рәйсә өчен ачык түгел иде әле. Шунысы мәгълүм, үлүчеләрнең күп өлеше медицина ярдәме җитмәүдән, ә авыруларның интегүе врачка күренмәүдән иде.

— Безгә бульнис ерак, анда без ахыр чиктә генә барабыз,— диләр авыл кешеләре. Ахыр чик дигәннәре шул — им-томчылар бозып чир азгач, кешенең якасыннан үлем тотып алгач кына врачларга мөрәҗәгать итүләре икән.

Шундый бер чирлене күптән түгел генә медпунктка китерделәр. Язтургайда унбиш көн эшләп, медпунктка килгән беренче авыру иде. И куанды инде Рәйсә апа. «Төкле аягың белән!» — дип, чак әйтеп жибәрмәде. Бу кеше печән чапканда чалгы янап ялгыш бармагын кискән булган. Кулъяулыгын ертып, туфрак сибеп ярасын бәйләгән, ләкин кул һаман төзәлмәгән. Билгеле, инфекция биргән. Печән вакыты үтеп, урак өсте килеп житкән. Бу вакытта инде Язтургайда медпункты та ачылган иде, ләкин аны белә торып та кермәгән, шифа эзләп им-томчы карчыкка киткән. Им-томчы печән чапкан жиреннән кара елан тотып китерергә кушкан. Китергән бу. Карчык еланның тиресен салдырып, өшкереп-төкереп моның бармагына япкан. Җәрәхәт тагын да азыбрак киткән. Авыруны медпунктта каты температура белән, битләре-куллары шешенгән хәлдә китереп салдылар. Көн саен дүрт мәртәбә пенициллин уколы кадап, инфекциягә каршы төрле дарулар биргәч кенә шеше кайта башлады. Монда килеп эшли башлагач, беренче рәхмәтне дә шушы кешедән алды Рәйсә.

Институтның хирургия факультетын тәмамлау да ярап куйды Рәйсә өчен. Бер көн шулай эштән соң кызы Ләләне алып кайтырга әзерләнә башлады (Ләләне көндез бер әби карый иде). Хатыны белән кызының яшәгән урынын күрергә дип, Фазыл да буровойдан авылга төшкән, тегендә-монда сугылып, бүлмә буйлап фатирны карап йөри. Фатир дигәне бер бүлмәле мәктәп торагы — яшь укытучылар жәйге каникуллардан килгәнче генә дип урнаштырганнар иде Рәйсәне.

Чыгып китәм дип торганда гына, шакымый-нитми өйгә авыл Советы председателе Хафизов килеп керде. Керде дә бер сүз дә әйтә алмыйча, эчен тотып ишек төбенә ауды.

Зөбәеров кына түгел, хәтта Рәйсә үзе дә каушап калды. Фазыл председательне исерек дип уйлады. Ә Рәйсә күз ташлау белән үк кешенең хәлен сизеп алды: кризис. Фазыл белән тиз генә чишендерделәр дә караватка илтеп салдылар. Авыруның касыгын тотып, уң якка бөгәрләнеп ятуыннан Рәйсә диагноз куеп алды: Хафизовта кискен формадагы аппендицит өянәге. Соңгы стадия. Кичекмәстән операция ясарга кирәк. Нишләргә? Машинасы белән Фазыл аны район больницасына да илтергә булган иде, Рәйсә каршы килде. Өлгерә алмас, соңгарып...

Операция ясаргамы? Юк, фельдшер-акушерка монда хокуклы түгел. Ә нигә булмасын, штат буенча Рәйсә фельдшер-акушерка исәпләнсә дә, чынлыкта бит ул дипломлы врач, житмәсә, хирург!

— Син, Фазыл, авыруны операциягә әзерлә, учакка як, су кайната тор,— дип боерды ул иренә,— ә мин медпункттан тиз генә даруларны, инструментларны алып кайтам. Зөбәеровта мең төрле сорау, гажәпләнү һәм каушау калдырып, өйдән чыгып йөгерде.

— Операциягә әзерлә, имеш... Тапты ярдәмче...

Авыр сулап, ыңгырашып яткан Хафизовка карап торды да, мич янына килеп, учакка ут алды Зөбәеров. «Мастер булып гомер итәрмен дигән идем, болай булгач табиб булып китәрмен», дип, Такташны исенә төшерде. Я ходаем, күрсәтмәсен врачлыкны!

Апендикс алуда азмы-күпме тәжрибәсе бар иде Рәйсәнең. Бөгелмәдә ул озак еллар хирург булып эшләгән баш врач кулы астында ассистент хезмәтләрен үтәп торды. «Аппендицитка операция ясау ул икене икегә тапкырлау белән бер»,— дип әйтә торган иде карт хирург. Җиңел операция буларак, сукыр эчәкне алуны күп вакытта Рәйсәнең үзенә тапшыра иде һәм үзе бу вакытта ассистент ролен үти иде. Үзенә күрә яшьләрне өйрәтүнең бер формасы.

Сукыр эчәктән бик күп авыруларны коткарды Рәйсә, әмма мондый шартларда бер ярдәмчесез эшкә тотынырга курка иде Кем белә, төзәлмәслек хата эшләве бар. Врач та, мина эзләүчеләр теле белән әйткәндә, бер генә ялгыша. Аннан инде операция ясарга хокуклы икәнеңне исбат итеп кара...

Төзәлмәслек хата да була язып куйды бу көнне. Кайнатырга тиешле инструментлар кайнатылып, кирәкле дарулар, түндыру дарулары тәртибе белән өстәлгә тезеп куелгач, ашыгудан медпунктта операция җебе онытылып калганы беленде. Кабат йөгерергә соң иде инде — кешенең хәле гадәттән тыш авыр, ул көчкә-көчкә генә сулап ята иде.

— Җеп кирәк, җеп...— дип, үзен-үзе белештермичә кычкырып җибәрде Рәйсә.— Тегәрҗеп булса да ярый.

— Нинди тегәрҗеп? — дип гаҗәпләнеп сорады Фазыл.

— Сүс җебе. Гади сүс җебе!

Күрше карчыкка йөгереп кереп, бер саплам тегәрҗеп алып чыкты, шунда ук аны кайнатты, медицина кушканча стерилизацияләде. Зөбәеров-ассистентына ашыгыч кына күрсәтмәләр биреп, операциягә керешге. Я аллам, инде уңышлы гына чыкса ярар иде...

Операция көтмәгәнчә яхшы чыкты. Бер атнадан Хафизов аякка басты. Шунда, җөйдән җепләрне чүпләгәндә, Хафизов җеп кисәген алып карады да: «Кызык була икән бу операция җебе»,— дип куйды. Рәйсә көлеп җибәрде. «Җамал әбинең оек ямый торган җебе ул! Корсагыгыз нык булыр, тегәрҗеп белән тектем!»

Фазыл төн йокысы бирмичә медсестра урынына чаптырып йөрткәне өчен хатынынннан зарланды зарлануын, әмма шул көннән соң Рәйсә «духтырның» абруе бик тиз үсеп китте, даны авылга таралды. Хафизов: «Җен икән бу, фельдшер түгел» дип сөйләп йөргән. Ә усал телләләр исә (кемнән ишеткәннәрдер): «Рәйсә духтыр Хафизовның корсагына тегәрҗеп белән күн ямау салган», дигән мәзәк чыгардылар. Ничек кенә булмасын, болар Язтургайдагы беренче фельдшер-акушерка исеменә әйтелгән мактау сүзләре иде.

## 17

Мотгәрәй кырлардан әйләнеп кайтканда, бораулаучыларның бер төркеме йокыдан торып төшке аш хәзерли, икенчеләре, үләнгә ятып, чатыр күләгәсендә кәрт суга, өченчеләре җыелып гәп сатып утыралар иде. Бик рәнҗеп куйды Мотгәрәй бу тормышка. Менә бит разведка кешене ни эшләтә! Басуда, урманда яки фермада умырып эшләп йөрисе урында сырыктай егетләр гомерләрен ифрат та заяга уздыралар. Алар өчен ни печән өсте, ни сабан өсте, ни урак, ни мал юк. Кешене гарипли торган гамьсез, ярлы тормыш түгелме бу разведка?

Нәрсә турында сөйләшеп утыралар дисең менә хәзер. Берәр дөньяви файдалырак нәрсәләр сөйлисе урында һаман да шул Фәрхетдиннең мәхәббәт тарихы, Тин-Тинычның Ташлыярда булып та Валяны таба алмавы һәм геологларның тагын каядыр чыгып китүләре, Сапарбайның казакъ даласын мактавы, Саакян белән Миша Кубракның гитара уйнап авыз күтәреп җырлап утырулары...

Аннан эш турында сөйләшкән булалар инде: кем бүген күпме бораулаган, ничек бораулаган, нәрсә белән бораулаган. Я, кызыкмы шул?

Мотгәрәй килгәндә Фәрхетдиннәр төркемендә бораулаучылар кызып-кызып разведканың авырлыгыннан, мәшәкатеннән зарланып утыралар иде. Нәҗипне һаман да шул укып булмау, белем ала алмау борчый икән. Миша Кубрак: «Сменалы эш вата, төнлә торып эшкә китүләр

әҗәл белән бер»,— ди. Еланский быел да вахтада булып спорт ярышларына катнаша алмый калуына үкенеп утыра. Ни әйтсәң дә, барысы да шул күчмә тормыш аркасында...

Тик ачу китереп Сапарбай каршы төшкән була: Имеш, аның өчен күчмә тормыш яңалык түгел, ул инде дала гизеп йөрүләрне туганда ук күреп туган. Имеш, менә шушылай кырда кунып ятулар җылкы көтеп йөргән вакытларны искә төшерә. «Тик менә җылкысы гына юк атланып чабарга»,— дип күрсенә.

Шуннан Тин-Тиныч элеп алып китә:

— Мин разведканың нәрсәсен яратам? Разведкада йөрү мина, ничектер, Тын океанда йөзеп йөрүләрне хәтерләтә. Диңгезчеләр белән нефть эзләүчеләр язмышы охшаш кебек мина. Кораб белән шушылай океанга чыгып китә идек тә атналар, айлар буе кайтмый идек... Сирәксирәк кенә чит җирләрдә ят портларга туктыйсың. Ярга төшәсең... Тәндәге җинеллекне сөйләп бетерешле түгел. Ну, рәхәт соң!.. Аяклар туфракны, каты җирне сагынган. Кая барганыңны белми ашкынып алга атлыйсың, ә үзең һаман әле чайкаласың... һаман дулкыннар арасында барган төсле... Әнә шул, гомереңдә эз басмаган, күрмәгән-ишетмәгән урыннар да, нигәдер, бик якын тоела...

Фуражкасын колагына таба этеп куйды да Фәрхетдин сөйләп китте:

— Кемгә ничектер, әмма да яратам шул ил гизеп йөрүләрне! Дөнья тирәли сәяхәт! Нинди генә авылларда булмыйсың да нинди генә кырларны күрмисең! Нинди генә йортларда кунмыйсың да нинди генә кызларны кочмыйсың! Шулай бер вакыт Азнакайда эшләгән чакта керәм бер фатирга. Зөбәеров кушуы буенча, билгеле. Хуҗалары ачыклар инде менә! Өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар. Ятсаң пружиналы караватторуыңа өстәлдә коймак, бәлеш! Һич инде сөйләргә дә түгел! Шулай да тора алмадым.

— Нәрсә, кандала таладымы?

— Кандала сиңа! Әх, егетләр, күрсәгез кызларын фатир хуҗасының! Инде дә сылу, инде дә гүзәл булса булыр икән кызлары! Кашыкка салып суырып йотарсың менә! Кичтән хәерле йокы теләп дә бу мина, бүлмәгә кереп китә. Мин төне буе теге кызның сылу гәүдәсен күз алдына китереп йоклый алмый ятам. Арада тактадан бүлгән бүлмә генә. Сулышларына кадәр ишетелеп тора кызның. Билгеле, мине уйлап, ул йоклый алмый инде. Кереп кенә чумарга да бит янына, юк, әти-әнисе минем якта. Шулай бер атналар керфек тә какмый азапланган, көннәрдән бер көнне чемоданымны алдым да: «Хушыгыз, мин әйтәм, мин киттем». Кыз кулга ябыша. Нәрсәбезне килештермәдек, нигә китәсең дә фәлән дә төгән. Сине ошатмадым, мин әйтәм, төнлә яман саташасың... «Нәрсә дип әйтеп саташам?» — ди бу. «Минем исемне әйтеп саташасың»,— дим. Чыгып киттем.

— Ай-һай, андый кызларны ташлап чыгып китә алыр идең микән? — дип көләләр бораулаучылар.

Фәрхетдин үзен патриот итеп күрсәтмәкче була:

— Сезнеңчә, Фәрхетдин шул чибәр аркасында аягүрә йоклап авария ясарга тиешмени? Җитмәсә, йөрәк чире алып куюың да бар кызлар уйлап...

Әңгәмәләре бетүгә, Фәрхетдин Мотгәрәйгә борылып карады:

— Менә, егетләр, дөресен әйтим, көнләшәм мин Мотгәрәйдән. Бер хәсрәтсез кеше: аның өчен бригадаң да юк, буровоең да юк, аварияң дә ниечем! Хәтта хатын-кыз да дөньяда яшәми аның өчен! Эх, уздыгомерләр, бу кадәр гамьсез булып булмады.

Фәрхетдиннең сүзе Мотгәрәйне көләргә мәҗбүр итте: ул уйлаганның нәкъ киресен уйлый бит бу ахмак. Кем гамьсездер бит әле.

— Ну, шулай да әйт әле, Мотгәрәй, бездән аерылып китеп нинди кызык таптың?

— Иркенләп кырларда йөрдем, кошлар сайравын тыңладым, бакалар бакылдаганын ишеттем, җәйләүне күрдем,— дип тезеп китте Мотгәрәй.

— Җәйләүгә бардың? Сыер савучыларны күрдең? Кызлар күрдеңме?

— Күрдем.

— Күрдең? — Фәрхетдин кулындагы картасын үлән өстенә ташлап, сикереп торды һәм шундук, артистланып, кулларын күкрәгенә куеп, Мотгәрәй алдына тезләнде: — Җаным Мотгәрәй, кайда ул җәйләү дигәннәре? Еракмы? Зинһар алып бар... Ялындырма, күптән кызлар кулы тотканым юк, билләһи-валлаһи. Урманда ята-ята шүрәлегә әйләнеп беттем бит инде!..

Башкалар Фәрхетдиннең кыланышларына авыз ерып торсалар да, Мотгәрәй аны килештерми иде. Юкка-барга авыз еручыларның үзләрен дә өнәми иде әле ул. Монын белән бит алар Фәрхетдинне бозалар гына. Ә тегесе тиле дигән саен тигәнәк буе сикерә. Шушы маймыллыгы белән кызларга да ярый, күрәсең. Әнә, Карабашта ничә яшь кызның башын әйләндерде, Ык буе авылларында ничәмә-ничә яшь кызны тилмертеп йөртте, хәзер инде Язтургай чибәрләренә үрелмәкче була... Юк, күрсәтергә ярамый аңа җәйләүне...

Төркемнән үгетли башладылар:

— Алып бар инде! Аягың корымас бит. Сөт-катык ашап кайтыр идек, ичмасам!

Буровойдан мастер кайтмаган булса, Мотгәрәй берничек тә җайга килмәгән булыр иде.

— Нәрсә сатулашасыз, егетләр? — дип кычкырды ерактан ук Зөбәеров, болар янына атлый-атлый. Юктан-бардан бәхәс кузгалып, эшчеләре ызгыша башласа, мастер аларны шулай аергалый иде.

— Менә бит, мачтыр,— дип сөйләп китте Фәрхетдин,— безнең арада аерым хуҗалык юк димә: Мотгәрәй җәйләүдә кызлар янында булып кайткан да нитукмышты бүлешү, адресларын да әйтми!

— Яхшы итмисең болай булгач, Мотгәрәй,— дигән булды Зөбәеров.— Безнең коллективка хас нәрсә түгел бу! — Шул ук вакытта бу сүзе белән ул Мотгәрәйне югалып йөргәне өчен шелтәли дә иде.— Барыгыз, күрегез, танышыгыз!..

Әнә, Рәйсә духтыр да егетләргә кызлар белән йөрү ярый ди бит. Аларда, имеш, кызлар белән танышкач, тормышка аек караш, эшкә дәрт туа, кеше, имеш, җыйнаклана, үзен ыспай йөртә башлый... Сынап карыйк Рәйсә рецептын. Тора-бара бораулаучыларыңны җыеп алырга калмасын.

Егетләр Мотгәрәйгә ияреп урманга кереп киттеләр.

Мотгәрәйнең әйтүенә караганда, җәйләүгә ерак түгел, шушы буровой утырган урман артында гына, ләкин текә үре булган урман аша сукмак юк, Сагындык елгасына атлы юлдан төшеп болын буйлап киләсе икән. Каян эзләп тапкан диген син ул җәйләү дигән хәзинәне! Исләре китеп барды бораулаучылар. Разведчиклар арасында табигатьне Мотгәрәйдән дә ныграк яратучы, аның рәхәтен, кадерен белүче кеше юктыр. Эштән соң аның урманга бармыйча, су керергә төшмичә яки басуларны әйләнеп кайтмыйча калган көнен дә тапмассың. Аны югалып йөргәне, буровойга күңел бирмәве, эшкә соңга калганы өчен тиргәп бетерсәләр дә, табигатьне яратуына сокланалар иде. Ул теләсә нинди үләнне исеннән әйтеп бирә, теләсә нинди җәнлекне йөрешеннән таный, теләсә нинди кошны сайравыннан белә. Аның бу гыйлеменә бигрәк тә Тин-Тиныч, Миргазиян, Еланский, Миша Кубрак кебек юкәне өрәңгедән

аера белмәгән шәһәр малайлары гаҗәпләнә. «Табигать энциклопедиясе» дип йөртәләр Мотгәрәйне.

Урманда инде кошлар сайравы күптән тынган, тик анда-санда гына чыпчыклар чыркылдаша да, курыккан мәче башлы ябалакның пырхылдап очканы гына ишетелеп куя.

Агачлар да җәйге яшел киемнәрен сары төскә алыштыра башлаган. Көз житәсен белдереп үрмәкүчләр ботактан ботакка җеп сузган, пәрәвез корган. Кайдадыр әчтә, куаклар арасында, яфракларны кыштырдатып, урман хуҗасы — пошн йөри бугай...

Узып бара икән җәй. Ничек соң әле шушында урман буенда, аланда, табигать куенында яшәп күрми, сизми калдылар җәйнең узганын? Эш артыннан куып, кеше дигәнең дөньясын оныта, күрәсең...

Егетләр күтәрелеп әле агач башларына, әле куакларга карап алалар, әле биек агачлар арасыннан күренгән аксыл болытлы зәп-зәңгәр күккә башларын ташлыйлар.

— Их, Мотгәрәй, нигә син безне шушылай элегрәк иярттеп йөрмәдең?

— Иярттеп йөрергә әллә сез бала-чагамы?

Һәркем үзенчә кыланып бара урман эчендә. Нәҗип, шашкан шикелле, абагалар арасында йөгереп йөри. Сергей туктап-туктап агач ботакларына асылына да аякларын күтәреп атынып тора. Нәҗип уч төбенә салып яфрак шартлата. Урман күрмәгән Сапарбай, адашудан куркып, бер адым да калмыйча Мотгәрәйгә ияреп йөри. Тин-Тиныч бер карт юкә төбенә килеп, агачка шигырь укырга тотына:

Саумы, дустым, саумы, имән?
Сиңа килеп мин баш иям!
Шуның өчен сиңа киләм.
Саумы, имән, саумы, имән?
Хәтерләтеп батырларны
Син торасың минем алда.
Исең китми мактауларга,
Гаҗәпләнми шөһрәт-данга?

Фәрхетдин Валентинның аркасыннан какты:

— Яхшы сайрыйсың, Тин-Тиныч, тик белеп сайрамыйсың!

— Ә нәрсә?

— Имән түгел ич ул, юкә!

— Юкә? — Валентин күтәрелеп агач башына карап алды. — Юкә... Ну, юкә булса?!.

Егетләр Валентинны үртәп көлешеп алдылар.

— Мин шикләнә калдым әле, Тин-Тиныч, — диде Фәрхетдин. — Син, мөгаен, Ташлыярга баргач, Валяны да танымый кайткансыңдыр.

Җәйләүдә кызларның төшке савымны тәмамлаган чаклары гына иде. Күктән ингәндәй кинәт бер төркем егетнен килеп чыгуын күргәч, аптырап калдылар, көмеш кебек ялтырап торган савытларга сөт бушаткан җирләреннән туктап тордылар.

— Әбәү, болар каян шушы кадәр?..

— Менә кайда икән ул кызларның асыллары! — дип кычкырып җибәрде Фәрхетдин.

Аның белән рәттән басып торган Саакян күзләрен уйнатып алды.

— Ай, яхшы кызлар, ай, чибәр кызлар!

Кызлар, төрле якка егетләр чолгап алгач, бөтенләй югалып калдылар. Аларны уңайсыз хәлдән чыгарырга теләп, Валентин сүз башлады:

— Гаҗәпләнмәгез, кызлар, су эчәргә генә килдек!

— Сез кемнәр соң?

— Әллә су кемнең кемлегенә карап бирелә?

Бер чаясы алга чыгып басты да егетләргә чишмәне күрсәтте:

— Рәхим итегез, су чишмә тулы! — Күренеп тора: аның егетләр белән бик сөйләшәсе килә иде.

Ялыныч төшкәнне сизеп, кызларга җан керде:

— Әйе, әйе, кемнәр сез?

— Кайдан икәннәрен әйтмәсәләр, бирмибез!

Фәрхетдин, җиңнәрен сызгача-сызгана, сабан туе батырыдай уртага чыкты:

— Без каяннмы? СССРның кайсы почмагыннан телисез — шуннан!

— Аңлашылды! — дип, балаларча кулын чәбәкләп кычкырып җибәрде чаясы.— Нефтьчеләр! Беләбез! Ишеткән идек!

Кызлар бер-берсенең колагына иелеп нәрсәләрдер пышылдаша, көлешә башладылар. Берсе, колагына кечкенә алка таккан зифа буйлысы, зур гына сөт чүмече алды:

— Бәлки, әйрән эчәрсез?

— Әйрән! — дип кулын уып куйды Фәрхетдин.— Әйрән булса эчәрбез, туташ!

— Сөт эчәргә теләмисезме?

— Каймак кирәкмиме? — дип берсеннән-берсе уздырып китте сыер савучылар. Күрәсең, разведчикларга үзләренчә хөрмәт күрсәтүләре булды.

Ул арада терлекчеләр йортында табын да әзерләнде, өстәлгә табак белән катыгы да, чиләге белән әйрәне дә, агач коштабакларга мөлдерәмә итеп тутырып куйган сап-сары сөт өсте дә килгән иде.

— Рәхим итегез!

Дөресен әйткәндә, кызлар күргәч, егетләрнең аппетитлары да качкан иде, танышуга сәбәп булыр дип кенә утырдылар.

— Ә үзегез нигә утырмыйсыз?

— Без һәр көн сөт-катык эчендә...

— Юк инде, җәмәгать, булмый! — дип сикереп торды Фәрхетдин.— Кызлар карап торса, минем авызым ояла! Шундый чибәр авызны оялтасыгыз киләме?

Кызлар да табынга утырган булдылар. Ләкин яшьләр ашаудан бигрәк уен-көлке белән мавыктылар. Сапарбай белән Сергей күзләрен кызлардан алмадылар. Тин-Тиныч та астан гына кызларны күзләде: Валяга охшаганы юкмы ди торгандыр, ә Фәрхетдин бер туктамый шаян сүз, мәзәк ташлады:

— Менә кызлар, шулай. Кунак ашы — кара-каршы. Икенче атнага үзегез безгә килегез. Разведчиклар ярлы тора дип уйласагыз, ялгышкан булырсыз. Безнең дә үзебезгә күрә байлыгыбыз бар...

— Нәрсәгез бар? — дип кызыксынды кызлар.

— Нәрсәбезме? — Ул янындагы Тин-Тиныччка, аннан икенче ягындагы Сергейга карап алды.

— Нефтебез бар!

— Әйе, әйе, нефтебез бар. Нефть инде ул, җанкисәккәйләрем, барысы да дигән сүз. Безнең өйләр дә нефтьтән ясалган, җиһазларыбыз да, табак-савытларыбыз да, хәтта азыгыбыз да!..

Кызлар чырык-чырык көлеште.

— Ышанмыйсызмы? Палаткаларны нәрсәдән ясаган дип беләсез? Брезенттан. Ә брезент — ул нефть! Ә пластмасс савыт-сабалар? Нефтьтән! Өстәлдәге клеенка нәрсәдән? Ә азык? — Фәрхетдин кашык белән сөт чөмереп алды да уйланып торды.— Азык та безнең нефтьтән! Маргаринны нәрсәдән ясыйлар дип беләсез? Нефтьтән, әлбәттә!

— Монысын арттырып җибәрдең инде! — диде Сергей.

Фәрхетдин чынлап торып бәхәскә кереп китте:

— Нигә, алайса, «майгарин» түгел, «маргарин»? Әйтә алмыйсың шул! Парафин, стеарин, маргарин — алар, беләсең килсә, исемнәре үк бертуганнар!

— Син, бәлки, үзең дә нефтьтән ясалгансыңдыр?

Саакян барысын да гөж китереп көлдерде.

— Анысы инде синдер! Атаң нефтьче булган бит синең!

Тагын күтәрелеп көлештеләр.

Валентин аларның арасына керде.

— Туктагыз әле, егетләр, монда нефть турында лекция укырга килмәдек. Без бит әле бу чибәр кызларның исемнәрен дә белмибез. Танышып алыйк, булмаса!

— Үзегездән башлагыз! — диештеләр кызлар.

Фәрхетдин дилбегәне шундук үз кулына алды.

— Бездәнме? Рәхим итегез! — Кулы белән Валентинга күрсәтте:— безнең хөрмәтле Тин-Тиныч. Валентин Валентинович була, ягъни мәсәлән. Атаклы бораулаучы, атаклы вахта житәкчесе. Заманында атаклы моряк. Яше шактый узып бәрса да, өйләнмәгән. Дәрте бар, дәрманы юк, дигәндәй...

Валентин ачуланып Фәрхетдингә төртте:

— Арттырма син!

— Монысы — әрмән малае Сергей Саакян. Потомственный нефтьче. Шулай ук ялгыз. Безнеңчә дә яхшы сукалый — түбәсе карабодай саламы белән япкан, димәк...

Фәрхетдиннең шаян күзләре Сапарбайга юнәлде.

— Бу кечкенәсе казакъ баласы Сапарбай булыр. Үз илендә калымга акчасы житмәгәч, Татарстаннан бушлай кыз табып булмасмы дип килгән. Моны колагыгызга киртләп куегыз, кызлар!

— Уй, нәлэт! — дип сикереп торды Сапарбай.

— Сиңа сүз бирелмәде! — Фәрхетдин Сапарбайның җилкәсеннән басып утыртты.

Һаман сөт-катыктан кашыгы бушамаган Мотгәрәйгә дә чират житте.

— Авызына катык буялганга игътибар итмәгез,— дип төрттерде Фәрхетдин.— Бу түбәтәйлесе безнең Мотгәрәй булыр. Мут Гәрәй дисәң дә була, чөнки ул һәр көнне кайдадыр мутланып, югалып йөри. Ярлы крестьян баласы. Өйләнә алмаган.

Мотгәрәй кешеләргә ияреп көлгән булды, кызарып утырды. «Ну, теләңә тилчә чыккыры! Ачуны алыйм әле мин синнән!»

— Ә бу бәндә Фәрхетдин, түбәтәе бәрхетдин! Кияүдән кайткан тол хатыннар бар да аның бәхеттин! Теленә алданып тозагына каба күрмәгез, кызлар, сак булыгыз!

Терлекчеләр өендә кызлар белән егетләр ду килеп көлеште. Егетләрнең исеме, холкы әйтелеп беткәч, Фәрхетдин кызлар янына килде.

— Ягез, чибәркәйләр, хәзер инде сез безне таныштырыгыз!

Кызлар чырык-чырык килделәр, төртештеләр, ләкин берсенең дә исемен әйтәсе килмәде.

— Таныштырырга безнең тел бистәбез юк шул! — диде зифа буйлысы.

— Менә, мәсәлән, синең исемең ничек?

Кыз алсу янып торган йөзен каплап, иптәшләре арасына кереп яшеренде.

— Нәсимә ул, Нәсимә,— диде чаясы.

— Нәсимә? Исеме җисеменә туры килә!
— Ә үзеңнеке? Зәмзәмбану, Кислотабану?
Анысы өчен тагын башкалар җавап бирде:
— Саймә була!
— Саймә? Тоже ярыйсы исем...
— Ә синеке?
— Бәрикә.
— Фу, кызын тапканнар, исемен таба белмәгәннәр. Бәрәкалла!
— Ә синеке?..
Берсенең исемен икенчесе әйтә торгач, үзләре белән дә таныштырып бетерделәр кызлар. Баштарак уйлаганча, сыер савучылар алай ук кыргый булып чыкмады. Сүз разведчикларның эшләре, тормышлары, нәрсә белән шөгыльләнүләренә күчте.
Мондый чакта егетләргә сорау гына бир, алар сиңа берне биш итеп, бишне ун итеп сөйләр, тузга язмаганны әйтеп бирер.
Әнә Фәрхетдин үзен чолгап алган кызларга ничек итеп җир бораулаганын сөйли:
— Җир бораулау ул, кызлар, пүчтәкнең дә пүчтәге. Кулыңа борау аласың, җир куенына туры юл саласың. Бик тирәнгә китсәч, ничек дисеңме? Анда торба төшерергә кирәк. Менә мине шушы Тин-Тиныч — ул безнең начал кеше — билдән бау белән бәйли дә, борау тоттырып, торба эченә төшереп җибәрә. Кысан бераз, әлбәттә. Торба тар. Ә мин аста борам. Уйлап карагыз, мең метр тирәнлектә! Һава җитми. Тирлисең, билгеле, күлмәк сыгып алырдай була. Шулай сигез сәгать буена бораулыйсың. Ә Тин-Тинычка нәрсә: аксөяк кеше, аңа рәхәт — өстән кычкырып кына тора: «Күпме бораулადың, ничек анда, нефть исе килмиме? Ул син анда, забойда, шартла, ә сменаң бетмичә тартып алмас...
Кызлар, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бер-берсенә караша. Егетләр көлмичә авызларын чак тыеп тора.
Валентин, китәргә вакыт җиткәнен белдереп, Фәрхетдиннең борын төбенә сәгатен суза.
— Син күбрәк бораулап ташладың, ахры! Җәмәгать, дөньябызны онытмыйк!
— Менә бит, кызлар, күреп торасыз, хуҗа безнең нинди кырыс! Шулай буйсынып, баш иеп торабыз инде аңа. Бай абзый ят дисә — ятабыз, тор дисә — торабыз. Ашарга кушса — ашыйбыз, кушмаса — көтәбез. Безнең язмыш аның кулында...— Фәрхетдин мескен кыяфәткә керде.
Валентин кызлар янына килде дә бик итагатьле итеп баш иде:
— Гафу итегез, кызлар, безне эш көтә.
Матур гына сөйләшеп, шаярышып, көлешеп торганда, Тин-Тинычның сүзе аяктан еккандай тәэсир итте үзләренә. Кызлар күңелсезләнеп калды.
— Татар ашар да качар дигәндәй, нигә ашыгасыз? — диде чая кыз Саймә.— Әллә җәйләүне ошатмадыгызмы?
— Бик тә рәхмәт сезгә. Тагын килербез.
— Гармун алып килегез.
— Җырлый беләсезме?
Җырлый да беләбез, бии дә беләбез! — диеште сыер савучы кызлар.— Музыкагыз гына булсын!
— Киләбезме, егетләр!
— Киләбез!
Аз гына вакыт эчендә бу шаян егетләргә ияләшеп алган кызлар да, Язтургайның оялчан кызларын үз итәргә өлгергән егетләр дә теләмичә генә, үкенешеп кенә аерылыштылар.

Камил буровойда бик кызыклы хәлләрнең шаһите булды бу арада.

Турбобуры-ние белән забойда бораү кысылып калмаса, бораулау эше тыныч, ансат, мәшәкатьсез дип йөрисе булган икән. Чөнки Камилнең күз алдында гына да ике йөз метрдан артык җир төшелде — һичнинди авырлык сизелмәде. Эш күңелсезләнә башлаган кебек булган иде.

Авырлык килгән чакта кеше үзгәрүчән була икән. Моңа кадәр тупас кына кыланган помбур Еланский да ягымлыланып, яхшырып киткән төсле булды. Камилгә «брат» дип кенә дәшә хәзер. Верховой Миргазиян, киресенчә, бераз житдиләнде — «кош оясында» җырлап кына утырмый.

Һәр хәрәкәте үлчәүле булган Кадермәт абыйсы гына һаман бер көенчә калды. Ул эш вакытында шаяргәнны яратмый. Син аңа гына дикъкать итәргә, аның нәрсә таләп иткәнен аңларга тиеш.

Забойда торпедо төшереп шартлатканны бик тә күрәсе килгән иде Камилнең — вахтасы туры килмәде. Әкәмәт кызык булган диләр. Хәтта контордан директор да, баш инженер да, геолог та килеп карап торганнар.

Камилнең бәхетенә җир астында калган торбаларны гына чыгару насыйп булды. Күрәсең, бу торпедо дигәннәрендә җен көчләре бар: бүрәнә юанлыгы торбаны өзгән дә ыргыткан. Өзмәгән дә — муенын борып ыргыткан.

Торбаны алыштырып, яңа турбобур, яңа бораү куеп бораулый башлаганчы, тагын смена үтеп китте — яңа инструментның җир астына ничек төшкәнен тагын Камил күрә алмады.

Бу килүендә «бораү забойда» диде Кадермәт абыйсы. Димәк, ишелгән зонаны Саакян вахтасы белән Тин-Тиныч вахтасы бораулаганнар, болар вахтасына тагын берниндн кызык та калдырмаганнар булып чыга.

Тәмам кәефе китеп, моны ул Кадермәт абыйсына әйтте. Бик житди эшкә керешкән Кадермәт елмаеп куйды:

— Иң кызыгы да хәзер шушында. Безнең бурыч: забойда өзелеп калган турбобур белән борауны әйләнеп үтү һәм туры юлга чыгу.

Яшь бораулаучы эш арасында гел Кадермәт абыйсын күзәтте, ләкин аның йөзендә шатлык та күренми, борчылу да сизелми иде. Вахта житәкчесенең кулы, әүвәлгечә үк, тормоз рычагында, күзләре приборда.

Дүрт-шатыр килеп ярты сәгатьләр эшләгәч, Камил түзмәде:

— Туры юлга төштекме әле? — диде.

— Иске бораү юл бирми бит, нәләт!

— Ә сез каян беләсез аны, Кадермәт абый?

— Беләм, энә, ишетәсеңме, күчәрләре орынды.

— Без андый чакта күчәр ордырган кешенең атына камчы белән тамыза торган идек!

— Әйе, бу да минем атка тамызып маташа шул...

Еланский Камилгә карап тора да баш селки:

— Бик төпченүчән булып чыктың әле, егет. Нәкъ менә Нигәалай малай төсле!

Тагын тавышсыз-тынсыз гына эшләп киттеләр. Бераздан янә Камилнең соравы:

— Ничек анда аста, Кадермәт абый, аерылышып китә алдылармы?

— Алуын алдылар...

Димәк, юл бирешкәннәр булып чыга. Тагын нәрсә житмәде икән? Нәрсә бүлешәселәре бар икән бу бораўларның — монысын әлегә Кадермәт абыйсы әйтми. Сер... Бәлки, чыннан да сугыша торганнардыр?

Камил кызык кына итеп забойда ике бораунын сугышын күз алдына китерде. Бу яңасы: «Булдыксыз, менә карап тор ничек бораулаганны»,— дип үртәп узып барадыр, ә ватылып калганы: «Нигә минем янга төштең?» — дип, көндәшенә корыч тешләре белән ябышадыр...

Буровойга Зөбәеров килде. Платформа янына туктап озак кына буровой тавышын тыңлап торды, бораулаучыларның эшләрен күзәтте, аннан Кадермәт янына басты. Саңгырау кешеләр кебек бер-берсенең колагына иелеп кычкырып сөйләшә башладылар:

— Исән-сау үттегезме?

— Үтүен үттек... Минемчә, бора ялгыш юл белән китте.

— Мин аны уйлаган идем... Нәрсә эшлибез, ничек турылыйбыз скважинаны?

— Бераз төшмичә барыбер борып булмас, мастер.

Камил аңлады хәзер Кадермәт абыйсының бая сүзне өзеп әйтмәвен. Менә нинди хикмәт икән аста. Борау адашып кереп киткән икән...

Ә каян барысын да белә ул Кадермәт абый? Эх, аның кебек җир астындагы нәрсәләрне күреп тора торган могҗизалы кеше буласы иде!

Хәзер инде Камилнең бар уе-хәсрәте адашып, ялгыш юлга кереп киткән бораудa иде. Нефтькә дип әллә кая китеп баруы мөмкин бит аның. Дилбегәсе-ние юк, юнәлешен ничек үзгәртәләр икән ул бораунын?

Барыбер белә алмый кайтып китәргә туры килде бу юлы. Кызганыч, смена тәмамланды.

Икенче килүендә тагын бик күп нәрсәләрне күрми калган булып чыкты. Зур машиналарда кароаттажчылар килгән — скважинага резин көпшә төшереп, бораунын кайсы якка, ничә градус авышлык белән киткәнен үлчәгәннәр. Кадермәт абый әйтә: бораy гел кире якка, Язтургайга таба китеп барган, ди. Хәзер аны йөз сиксән градус белән борырга туры килә, ди.

Моның остасы Кадермәт түгел, ә мастер Зөбәеров икән. Ул турбобур белән бораyны скважинадан чыгаргач, аларны кәкре трубага кигерде һәм скважинага төшерде:

— Хәзер туры юлга төшкәнче бораула да бораула!

Кадермәт яңадан идарә пультенә килеп, рычагларга ябышты. Аларның берсен күтәрә, икенчесен төшерә, аягы белән алмаш-тилмәш педальләргә баса. Аны комбайнда барган итеп тә, руль артында автомашинада итеп тә, яхшы ат туткан кучер итеп тә күрә Камил. Менә хәзер урыныннан куптарып, буровойны сөйрәтеп китәр төсле Кадермәт абый. Ничек икән аста, бораy Язтургай ягыннан Баланлыга борыла башладымы икән? Әллә «кайтмыйм» дип киреләнеп маташа микән?

Эшли торгач, биш-алты сәгатьләр вакыт узды. Камил генә түгел, кин җилкәле Еланский да, Кадермәт абый да арыды. Әнә ул туктап бияләй сырты белән маңгаеннан тирләрен сыпырып ала. Вахта җитәкчесен Камилнең әле алай күргәне юк иде. Ул агарынган, куллары белән рычагларга чак тотынып тора.

— Мә әле рычагын, Геннадий, әллә нәрсә кәеф юк...

Идарә пультенә Геннадий баскач, Кадермәт бер читкә китеп утырды.

— Нәрсәгәдер йөрәк сикерә...

— Бүген эш тә ай-яй күп булды бит,— диде Геннадий.— Кеше түгел, ат чыдамас!

Тәмәке тартып алгач, тагын үз урынына килде Кадермәт. Ләкин ярты сәгатьтән тагын йомшап төште, рычагларны җибәреп, кулы белән маңгаен тотты.

— Күңел болгана... Авырыйм, ахрысы... Бар әле, Камил, мастер...

Сүзен әйтеп бетерә алмыйча, чайкалып китеп, шәмнәргә барып сөялде, аннан гөрселдәп буровой идәненә ауды.

Өстән г:рховой Миргазиян йөгереп төште.

— Нәрсә карап торасыз, әйдә, алып чыгабыз!

Өчәүләп һушын җуйган Кадермәтне тышка, саф һавага күтәреп алып чыктылар.

— Бар, син мастерны алып кил!

Берничә минуттан буровойга Зөбәеров, аның артыннан өере белән егетләр чабып килде.

— Кадермәткә ни булды?

Кадермәтнең йөзе көл кебек ак, иреннәре күгәреп каткан, күзе йомык. Ул, авызын зур ачкан хәлдә, күкрәге белән авыр сулап ята.

Зөбәеров вагонга кереп телефоннан Язтургайга — авыл Советына шалтыратты:

— Зөбәеровага кереп әйтегез, әйе, фельдшерга. Буровойда кеше үлем хәлендә. Сәбәбе билгесез. Һушы юк. Әзерләнеп торсын, килеп алабыз!

Буровойны да озак туктатып торырга ярамый иде. Забойда инструмент ябышып калуы мөмкин. Вахтага Сергейны куеп, егетләргә Кадермәтне карап торырга кушып, Зөбәеров машина белән Язтургайга чапты.

Рәйсә белән Зөбәеров килгәндә инде Сергей Саакян да нәкъ Кадермәт хәлендә ята иде... Аны, башы әйләнә башлагач, Еланский белән Камил култыклап алып чыкканнар — Сергей чыккач егылган. Ул бераз аңында, иреннәрен чәйни-чәйни, торырга азаплана иде.

— Газ килә бит скважинадан! — дип кычкырып җибәрде Зөбәеров.— Якын килмәгез буровойга! Тәмәке тартмаска!

Рәйсә агуланучыларга ашыгыч ярдәм күрсәткән арада, Зөбәеров скважинаны кереп карады. Әйе, сизелер-сизелмәс кенә газ чыгып ята. Җил аны нәкъ бораулаучыга өргән, ярдәмчеләре сизмәгән, читтә калганнар. Нишләргә?

— Сөт кирәк, сөт! — дип кычкырды Рәйсә Зөбәеровка.— Агуны җиңсә сөт җиңә, бары сөт кенә!..

*Ахыры бар*

## Разил Вәлиев

### Тормыш асылы

Ни җәй түгел, ни көз түгел җирдә —
Урталыгы ике фасылның:
Оныта бара кошлар сайрауларын,
Нидер көтеп мин дә басылдым.

Кышкы причал кебек буп-буш йөрәк.
Сөенеч тә юк, каргыш, ачу да.
Туй төшәсе йорттай... күңелемнең
Капкалары шәрран ачылган.

Җиңел үлем булмый. Качып елый,
Болытларга качып агълый җәй...
Көз — җиңүче! Көз тантана итә,
Ике бите ике алмадай.

...Тынычлыгын бүлдерергә куркып,
Исеме юк шушы фасылда,
Әкрен генә көзгә керә барам,
Төшенә барам тормыш аслына.

### Чакырма

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
Өметтәй олы ул диңгез,
Күз яше кебек тозлы.

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
...Сезнең яктан килгән болыт
Күкне күкрәтеп узды.

Күкрәгемне ачып тордым
Саф диңгез һавасына.
Яңгыр түгел, синең сагыш
Болыттан ява сыман.

Чакырма син үз иленә,
Чакырма, диңгез кызы.
Җибәрми туган ягымның
Давылы, кары, бозы.

Өмет кебек олы диңгез,
Яшьләрем кебек тозлы...
Сагышларым болай да күп...
Чакырма, диңгез кызы.

●

Бүген тагын мине ташлап киттең...
Төне буе сине эзләдем.
Таңга кадәр мөлдерәшеп торды
Бар йолдызлар — синең күзләрең.

Күзләреңдәй күктә бар йолдызлар,
Синең сының кебек бу таллар,
Син киткән юл кебек айның юлы...
Мин адашам, абынам, буталам.

Йолдызларга үреләм — буем җитми,
Кочагыма сыймый таллар да...
«Ул кайда?» дип гөлләр сорасалар,
Мин ни диеп әйтим аларга?..

Син кайт инде... Йолдызларны кызган...
Алар кабат көләч булсыннар...
Кояш чыгып килә... Кояш юлы
Син кайтачак алтын юл сыман.

## Сине озатканда

Сагынуым басылмады әле,
Ачылмады синең йөрәгең,
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем.

...Билет юктыр бүген самолетка,
Буш урыннар юктыр поездда,
Трамвайлар шыгрым тулы халык,
...Җил дә, әнә, моңлы җыр суза.

Адашырсың... Күктә йолдызлар юк,
Юл тапмассың... Төн бик караңгы.
Тутырыр күк айсыз, йолдызсыз төн
Синең белән минем араны.

Көз сагышы миңа күчте, дисең...
Телисеңме? — Хәзер яз ясыйм!
Чәчәк белән күмәм йөрәгеңне —
Мәхәббәтнең алсу вазасын.

Кирәк түгел чәчәкләрең, дисең,
Кирәк түгел язлар ясавың:
Калсам — бары мине табарсың син,
Китсәм — сагынып җырлар язарсың...

Ничек итеп җырлар языйм ди мин? —
Ачалмадым синең йөрәгең...
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем...

## Игенчеләр нәселе

Җиргә иелеп сабан сөргән бабам,
Чалгы селтәп чапкан печәнне.
Аршин түгел, метр, сажин түгел —
Өмет булган җирнең үлчәме.

Гомерендә алтын күрмәгән ул,
Көмешләр дә кулга төшмәгән.
Алтын төсен күргән игеннәрдә,
Көмеш сулар эчкән чишмәдән.

Ракеталар очмаса да ул чак,
Ай турында җырлар җырлаган.
Ачмаса да йолдызларның серен,
Күккә карап язмыш юраган.

Вакыт җитте инде галәм иңләп
«Карурман»ны җырлап үтәргә...
Тик һаман да туган җирне сөю
Җитеп бетми әле күпләргә.

Нәселемә мин хыянәт итмәм! —
Игенчеләр безнең ыруда.
...Бураэналар ярып барсаң иде
Шигъриятнең яшел кырында.

## Казан вокзалы

Ниләр уйлый Мәскәү бу көннәрдә?
Ниләр уйлый Казан вокзалы?
Тасма кебек яткан рельсларның
Казандамы очы, азагы?

Ак кермәнең һаман акмы, Казан?
Элеккедәй киңме Иделең?
Син бит миңа: туу, сөю, тормыш,
Шатлык, кайгы, яшәү... һәм илем.

Мәскәү белән Казан арасында
Дуслык җебе кебек рельслар...
Ике туган төсле ике шәһәр,—
Казан белән Мәскәү — гел дуслар.

## Хәйдәр Гатин

### Әни искә төшкәндә

1

Хәтерләмим күңел ачкан көнен
Урман-болыннарга бер чыгып.
Гомере узды эштә ил белән өй
Иминлеге өчен борчылып.

Уңышыбыз өчен бер сөенсә,
Мең көенде ялгыш адымга.
Нәтиҗәсе менә!
Дигән төсле,
Салкын кабер тора алдымда...

2

Тормышымда якты бер юнәлеш
Биреп килә иде һәр көнне.
Бүген шаулы диңгез уртасында
Бер ялгызым калдым шикелле...

Таралдылар дуслар берәм-берәм,
Минем белән, бүлмә тутырып,
Кара кием кигән олы кайгы
Гомерлеккә калды утырып...

### Табигать туе

Тал-тирәкләр, гөлләр сусаганнар,
Урман-болыннарга дым кирәк.
— Мин киләм, мин юлда! — дигән төсле
Тавыш бирә-бирә күкрәп,

Күтәрелеп чыкты зәңгәр болыт,
Еракгагы офык артыннан,
Торган саен якынлаша барды
Әкияттәге сихри ат сыман.

Томырылды урман-кыр өстенә
Тузгып китте бәдрә яллары.
...Кинәт искән дымлы салкынча җил
Башын сыйпап узды талларның.

Киң болында үскән каеннарны
Сагынып кайткан кебек күрергә,
Йөгереп килеп яңгыр кулы белән
Кочагына алды өермә.

...Утлы угын атты күктә яшен,
Менә тагын күкрәү яңгырар...
Һавадан җир пуля, бомба түгел,
Көтә бары җылы яңгырлар.

## Кара күзле ак бәхетем

Йөзен тулган ай тәсле ак,
Күзләрең кара синең,
Көнләшеп карый бакчадан
Ак чәчәк аткан сирень.

Аякларым җиргә тими,
Кош кебек очам гына.
Кара күзле ак бәхетем,
Ал мине кочагыңа!

Гамил Афзал

# КАРАБАШ КҮЛЕНДӘ

хикәя

Ятып торган гаять зур хайванның сыртына охшаган Карабаш тавы итәгендә, вак таллар ышыгында гомер-гомер тыныч кына агып яткан Зәйне нефтьче комсомоллар буган да, бик зур буа хасил булган. Буага маймыч җибәргәннәр, балык мыж килеп үрчеп, үсеп ята. Буаны комсомоллар буасы да, Карабаш күле дә, хәтта Карабаш диңгезе дип тә җибәрәләр. Диңгез дисәң, бик зурдан кубу булыр, буа дисәң, хәтере калыр, бик кечерәйтеп, ямен җибәреп әйтү булыр дигәннәрдер, хәзер аны авыз тутырып Карабаш күле дип йөртәләр.

Без — Сафуан, Тәлгат, мин — хатыннарны, бала-чагаларны ияртеп, Карабаш күленә ял итәргә килгән идек. Тәлгатнең моторлы көймәсе бар, хатыннар ятьмә, сумка белән азык-төлек күтәргәннәр. Күңелләр көр, кәефләр шәп чак. Күктә йөзеп барган бәләкәй генә күгелҗем болытның шәүләсе тау сыртыннан шуып бара. Карабаш күле, чын диңгезгә охшарга тырышкандай, зур-зур дулкыннарын шап-шоп ярга бәреп яткан була. Күл буенда рәхәт, җиләс икән, суның салкын сулышы күңелләрне күтәреп, ничектер сафландырып җибәрде.

Тәлгат яр буенда чайкалып торган көймәсенә моторын беркетеп куйды, аннары төенчекләре, сумкалары белән хатыннарны утыртты, бала-чаганы төяде. Дөп-дөп итеп мотор кабыну белән көймәгә җан керде, ул салмак кына кузгалып, алга ыргылды, карлыгач кебек кыеклатып, киң дуга ясап зәңгәр су өстен сыздырып-сөздереп кенә китеп барды. Хатыннарның косынкалары җилфердәде, бала-чаганың, кош тоткан кебек, шат чырайлары ялтырап калды. Очтылар гына.

Без бер папирос тартып бетергән арада көймә тагын күренде. Тәлгат безне алырга килеп тә җитте. Сафуан белән тәвәккәлләп, көймәгә кереп утырдык. Кузгалдык, кыеклатып, дугалатып күл өстенә кереп тә киттек. Тыгыз җил куенга керә, тәнне кытыклый, чәчләрне тарата. Зәп-зәңгәр су өстеннән очып кына баруы, һай, хозур икән.

Под ним струя светлей лазури,
Над ним луч солнца золотой...

Карабаш тавының текә итәге буйлап, суны ярдырып барабыз. Ярда контта кызынып ятучылар, кармак салып утыручылар ялты-

рап торган җиңел машиналары янында трусиктан гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә кайнашкан һавалы агайлар, кыйммәтле бюстгальтер кигән, бөдрә чәчле тәкәббер ханымнар күзгә чалынып кала.

Әнә яр читендә генә ак күлмәкле бер хатын белән бер малай утыра. Болар кояшта кызынмыйлар, күзләрен бер ноктага текәп, иякләрен тезбашларына куеп, тып-тын уйга талганнар. Малай юа-юа уңган кызыл күлмәк кигән, хатынга сырышып, боек кына утыра; уйнамый, сикерми, таш ыргытмый, боларның кайгылары бардыр, кайгылары күлнең нәкъ шушы урыны белән бәйледер дип уйладым мин. Ялт итеп үтеп киткән көймәгә алар күтәрелеп тә карамадылар.

Күл уртасында йөзек кашы чаклы гына яшел утрау бар икән. Шуннан безнең балалар сикерешә-сикерешә кул болгадылар. Көймә утрауга килеп төртелде, мотор тынды. Без утрауга төштек. Тәлгат хатыны белән Сафуан хатыны, чыбык-чабык җыеп, учак тергезеп яталар, минем хатын газета җәеп табын әзерли. Болар балык кыздырмакчы, чәй кайнатмакчылар икән.

Без трусиктан гына калып, утрауны бер әйләнеп чыктык. Үзебезне Робинзоннар итеп хис иттек. Сафуан белән Тәлгат көймә койрыгыннан суга сикереп, атлар кебек пошкыра-пошкыра чума, йөзә башладылар. Бала-чага чыр-чу килеп су кердә, су чәчрәтә, сөенечнең игечиге юк. Ун ел инде суга сикергәнем, ялан аяк йөргәнем юк иде, кыргыйларга әмма рәхәттер бу дөнья. Мин йөзә белмәгәч, билдән суга кереп, тегеләрнең бәхетеннән көнләшә-көнләшә, җыр җырлаган булам.

Суда Сафуан йөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер шул, сизәдер.
Табагызда бер балык бар,
Шул балык анын үзәген өзәдер, шул...

Судан күшегеп чыккач, халык табын янына кырын-ярын яткач, уен-көлке бетте. Балык гаҗәп тәмле, ә чәй... Мондый чәйне гомергә эчкән юк иде кебек.

Көн сүрелә төшкәч, шау-гөр кузгалып кайтырга җыена башладык. Тәлгат башта хатыннарны, бала-чагаларны төяп алып китте, аннары безне алырга килде. Юеш чәчләрне җил киптерә. Тагын текә тау итәге буйлап элдерәбез. Бәйләнде бит миңа ике юл шигырь, дога кебек укып барам:

Под ним струя светлей лазури,
Над ним луч солнца золотой...

Кояшта кызынучылар киткәннәр инде, кармак салып утыручылар да сирәгәйгән. Теге хатын белән малай һаман хәрәкәтсез утыралар. Малай хатынга сыенып, башын иеп, суга текәлгән, хатын баягыча тезләрен кочаклап, ияген тез башларына куеп, алдына карап утыра. Без утрауда күпме юанганбыздыр, ә алар кузгалмаганнар да.

Күк йөзеннән соры болытлар ага, су да ачык зәңгәр төстән күгелҗем-кара төскә керде, салкынча җил исә башлады. Ятып торган гаять зур хайванны хәтерләткән Карабаш тавының төсе, яме үзгәрде. Ул моңайган, язмышына буйсынган, юашланган ятим кебек, төсе дә эчпошыргыч соры, бертөрле, күңел биздергеч иде. Мин артка борылып карадым, соры тау фонында бәләкәй генә ак һәм кызгылт нокта булып, хатын белән малай утыра иде.

Миңа кинәт күңелсез булып китте, шушындый көндә ял итеп, күңел ачып йөрү гаеп эш кебек тоела башлады. Берәүләргә бәхет, шатлык, икенчеләргә кайгы-хәсрәт китерә дә тора шул бу дөнья.

Байтак еллар үтте. Шул тау итәгендә ак күлмәкле хатын белән уңган күлмәкле малай һаман моңаеп утыралар кебек тоела әле.

Малик Хәмитов

# БӘХЕТЛЕ ЯЗМЫШ

Мәскәү. Патрис Лумумба университеты.

Күп катлы бу бинага килеп керү белән үзеңне бөтенләй бүтән дөньяга эләккәндәй хис итәсең. Иң башта ыгы-зыгы килеп йөргән студентларның киемнәренә күзең төшә. Чуп-чуар. Битләренә, күзләренә карыйсың. Күбесе безнең халыкка охшамаган. Менә бөдрә чәчле, баһадир гәүдәле негр. Бите чуен шикелле кап-кара, ә тешләре энҗе кебек ялтырап тора. Күзләре ягымлы, хәрәкәтләре салмак. Үзе кебек үк бер студент белән чатнатып русча сөйләшә. Тирә-юньдә — шау-шу. Ара-тирә гарәп, испан, инглиз, грек, француз телендәге сүзләр ишетелеп кала. Тәнәфес вакыты.

Профессор белән сәгать унберда очрашырга сүз куешкан идек. Ашыга-ашыга өченче катка күтәреләм.

Кафедра мөдире бүлмәсенең ишеген шакыйм. Профессор үзе генә.

Ул мин керүгә урыныннан торып, каршы килде. Күрештек.

— Казандагы 13 нче мәктәп пионерлары сезгә сәлам әйтте,— дидем мин, сүзне башлап җибәрү өчен.

Профессорның күзләре нурланып, яктырып китте:

— Рәхмәт,— диде Габделхак абый, якын итеп мине култыклап алды.— Ул мәктәпнең почетлы пионеры бит мин. Димәк, онытмыйлар...

Әйе, Габделхак Галиуллин Казандагы 13 нче мәктәпнең алдынгы укучысы булган. Шунда беренче тапкыр муенына ал галстук таккан. Әдәбият түгәрәгенә йөргән. Пионер Габделхак язган хәбәр, шигырьләрне ул елларда чыккан «Яшь ленинчы» газетасында да, «Пионер каләме» журналында да очратырга мөмкин. Аның бер шигыре «Шат балалык» исемле альманахка да кертелгән. Габделхак хәтта Татарстан язучыларының беренче съездына делегат итеп сайланган. Ул анда пионерлар исеменнән чыгыш ясаган. Бу турыда Максим Горький «Правда» газетасында язып та чыккан.

«...Казанда язучылар алдында,— ди ул «Малайлар һәм кызлар» исемле мәкаләсендә,— ике пионер чыгыш ясады: берсенә 12 яшь (анысы — хәзерге балалар язучысы Гарәфи Хәсәнов. Ред.), икенчесенә — 14...

Икенчесе, 14 яшьлеге, шактый зур речь сөйләде. Менә аннан кайбер өзекләр:

— Безнең 13 нче мәктәптә әдәбият түгәрәге бар. Ул шактый яхшы эшли. Түгәрәк членнары, пионерлар, әдәбият белән кызыксыналар. Алар белемнәрен күтәреп, әдәбиятны тирәнрәк өйрәнергә тырышалар...



Әсәрләрдә тере мажаралар да, юмор да җитми... Мин барлык пионерлар исеменнән әсәрләргә көлке моментлар күбрәк кертүегезне үтенәм.

Рус әдәбиятында балалар өчен кызыклы китаплар бик күп, шуларның иң яхшылары татарчага тәрҗемә ителсен иде...

Безнең пионерларның акчасы юк. Китап бәяләре югары. Шулай булуга карамастан, тышлыклары шәптән түгел. Без нәшрияттән һәм оргкомитеттан балалар китапларының техник яктан яхшы басылуын һәм арзан булуын үтенәбез...

Иптәшләр, зур язучылар, без сездән безнең газета-журналларда катнашуыгызны сорыйбыз. (Көчле кул чабулар.) Өлкән язучыларыбызның безгә якынаюларын телибез»... [1]

...Безгә бу юлы озак сөйләшеп утырырга туры килмәде, звонок шалтырады.

— Гафу итегез,— диде Габделхак абый, урыныннан торып.— Хәзер миңа лекциягә керергә кирәк. Бәлки, сез дә кереп утырырсыз.

Мин, әлбәттә, шатланып риза булдым.

Аудитория зур түгел. Һәм ул Казандагы яки бүтән шәһәрдәге югары уку йортлары аудиторияләреннән берни белән дә аерылмый. Озынча өстәлләр, урындыклар... Каршыда — кара такта.

Студентлар Габделхак абыйны аяк өсте басып каршы алдылар. Профессор, студентлар белән исәнләшкәннән соң, лекциянең темасын әйтте: «Механик системаларның хәрәкәт принциплары». Студентларның җитди карашлары профессорга текәлде. Төрле илләрдән килгән төрле милләт кешеләре алар. Әнә, икенче рәттә утырган өч егет һәм беренче рәттәге мыеклы студент, әлбәттә, Африка илләреннән. Дүртесе дә негрлар. Ә тез борынлы, зур кара күзле, озын чәчле кызның кайсы илдән икәнлеген әйтүе кыен. Ачык зәңгәр күзле, аксыл-сары төстәге бөдрә чәчле, ап-ак йөзле егетнең дә, үзеннән сорамыйча, кайсы илдән килгәнлеген белеп булмый. Хәер, нигә баш ватарга? Дөньяның йөзгә якын иленнән килеп укыйлар бит алар...

Азия, Африка, Латин Америкасы илләрендәге прогрессив фән һәм культура эшлеклеләре, кайбер хөкүмәт җитәкчеләре барлык халык вәкилләре бертигез хокук белән белем алырдай югары уку йорты булдыру турында күп мәртәбәләр сүз кузгаттылар. Мондый югары уку йортын оештыру өчен иң кулай ил — Советлар Союзы. Бездә зур белемле галимнәр, укытучылар, лабораторияләр өчен кирәк булган катлаулы фәнни җиһазлар бар. Фәнни казанышларыбыз зур. Иң мөһиме — халыклар арасында дуслык, туганлык хисенә бездә зур ихтирам белән карыйлар.

1960 елның февралендә Мәскәүдә андый югары уку йорты — Халыклар дуслыгы университеты ачылды. Африкада милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе, Конго республикасының беренче премьер-министры истәлегенә бу университетка Патрис Лумумба исеме бирелде.

Төрле илләрдән килгән студентларның яшәүләре, дәваланулары, укулары өчен кирәк булган барлык чыгымнарны Совет хөкүмәте үз өстенә алды.

---

[1] Татарстан язучыларының I съездында пионер Габделхак Галиуллин сөйләгән речь «Кызыл Татарстан» газетасының 1934 ел, 2 август санында басылып чыккан.

Хәзер инде Патрис Лумумба исемендәге халыклар дуслыгы университетын тәмамлаган меңнәрчә белгечләр — врачлар һәм агрономнар, инженерлар һәм геологлар, укытучылар һәм галимнәр — дөньяның төрле почмакларында үз халыкларына, үз илләренә хезмәт итәләр.

Менә хәзер дә төрле ил халыкларының бер төркем вәкилләре — инженерлык факультетының өченче курс студентлары — техник фәннәр докторы, профессор, безнең якташыбыз Габделхак абый Галиуллинның теоретик механика буенча лекциясен тыңлыйлар. Студентлар профессорның һәр сүзен хәтерләренә сеңдереп калырга тырышалар.

Профессор лекцияне җанлы әңгәмә формасында алып бара. Һәр формуланың асылына төшенү өчен үткән дәресләрне искә төшерергә кирәк. Шуңа күрә Габделхак абый яңа формуланы чыгарыр алдыннан әледән-әле студентлар алдына сораулар куя. Бу сорауларга җавап бирергә стуентларның һәрберсе әзер. Әлеге зур күзле, тәз борынлы кыз һәм негр егете аеруча активлар. Һәр сорауга бик теләп җавап биреп баралар...

Университетта мин берничә көн булдым. Профессор Галиуллинны үзе белән бергә эшләүче галимнәр дә, аның җитәкчелегендә тикшеренүләр алып баручы фәнни хезмәткәрләр дә, аспирантлар да, студентлар да хөрмәт итәләр. Теоретик механика кафедрасы ассистенты, физика-математика фәннәре кандидаты Роберт Мәхәрләмовтан мин моның сәбәбен сорадым.

— Аның кул астында эшләгәндә,— диде Роберт,— үзеңнең даими үсәнеңне сизәсең, Габделхак абый белән сөйләшкәннән соң, үзеңне сафланып киткәндәй тоясың. Кешенең күбрәк яхшы якларын күреп, шуңа басым ясап тәрбияли ул. Кимчелекләреңне куңелгә тимәслек итеп әйтә белә. Ә бу күбрәк тәэсир итә. Үзен синең белән тиң итеп тота. Студент белән дә, аспирант белән дә бик гади мөнәсәбәттә — әйтерсең ул һәрберсе белән гомер буе дус булган! Һәркем өчен ул кайгыртучан иптәш, якын дус. Синең шатлыгыңны да, кайгыңны да уртаклашырга һәрвакыт әзер тора...

Профессор Галиуллин шәкертләре, әлбәттә, бер Роберт кына түгел. Илледән артык галим аның җитәкчелегендә докторлык һәм кандидатлык диссертациясе яклаган. Алар Мәскәүдә генә түгел, Казанда, Саратовта, Алма-Атада, Чимкентта һәм илебезнең башка шәһәрләрендә, шулай ук чит илләрдә фәнни-тикшеренү эшләре алып баралар. Профессор Галиуллин югары уку йортларының физика-математика факультеты студентлары өчен дәреслекләр дә язган, һәм ул бик күп фәнни хезмәтләрнең авторы да.

Профессор Галиуллин җитәкли торган даими семинарда илебезнең күренекле галимнәре теоретик механиканың хәзерге заман өчен гаять мөһим мәсьәләләрен тикшерәләр.

Әйе, Казан шәһәрендәге 13 нче мәктәпнең элекке пионеры, балалар өчен чыга торган газета-журналларның актив хәбәрчесе Габделхак Галиуллин хәзер илебезнең күренекле галиме, җәмәгать эшлеклесе, оста педагог һәм кайгыртучан тәрбияче. Ә ул моңа ничек ирешкән соң?

Грузчик семьясында туып-үскән Габделхак урта мәктәптә бик тырышып укый. 1938 елда мәктәпне «отлично» билгеләренә генә тәмамлый һәм Казан дәүләт университетының физика-математика факультетына керә. Әмма өченче курсны тәмамлагач, укуын калдырырга туры килә аңа: сабакташлары белән бергә фашистларга каршы сугышка китә. Югары командование аны, укуын дәвам иттерү өчен, фронттан Хәрби академиягә җибәрә. 1944 елда академияне тәмамлап, Габделхак Галиуллин инженер-механик дипломы ала һәм Хәрби-һава училищесында эшли башлый. 1947 елда Мәскәү авиация институтының аэродинамика кафедрасына аспирантурага кабул ителә. 1950 елда — кандидатлык, 1957 елда докторлык диссертациясен яклый.

Профессор Габделхак Галиуллин Патрис Лумумба исемендәге халыклар дуслыгы университетындагы физика-математика факультетын һәм теоретик механика кафедра-

сын оештыручыларның берсе. Ул анда ун елдан бирле инде лекция укый, фәнни хезмәткәрләр тәрбияли, катлаулы теоретик һәм практик фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. Габделхак Галиуллин биредә университет парткомы, Гыйльми совет члены, «СССР — Алжир дуслыгы җәмгыяте» члены, төрле гыйльми комиссияләр председателе. Кыскасы, ул университетта иң хөрмәтле кешеләрнең берсе...

...Лекция тәмамлануны белдереп звонок булуга инде әллә кайчан. Әмма студентларның профессорны үз яннарыннан җибәрәселәре килми. Һәрберсенең аңа йомышы бар.

— Дәреслектән укыганда көч-хәл белән генә аңлашыла, ә сез сөйләгәндә бик гади булып тоела,— ди Кипр кызы.

Икенчесе тема буенча өстәмә чыганаклар белән кызыксына, өченчесе теоретик механикага бөтенләй бәйле булмаган сорау бирә, дүртенчесе Кения студентларының дуслык кичәсенә чакыра...

Ә кафедра бүлмәсендә аны аспирант кыз Люся көтеп тора. Аңа, диссертациясенең бер өлешен укып, консультация бирәсе бар. Кичен казакъ егете Кирәй Мостакишев кандидатлык диссертациясе яклый...

Кутузов проспектындагы квартирасына Габделхак абый күп вакытта соң гына, төн җиткәч кенә кайтып керә. Шактый арган булса да, канәгать ул, чөнки көн буген дә файдалы эш белән үтте, бүген дә кешеләргә яхшылык эшләнде. Шәкертләренең берсе — Кирәй Мостакишев — чын галим булып җитлеккәнлеген раслады. Аның диссертациясен Гыйльми совет членнары яхшы дип таптылар. Ә бу профессор Галиуллин өчен дә зур шатлык...

## Мәгъсум Насыйбуллин

# ПРОКУРОР

## Туганлашу



Мин аны республика прокуратурасында очраттым. Иң элек җыйнак, пөхтә киеме күзгә ташланды: зәңгәр төстәге костюм — юристлар формасы, петлицаларында икешәр зур йолдыз. Димәк, юстиция советнигы. Буйга артык зур түгел, әмма киң иңсәле. Сирәкләнә төшкән коңгырт чәчләр, киң маңгай. Тәз буй-сын, алланып торган ачык йөз, үткен карашлы тере күзләр.

— Таныш булыгыз,— диде бер хезмәттәшем,— Әлмәт прокуроры.

— Шәйхетдинов,— дип, ул нык итеп кулымны кысты.— Тәлгат Шәйхетдинович.

Өстәл янына утырып алгач, кунак, барыбызга да берьюлы мөрәҗәгать итеп, сәер генә сорау ташлады:

— Тумыштан килгән катарактаны дәвалап буламы?

Маңгаендагы тирән җыерчыклар, җыерылган кашлар, кысылган иреннәр — болар барысы да бу сорауның аны бик нык борчуы турында сөйли иде. Ул урыныннан күтәрелә төшеп, авыр сулады һәм күкрәк тавышы белән әйтеп куйды:

— Кирәк! Аңлыйсызмы, ярдәм итәргә кирәк!..

Кемгә ярдәм итәргә кирәк? Ни белән? Болар турында Шәйхетдинов сөйләргә өлгерә алмады, аны кинәт кенә чакырып алдылар.

Озакламый мине Әлмәткә командировкага җибәрделәр. Андагы эшем Әлмәт прокуратурасы белән бәйле иде. Бик табигый: миңа анда Шәйхетдинов белән күп мәртәбәләр очрашырга, сөйләшергә туры килде. Сүз ара сүз чыгып, ул миңа түбәндәге вакыйганы сөйләп бирде.

...Шәйхетдинов белән Малик бер урамда яшиләр иде. Кече яшьтән үк ятим калган Малик Тәлгатнең күз алдында үсте, өйдә кул астына керә башлады. Ул Тәлгатләргә еш кереп йөри иде: телевизор карыйлар, шахмат уйныйлар, кайчак прокурор фронт хәтирәләрен дә сөйләштергәли.

Бер кичне Тәлгатнең өч баласы — Мәскәү нефть институты студенткасы Эльза, слесарь-механик Наил һәм тугызынчы класс укучысы Равил — барысы бергә җыелышып паркка яшьләр кичәсенә барырга ниятләделәр. Маликны үзләре белән дәшеп, күпме генә үгетләп карасалар да, ризалата алмадылар. Иптәшләре артыннан ишек ябылгач, Малик йөзен читкә борды. Шәйхетдинов аның янына килде, күзләренә карады. Алар яшьле иде. Кайнар, эре тамчылар, егетнең әле пәке тимәгән йөзендә юеш

ээ калдырып, елтырашып түбән тәгәриләр. Моңа кадәр егетнең үз-үзен тотышында сәерлек сизелсә дә, күзендә яшь күренгәне юк иде әле. Тәлгат Шәйхетдинович үзенең күңелендә ниндидер нечкә кылларның зыңлап китүен, йөрәге кысылып куюын тойды. Моннан утыз ел элек булган хатирәләр яңарды аның күңелендә. 1941 елның декабрендә аның да күзләрен яшь томалый иде, көчсезлектән, кимсенүдән килгән ачы яшьләр иде алар. Ул, егерме өч яшьлек лейтенант, взвод командиры ярдәмчесе, дошман снаряды шартлап, аягы, күкрәге яраланган, гипска катырылган, бинтка уралган килеш госпитальдә ята, ә фашист чирүләре илебез башкаласы янына килеп җиткән иде...

Тәлгат егетнең иңбашына кулын салды:

— Нәрсәгә кәефең китте әле?

Малик гаҗиз булып аңа карады. Шәйхетдинов шунда барын да аңлап алды: егетнең күзләре авырый бит! Бу турыда моңа кадәр дә белә иде ул. Улының күзләре турында сүз кузгалса, әнисе өметсезләнеп кул селти, берничек тә савыктыра алмаулары турында сөйли иде. Берәүләр аны үзеннән-үзе төзәлер дип тынычландырганнар, икенчеләре операциянең зарар китерүе бар дип куркытканнар. «Тәкъдиргә язганы шулдыр инде»,— дип, Маликның әнисе улының бәхетсезлегенә күнегә дә башлаган иде.

Ә малай үсте, үзенең башкалар кебек булмавын аңлап кимсенә, хурлана торган булды. Аның яшендәгеләр инде кызлар белән танышалар, паркларга, театрларга, стадионнарга йөриләр, сәхнәдә чыгыш ясыйлар. Ә Малик бу тормыштан читтә, ялгыз җәфа чигә, яшерен газаплана.

Бу минутта Тәлгат боларның барысын да ап-ачык төшенде. Төшенде һәм шунда ук кискен карарга килде:

— Боекма, бары да рәтләнер...

Малик күрше абыйсыннан җылы сүзләр ишеткәч, башын күтәрде һәм өлмәеп куйды.

...Елдан артык вакыт узды. Күзенә операция ясаганнан соң, Малик танымаслык булып үзгәрде. Ул хәзер унынчы класста укый, комсомолга кабул ителде. Сәламәтлеге яхшы. Хәрби комиссариат аны хәрби училищега керергә кандидат итеп теркәде. Малик өчен Тәлгат абыйсы дөньяда иң яхшы кеше. Туганнан да артык.

«Яхшылык ит тә диңгезгә ат, балык белер, балык белмәсә, халык белер»,— дип, бик дөрес әйткәннәр борынгылар.

Ике буын вәкиленең, коммунистның һәм комсомолецның, офицер-фронтовикның һәм допризывникның, прокурорның һәм укучының туганлашуы менә шулай булды.

## Шелтә урынына—рәхмәт

Республика Верховный Суды работниклары мөһим эш белән Әлмәткә килделәр. Алдан кисәтеп куюга карамастан, Шәйхетдинов эш урынында түгел иде. Өстәвенә, Верховный Судның бирәдә үткәрелгән утырышына да килмәде. Дежурныйга: «Вакыйга булган урынга киттем»,— дигән дә юкка чыккан. Верховный Суд работниклары эшне шәһәр прокурорыннан башка гына тәгәлләп, Казанга китеп бардылар.

Республика прокуратурасында бу фактка игътибарсыз калмадылар, әлбәттә. Ни әйтсәң дә бик сирәк була торган хәл: прокурор үз җитәкчесенең поручениесен үтәми калганы юк иде әле. «Вакыйгага булган урынга бару өчен тикшерүчеләр бар»,— дип фикер йөрттеләр анда. Прокуратура системасында утыз елга якын эшләгән юристның бу хәле күпләрне гаҗәпләндерде.

Бер генә прокурор, бер генә тикшерүче дә үзен ни көткәнлеген алдан белә алмый. Әлмәт урамы буйлап иртән эшкә килгәндә Шәйхетдинов та бүген ниләр буласын белми иде әле. Ул кабинетына килеп кергәндә сәгать җиде иде. Күзе өстәлдә

ткан хатка төште. Конверт тышына: «Прокурорның үз кулына»,— дип язылган. Кузләгеч киеп, Шәйхетдинов конвертны ачты. Хат кыска иде: «Моннан ике ай элек Полковниково авылында бер картны үтереп күмеп куйдылар. Үтерүче хәзер башкаларга да яный, качарга әзерләнә. Тикшерегез, югыйсә, соң булыр».

Прокурор хатны да, конвертны да җентекләп тикшереп чыкты. Әмма авторның адресы да, фамилиясе дә юк иде.

— Анонимка! — прокурорның йөзендә канәгатьсезлек, чиркану билгеләре күренде. Ул мондый хатларга җирәнеп карый иде. Хат аның кулларын яндырган шикелле булды, шушы минутта ук кәгазьне ерткалап ташлыйсы килде аның. Шулай да тыелып калды.

Ышанырга буламы бу хатка? Нигә автор үз исемен куярга курыккан? Җинаять эшләнгәнне белә, бу турыда прокуратурага хәбәр итәргә кирәк икәнен дә аңлый, югыйсә.

Анонимка авторларын табып оялтырга, әә вакыты белән закон буенча җәза бирергә, яла ягучыларны, ялганчыларны хөкемгә тарттырырга да туры килгән чагы булды аның. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки анонимчылар җинаять ачуны кыенлаштыралар.

— Ә бу хатның сере нәрсәдә икән? — дип уйлады прокурор.— Бәлки, язучысы намуссыз кешедер? Бәлки, ул кемнәндер, ни өчендер үч алу нияте белән язгандыр? Бик мөмкин. Андыйлар да очрап тора. Әгәр авторы билгеле булса икән! Чакыртыр иде, күзгә-күз карап сөйләшер иде дә нишләргә кирәклеге үзеннән-үзе ачыкланыр иде...

Бер генә юл кала: тикшерергә кирәк. Борынгы Рим юристлары кебек, барлык җиде сорауга җавап табарга кирәк иде: нәрсә, кайда, кайчан, ничек, нәрсә белән, ни өчен, кем? Әлегә бу сорауларның берсенә дә җавап юк.

Үтерү турында хәбәр. Һәр минут кадерле. Һәлакәткә очраган кешеләрне коткаргандагы шикелле. Шәйхетдинов үз тәҗрибәсеннән белә: тикшерү, никадәр иртәрәк башланса, эш шул кадәр уңышлырак булачак.

Прокурорның хәтеренә кылт итеп үткәндәге бер вакыйга килеп төште. Моннан ун ел элек булган иде ул. Буралы авылында сабан туе иде. Ә икенче көнне мәет күмделәр. Унтугыз яшьлек ятим егет Рәдис Нигъмәтуллин үлгән иде. «Кинәт кенә чирләде дә үлеп тә китте»,— диделәр. Дүрт ай үткәч, хәбәр калкып чыкты: Рәдисне каты кыйнаганнар, егет шуннан үлгән. Бу хәбәрне Тәлгат җиң сызганып үзе тикшермәгән булса, кем белә, бәлки, кеше үтерүче әле дә иректә йөрер иде.

Һәм менә бүген дә шундый ук сигнал.

— Киттек, Самат! — диде прокурор һәм җәһәт кенә «Волга»га кереп тә утырды.— Киттек! Юл уңаеннан тикшерүчене, милиция инспекторын алырбыз, врачка сугылырбыз.

Җитез «Волга» яңа уянып килгән урамнар буйлап йөгерде. Шәйхетдинов кереп утырдымы, «әкрен барган калыр, йөгереп барган алыр»,— дигән мәкальне кабатлау кирәкми шоферга. Ә Шәйхетдиновны борчулы уйлар биләп алган иде. «Бәлки, бармаскадыр? Казаннан килергә тиешләр бит,— дип уйланды ул.— Самолетны каршылыйсы, суд утырышында катнашасы булыр. Өйгә дә вакытында кайтылыр. Мәрьям куанып каршылар. Кичен киногa барырбыз. Хәмит Миңнехановны гына җибәрергәме әллә? Булдыклы тикшерүче. Белеме дә җитәрлек, университет бетергән. Аның белән бергә инспектор Мөхәммәтдинов һәм суд-медицина эксперты Кузнецов та бара алалар. Өчесе дә ышанычлы кешеләр».

Әмма икенче эчке тавыш беренчесенә каршы төште: юк инде, эш гади түгел бит, мәсьәлә җиде билгесезле. Әгәр хатта язылганнар дөрес булса? Бәлки, үтерелгән ул кеше әтиең шикелле үк өлкән кешедер? — Шәйхетдинов үзе дә сизмәстән сискәнеп китте, инде дөнья куйган әтисен хәтерләдe, туксанга җиткән әнисен күз алдына китерде.— Кешене үтергәннәр дә берни булмагандай күмеп куйганнар булып чыга түгелме соң? Энә очы кадәр дә гаебе булмаган бераү җир куенына кергән, ә икенче бер явызы якты дөньяда рәхәт чигә. Өстәвенә, башкаларга яный, куркыта. Ике ай инде— җинаятьче иректә. Алтмыш тәүлек дигән сүз. Җинаятьчегә уйлану, эз буташтыру, тикшерү органнарын ялгыш юлга этәрү өчен күп вакыт бу!.. Аны фаш итү өчен синең тәҗрибәң бар. Мәетне яңадан казып алырга туры киләчәк. Шул ук вакытта авылдагы

бер генә өлкән кешенең дә нечкә хисләренә, иң изге дип исәпләнгән кануннарына кагылырга ярамый. Житди һәм четерекле эш. Прокурорның авторитеты һәм кодрәте генә булдыра ала моны. Партиянең шәһәр комитеты члены, депутат кешегә халык ышанмый булмас...

Ләкин капма-каршы фикерләрнең көрәше моның белән генә туктамады әле. Ә республика прокурорының порučениесе? — дип, искә төшерде беренче тавыш.— Әмма анда инде җинаять ачылган, тикшерү тәмамланган, ә судта урынбасарың чыгыш ясар,— дип каршы төште икенче тавыш.— Ләкин башбаштаклык бит бу... Нишләргә соң? Синең башка чараң юк, һәр минутың кадерле...

Фикерләр бәхәсе кинәт өзелде. Өеннән чыгып өлгергән Миңнеханов күренде, ул тикшерүче чемоданын үзеннән алга сузып, кабинага кереп утырды. Тиздән милиция работнигы һәм врач-эксперт та машинада иделәр инде.

Шәйхетдинов хатны кесәсеннән алып тикшерүчегә сузды:

— Танышыгыз,— дип, башкаларга да дәште.

Аноним ка, куллан-кулга күчеп, төрле кешедә төрлечәрәк фикер тудырды. Прокурорның болай иртә кузгатуы юкка гына түгел икәнен һәркем үз тәҗрибәсеннән белә иде инде.

«Волга» алга җилдерде. Таш йортлар артта калды. Шәһәр читендә яшеллеккә күмелеп утырган өйләрне узып, туп-туры офыкка сузылган шоссега чыктылар.

Юлчылар алдында сокландыргыч күренеш ачылды. Алда, еракта, урман белән капланган сөзәк калкулык күренә, ә тирә-якта киңлек, иркенлек, зәңгәрсу сафлык. Яшел сыртлы калкулык өстендә офык җиңелчә генә дулкынлана, дерелди шикелле.

Шәйхетдинов уң ягына күз салды. Юлдан эчтә юмарт җирләр, изге туфрак. Мөслим районында, аның туган авылы Ташлы Яр тирәсендә дә, шушындый ук күңелгә якын күренешләр, шушындый бәрәкәтле туфрак. Авылдан аерылганга утыз алты ел узып та киткән шул. Ул чакта Тәлгат унҗиде яшьлек егет кенә иде әле. Ә туган яклары һаман онытылмый.

Күп сулар акты ул вакыттан соң. Балалар туганда бары да бер төрле булып туа, ә тормыш юлын һәркем үзенчә уза. Шәйхетдиновның үткән юлларын исәпли китсәң, аз түгел алар. Юк, ул бер вакытта да җиңел юл, тыныч утрау эзләмәде. Уку, Совет Армиясендә хезмәт, Бөек Ватан сугышында дошман белән йөзгә-йөз килү, хәрби госпиталь, янә уку һәм хезмәт фронты — болай санап чыкканда гади генә кебек. Ә бу гадилек артында әллә никадәр катлаулы вакыйгалар яшеренеп ята. Бәхеткә, шатлыкка максатыңа илтә торган юл әкиятләрдә генә үзеннән-үзе табыла, серле капкалар әкиятләрдә генә җиңел ачыла.

...Бүген дә матур, кояшлы көн. Бөтен тирә-як хуш ис бөркә. Табигатьнең самими күренешләре күңелдәге нечкә кылларга кагылып, хәтерләрне яңарта, хыялларны канатландыра. Табигать, тормыш үз кочагына дәшә. Машинадан төшәсе дә ялан аяклап ата-бабаларыңның эзләренә басып үтәсе иде, шушы изге туфракның якынлыгын, җылысын, аяк табаннарын җиңелчә кытыклавын тоясы иде!..

Юк, тукталырга ярамый. Хатта язылганнар, бәлки, дөрестер. Шулай була калса, димәк, кешеләргә кайгы, газап китерүче дә шушы җирдә йөри. Кеше гомерен өзгән явыз да башка яхшы кешеләр шикелле үк шушы җирнең бөтен нигъмәтеннән файдалана.

— Авыл Советына борыл,— дип ашыктыра Шәйхетдинов шоферны.

— Үлгәннәрне теркәү кенәгәсен бирегез әле! — прокурорның авыл Советындагылар белән күрешкәч әйткән беренче сүзе шул булды.

Кенәгәне актарып чыккач, прокурор аны тикшерүчегә сузды. Миңнеханов һәр битне җентекләп карап барды.

— Юк, Тәлгат Шәйхетдинович.

— Шулай шул менә...— прокурор канәгатьсезлеген яшермәде һәм тагын председательдән сорады: — Үлгән һәр кешенең исеме кенәгәгә теркәлеп барыламы?

— Әлбәттә, иптәш прокурор! — председательнең тавышында үпкә чагылды.— Законны беләбез. Ә сезне кем кызыксындыра?

«Кем кызыксындыра?» Әгәр прокурор моны белсә иде! Ә бит кемдер белә, ләкин үзе билгесез булып калырга тели.

— Соңгы ике айда кемнәр үлде?

— Үлүче бераү генә, ә туучылар күп: сигез кеше, председатель авыл статистикасыннан хәбәрдар булуын күрсәтеп куйды.

— Үлүчесе кем?

— Колотушкин, Федор Сергеевич.

— Нәрсәдән үлде?

— Мәрхүмгә сиксән яшь иде.

— Кайчан үлде?

— Ничек инде ул «кайчан»? — дип кайтарып сорады председатель.— Кенәгәдә күрсәтелгән, нәкъ бер ай элек.

— Ә кайчан күмделәр? — дип төпченде прокурор.

— Менә бездә медицина белешмәсе бар. Бер ай элек күмелгән.

— Юк, бу дөрес түгел,— дип, медсестра сүзгә кушылды.— Гаеп миндә: ни әйтсәләр шуны яздым. Күз яшьләре белән ялынгач, түзмәдем, язып бирдем. «Үзең белеп торасың бит, картка сиксән яшь иде. Күмгәнебезгә бер ай була инде»,— диделәр.

— Белешмәдә нинди көнне үлгән дип күрсәттегез?

— Белешмәне язган көнне.

— Ә чыннан да карт кайчан үлгән?

— Ике ай булды,— диде медсестра.— Колотушкиннарның үзләреннән сорый аласыз.

— Федяның дөнья куйганына ике ай була инде,— дип, әби кеше яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп алды.— 1908 елны өйләнешкән идек. Миңа унҗиде генә яшь иде. Алтмыш ике ел бергә гомер иттек. Җиде балабыз булды, өч улым, бер кызым исән әле. Иремме? Чирләп үлде...

Улы Игорьның күрсәтмәләре әнисенеке белән туры килмәде:

— Әти нык кеше иде, беркайчан да чирләмәде,— диде.— Әни белән тату яшәделәр, бер-берсенә усал сүз әйткәннәре булмады. Тынгысыз җанлы, намуслы кеше иде. Чын коммунист. Егерме биш еллап колхоз председателе булды. Начарлыкны, гаделсезлекне күралмый иде. Балаларының да андый-мондый тәртипсез кыланышларын авыр кичерә торган иде.

— Кемнекен, мәсәлән? — дип сорады прокурор.

— Абыйнныкын инде, Михаилныкын.

— Нишләде соң ул?

— Хөкем иттеләр аны. Урлашкан өчен. Әти авыр кичерде. Бервакыт Михаил эчә башлады, эшен ташлады. Әти тузынды: «Әрәмтамак булып яшәргә уйлыйсыңмы?» — диде. Шуннан абый Чабаксарга чыгып китте. Сездән башка да яшәрмен әле, диде. Семьясы авылда калды. Михаилның кайтканына әле күптән түгел. Әтигә зур гына бүләкләр дә алып кайтты. Ләкин аралары суынган иде инде. Бүләгеннән әти баш тартты: «Тиген эш түгел бу»,— диде. Тагын бозылыштылар.

Үзенең күрсәтмәләрен язып баруларын шәйләп алгач, Игорь Колотушкин агарынып китте:

— Кирәкми, иптәш прокурор! — дип ялварды ул.— Ходай хакына!

Әнисе белән күзгә-күз очраштырганда, Игорь үзенең күрсәтмәләреннән тулысынча баш тартты. «Ялган сөйләсәң — тотылырсың, дөрес сөйләсәң — котылырсың»,— дигән халык мәкале дә ярдәм итмәде. Ничек кенә тырышса да, Шәйхетдинов шундый кинәт үзгәрүнең сәбәбенә төшенә алмады.

Башка туган-тумачаларның күрсәтмәләрендә дә бердәмлек юк иде. Сүз Михаилга кагылу белән барысы да тукталып калалар. Сәер иде бу. Сораулар да, аңлатулар да, үгетләүләр дә файда бирмәде.

— Их, хатның авторы билгеле булса иде!..

Җыелышып, кемнең нәрсә эшләргә тиешлеген билгеләделәр. Иптәшләре киткәч, Тәлгат каләмгә тотынды. «Мәетне күмелгән җиреннән алу турында карар,— дип язып куйды ул.— Колотушкин Федор Сергеевичның үлү сәбәбен билгеләү өчен, мәрхүмнең гәүдәсенә суд-медицина тикшерүе үткәрү таләп итеlә. РСФСР җинаять процесслары кодексының 180 нче статьясына нигезләнеп, карар итәм: 1889 елны туган Ф. С. Колотушкинның гәүдәсен Полковниково авылы читендәге каберлеккә күмелгән урыныннан казып алырга».

Документ әзер булгач, прокурор кәберлеккә ашыкты.

— Кабыргалары сынган,— диде эксперт Кузнецов, Колотушкинның гәүдәсен тикшергәннән соң.— Уналты урыннан. Үз үлеме белән үлмәве бәхәссез.

Миңнеханов белән Мөхәммәтдинов Колотушкиннарның эш урыннарында булып кайттылар. Һәр җирдә бер үк хәл: Михаил турында сүз кузгалса, һәркем туры җаваптан читләшергә, күләгәдә калырга тырыша.

Әйе, Колотушкин картның үтерелүе бәхәссез. Ләкин кем үтергән аны?

Прокурор Михаил Колотушкинны чакыртты. Энеләре, сеңелесе: «Хәзер килер»,— дип вәгъдә иттеләр. Әмма Михаил килмәде.

— Хәзер табып алып киләм,— дип, милиция капитаны Мөхәммәтдинов ишеккә атлады. Бераздан ул да ялгызы урап кайтты: Михаил Колотушкин юкка чыккан иде.

Шәйхетдинов сотрудникларны һәм авыл Советы работникларын аэропортларга, пристаньнарга, тимер юл станцияләренә җибәрде.

— Тотыгыз, тентегез һәм бирегә алып кайтыгыз. Ләкин сак булыгыз.

Тәлгат элемтә бүлекчәсенә килде. Чабаксарга телеграмма җибәрелде.

— Булды! — дип шатланып кайтып керде Миңнеханов.— Алып кайттык. Бәгелмәгә кадәр үк барып җиткән. Поездга ашыга, ә без аның артыннан. Менә, карагыз! — тикшерүче портфелендәге әйберләрен өстәлгә бушатты: йөзәр сумлык — биш, унар сумлык — ике акча, сәгать, тарак, Казан тәмәке фабрикасында эшләнгән бер тартма «Шүрәле» папиросы, бер кап шырпы.

Шәйхетдинов каршында кырык тугыз яшьлек Михаил Колотушкин басып тора. Мәрхүмнең иң олы улы. Зур буйлы, киң иңсәле ир. Янып торган ике күзе җыерылган кашлар астыннан прокурорга сагаеп, сөзеп карый. Шешенә төшкән күз кабаклары зәңгәрләнеп тора. Йөзе җыерчыклар белән телгәләнгән. Шәйхетдинов әле Михаилның үзенә, әле аңа бирелгән характеристикаларга карый. «Спиртлы эчемлекләрне еш куллана, сәбәпсез эш калдыра, тотанаксыз». Йөзеннән үк күренеп тора. «Кешенең йөзе — күңел көзгесе»,— дип, юкка гына әйтмиләр шул.

— Әтиегез үлгән көнне кайда булдыгыз һәм нәрсә эшләдегез?

— Энем Вильгелм белән Яңа Зәйгә бардык, бер ярты аракы алдык,— дип сөйли башлады Колотушкин.— Ресторанга кердек, эчтек. Кичке сәгать унда авылга кайттык. Урамда бер төркем ирләр очрады. Тагын ике йөз грамм чамасы эчтем. Өйгә ярты төндә кайттым. Әти тирги башлады. Мин аны калдырып күршеләргә кердем. Әни дә шунда иде. Аның белән өйгә урап кайтканда әти аңын югалткан иде инде.

— Әтиегез чирләвен әйтмәдеме?

— Юк, иптәш прокурор. Паралич суккандыр.

— Әтиегезнең кабыргалары сынган.

— Тартырга мөмкинме? — Рөхсәт биргәнне дә көтеп тормастан, Михаил прокурор алдында яткан «Шүрәле»гә үрелде. Бу кулның инде байтактан бирле сабын да, кайчы да күргәне юк иде.

— Мөмкин,— Шәйхетдинов папирос тартмасын аңа табан этәрде.

Тартырга рөхсәт булгач, Колотушкин җанланып китте. Папирос сайлап алып, аның бөтен сабагын диярлек авызына капты. Саклык белән генә кабызды да папирос тартмасын гадәти хәрәкәт белән пинжәгенең уң кесәсенә салды. Колотушкин папиросын тирән итеп суырды, яңаклары эчкә батып керде, яңак сөякләре калкып чыкты.

— Кабыргалары сынуын ни белән аңлата аласыз? — дип сорады Шәйхетдинов.

— Исерек килеш мич башыннан егылып төшкән ул.— Бу җавапның күптән әзерләнгәнлеге сизелеп тора иде.

— Кем әйтте аны?

— Күрше хатын, Анна Чекменова,— прокурор бу сүзләрнең дә әле генә уйлап чыгарылмаганлыгын сизенә иде, әлбәттә.

— Чекменовадан сорау алынды,— дип каршы төште прокурор.— Ул алай дип әйтми.

— Әллә ак эт бәласен кара эткә якмакчы буласыз инде, гражданин прокурор! Күзгә күз очраштырыгыз,— дип карышты Михаил.

— Очраштырырбыз. Ләкин башта шуңа җавап бирегез әле: ни өчен әтиегезнең кабыргалары уналты урыннан сынган?

— Монысын мин әйтә алмыйм.

— *Ә мин әйтә алам!* — диде Шәйхетдинов, ышанычлы тавыш белән, һәм, урыныннан күтәрелеп, Колотушкинга якынлашты. Тегесе, берни дә аңламаган кыяфәттә, күзләрен челт-челт йомгалап тора иде.

— Бирегез әле,— дип, прокурор Колотушкинның авызыннан папиросын тартып алды.

Шактый гына җебегән папирос төпчеген сүтеп, Шәйхетдинов эченнән елтыравыклы бер әйбер тартып чыгарды һәм:

— Папирос тартмасын өстәлгә куегыз! — дип боерды.

Колотушкин теләмичә генә кесәсенә тыгылды, калтыранган куллары белән тәмәке тартмасын алды. Шәйхетдинов шаһитлар чакырды.

— Барлык папиросларны да сүтегез! — диде ул понятойларга.

Бер минут та үтмәде, өстәл өстендә берничә алтын теш ялтырап ята иде инде.

Игорь Колотушкинны яңадан чакырттылар.

— Әтиегезнең тешләре нинди иде?

— Үзенекеләр дә, куелганнары да бар иде.

— Куелганнары нинди иде?

— Бишесе алтын, өчесе гади ак металлдан.

Игорьның абыйлары, сеңелләре һәм әнисе дә шуны ук расладылар: бишесе алтын, өчесе гади металлдан.

Соңгы сүзне эксперт әйтергә тиеш иде.

— Мәетнең авызыннан биш алтын теш алынган, ә гади металлдан эшләнгән өчесе үз урыннарында,— дип раслады врач Кузнецов.— Мәрхүмнең авыз эчендә һәм уртында үлгәннән соң барлыкка килгән күп кенә яралар бар.

— Мин исереп кайткач, әти ачулана башлады, миңа ташланды,— дип сөйләде соңыннан Колотушкин.— Сугарга теләде. Мин суктырмадым, төртеп җибәрдем. Берничә тапкыр типтем. Шуннан мич башына салдым.

— Кайсы җиренә суктыгыз?

— Күкрәгенә.

— Аягыгызда нәрсә иде?

— Кирза итек.

— Үзегезне үтерүдә гаепле дип таныйсызмы?

— Өлешчә таныйм.

— Ничек инде ул өлешчә?

— Мин үтерергә теләмәгән идем. Ачу килгәнгә генә типкән идем.

— Әтиегезнең алтын тешләре сезгә ничек килеп эләкте?

Колотушкин эндәшмәде. Ул телсез калган кешегә охшаган иде.

Әлмәткә кайткач, Шәйхетдиновка Чабаксардан телеграмма китерделәр. Анда Михаил Колотушкинның квартира таләп качуы, милиция тарафыннан эзләнүе, прокурор тарафыннан кулга алырга санкция бирелүе турында әйтелгән иде...

— Приказ языгыз! — дип боерык бирде республика прокуроры бу мәсьәләне һәрьяклап ачыклагач.— Мин аңа рәхмәт белдерәм. Юристның нинди кеше булырга тиешлеген иптәш Шәйхетдинов тагын бер тапкыр раслады.

* * *

Бу очеркта Әлмәт прокуроры Тәлгат Шәйхетдинов тормышында булган ике генә вакыйга алынды. Андый хәлләр аның көндәлек эшендә сирәк түгел. Нинди генә хәл булмасын, Тәлгат Шәйхетдинов һәр очракта, һәр мәсьәләне хәл итүгә бөтен күңелен биреп керешә, аны җентекләп тикшерә һәм чын дөреслекне барыбер ачыкламыйча тынычланмый. Шуңа күрә дә аның турында, тынгысыз җан, диләр. Дөрес әйтәләр. Әйе, тынгысыз ул, шул ук вакытта гаять кешелекле дә.

Зәки Әхмәтҗанов

# ГЕРОЙ КАБЕРЕНДӘ ЧӘЧӘКЛӘР...



Ана рәсеме.

Сугышта аны һәр солдат, һәр офицер йөрәге янында — гимнастеркасының сул як кесәсендә, партия һәм комсомол билеты белән бергә йөртә иде.

«Кайнар сәлам, әни, фронттан,— дип башлады Мингали хатын,— язмый торуым өчен ачуланма. Эш бик тыгыз булды бу арада. Һаман алга барабыз. Күңелләр күтәренке хәзер. Көн саен туган илебезнең чигенә якынлашабыз. Менә озатканда «шул мәлгуньне тизрәк җиңеп кайтыгыз» дигән сүзеңне бер дә онытмыйм, әни. Нинди генә явызлык эшләмәгән фашист безнең җирдә. Шәһәрләр урынында — тузан һәм таш өеме. Авыллардан мичләр генә тырпаеп калган. Фашистларга яңа туган яшь баланы да, көчкә йөри торган карт бабайны да чәнчеп китү берни түгел.

Шуларны күргәч, нәфрәт ташый, явызлардан тизрәк үч аласыбыз килә».

Мингали язган кәгазь битенә күз йөртеп чыкты. Аннары тагы берничә юл өстәде.

«Менә әле рәсемеңә карап утырдым. Картайгансың, әни, битеңдә җыерчыклар арткан. Тимергали абыйның үлемен авыр кичерәсеңмени? Нишлисең, сугыш корбансыз булмый инде. Үзеңне сакла, әни, артык кайгырма. Бу сугыш безгә генә түгел, илгә килгән афәт. Тәшенкелеккә бирелмә, әни, нык бул.

Тимергали абый өчен мин үзем исәп-хисапны өзәрмен».

Аннан соң ул колхоз хәлләрен сорашты, туган-тумачаларына сәламнәр язды һәм өчпочмаклы конверт ясап, хатын планшетына салып куйды.

Тәбәнәк буйлы, нык гәүдәле, ачык йөзле бу яшь офицерны тормышта шат күңелле, сугышта кыю һәм түзем булганы өчен ярата лар иде.

1943 елның сентябрендә Молочная елгасы буенда булган сугышларда Мингали зур батырлык күрсәтте.

Көз. Урманнар алтын-сары. Немец әнә шул күз явыңны алырдай матур урманнарны кисеп, Германиягә озата. Партизанлы урманнарга бомба, снаряд яудыра.

309 нчы укчы полк гвардиячеләре 27 сентябрьдә һөҗүмгә күчтеләр. Алар, лейтенант Гобәйдуллин взводы пулеметларының көчле уты ярдәмендә беренче сәгатьтә үк дошман оборонасын өзеп, алга баруларын дәвам иттеләр. Танкларны үткәрмәү өчен казылган чокырлар аша да уздылар алар.

Безнең укчыларны туктатырга теләп, немец берничә мәртәбә контратака оештырырга маташып карады. Ләкин Гобәйдуллин пулеметчылары аларны һәр тапкыр җиргә сыенырга мәҗбүр иттеләр. Шактый гына солдатын югалткач, дошманның уты кими башлады. Тагын бераздан бөтенләй туктап калды.

Лейтенант Гобәйдуллин берсеннән берсенә шуышып, пулемет ячейкаларын әйләнеп чыкты. Аларга яңа ату секторлары билгеләде.

— Бу тынычлыктан яхшылык көтмәгез, егетләр,— диде ул пулеметчыларга.— Дошман мәкерле хәйлә кора. Ут ачарга әзер торыгыз.

Мингали дошман ягына күз йөртеп чыкты да, телефонист Федоров окобына төшеп, планшетыннан карта чыгарды. Шул вакытта шинель җиңеннән карта өстенә берничә тамчы кан тамды.

— Бу нәрсә тагын? — диде ул, җиң эченә карап,— үзем берни сизмәдем...

— Сез яралангансыз бит, иптәш лейтенант,— дип, Федоров аңа шинелен, гимнастеркасын салырга булышты. Яра авыр түгел иде. Ерактан килеп көче беткән пуля шинельне, гимнастерка белән эчке күлмәк җиңен үтеп кергән дә, беләкне аркылы чыга алмыйча, тәрәлеп калган.

— Кара әле, Федоров, бу хәлне, ярый әле, шартлый торган пуля булмаган.

— Бәхетегез бар икән, иптәш лейтенант. Әгәр дә кулны үтеп чыкса, туп-туры йөрәккә барып керәсе булган.

Мингали, тешләрен кысып, ике бармагы белән ян яктан басып, пуляны чыгарды да сертеп кесәсенә салып куйды.

— Ярый,— диде ул, Федоровка карап,— исән-мин кайтсак, бер истәлек булыр.

Федоров, противогаз сумкасыннан медицина пакеты чыгарып, лейтенантның ярасын бәйли башлады.

— Кирәкми, Федоров, мин үзем дә бәйли алам,— диде лейтенант,— син тирә-якны күзәт.

Федоров окоптан башын калкытуга кире иелде. Шунда ук алар өстеннән пулялар сызгырып үтте. Ул да түгел, окоплар артында миналар ярыла башлады.

— Немец тагын килә, иптәш лейтенант.

Хәл шәптән түгел. Мингали окоптан чыгып, пулеметчылар янына үрмәләде. Немец артиллериясе утына ышыкланып, өч яктан да якынлаша иде.

— Әзер торырга! Якынрак килсеннәр, команда булгач кына ут ачарга! — Окоплар буйлап, взвод командирының шундый командасы яңгырады. Бер пулемет артына Мингали үзе ятты.

Батырлык өчен дип мул гына төшереп алган гитлерчылар, әллә нинди кыргый авазлар чыгарып, акырып-бакырып, гвардиячеләр позициясенә якынайдылар. Ара-тирә: «Рус капут! Рус, сдавайся!» — дигән тавышлар ишетелде.

— Хәзер бирәбез без сезгә «сдавайсяңне», якынрак кил әле...

Окоплар өстендә очкыннар чәчеп, тирбәлә-тирбәлә, яшел ут шары күтәрелде. Ул җиргә төшеп җиткәнче үк, пулеметлар эшкә кереште. Алар, тончыга-тончыга, фашистлар өстенә кургаш яудырдылар. «Максимка»ларда су кайнап чыкты. Лейтенант Гобәйдуллин кул пулеметы белән әле бер, әле икенче флангка шуышты.

Гвардиячеләр позициясен җиңел генә кулга төшерергә уйлаган фашист солдатлары, шундый көчле ут астына эләгеп, тәмам югалып калдылар, төрле якка кача башладылар. Кайсы корал ташлап, кулын күтәрде. Күбесе Украина җирендә, окоплар янында ятып калды. Рус җирен яуларга килгән немец солдаты әнә шунда үзе бик теләгән ике метр җирне тапты. Бу бәрелештә икенче тапкыр яраланып, күп кан югалтудан хәлсезләнгән взвод командиры Мингали Гобәйдуллин сугыш кырын, сугышчан иптәшләрен калдырып китмәде.

Гвардияче яшь офицер бу сугыштагы тәвәккәллеге, кыюлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде.

* * *

Язган хатымны да почтальонга тапшырырмын, ял итүче пулеметчыларның да хәлен белермен дип, Мингали кеше буе тирәнлегендә казылган тар траншея буйлап үз взводы сугышчылары янына юнәлде.

Сугышта сирәк кенә булса да ял көннәре дә булгалый бит. Соңгы сугышларда талчыккан сугышчылар, оборонага туктагач, икенче эшелонга күчеп, үзләрен тәртипкә китерәләр. Мөмкинлеккә карап берничә көн ял итәләр. Ял дигән нәрсә шуннан гыйбарәт: тимер мичкәләрдә су җылытып, «мунча» керәләр, кием алыштыралар. Газета-

журнал укыйлар. Солдат капчыгында әвәләнеп, тузып беткән китаплар кулдан кулга йөри. Көн саен алга барудан, илебез чикләренә якынаюдан кәефләре күтәрелгән сугышчыларның күңелләрен тагын да күтәреп, йөрәкләрдә дәрт арттырып, концерт бригадалары чыгыш ясый.

...Пулеметчылар землянкасындагы көчле көлү тавышын Мингали ерактан ук ишетте.— Абрамов ни дә булса сөйлидер,— диде ул үзе-үзенә һәм үзе дә елмаеп куйды. Һәр взводта боегу-моңаюны белмәгән, гаҗәеп шат күңелле бер мәзәкче була. Гобәйдуллин взводында андый «почетлы эш»не моннан ике ел элек полкка килүенең беренче көнендә үк «клоун» кушаматы алган егерме яшьлек Тамбов егете Иван Абрамов үз өстенә алды.

Авылда малай чактан ук бу кушаматка иялəнгән Иван беренче көннәрдә, әллә авылдан берәрсе яздымы икән, дип уйласа да, артык игътибар итмәде. Миңа калса, маймыл дисеннәр, Полинам гына яратсын, дип тынычланды һәм тырышып хезмәт итә башлады.

Клоун дигәннән, Иванның чыннан да ачуланыр урыны юк иде. Аның юри ясап куйган кебек, югары чөелеп торган җәенке борыны, яңак сөякләре чыгып торган күе сипкелле киң бите, уттай кызыл-сары җирән чәче бер күрүдә үк цирктагы клоунны хәтерләтә.

Ләкин аның киң җилкәле, киң күкрәкле тигез, таза гәүдәсе, бер сугуда атны егарлык олы йодрыклары бу авыл егетенең табигать кочагында эш белән чыныгып үсүен аңлатып тора.

Курку белмәве, эшне төгәл үтәве, турылыклы һәм беркатлылыгы өчен ихлас күңелле рус егетен взвод командиры да ихтирам итә иде.

Землянка ишеге төбендә лейтенант күренү белән, сугышчылар көлүдән туктап, аягүрә бастылар.

— Утырыгыз, егетләр, эшегезне дәвам итегез,— дип, Гобәйдуллин патрон ящигы өстенә урнашты.— Я, хәлләр ничек, нәрсәдән көләсез?

— Билгеле инде, иптәш лейтенант,— дип елмайды сержант Никитин,— Абрамовтан көләбез.

— Нәрсә сөйли тагын?

— Нәрсә сөйләсен, һаман шул Полинасын мактый.

— Мактарлыгы булгач, нигә мактамаска, дөрес бит, Абрамов,— дип,— лейтенант Иванга күз кысып алды.

— Дөп-дөрес, иптәш лейтенант, болар мәхәббәтнең нәрсә икәнен беләләрме соң? Өлкәннәре аны онытканнар, ә бу яшьләре әле татып карамаганнар, көлә белми көләләр.

— Тукта, Иван, сүзне икенчегә борма,— дип бүлдерде аны үзбәк егете ефрейтор Ирназаров,— монда сүз сугышка керү алдыннан кемнең нәрсә уйлавы хакында бара. Саенко менә мин әни турында уйлыйм, ди.

— Молодец, Саенко, дөрес эшлисең,— диде лейтенант, бер читтә шинель төймәләрен чистартып утыручы яшь сугышчыга борылып,— ана сүзен онытырга һич ярамый.

— Ә мин әнидән яшьли калганмын, иптәш лейтенант,— дип башлады сүзен, мордва егете Гриша Осипов,— мине авыл халкы үстерде. Шуңа күрә сугышка керү алдыннан һәрвакыт авылымны, аның кешеләрен күз алдына китерәм.

— Ә син ни уйлыйсың, Беридзе?

— Мин, иптәш лейтенант,— диде Беридзе, өске иренендәге берничә бөртектән торган кара мыегын сыпырып алгач,— бары тик үч алу турында гына уйлыйм, фашистлар минем хатынымны үтерделәр. Ул медицина институтының соңгы курсыннан үзе теләп фронтка киткән иде. Кавказ тавы кадәр ачуым бар минем немецларга. Шул үчне кайтарсам, үзем үлсәм дә ризамын.

— Син үләргә ашыкма, Гиви, алар минем дә абыемны үтерделәр. Үчне бергәләп алырбыз. Без яшьләр бит әле, сугыштан соң менә дигән тормыш корырбыз.

— Хәзер миңа да әйтергә ярыйдыр инде,— дип, моңарчы тыңлап кына утырган Абрамов та сүзгә кереште.

— Ә мин, иптәш лейтенант,— диде ул,— барыбер шул Полинам турында уйлыйм. Аның чибәрлеген генә күрсәгез иде сез, егетләр, билләһи, һуштан язар идегез.

Туган ай кебек түгәрәк йөзле, тал чыбыгыдай зифа буйлы, шомшә кебек нечкә билле — минем өчен заказ буенча гына туган диярсең. Ә эшкә дисәң, кулына күз ярми, көненә бишәр йөз көлтә бәйли. Арыш капчыкларын очыртып кына йөртә.

— Нәкъ үзеңә охшаган икән,— дип кысылып куйды кайсыдыр. Землянкада тагын дәррәү көлү тавышы күтәрелде.

— Туктагыз әле, тыңлап бетерегез, кеше сезгә дөресен сөйли.— Иван дәвам итте: ә күзләрен күрсәң, көлеп торалар. Аларның тирәнлеге кара диңгез кебек, үзең кереп батарсың.

— Кара диңгезне күргәнең бармы соң?

— Күрмәсәк күрербез, ерак калмады, шул якка барабыз бит...

Кичке аштан соң гвардия лейтенанты Гобәйдуллинны батальонның күзәтү пунктына чакырдылар. Анда Мингалине батальон командиры, Хәсән күле янындагы бәрелешләрдә үк Сугышчан Кызыл Байрак ордены алган, Халхин-Гол операциясендә катнашкан кадровый офицер, майор Поляков көтеп тора иде.

— Я, хәлләр ничек, Мингали, ял иттегезме, пулеметчыларның кәефе нindиpәк?

— Кәеф яхшы, иптәш майор, һөҗүм башларга боерык көтәбез. Безне туктарга мәҗбүр иткән теге калкулыктагы дзотларны юк итми торып, һич күңел тынычланмый. Шунсыз алга барып булмаячак.

— Менә шул турыда киңәшергә чакырдым да мин сине, иптәш лейтенант. Ул калкулыкны кулга төшерми торып, полк алга бара алмый.

— Безнең взвод юлы өстендәгесен безгә тапшырырсыз дип уйлыйм.

— Дөрес уйлыйсың, Мингали,— диде комбат, без полк командиры белән уйлаштык та, шул дзотны юк итүне синең пулеметчыларга тапшырырга булдык. Һөҗүм алдыннан ул биеклекне авиация белән артиллерия дә утка тотачак. Ләкин алардан соң да бөтен ут оялары тынып калыр диген ышанычыбыз юк.

— Ышанычыгызны акларбыз, иптәш майор,— диде Гобәйдуллин честь биреп.— Приказыгыз үтәлер.

Мингали батальон командиры һәм штаб начальнигы белән саубуллашты да, землянкадан чыгып, үз взводы позициясенә ашыкты.

Йөзләрчә кешенең язмышы өчен аталарча кайгыртучы ике өлкән командир озак кына Гобәйдуллин киткән якка карап тордылар.

— Менә, ичмасам, командир бу,— диде комбат, штаб начальнигына борылып,— нинди генә шартларда да югалып калмый. Кешеләрне оештыра, аларның ихтыярын, батырлыгын кирәкле урынга юнәлтә белә. Иң авыр минутларда, беренче булып, үзе атакага күтәрелә.

— Гобәйдуллин кебек командирлар белән сугышырга була, иптәш майор, аңа солдатлар ышана, тәвәккәллеге өчен яраталар. Аның кул астында теләсә нинди заданиене үтәргә әзер торалар.

— Ә бу инде, иптәш капитан, командир өчен иң кирәкле сыйфатларның берсе. Сугышта бигрәк тә.

Позициягә кайткач ук, лейтенант, отделение командирларын җыеп, алдагы һөҗүмнең бурычларын аңлатты.

Ике көндә яхшы гына ял иткән сугышчылар, караңгы төшү белән, алгы сызыктагы окопларга барып урнаштылар. Лейтенант Гобәйдуллин элемтәче ефрейтор Абрамовны да үз окобына ияртеп килде. Үз эшенең бөтен нечкәлекләрен белеп, сөеп башкаручы Иван Абрамов, кабельдән бушаган катушканы бер читкә куйды да телефон аппаратын элемтә линиясенә тоташтырды, күрше взводларга, рота һәм батальон командирларының күзәтү пунктларына шалтыратып чыкты.

— Элемтә эшли, иптәш лейтенант.

— Без монда килгәнне сизмәделәр әле алар,— диде лейтенант, кулы белән немецлар ягына күрсәтеп.

— Сизсәләр дә әллә ни кыра алмаслар, иптәш лейтенант, соңгы көннәрдә яңа көчләре килмәде.

— Анысы дөрес, Абрамов. Лакин өнә теге калкулык итәгендәге дзотлар тагын комачаулаячак.

— Иптәш лейтенант, һөҗүм башлангач та аны демектерүне миңа тапшырыгыз. Әнә теге яктан куренмичә үрмәләп булыр дип уйлыйм.

— Юк, Иван, сине җибәрмим мин анда,— дип елмайды Мингали,— берәр хәл булса, Полинага нәрсә дип җавап бирермен. Көтеп тора дисең бит.

— Бик көтә, иптәш лейтенант, хат саен «тизрәк кайт»,— дип яза. Белми ул Иванның һәр вакыт кабер якасында торуын. Немец белән сугышуны колхозда сыер саву дип белә, ахрысы.

— Көтүенә ышанасың, димәк?..

Иван дәшмәде, ул, Полинасын күз алдына китереп, тынып калды.

Каршы яктагы калкулыкны, нейтраль зонадагы ялгыз, вак куакларны, окоплар алдындагы җир өемнәрен төн караңгылыгыннан аерып, таң сызыла башлады.

Батальон командиры әйткәнчә, яктырып бетүгә дошман позициясе өстендә безнең бомбардировщиклар әйләнә башлады, зенит туплары атарга тотынды.

Калкулык өстендә каткан җир кисәкләре катнаш тузан һәм төтен баганалары күтәрелде. Немецларның тыл подразделениеләре һәм штабы урнашкан авыл өстендәге ялкын телләре күренде. «Илюшин»нар, эшләрен бетереп, кайту ягына борылганда, гвардиячеләр окоплары өстеннән дошман ягына миналар, снарядлар сызгырып үтә башлады.

Лейтенант Гобәйдуллин, күзен дә алмыйча, бинокль аша каршы якны күзәтә.

— Хәзергә эшләр әйбәт бара,— ди Мингали, Абрамовка борылып,— тикшер әле, батальон эшлиме?

— Эшли, иптәш лейтенант,— ди ефрейтор һәм шундук трубканы аңа суза:— сезне комбат сорый.

Майорның беренче сүзләрен ишетү белән, Мингали күңелләнеп, елмаеп куйды.

— Гафу ит, дускай,— дип башлады комбат сүзен, Мингали алдында гаебе булган сыман,— кичәге ыгы-зыгы белән онытып җибәргәнмен... штабның барлык офицерлары исеменнән туган көнең белән котлыйм сине.

— Игътибарыгыз өчен рәхмәт, иптәш майор. Шул каһәр суккан дзот турында уйлап, туган көнемне үзем дә онытканмын.

— Дзот тирәсендә сак бул, Мингали, ул һаман кыймылдый. Миңа моннан яхшырак күренә.

— Тырышырбыз, иптәш майор.

— Ә туган көнеңне шул калкулыкны алып беренче ялга туктагач та үткәрербез. Нарком нормасында тотарбыз, колагыңны да тартырбыз.

— Чәчтән йолкысагыз да сүз әйтмим, иптәш майор, һөҗүм генә уңышлы чыксын.

— Менә ничек бит, Иван, бу сугыш белән картайганыңны да сизми калырсың,— дип, Мингали аңа телефонын сузды,— бүген миңа егерме бер яшь тулган. Ярый әле, комбат искә төшерде.

...Артиллерия уты кими башлагач ук гвардиячеләр окобы өстендә бер-бер артлы ике ракета күтәрелде.

Алар җиргә төшеп җиткәндә, кулына пистолет тоткан, җилкәсенә автомат аскан взвод командиры окоптан сикереп чыкты да:

— Алга, гвардиячеләр, минем арттан! — дип кычкырды.

Пулеметчылар, дәррәү күтәрелеп, командир артыннан ташландылар. Ләкин йөз метрлар чамасы үткәч үк, калкулыктагы пулеметлар аларны җиргә ятарга мәҗбүр итте.

Нишләргә? Нинди карарга килергә? Берсен берсе кысрыклап, Мингалинең башында төрле уйлар чуала башлады. Бер дзотның утын сүндерер өчен ямьмышлары үз кулына тапшырылган ничәмә-ничә егетне күрәләтә үлемгә куып булмый бит. Ни булса була, үзем барам, диде ул, катгый итеп, һәм автоматын кысыбрак тотты.

Кинәт шул вакытта аның исенә халык шагыйре Мәҗит Гафуриның кайчандыр мәктәптә күңелгә ятлаган шигъри юллары төште:

Килде шул көн: я үлемдер,
Я җиңүдер — башка юк.
Чын каһарман мондый чакта
Курыкмас вә артка атламас.

Менә ул, автоматын күтәреп,— сез калыгыз,— дигән ишарә ясады да, мөмкин кадәр җиргә сыенып, алга, дошман дзотына таба шуышты. Азрак бара да шинель җиңе белән тирен сөртә, арттагы иптәшләренә карап ала һәм тагын үрмәли. Тезләр, терсәкләр кызыша, үзе һаман шул дзот турында уйлый. Аны тизрәк тончыктырасы, укчыларга һәм пулеметчыларга юлны ачасы килә.

Ниһаять, дзот. Мингали үзеннән бары ун адымда аның ике пулемет көпшәсе тырпаеп торган амбразурасын күрде. Алар тын да алмыйча командирларының һәр хәрәкәтен күзәтеп ятучы гвардиячеләр өстенә пуля сиптерүләрен дәвам итәләр. Берсе туктагач, икенчесе тотына.

Гобәйдуллин тагын бер адым атлады да, амбразурага тизәп, озын бер чират җибәрде. Пулеметларның берсе кинәт тынып калды. Көтелмәгән бу хәлдән немецләр бер мәлгә каушап калдылар.

Лейтенант тагын берничә адым амбразурага таба атлады. Шул вакыт икенче пулемет янындагы фашист, ачудан ярсыган офицерның күзләренә карап, пулеметтан тырылдатып алды.

Гобәйдуллинның күз алды кинәт караңгыланып китте, кулыннан автоматы төште. Берничә секунд эчендә, соңгы минутына кадәр, аның бөтен тормышы күз алдыннан үтте. Хәлсез калган тәнне көзән җыера башлады. Артык уйларга да, көтәргә дә вакыт юк иде.

Мингали иптәшләре яткан якка борылып карады да, соңгы көчен җыеп, үлем чәчеп торучы пулемет өстенә капланды.

Дошман пулеметы да, лейтенантның куркусыз йөрәге дә бер үк минутта туктап калдылар. Шул ук минутта гвардиячеләр, ура кычкырып, атакага ташланды һәм фашистларның төп терәге булган калкулыкны штурм белән яулап алды...

Бу көнне, туган иленә һәм хәрби антына турылыклы булып, халкы өчен яшь гомерен биргән гвардияче, татар халкының батыр йөрәкле улы лейтенант Мингали Гобәйдуллинга егерме бер яшь тулды.

Башкортстанда герой туып үскән Оршәкбаш-Карамалы авылы мәктәбенә һәм авылның бер урамына Советлар Союзы Герое Мингали Гобәйдуллин исеме бирелгән.

Мәктәп пионерлары геройның гәүдәсе җирләнгән Херсон шәһәре пионерлары белән элемтә тоталар. Герой каберенә килеп, илгә турылыклы булырга ант итәләр.

Герой каберендә чәчәкләр ятә...

Игорь Алексеев

# КИНОПУБЛИЦИСТИКАНЫҢ СУГЫШЧАН ЖАНРЫ

Илебез, республикабыз халык хуҗалыгының барлык тармакларында көн саен, сәгать саен санап бетергесез зур һәм мөһим үзгәрешләр булып тора. Һәм һәр совет кешесе, тормышның нинди генә тармагында эшләвенә карамастан, шул материаль һәм рухи байлыкларны тудыруда күп очракта үзе дә турыдан-туры катнаша. Үзе катнашу белән бергә, аның бүтәннәр башкарган эшләрне дә яхшырак беләсе, алар турында да күбрәк ишетәсе килә. Шул ук вакытта ул үзен кызыксындыра торган мәгълүматларның бик төгәл һәм мөмкин кадәр кыска булуын да таләп итә.

Заманыбызга хас үзенчәлекләрнең тагын берсе шул: бүгенге совет кешесе теге яки бу мөһим вакыйганы матур итеп сөйләп бирүне генә түгел, бәлки ул вакыйганың фактик дөрес булуын да таләп итә. Бу хәл әдәбиятта, сынлы сәнгатьтә һәм музыкада соңгы елларда аеруча нык сизелә башлады. Документ белән сәнгатьнең синтезы булган документаль кино һәм кинохроника өлкәсендә дә эш шулай тора.

Җәмгыятебезнең хәзерге үсеш темпы, промышленностьның һәм авыл хуҗалыгының бик тиз алга атлавы, зур социаль үзгәрешләр, фәннең яңадан-яңа ачышлар ясап торуы, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге яңа тенденцияләр — болар барысы да бүгенге кинодокументалистлардан кино тасмаларына теркәп баруны гына түгел, бәлки үзенчәлекләрен, сәбәпләрен аңлауны һәм тамашачыга тулырак итеп аңлатып бирүне дә сорыйлар. Тормышның кайсы гына тармагына багышланган булмасын, документаль фильмнан шул тармакка тирәнрәк үтеп керү, тамашачыларга күбрәк, тирәнрәк мәгълүмат бирү һәм ул тамашачыларның үзләрендә дә иҗат, хезмәт дәрте тудыру таләп ителә. Кыскасы, кинопублицистларның эше һаман саен катлаулана бара. Заман тамашачыларының таләпләренә җавап бирерлек фильмнар эшләү өчен, алар да үзләренең профессиональ осталыкларын көннән-көн арттыра барырга, иҗади эзләнүләрен тәрләндерергә һәм тизләтергә мәҗбүрләр. Хәер, бу шулай булырга тиеш тә. Чөнки партиябез һәм хөкүмәтебез совет кинематографларына һәрвакыт зур игътибар биреп киләләр һәм сәнгатьнең бу тирән мөһим политик бурычларны хәл итә ала торган алдынгы һәм сугышчан төре дип исәплиләр. КПСС Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы һәм СССР Министрлар Советының илебез кинематографларына адресланган котлавында менә болай диелгән: «Иҗат коллективларының көче совет кинематографиясенең идея-художество дәрәҗәсен тагын да күтәрүгә, безнең сәнгатебезгә чит булган тәэсирләргә каршы, йомшак, сай эчтәлекле картиналар тудыруга каршы көрәшкә юнәлтелергә тиеш. Безнең кино сәнгатебез киләчәктә дә совет тормышын коммунистик әхлакны ялкынлы пропагачдалаучы, халыклар тынычлыгын һәм дуслыгын алга сөрүче, буржуаз идеология белән

көрәштә какшамас көрәшче булырга тиеш».

Партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең бу чакыруы совет кинематографистларына, шул исәптән Идел буендагы дүрт автономияле республика хезмәт иялөре тормышы елъязмасын чагылдырып бара торган Казан кинопублицистлары отрядына да турыдан-туры кагыла. Алар алдына тагын да зуррак, җаваплырак бурычлар йөкли.

Казан кинохроника студиясе утызынчы еллар башында ук оештырылган иде. Башта ул «Союзкинохроника»ның Казан бүлеге яки «Востоккино»ның Идел-Кама бүлеге буларак эшләп килде. Ә сугыш елларында Куйбышев документаль фильмнар студиясенең Казан корреспондент пункты итеп үзгәртелде һәм 1961 елга тикле хезмәт күрсәтте. Ә 1961 елдан исә Казан кинохроника студиясе итеп үзгәртелде һәм аңа Татарстан, Мари, Мордва, Чуваш автономияле республикаларына хезмәт күрсәтү бурычы йөкләтелде. Нәфис фильмнарны русчадан Идел буендагы биш милләт халыклары телләренә тәрҗемә итү эше дә әлеге Казан студиясенә тапшырылды. Һәм, әйтергә кирәк, узган уч ел эчендә студия шактый зур эшләр башкарды: экранга 60 тан артык документаль һәм техник-пропаганда фильмы, 400 дән артык «На Волге широкой» («Киң Иделдә») дип атала торган киножурнал чыгарды, Идел буе халыклары телләренә 500 дән артык нәфис фильм, татар һәм чуваш телләренә 800 ләп киножурнал тәрҗемә итте.

Казан студиясе эшләп чыгарган фильмнарның байтагы, атап әйткәндә, «Кама-66», «Фестиваль на Волге» («Иделдә фестиваль»), «Ленин в Казани» («Ленин Казанда»), «Сутки» («Бер тәүлек»), «Тукай», «СТЭМ», «Звезды над Нижнекамском» («Түбән Кама өстендә йолдызлар») исемлеләре зона һәм бөтенсоюз конкурсларында, кинофестивальләрендә почетлы призлар, дипломнар һәм грамоталар белән дә бүләкләнделәр. Кыскасы, Казан документалистларының ун еллык хезмәте шактый зур. Казан студиясендә эшләнгән фильмнар турында авыз тутырып һәм озаклап сөйләргә мөмкин булыр иде. Ләкин бер мәкаләдә генә аларның барысына да анализ ясап бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә без Казан студиясе кинопублицистларының иҗади йөзен билгеләп торган аеруча әһәмиятле фильмнарны һәм шул фильмнарның үзенчәлекләре хакында гына сүз алып барырга булдык.

* * *

Сәнгатьнең һәр өлкәсендә эшләүче художникларның да үзенә аеруча якын һәм кабат-кабат кайтып эшли торган һәм күпме эшләсә дә ялыктырмый торган төп бер темасы була. Казан документалистларының әнә шундый яратып эшли торган темалары — Ленин темасы. Һәм моның шулай булуы табигый да. Ильичның революцион яшьлеге белән бәйле шәһәрдәге студия коллективы ничек шушы бәхетле форсатны игътибар үзәгендә тотмасын инде? Студия ачылуның беренче көннәреннән үк Казан режиссерлары һәм операторлары үзләренең кинолениниангсын булдыру өстендә эшли башладылар. В. И. Ленин турында документаль кинотасмалар эшләү — бик җаваплы һәм күп көч, зур белем, тырышлык сорый торган хезмәт. Монда һәр нәрсәне кат-кат уйлап эш итәргә кирәк иде. Казан студиясе документалистлары моның шулай икәнлеген яхшы аңлыйлар иде һәм, үз алларына куйган бурычны тормышка ашыру өчен, бар көчләрен куеп эш башладылар. Бу өлкәдә беренче «чирканчык алу» 1962 елда булды. Казан студиясе коллективы «Киң Иделдә» киножурналының 15 нче санын В. И. Ленинчың тууына 91 ел тулуга багышлап чыгарды. «С Лениным в сердце» («Ленин йөрәктә») дип аталган ул журнал бар яктан да килгән фильм түгел иде әле. Фильм булудан бигрәк, Казанның Ленин белән бәйле урыннары турында сөйли торган информацион лента иде ул.

...Ульяновларның Казандагы йорты, андагы җыйнак һәм гади җиһазлар, Володя утырып эшләгән өстәл. Яшь Ульяновның беренче революцион «чирканчык» алган урыны — Казан университеты. Аның беренче сөрген урыны — Кокушкино авылы күренешләре, Татар академия театры сәхнәсендә куелган «Мылтыклы кеше» спектакленнән бер өзек. Анда В. И. Ленин ролен ТАССРның халык артисты Г. Шамуков башкара...

Менә шундый өзек-өзек күренешләрдән гыйбарәт иде ул киножурнал. Ләкин әнә шул чакта ук инде Казан документалистларының фактларны теркәп-күрсәтеп бару белән генә чикләнмичә, публицистик гомумиләштерүләр ясарга омтылулары да сизелеп тора иде. Әйтик, авторларның журналны кышкы йокыдан уянып килә торган язгы табигать күренешләре белән башлап җибәреп, Казандагы Ильич һәйкәле янына бөек юлбашчы васыятьләренә һәм комму-

нистлар партиясенә турылыклы булырга ант бирергә килүче пионерлар маршын күрсәтү белән тәмамлап куюлары әнә шул хакта сөйли иде.

Турыдан-туры Ленинга багышланган фильмнар эшләмәсәләр дә, Казан студиясе хезмәткәрләре моннан соңгы елларда да бу темага әледән-әле мөрәҗәгать итеп килделәр. Алар республикабыз хезмәт ияләренең Ильич васыятьләрен ничек итеп тормышка ашыруларын, Идел буенда яшәүче төрле милләт халыкларының үзара дуслыгын, Ленин өйрәткәнчә тыгыз элемтәдә торуларын ачык чагылдыра торган киножурналлар эшләделәр. Шулай итеп, акрынакрын үзләренең киноленинианасын тудыру өчен тәҗрибә тупладылар.

В. И. Ленинның йөз еллыгына әзерлек уңае белән илебездә башланган хезмәт күтәренкелеге һәм бөтен халык энтузиазмы Казан студиясе хезмәткәрләре эшенә дә бик зур йогынты ясады. Зур юбилей көннәренә республикабыз хезмәт ияләренең нинди уңышлар белән килүен күрсәтә торган киножурналлар белән бер үк вакытта, Казан документалистлары Ленинга багышланган фильмнар иҗат итү өчен дә бик актив эш башладылар. А. Стремяковның «Володя Ульянов» исемле кинохикәясе әнә шундый фильмнарның берсе булды. Бу фильмның отышлы ягы шунда, анда фотодокументаль материаллар ярдәмендә Володя Ульяновның күңелендә әле бала вакытында ук шул чорда яшәп килгән стройга карата нәфрәт тууы һәм үсә төшкәч ул нәфрәтнең аңлы протестка әверелүе уңышлы күрсәтелгән.

«Киң Иделдә» киножурналының «80 ел үткәч» исемле махсус чыгарылышында Ленин темасы шулай ук үзенчәлекле һәм кызыклы хәл ителгән. Ул кинолента 1887 елда Казан университетында Володя Ульянов катнашында үткәрелгән студентлар сходкасының еллыгына багышланган. Ләкин ул тарихи сходка турындагы лента гына түгел. Анда бүгенге студентлар тормышы да чагылдырылган. Аудиторияләрдә дә, уку залларында да, спорт залларында, фәнни түгәрәк утырышларында да күрәбез без аларны. Алар барысы да бер максат белән яши: Ленинның укырга, укырга, укырга дигән васыятен тормышка ашырырга тырышалар.

Казан студиясенең бу хезмәте Ленин тематикасын яктыртуда тагын бер адым алга китеш булды. Әмма студиянең бу темага багышланган иң уңышлы һәм иң җитди хезмәте — «Ленин в Казани» («Ленин Казанда») исемле фильм.

Владимир Ильич Ленин үзе тутырган анкеталарның берсендәге: «Революцион көрәш юлына беренче тапкыр кайда аяк бастың?» дигән сорауга «Казан университетында» дип җавап биргән. «Ленин Казанда»ның авторы В. Стрельков һәм операторы В. Николаев бу фильмны эшләгәндә менә шул фактны кинопублицистика теле белән экранга күчереп күрсәтүне максат итеп куйганнар. ТАССР дәүләт музеенда, Казандагы В. И. Ленин музей-йортында, Лобачевский исемендәге китапханәдә саклана торган фотоматериаллар, В. И. Ленин туганнарының истәлекләре һәм архив документлары нигезендә эшләнгән бу документаль фильмда натурадан төшерелгән бер генә кадр да юк. Ул гел документлардан гына тора. һәм аның әнә шулай булуы аеруча әһәмиятле дә инде. Бу фильмның уңышы бигрәк тә шунда, анда әлеге фоторәсемнәр һәм документлар коры рәсем һәм коры документ кына булып калмаган. Режиссерның осталыгы нәтиҗәсендә алар җанланып киткәндәй булганнар, тамашачыны да дулкынландырып, аның да күңеленә тирән сеңеп калырлык итеп экранлаштырылганнар.

Менә шуңа күрә дә студиянең «Ленин Казанда» исемле бу документаль фильмы бөтенсоюз киноленинианасында лаеклы урынны алды: ул, СССР халыклары телләреннән тыш, социалистик илләр халыклары телләренә дә тәрҗемә ителде; В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышлап чит илләрдә үткәрелгән кинофестивальләрдә дә күп мәртәбәләр күрсәтелде.

* * *

Хәзерге заманда документаль кинофильмнарның мөһим социаль теманы кузгатканнары һәм аларда күрсәтелгән фактларга карата кинопублицистның үз уй-фикерләре ачык чагылдырылганнары гына яхшы фильм булып санала. Шул ук вакытта бүгенге көн тамашачысы документаль фильмнарда теге яки бу фактны дөрес күрсәтеп бирүне генә түгел, бәлки ул фактларның драматургик алымнар аша кызыклы итеп күрсәтелүен дә күрергә тели. Шундый сорау туарга мөмкин: фактның дөреслегенә хилафлык китермичә моңа ирешергә мөмкинме соң? Бу сорауга җавап бирү өчен Казан документалистлары иҗатында

тагын бер әһәмиятле урын алып тора торган тематиканы — патриотизм тематикасын күздән кичереп үтик.

Патриотизм темасы — бик киң һәм күп планлы тема. Аны тормышка ашыруның формалары да бик күп төрле. Шул ук вакытта бу бик катлаулы һәм җаваплы эш тә. Моның шулай икәнлеге бигрәк тә документаль фильмнар иҗат иткәндә нык сизелә. Әйтик, художестволы фильм тудыру өстендә эшләүче режиссерның теге яки бу мәсьәләне хәл кылганда билгеле бер дәрәҗәдә үзенең хыялын кушып җибәрергә хакы булса да, документаль фильм иҗат итүче режиссерга факттан аз гына да читкә китәргә ярамый. Хәтта теге яки бу вакыйгага һәм фактка карата аның үз фикере булса да, ул әлеге вакыйганың һәм фактның документальлегеннән, тарихи дөреслегеннән тайпылырга тиеш түгел. Шул ук вакытта ул вакыйгаларны, тарихи фактларны экранлаштырганда аларны художестволы-драматик чаралар аша тамашачыга җиткерү турында да бик нык уйланырга мәҗбүр. Шулай булмаган очракта, аның фильмы ялыктыргыч һәм бик сүлпән булып чыгарга мөмкин. Димәк, яхшы кинодокументалистлар, бер яктан, фактны тормыштагыча күрсәтүне, икенче яктан, аны тамашачы өчен кызыклы итеп күрсәтүне һәрвакыт күз уңында тотып эш итәргә тиешләр. Шул максатка ирешкән очракта гына аларның фильмнары тамашачының игътибарын җәлеп итә, аның күңелендә уй-фикер кузгата.

Казан документалистларының эшләре шушы күзлектән карaганда ничегрәк тора соң? Алдан ук әйтеп куярга кирәк, алар бу мәсьәләдә дә беренче фильмнары белән ук шактый гына уңышларга ирештеләр. Мин режиссер Йолдыз Карамышеваның Муса Җәлил турындагы «Жизнь-песня» («Тормыш-җыр») исемле документаль фильмын күздә тотып әйтәм. Бу фильм Казан студиясенең патриотизм темасына багышланган беренче хезмәте иде. Мин аның эчтәлеген сөйләп тормыйм, чөнки журнал укучылары арасында ул фильмны карамаган кешеләр сирәктер дип уйлыйм. Тик шуны гына искәртеп китәсем килә: бу фильмны эшләгәндә Й. Карамышева, материаль документальлеген саклаган хәлдә, драматургик яктан да мәсьәләгә үзенчә килергә тырышкан. Шуның нәтиҗәсендә фильм шактый уңышлы, тамашачыларны дулкынландыра торган булып чыккан. Муса Җәлил бөтен дөнья халкына билгеле булган патриот шагыйрь. Аның иҗаты турында да, батырлыгы турында да бик күп китаплар язылды һәм хәзер дә языла тора. Шулай булуга да карамастан, «Тормыш-җыр» исемле документаль фильм Муса Җәлил турындагы әнә шул күп санлы материаллар арасында һич тә югалып калмады, тамашачылар тарафыннан җылы каршыланды. Ә бу хәл безнең Казан документалистларының экранлаштыру өчен зур осталык таләп итә торган патриотик теманы да әйбәт кенә хәл кыла алуларын дә раслый булса кирәк.

Шул ук патриотизм темасына багышланган һәм Казан документалистлары тарафыннан иҗат ителгән «Помнит мир спасенный» («Коткарылган дөньяның хәтерендә») исемле документаль лента да студия хезмәткәрләренең уңышы саналырга лаеклы. Якташыбыз, Ватан сугышы елларындагы атаклы снайпер Анатолий Чеховның легендар батырлыгын чагылдыруга багышланган бу фильмның режиссеры В. Шорохов, документаль хрониканы бик урынлы файдаланып, кырыс сугыш еллары атмосферасын дөрес һәм тәэсирле итеп күрсәтә алган. Безнеңчә, бу фильмның аеруча отышлы ягы шул, анда сүз бер Анатолий Чехов турында гына барган кебек булса да, халкыбызның сугыш елларындагы күрсәткән күмәк батырлыгы һәм туган илгә турылыклы булуы бик ачык һәм дөрес чагылыш тапкан.

Тыныч елларда патриотизм төшенчәсенең характеры бераз үзгәрә, башкачарак төсмер ала. Ләкин бу төшенчәнең асылы барыбер үзгәрешсез кала. Ул — илгә, туып үскән җиренә һәм халыкка мәхәббәт. Әгәр художник (бу очракта кинодокументалист) менә шушы санап кителгән нәрсәләрне экранда уңышлы чагылдырып, тамашачының күңеленә тәэсир итәрлек итеп күрсәтеп бирә ала икән, ул инде һәр совет художнигының изге бурычы булган патриотик тәрбия бурычын уңышлы үтәп чыккан була. «Кама-66» исемле документаль фильм, безнең фикеребезчә, нәкъ әнә шул зур һәм изге максатны күздә тотып эшләнгән. А. Стремяковның бу фильмын мин туган җиребез буйлап ага торган, илебезгә, халкыбызга әллә кай заманнардан бирле искиткеч зур хезмәт күрсәтеп килә торган Кама елгасы турында, ул елга ярында гаҗәеп зур эшләр башкара торган батыр кешеләр турында поэма дип атар идем.

...Кама җанлы тарих ул. Татар халкының бабалары аны Чулман дип йөрткән. Алар шул Чулманда су коенганнар, көек-

ларда йөзгәннәр. Шушы елга буйлап Ермак Себерне буйсындырырга юл тоткан. Бу елганың ярларында кешеләр бик күп тоз запаслары, аңа Вишера килеп кушылган урында алмаз ташлары тапканнар. Ә анчары Кама буенда нефть ятмалары табылды. Кама буйлары үзенең матурлыгы белән дә элек-электән дан тотып килгән. Шишкин үзенең бөтен дөньяга таралган атаклы нарат урманын шушы Кама буйларындагы зифа агачларга карап ясаган бит инде... Кама бер үк вакытта илебезнең борынгы үткәне дә, хәзерге яшьлеге дә. Шушы Кама буенда хәзер илебезнең эшчән кызлары һәм эшчән егетләре моңарчы дөньяда тиңе күренмәгән автогигант төзиләр, иң яңа һәм иң матур шәһәр салалар... Ниһаять, җәй айларында шушы елга буйлап никадәр йөк ташылуын, җилдән җитез чаба торган «Метеор»ларга, «Ракета»ларга утырып күпме кеше сәяхәт кылып йөргән дә искә алсак, Каманың илебез тормышында тоткан мөһим урыны турында озаклап сөйләп торуның хаҗәте дә калмый шикелле.

Ә «Кама-66» исемле документаль фильмның авторлары мәсьәләгә Каманың нәкъ менә шул якларын күздә тотып якын килгәннәр дә инде. Шуңа күрә фильм бер үк вакытта мавыктыргыч та, тамашачыларга зур мәгълүмат бирә алырлык, һәм аларда патриотизм хисләре уятырлык та булып чыккан. Бу фильмның бердәнбер кимчелеге шул, аның исеме уңышлы түгел. Кама тикле Каманың художестволы образын тудырган авторлар, кызганычка каршы, яхшырак исем табу турында тиешенчә уйламаганнар. Күрәсең, модага ияргәннәрдер инде.

Казан документалистлары тарафыннан иҗат ителгән һәм патриотизм темасын яктыртуга багышланган әйбәт фильмнарның тагын берсе — «Эрьзя». Эрьзя — мордва скульпторы Степан Нефедовның псевдонимы. Степан Нефедовның язмышы шактый катлаулы була. Байтак еллар, туган җиреннән аерылып, чит илдә яшәргә туры килә аңа. Ләкин ул шул хәлендә дә күңеле һәм эше белән туган иленә, туган халкына турылыклы булып кала. Һәм ахыр чиктә барыбер туган якларына әйләнеп кайта. «Эрьзя» фильмында сүз әнә шул хакта алып барыла. Кеше туган иленнән читтә кешечә яши дә алмый, яхшылап иҗат итә дә алмый. Кеше туган иленнән читтә беркайчан да бәхетле була алмый. Дан да, байлык та туган илне алыштыра алмый... Степан Нефедовның тормыш һәм иҗат юлын экранлаштыру аша фильм авторлары әнә шул бик дөрес фикерне алга сөргәннәр. Шунысы куанычлы: бу фикер коры декларация булып кына калмаган, бәлки тиешле художество чаралары табылып, тамашачыларга нык тәэсир итәрлек итеп үткәрелгән.

Халыкара дуслык темасына багышланган «Фестиваль на Волге» («Иделдә фестиваль») исемле документаль фильм, «Киң Иделдә» киножурналының «Люблю и ненавижу». («Яратам һәм күралмыйм») исемле махсус чыгарылышы һәм «Мы с тобой, Вьетнам!» («Без синең белән, Вьетнам!») исемле лентасы шулай ук Казан документалистларының бу өлкәдә шактый актив эшләүләрен күрсәтеп торалар.

* * *

Совет документаль кинолларында эшчеләр һәм крестьяннар тормышын чагылдыруга элек-электән зур әһәмият бирел килende һәм бу тема хәзер дә шулай ук киң яктыртыла. Күп санлы совет кинематографистларының бер отряды булган Казан документалистлары да героик хезмәт темасын экранда чагылдыруны үзләренең төп бурычларының берсе итеп саныйлар. Ә промышленность өлкәсендә дә, авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә елдан-ел зуррак уңышларга ирешеп бара торган безнең республикабызда кино герое булырлык хезмәт алдынгылары бик күп. Тик аларны күрә белергә, художникларча осталык белән экранлаштырырга гына кирәк. Менә монда кинодокументалисттан аеруча зур осталык сорала. Ул тегe яки бу алдынгы кешене фән һәм техника яңалыкларын гади күрсәтү белән генә чикләнеп калмаска, бәлки зур гомумиләштерүләр ясап, мөһим проблемалар кузгату аша күрсәтергә тиеш. Икенче төрле итеп әйткәндә, кинодокументалист күп санлы алдынгыларның һәм яңалыкларның иң алдынгыларын һәм иң әһәмиятле яңалыкларны аерып ала һәм шуларны калку итеп, тамашачыга тәэсирле итеп күрсәтеп бирә белергә тиеш.

Казан студиясе хезмәткәрләре тарафыннан эшләп чыгарылган фильмнар арасында менә шушы мактаулы һәм мөһим мәсьәләне уңышлы хәл иткән документаль фильмнарның берсе — «Сутки» («Бер тәүлек»).

Хезмәт героикасын экранлаштыруның документаль чаралары күп төрле. Бу мәсьәләне һәр автор үзенчә хәл итәргә тырыша. «Бер тәүлек» исемле фильмны эшләгәндә Казан операторлары Л. Барышев

һәм В. Севостьянов бу теманы шактый үзенчәлекле хәл иткәннәр. Алар бер нефтьчеләр бригадасының бер тәүлек эчендәге тормышын сөйләп биргәннәр. Ләкин алар моны сүз белән түгел, бәлки экран теле белән әлеге бригаданың бер тәүлек эчендәге эшен һәм тормышын күрсәтү юлы белән башкарганнар. Тамашачы бу фильмда барысын да: вертолет белән очып килеп вахта алышынуын да, бригаданың табигый кыенлыклар белән көрәшен, аварияне бетерү өчен тырышуын да, төнге сменада эшләүнең кыенлыгын да үз күзләре белән күреп бара. Шуңа күрә ул бу очракта диктор сөйләп-аңлатып баруга һич тә мохтаҗ түгел. Ул барысын да үзе аңлый, барысына да үзе бәя биреп бара. Фильм авторлары бары тик фильмның башында һәм ахырында Бөтенсоюз радиосыннан тапшырылган кыска-кыска ике информация бирү белән генә чикләнгәннәр һәм бик дөрес иткәннәр. Әгәр алар инде бик күп фильмнарда кабатланган шаблон буенча китеп, әлеге бригаданың бер тәүлек дәвамындагы тормышы турында диктордан комментарий бирдереп бардырган булсалар — бу фильм башкалардан бер дә аерылып тормас, шулар арасында югалып калыр иде. Ә «Бер тәүлек» югалып калмады: 1970 елның апрелендә Свердловск шәһәрендә эшчеләр сыйныфы турындагы документаль фильмнарга үткәрелгән смотрда бу темага багышланган иң әйбәт фильм буларак, махсус приз белән бүләкләнде.

Хезмәт темасын үзенчәлекле хәл итү ягыннан режиссер Д. Дальскийның «Түбән Кама өстендә йолдызлар» исемле документаль фильмы шулай ук игътибарга лаеклы. Бу фильмның әйбәт сыйфатларыннан берсе шул: анда төзелеш турында төзүчеләр үзләре сөйлиләр. Ә бу хәл әлеге дә баягы инде шактый туйдырган диктор сөйләп баруга караганда күп тапкыр отышлы, чөнки тамашачыга төзүчеләр хезмәте турында төзүчеләрнең үзләре сөйләве кызыклырак та, тәэсирлерәк тә. Төзүчеләр үз профессияләре хакында нинди фикердә, ни өчен алар әйбәт квартираларын, семьяларын калдырып, монда бернинди дә уңай шартлары булмаган Түбән Кама төзелешенә эшкә килгәннәр? Фильм авторлары менә шул сорауларга җавап бирүне максат итеп куйганнар. Бу җәһәттән фильм режиссеры белән Түбән Кама төзелешендә эшләүче монтажниклар бригадасы члены Юрий Чепурный арасында булган сөйләшү бик гыйбрәтле.

— Кайдан килдең? — дип сорый режиссер.

— Зәйдән,— ди тегесе.

— Ә анда кайда эшләдең?

— Электромонтажник идем.

— Нәрсә, акчасы аз төшә идемени?

— Нигә? Аз түгел иде.

— Ә ник монда килдең соң?

— Нигә килдемме? Яңа төзелештә кызык. Монда эш мин пенсиягә чыкканчы җитәрлек.

Күрәсең, Юрий күп акча эшләүне максат итеп тә, нинди дер бүтән җиңеллекләр эзләп тә килмәгән. Бары тик йөрәге кушканча, күңеле яңага, кызыкка омтылганга килгән ул. Бу — безнең заман эшчеләренең уртак фикере. Безнең заманда хезмәт — кешенең рухи таләбенә әверелүен бик ачык раслый торган факт.

Казан документалистлары республикабызның авыл хуҗалыгында барган зур үзгәрешләрне экран аша тамашачыларга ирештерү юнәлешендә дә соңгы елларда шактый актив эш алып бара башладылар. Шул уңайдан «Киң Иделдә» киножурналының колхозчыларның Бөтенсоюз съездына багышланган һәм кыска гына итеп «Икмәк» дип аталган махсус чыгарылышына тукталып үтәсе килә. Безнең уебызча, режиссер Х. Фәхретдинов эшләгән бу лента Татарстан авыл хуҗалыгы хезмәт иярләре турындагы фильмнарның иң уңышлысы. Бу фильмда республикабыз колхозларындагы һәм совхозларындагы хәзерге авыл хуҗалыгы техникасы әле беренче тапкыр бөтен тулылыгы белән күрсәтелгән. Күп санлы тракторлар, комбайннар, автомашиналар, ындыр табакларына кайтарылган ашлыкны эшкәртү техникасы, элеваторлардагы куәтле пневмонасослар — менә шулар барысы бергә күрсәтелгәч, республикабызда югары уңыш өчен көрәшнең никадәр ышанычлы булуын һәм зур масштабта алып барылуын бик ачык чагылдыралар. Шуның сын аеруча басым ясап әйтергә кирәк: техникага күп урын бирелүгә карамастан, бу фильмда барлык материаль байлыкларны тудыручы, әлеге куәтле һәм катлаулы техника белән идарә итүче зат — кеше дә югалып калмаган. Аңа да экранда тиешле урын бирелгән. Фильмда авыл хезмәт иярләренең үзләре өчен иң җаваплы чорда — урып-җыю көннәрендә искиткеч зур тырышлык белән һәр минутның кадерен белеп эшләүләре һәм, шулай итеп, зур уңышларга ирешүләре бик дөрес, уңышлы чагылдырылган.

* * *

Казан хроника студиясенең соңгы еллардагы эшчеләре турында сүз алып барганда «Татарстан, 1970 нче ел» исемле фильмга тукталып китмичә мөмкин түгел. Хикмәт шунда, бу Казан студиясендә эшләнгән беренче киң экранлы документаль фильм. Татарстанның илле еллыгына багышлап эшләнгән бу фильмның тагын бер үзенчәлеге шунда, анда Казан документалистлары нибары илле минут вакытка исәпләнгән лентада Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының узган тарихи илле ел эчендә ирешкән уңышларын һәм татар халкы тормышында булган үзгәрешләрне чагылдырырга тырышканнар. Фильмның сюжеты бик гади: ул республикабыз һәм аның кешеләре хакында лирик сөйләмнән гыйбарәт.

...Казан портына бертуктаусыз теплоходлар, «Метеор»лар килеп тора. Аларга утырып башкалабызга илнең төрле почмакларыннан һәм чит мәмләкәтләрдән күп санлы кунаклар килә. Даһи Ленин булган урыннарны, ул йөргән урамнарны карарга киләләр алар. Фильм әнә шул кешеләрне күрсәтү белән башланып китә. Һәм аның шулай башлануы бик яхшы. Безнең Татарстаныбыз узган илле ел эчендә искиткеч зур уңышларга ирешкән икән, бу — В. И. Ленин идеяләренең тантанасы лабаса! Бер кем дә онытылмаган, барысы да истә. Менә шушы фикер фильмның буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып бара. Анда республикабызның беренче елларындагы тормышын күрсәткән документаль кадрлар да, хәзерге үсешен чагылдыручылары да үзара чиратлаша барып, узган илле ел эчендә Совет Татарстаны ирешкән биеклекләрнең никадәр зур булуын, даһи Ленин идеяләренең никадәр дөрес икәнлеген тамашачылар күз алдына бик ачык итеп бастыралар. Ул фильмда Татарстанның атаклы нефть республикасы, мул иген үстерә торган республика, алдынгы промышленность һәм зур химия республикасы, югары культурага һәм зур сәнгатькә ия республика булуы да уңышлы чагылышын тапкан. Бер сүз белән генә әйткәндә, «Татарстан, 1970 нче ел» исемле бу фильм Казан документалистларының соңгы еллардагы аеруча зур уңышы һәм ул студия хезмәткәрләренең иҗади алга китеше турында сөйли.

* * *

Татарстан кинематографистларының документаль фильмнары Бөтенсоюз экраннарында танылсалар да, һәм аларның күбесе төрле призлар, грамоталар алуга лаек булсалар да, кинопериодика өлкәсендәге эшләре алай мактарлык түгел әле. «Киң Иделдә» киножурналлары белән танышканнан соң шундый фикергә киләсең: студия хроникерлары булып үткән вакыйгалар турында тамашачыларга шактый оста хәбәр итәргә өйрәнгәннәр. Ләкин хәбәр итәргә генә шул. Сүз дә юк, документаль кинода хәбәр итү, ягъни информация дә булырга тиеш. Ләкин ул информация чама беләнрәк кенә, артык төртеп тормый торган итеп кенә бирелергә тиеш. Югыйсә, безнең киножурналларның күбесе газета, радио һәм телевидение аша халыкка җиткерелә торган хәбәрләрдән әллә ни аерылып тормый торган була. Радио, газета һәм телевидение — болар барысы да теге яки бу вакыйганы янсә яңалыкны көне-сәгате белән халыкка җиткерә алалар. Шулай итеп, алар бик мөһим эш башкаралар. Гомумән, аларның төп вазифалары шул. Ә менә кинохрониканың андый мөмкинлекләре юк һәм була да алмый. Чөнки ул айга бер-ике тапкыр гына чыгарыла. Аннары аны әзерләп чыгаруга да шактый вакыт китә. Бүген яңа һәм кызыклы булып күренгән вакыйгалар киножурнал экраннарга чыкканда инде үзенең актуальлеген югалткан булырга мөмкин. Менә шундый хәлләр булмасын өчен, кинематографистлар күп санлы яңалыклар һәм вакыйгалар арасыннан аеруча яңаларын һәм әһәмиятләрен тиз генә югалтмый торганнарын сайлап ала белергә тиешләр. Безнең Казан кинематографистларына, кызганычка каршы, нәкъ әнә шул сизгерлек җитеп бетми. Алар еш кына вак темалар, әһәмияте әллә ни зур булмаган фактлар белән мавыгып китәләр. Киножурналларның күбесендә вакыйгаларга тирән анализ бирә белү, операторларның һәм режиссерларның ул вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен чагылдыра белү җитми. Күбесенчә, өйрәнелгән һәм инде тамашачыларга туйдырып бетергән бер төрле алымнар белән эш итү әле һаман үзен бик нык сиздерә. Фән һәм сәнгать эшлеклеләре, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре турындагы журналларда бу хәл аеруча күзгә ташлана.

Сүз җае чыкканда студия коллективының йомшак якларыннан берсе респуб-

ликабыздагы фән һәм культура тормышын тиешенчә чагылдыра алмауга кайтып калуын да әйтеп үтәсе килә. Документалистның бу өлкәдәге хезмәтләре, бердән, бик аз («Профессор Камай», «А. Арбузов — химик», «Тукай», «Нәҗип Җиһанов») икенчедән, алар заманыбызның таләпчән тамашачыларын да, кинематографистларның үзләрен дә һич канәгатьләндерерлек түгелләр. Бу фильмнар татар фәне ирешкән зур уңышларны, һаман алга барган әдәбият һәм сәнгать казанышларын һәм гомумән ике орденлы Татарстан культурасын бөтен тулылыгы белән күрсәтеп бирүдән бик ерак торалар әле.

Сугышчан кинопублицистика жанры халык массаларын агартуда һәм аларга коммунистик тәрбия бирүдә элек-электән әһәмиятле чара булып килде һәм бу хәзер дә шулай. Менә бу өлкәдә Татарстан кинематографистларының эшлисе эшләре байтак әле. Әйтик, тарихи һәм революциontарихи темалар. Безнең Татарстанда кая гына басма — шунда тарих лабасы! Һәм нинди генә тарих диген әле! Берничәсен генә атап үтик: Камил Якубов, Галимҗан Ибраһимов, Александр Гинцбург, Владимир Азин — болар һәркайсы аерым бер фильмлык темалар бит. Ә генералларыбыздан Гани Сафиуллин, Якуб Чанышев, Бөек Ватан сугышы кырларында һәлак булган каһарманнарыбыздан Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин, дошманның борын төбеннән аның үз самолетына утырып очып китеп иптәшләре белән исән-сау туган илебезгә кайткан һәм хәзер дә Иделдә «Метеор» капитаны булып эшләп йөри торган легендар Михаил Девятаев, даннары бөтен илебезгә таралган атаклы нефтьчеләребез, химикларыбыз, мул уңыш үстерүче игенчеләребез — болар барысы да татар халкының сугышчан һәм тыныч тормыш елларында башкарган героик хезмәтләренең елъязмасына кереп калырга лаеклы кешеләр бит. Һәм менә шундый замандашларыбыз турында яхшы публицистик фильмнар эшләү — кино хезмәткәрләренең төп һәм изге бурычы булып тора.

СССР кинематографистлары съездында катнашучыларның КПСС Үзәк Комитетына мөрәҗәгатендә түбәндәге юллар бар: «Коммунистлар партиясе, аның Үзәк Комитеты ихтыяры һәм кайгыртучанлыгы белән совет кинематографистларының художестволы иҗаты өчен барлык уңай шартлар тудырылган... Мондый кайгыртучанлыкка җавап бирү өчен, без рухланып иҗат итүне, эпохабызның чын геройлары тормышын, данлы тарихи үткәнен һәм бүгенге зур уңышларын дөрес, югары художестволы образлар аркылы күрсәткән әсәрләр тудыруны, социалистик җәмгыять юлында торган барлык нәрсәләргә каршы көрәшүне үзебезнең бурычыбыз итеп саныйбыз».

Бу сүзләр Казан кинохроника студиясе документалистларына да тулысы белән кагыла. Һәм алар да хәзер бөтен көчләрен биреп, илһамланып, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXIV съезды сәнгать хезмәткәрләре алдына куйган бурычларны үтәү өчен тырышалар.

≈≈≈≈≈≈

**Лэбибә Ихсанова**

# ЗАМАНДАШЫМ ТУРЫНДА

Мин кергәндә Гәүһәр телевизор каршында утыра иде. Мәскәүдән спектакль тапшыралар икән. Узганда бер кереп чыга торган гади танышы түгел, газиз әнкәсе килсә дә, бүген аны урыныннан кубаруы кыен икәнен күреп торам. Биш ел укыган башкаланың таныш театры, яраткан артистлар... Яшьлек еллары шуларның иҗатына табынып, шулардан өйрәнеп узган бит.

Кечкенә лампадан аз гына якты төшеп торган өч кырлы журнал өстәле янына килеп, креслога җайлап утырам. Өстәлдә бүген килгән газеталар һәм театр журналлары ята. Бәрхет тышлы фотоальбом читеннән ниндидер конвертның почмагы күренеп тора. Тапшыру озаккарак китсә, юанып торырлык әйберләр күп монда. Ләкин мин альбом алырга да, журналлар актарырга да ашыкмыйм, телевизор экраныннан төшкән зәңгәр яктылык аша бүлмәне күзәтәм. Ничә керер күз төшергәнем юк иде. Кош оясыдай җайлы, җыйнак бүлмәнең стеналары сыек яшел төскә буялган икән. Вак-төяк рәсемнәр белән дә чуарланмаган, бизәкле тәлинкәләр, кош каурыйлары да эленмәгән. Кергән бер кешенең күзе төшәрлек урында татар театрының беренче артистларыннан берсе булган Габдулла Камал I нең зурайтылган рәсеме генә тора. Ул — Гәүһәрнең әтисе. Татар әдәбияты классигы Галиәсгар Камалның бертуган энесе.

«Сәйяр» труппасында артист, режиссер, художник булып эшләгән, оригиналь әсәрләр язып та, рус һәм дөнья классикларын татарчалаштырып та театрның репертуарын кайгыртып яшәгән Галиәсгар Камалның сәхнәгә мәхәббәте бертуган энеләре Габдулла белән Габдрахманга да күчә. Габдулла Камал I бөтен гомерен театрга багышлап, «Сәйяр» артистларының авыр һәм романтикалы тормышын уртаклаша. Революциядән соң бу мәхәббәт тагын да көчәеп, егетнең бөтен күңелен биләп ала. Ул фронт труппаларында гражданнар сугышының ялкынлы юлларыннан уза, үзбәк, төркмән театрларын булдыруда, андагы милли сәнгать кадрларын үстерешүдә зур көч куя. Соңыннан агасы Галиәсгар Камал исемен йөрткән Татар академия театрында рухланып эшли. Әйе, гомере юкка үтмәгән. Артта татар халкын шатландырган матур образлар калган. Ә алда, сәхнәдә Камаллар традициясен дәвам иттерүче тормыш иптәше Фатыйма ханымның матур иҗат юлы бар. Инде менә кызы Гәүһәр...

Мамык шәлгә төренеп диванда утырган Гәүһәрнең бала чакларын күз алдына китерергә тырышам. Тетар сәнгатенең нечкәлекләре Гәүһәргә ана сөте белән күчкән булса да гаҗәп түгел. Аның әнисе Фатыйма ханым да унсигезенче еллардан бирле сәхнәдә уйнап килә бит. Ата-анасы роль өйрәнгән чакларында әле берни аңламаган сабый, гөнаһсыз күзләрен мөлдерәтеп, гаҗәпләнеп карап торгандыр, бүлмәдә шат авазлар яңгыраса, кулларын чәбәкләп көлгәндер, роль өйрәнүчеләрнең тавышы хәвефле, я рәнҗү белән ишетелсә, энҗе яшьләрен тәгәрәтеп елап җибәргәндер.



Габдулла да, Фатыйма да кызлары Гәүһәрне артистка итәргә теләгәннәр. Бу табигый да. Элегрәк үзенең һөнәрен бик яраткан такта яручы да, минем улым пилачы булыр, пилачы булыр, дип сөйгән ди бит баласын.

Яраткан эшенең ләззәтен балаларыңа бирү үзе бер талант ул.

Тукайның «Бала белән күбәләк» шигырен сөйләп сәхнәгә баскан нәни Гәүһәр сигез-ун яшьләренә кадәр әти-әнисе эшләгән Оренбург, Астрахань сәхнәләрендә малай рольләрен уйнап йөри. Ул заманның театр белгечләре Гәүһәрнең шактый «чын» итеп уйнавын әйтәләр. Әтисеннән килгән матур тембрлы көр тавышын, әнисеннән күчкән ихлас күңеллелек, хислелекне күрәләр.

Әмма Гәүһәр чын театр сәхнәсенә шактый өлгереп, Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр сәнгате институты студиясен тәмамлап кайткач кына аяк баса. Сугыш башлангач заводта эшләргә тотынган кыз өчен уку еллары өлкән буын артистларының бик күбесе хыялланa да алмаган олы бәхет була.

Әле 1944 нче ел гына бара. Мәскәү әле сугыш ритмы, сугыш авырлыклары белән яши. Бөтен җирдә соры шинельле хәрбиләр, азык кибетләрендә озын-озын чиратлар, трамвай-троллейбусларга утырыр хәл юк. Шулай да Левитанның куанычлы хәбәрләр китергән көр авазы торган саен ешрак, тантаналырак яңгырый.

Яшьлеккә ни җитә! Яшьләргә син дәртен дәрләтерлек эш бир, рухын күтәрерлек сәбәп тап. Тормыш авырлыгына исе дә китми аның шул чагында. Гәүһәр һәм аның сабакташлары өчен уку еллары өр-яңа бер дөнья була. Бала чакның буй җитмәс, күз күрмәс хыялы булып тоелган Мәскәүнең үзендә яшәү, заманында атаклы Самойловлар, Садовскийлар, Яблочкиналар, Турчаниналар ачып керган театр ишекләреннән, борынгы храмнарга кергәндәй, тантана һәм олылау хисе кичереп узулар, Тархановлар, Поповлар, Пыжовалардан сәхнә серләрен өйрәнүләр гомернең онытылмас сәхифәләре булып калдылар. Өченче курска җиткәч, бик яхшы укуы һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен Гәүһәр Дәүләт стипендиясе ала башлый. Институт сәхнәсендә мавыгып уйнаган кызның көннән-көн ачыла барган сәләтенә укытучылар югары бәя бирәләр. Чыгарылыш имтиханы өчен әзерләнгән спектакльне карагач, М. Горький исемендәге Мәскәү художество академия театры артисты-режиссеры А. А. Андерс аңа болай дип әйтә:

— Кадерле Гәүһәр, чын йөрәктән тәбрик итәм үзегезне! Театрны шундый көчле яратуыгызга, сәнгать дәреслегенә нык ышануыгызга сокланам. Сәхнәдә ныклы урын алачагыгызга минем шигем юк.

Диплом спектаклендә Гәүһәр Максим Горькийның атаклы пьесасыннан Васса Железнова ролен башкара. Шул спектакльдә уйнап ул Казан тамашачылары алдында беренче сынауны үтә. Утыз бишенче еллардан бирле бөек әдипнең бу әсәрен ничәмә-ничә буын артистлары башкаргандыр. Бөек рус сәхнәсендә туган Васса образы онытылмас булып хәтердә калган. Ә син инде табылган бизәкләр арасыннан үзеңнекен, үзең генә күргәнне ачарга, үз Вассаңны тудырырга тиешсең.

Тулы гәүдәсенә килешеп торган озын кара күлмәктән Васса-Гәүһәрнең сәхнәгә килеп кергән минутын хәтерлим әле мин. Күкрәк өстендә алтын чылбырга тагылган медальон-сәгать. Ашыкмыйча, вәкарь белән генә йөри, күкрәк тавышы белән салмак кына сөйләшә. Әйтерсең лә бу дөньяга мәңге килгән дә уч төбендә җир шарын уйната. Ул бай. Шуңа ул үзен көчле тоя. Ул үзенең байлыгын, үзенең идеалларын саклап калырга тели. Аның максаты ачык — ул үзенең варисларын яшәтергә, үз фәлсәфәсен аларга да калдырырга тели. Шуңа күрә без аның тавышында ныклык,

хәрәкәтләрендә үз-үзенә ышанган кешеләрдә генә була торган төгәллекне күрәбез. Сәхнәдә вакыйгалар алышына тора. Гәүһәр исә Вассаның катлаулы эчке дөньясын, үз сыйныфының бөтен әшәкелекләрен туплаган характерын әкрен-әкрен ача бара. Без Вассаның акыллы, хәйләкәр һәм шәфкатьсез кеше икәненә ышанабыз. Аның куллары агуны да, ришвәтне дә бердәй җиңеллек белән суза. Без аның каты бәгырьле хатын икәнен күрәбез. Балаларына булган мөнәсәбәте дә, аның аналарның олы хисләреннән бигрәк, җанварларда булган нәсел калдыру инстинктына охшый.

Менә аның килене революционерка Рашель кайтып төшә. Бу хәл Вассаның чуала башлаган тормышына тагын да ныграк буталчыклык кертә. Без инде Вассаның элекке горурлыгын күрмибез. Ул каушаган, ул үзенең зирәк акылы белән тиздән киләчәк котылгысыз һәлакәтне сизә. Ул инде бу яңа көчкә — Рашельләргә дошманлыгын да яшереп тора алмый, ул кычкыра, вакыт-вакыт нәфрәтенә буылып тынып кала. Без аның халәтен Гәүһәр-Вассаның кул хәрәкәтләреннән, адымыннан, тавыш тембрыннан, күзләреннән, йөз сызыкларыннан күреп утырабыз.

Институтны тәмамлаганда бирелгән характеристикада да Гәүһәр Камалованың күп уйланучан, акыл һәм эчке тойгыларны тирән ачарга тырышкан артистка икәнен әйтеп, Васса Железнова образында аның нәкъ шул планда эшләвен, тулы канлы, дөрес образ тудыруын, эмоциягә бай тавышы да бу образны ачарга ярдәм итүен язалар.

Васса Железнова Гәүһәрнең шөбһәсез уңышы була. Бу спектакльдән тамашачы аны яратып кала, аңа ышанып кала.

Горький образлары белән Гәүһәр соңыннан да берничә кат очраша. Менә алар: «Дошманнар» спектаклендә Полина, «Соңгылар»да Соколова. Васса Железнованы да кертеп исәпләгәндә, өч төрле тормыш, өч характер, өч язмыш. Горький драматургиясенең тирән фәлсәфәсен тышкы бизәкләр аша түгел, бары тик фикер активлыгы, тирән эчке кичерешләр белән генә бирергә мөмкин. Биредә хәрәкәт һәм хисләр бердәмлегенең аеруча тәңгәл килүе сорала. Бөек әдипнең иҗатын җентекләп өйрәнгән һәм Горький театр мәктәбенең традицияләрендә тәрбияләнгән артистка моны яхшы аңлый. Менә аның Полинасы — ир канаты астында сыенып гомер иткән гамьсез, бай хатын. Полина да, ире Захар Бардин да бер карауга йомшак табигатьле, либераль характерлы кешеләр булып күренәләр. Ләкин бу либеральлек крокодил турындагы билгеле бер әкиятне искә төшерә. Крокодил да бит үзе корбанын йота, ә үзе аны кызганып күз яше түгә, ди, имеш.



М. Горькийның «Соңгылар» спектакленнән Соколова.

1905 ел реакциясе вакытында үзенең бөтен әшәкелеген ачып биргән дворян Коламейцевлар

семьясының череп таркала баруын һәм аларның чыннан да капитал җәмгыятенең «соңгылар»ы булуын раслаучы әсәрдә Соколова образын Гәүһәр яратып, якты тонда ача. Ул революция эшенә гомерен багышлаган егетне тәрбияләп үстергән кеше, Ниловналар белән янәшә торырлык бөек ана. Тамашачы аның хисләренә, үз бәясен яхшы белеп яшәвенә, әшәке җаннарга булган тирән нәфрәтенә ышана.

Горький әсәрләрендә уйнау Гәүһәр өчен чын иҗат мәктәбе була.

Мәскәүдә уку елларында остазлары да, сәхнәдәш олы буын артистлар да, әнисе Фатыйма ханым Камалова да Гәүһәрне бер принципка туры булырга өйрәтәләр — барысы да тормыштагыча дөрес булырга тиеш. Тамашачы ялганны, ясалуны сөйми. Артист кеше тормыш дөреслегеннән чыгып кына сәхнә дөреслеген тудыра ала. Һәм Гәүһәр гомере буе шушы принципка буйсынып иҗат итә. Татар академия театрында эшли башлавына егерме елдан артык вакыт үткән. Шул арада татар драматурглары, рус һәм дөнья классиклары, тугандаш халыклар әдәбиятларыннан күпме рольләр уйналмаган да, нинди генә образлар тудырылмаган. Бу образлар галереясында бик күп төрле бизәкләр бар: трагик буяуларда бирелгән ярсу канлылык та, халкыбызның буыныннан-буынына килгән зирәк акыллылык, сабыр-салмаклык та, җиңел холыклы җилбәзәкләргә хас беркатлылык та, киң күңелле шаяннарның җорлыгы да салынган аларга.

Һиһаять, әтисе Габдулла Камал I, әнисе Фатыйма Камалова, агасы Габдрахман Камал II эшләгән театрда, Бари Тарханов, Шакир Шамильский, Гөлсем Болгарская, Зәйни Солтанов, Хәлил Әбҗәлилов, Нәгыймә Таҗдарова, Нури Сакаев һ. б. шикелле олы буын сәхнә осталарыннан килгән зур традицияләре булган татар академия театрында эшләү җаваплылыгын һәрвакыт тоеп яшәү дә Гәүһәр Камаловага иҗади үсәргә көч бирә.

Иҗат дигәннән, бервакыт аннан сораганым бар:

— Гәүһәр, әниең шундый күренекле артистка булу яхшыдыр ул. Әниләр бит алар бөтен байлыкларын балаларына бирергә генә торалар. Ул сине бик күп нәрсәләргә өйрәткәндер?

— Әнием кебек буласым да килә минем, шул ук вакытта аңар охшарга да теләмим,— дип, бераз шаярыбрак җавап бирде ул.— Охшамаска теләвем яңа образлар тудырганда, әлбәттә. Мәсәлән, «Хуҗа Насретдин»да бик озак еллар буе Гөлбануны әнием уйнап килгән. Соңыннан аны миңа башкарырга туры килде...

«Зифа»да да шул ук хәл. Кайбер начальникларның эшсез һәм гамьсез хатыннары яшәгән мәгънәсез тормышны тамашачыга РСФСРның атказанган артисткасы Фатыйма Камалова бик оста күрсәткән иде инде. Әнисеннән соң бу рольне үзенә уйнарга туры килгәч, Гәүһәр куркып калган. Инде туган һәм халык күңелендә урын алып өлгергән таныш образны гына кабатлап чыкмасмы соң ул? Нәкъ әнисе кебек итеп башкара алса, бер хәл әле. Әгәр начаррак уйна-



Г. Камалова «Зифа» комедиясендәге Әйшүк ролендә.



«Хужа Насретдин» спектакленнан бер күренеш. Сахилә карчык ролендә Г. Камалова.

са... Менә шунда инде ул әнисенә охшамаска тырыша, үз Әйшүген тудырырга тели һәм үзе күргән тормыштан, үзе белгән кешеләрдән материал җыя, өйрәнә.

— Булдыра алдыммы, дигән сорау хәзер дә булса борчый әле. Әниемә ошады үзе. Яратып карады ул минем Әйшүкне. Ул биргән бәя минем өчен иң олы бәя. Чөнки иң гадел тәнкыйтьчем ул минем, олы терәгем. Эше белән дә, киңәшләре белән дә гел ярдәм итеп килә.

Кызы әнисенең сүзен җиргә салмады. Институтны бик яхшы характеристика белән бетереп кайткан артистка үзенең иҗат йөзен тиз тапты. Ул сәхнә тормышын Горький пьесалары шикелле җитди, фәлсәфи әсәрләрдән башлап, замандашларыбызның яхшы һәм яман, авыр язмышлы һәм көлке образларын тудыруга ирешә. Аның үсеш баскычларын күрсәтерлек рольләр күп. Аларның берәүләре шактый зур, икенчеләре кечкенә, берәүләре тамашачы тарафыннан алкышлап каршы алына, артисткага чын иҗат куанычы китерә, икенчеләре андый ук эз калдырмый. Әмма аларның барысына да зур көч, ихлас күңел салынган була. Аларның барысы өчен дә туктаусыз эзләнү, яңу кирәк була. Һәм бу хезмәт күп вакыт үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Һәр спектакльдә Гәүһәр иҗатының әле бер ягы, әле икенче кыры ялтырап ачылып китә. Образ өстендә эшләгәндә ул күп кабатланган детальләрдән, әзер өлгеләрдән качарга тырыша, күзгә ташланып торган җете ачык буяуларны сирәк куллана. Образ ачыла барган саен күренәрәк төшкән характерлы детальләр һәм тәэсирле алымнарны табуга омтыла.

«Хуҗа Насретдин»да ул Сахилә карчыкны да уйный. Бу карчык карап торуга мескен, кыерсытылган булып күренә. Ә бит болар барысы да хәйлә генә. Чапан астыннан ялтырап киткән зур комсыз күзләре шул хакта сөйли. Сахилә ул явыз, җарияләр белән сату итүче намуссыз кеше. «Чаткылар»да без моның киресен күрәбез. Изге күңелле, шәфкатьле Газизә карчык тамашачы күңелендә аналар гына сала белгән җылы тойгы калдыра. «Беренче театр»да ул яктылыкка омтылыш чаткысы туа башлаган яшь хатын Факиһәне, М. Брэндлиның «Килен кайтты» спектаклендә кара һәм сары тәнлеләрне кешегә дә санамаучы шәфкатьсез Амелия Гамельтонны ышандырырлык итеп уйный.

Гәүһәр Камалова бервакыт Солодарьның «Сирень бакчасы»нда яшь врач Раевская ролен башкарып, водевиль жанрында уйный алу мөмкинлеген күрсәткән иде. «Күк капусы ачылса» водевилендә ул бу жанрның мөмкинлекләрен тагын да остарак файдаланды. Тормыштагы бар омтылышы дәрәҗәләрәк, баерак кияү эләктерү булган, шуның аркасында һәрвакыт мәгънәсез һәм көлке хәлләргә калып килгән җиңел акыллы тол хатыннан ул ачы көлә, куе сатирик буяуларны кызганмый файдалана. Шәмсиянең тупаслыгыннан, комсызлыгыннан, мәгънәсезлегеннән тамашачы эче катып көлә һәм бу келү тормыштагы андый кешеләргә карата каты хөкем булып яңгырый.

Шулай да Шәмсияне уйнау Гәүһәргә җиңелрәк булгандыр. Шәмсия бер генә

плandагы образ. Без аның бары тик кире якларын гына күрәбез. Һәм артистка аны никадәр ныграк камчылаcard, шул кадәр сөенеп утырабыз.

Туфан Миңнуллинның «Ир-егетләр» спектаклендә председатель хатыны Гашияне дә артистка көлке образ итеп бирә. Әмма биредә инде үтергеч сатира түгел, биредә йомшак юмор өстенлек итә. Гашия үзе дә сәхнәгә аяк басуга тулысынча ачылып китә торган беркатлы образ түгел. Бу уенда без аның тышкы доофалыгы астына яшеренгән хатын-кыз назлылыгын да, дәрәҗәле кеше хатыны булу белән горурланырга теләвен дә, яратмаган эшен дә тырышып башкарырга мәҗбүр иткән намуслы җанын да, баласын бәхетле итәргә теләгән олы йөрәкле ана булуын да, хәзерге заман яшьләренең уй-хисләрен аңлый алмас дәрәҗәдәге чикләнгәнлеген дә күрәбез. Бер үк кешедә никадәр капма-каршылык. Ләкин Гашиянең төп сыйфаты — аның кешеләрне яратуы, кешеләр өчен җанын ярып бирергә әзер торган изге күңелле хатын булуында. Әгәр егылсаң, иң элек әнә шундый кешеләр сиңа куллар бирәләр, бәлага тарсаң, йөгереп янына алар киләләр. Бу образны башкарганда нинди көчле эмоция, тавышның никадәр бай төсмерләре, хәрәкәтләрнең күпме кискен үзгәрешләргә буйсындырылган булуы кирәк.

Спектакльдә артык зур урынны алмаса да, әнә шул күп төрле сыйфатлары белән күз алдында гәүдәләнгән Гашия образы әсәрдәге гуманлылык идеяләрен ачуга күп өлеш кертә. Бу образ аша артистканың гражданлык йөзен, аның тормышны, кешеләрне ратуын тоеп торасың. Спектакльдән күңел күтәренкелеге белән китәсең, тирәягыңда шундый кешеләр барында дөньяда яшәү күңелле икәненә ышанып кайтасың.

Гәүһәрне «Ир-егетләр» спектаклендә күргәч, ирексездән «Сукыр»дагы Диакониссаны искә төшердем. Бу ике хатын арасындагы охшашлыкны эзләп түгел, характерлары һәм язмышлары белән аларның бер-береннән бик ерак булуларын уйлап искә алдым. Монахиня Диакониссаның бар уе әйтерсең лә аллада, дингә хезмәт итүдә. Ләкин дөньяда барган фаҗигаләр аңар да ят түгел. Сугышта аның ире һәм уллары үлгән. Эчтән сызып, тыштан тыныч күренгән бу хатынның язмышын Гәүһәр саран хәрәкәтләр, кайгылы сабыр тавыш белән ачып биргән иде. Һәм мин аның киң диапазонлы артистка булуын, һәр образның үзенә генә хас бизәкләрен табуын «Ир-егетләр»дә тагын бер кат күреп куандым.

-

Әйе, озаккарак китте бит әле бу Мәскәү тапшыруы. Барып, шул телевизорның колагын борып куярдай булып утырам. Шулай да хуҗа кешене борчырга кыймыйм. Әнә бит ул телевизорның эченә кереп китәрдәй булып, дөньясын онытып карый. Ул хәтта бүлмәсендә кеше барлыгын да онытты бугай инде. Вакытсыз килгәнемә борчылып, һәм чыгып китәргә дә җай тапмыйча, альбом кырыеннан чыгып торган кәгазьнең читеннән тартам. Яшел кара белән язылган таныш хат икән. Университетта укыганда Гәүһәр җитәкләгән драмтүгәрәккә йөргән егетнең хатын моннан ун-унбиш көн элек кенә без Гәүһәр белән икәү бергә укыган идек.

«...Авылга кайтып укыта башлагач, комсорг булу өстенә, авыл яшьләрен һәм мәктәп коллективын сәхнәгә якынайту бурычы да йөкләнгәч, Сезнең спектакль хәзерләү методыгызны мөмкин кадәр искә төшерергә һәм файдаланырга тырыштым. Сәхнәдән төшкәч, үземә әйтелгән мактау сүзләренең барысында да Сезнең зур өлешегез барын мин тоеп торам. Рәхмәт сезгә, Гәүһәр апа!»

Хатлар күп килә Гәүһәргә. Иркенләп утырып, икешәр-өчәр бит тутырып язганнары да, ашык-пошык блокнот битенә сызылып, тамаша барганда бирелгәннәре дә, бөтен бер цех, я бригадада эшләүчеләрнең исемнәрен тезеп куйганнары да бар аларның. Боларның барысында да «чын итеп» уйнаганы өчен артисткага аларның тирән рәхмәт хисләре, театр сәнгатенә мәхәббәтләре, үзләренең эшләре, тормышлары турында язылган була.

Казан телевидениесендә Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» әсәре буенча эшләнгән фильм куелгач һәм анда Гәүһәр Камалова Тулганайны уйнагач, хатлар тагын да күп килә башлый.

Аналарга гимн булырлык бу әсәрне укып дулкынланмаган кеше юктыр. Инде сәхнә осталары тарафыннан уйналгач, андагы кешеләр, вакыйгалар укучы-тамашачыга тагын да якынайды, аны тирәнрәк хис итәргә булышты. Телевизор экранының театр

сәхнәсеннән отышлы бер ягы да бар иде, тамашачы башкаручының йөз сызыкларын, күз карашын якыннан күрә, тавышын якында ишетә.

Менә без, дулкынланып, ике ананың очрашуын карыйбыз. Аның берсе — гасырлар буе барган каты дауларны һәм азат тормышның кояшлы иртәсен күргән, сагышмоң белән тулган, илереп елаган авазларны һәм мәхәббәтнең йөрәк җилкендергеч бәхетле пышылдавын ишеткән бик борынгы Җир әнкәбез. Икенчесе — озын гомер юлы үтеп, берсеннән-берсе асыл егетләр үстергән, газизләре олы яуда ятып калганнан соң ялгыз башы калып та, тормышка, кешеләргә мәхәббәтен сүндермәгән изге күңелле Тулганай. Аның да чәчләре иртә таңда Җир әнкәбез битен юган көмеш чыклар кебек ап-ак. Аның да йөзендә Җир әнкәбез битен сырлаган буразналар кук тирән җыерчыклар. Сөйләр сүзләре күп аларның бер-беренә. Тулганай-Камалованың хәсрәт тулы күкрәк тавышы, сагыш белән әртелгән күз карашы тойгыларыбызны шул кадәр үткенәйтә, без җәйрәп яткан кара җирнең әкрен генә уфылдап тын алганын ишеткәндәй булабыз.

Менә кайда кирәк була Гәүһәргә әчке тойгыларны бирә белү осталыгы. Бирергә бит хәрәкәткә бер генә дә урын юк. Үзе кебек үк картайган, кибеп, ярганалып беткән таягына таянган да ул, бер моң белән башыннан үткәннәрне сөйли дә сөйли. Экранда ул сөйләгәннәрнең җанлы күренешләре бара. Аларның кайберләрендә Тулганай үзе күренми дә, әмма без аның барлыгын, бу эшләрнең күбесе аның ихтыяры, аның кодрәте белән эшләнүен тоеп торабыз. Кайвакытны тел әйтеп бирә алмаганны күз карашы тизрәк аңлата. Тулганай-Камалованың ачылып киткән йөзе, нурлы күз карашы экранда барган вакыйгаларга, рәсем өстенә төшкән кояш нуры шикелле, яктылык, күңел күтәренкелеге өсти, һәм, киресенчә, чал кашлар астындагы моңлы күзләр, тирән йөз сызыклары, калтырап чыккан шомлы тавыш хәвефнең якын икәнен, бәхетсезлекнең котылгысыз булу тәэсирен көчәйтә, тамашачыны сагайта, борчылдыра. Шатлыгын да, кайгысын да Тулганай белән бергә кичерергә мәҗбүр итә.

Ниһаять, Мәскәү тапшырулары да тәмамланды. Мамык шәленә төренеп, Гәүһәр минем янга күчеп утырды.

— Әйбәт тапшыру оештырганнар,— диде ул, бик канәгать булып.— Әйеме?

— Мин карамадым шул.

Ул гаҗәпләнеп миңа төбәлә, зур, соры күзләрендә аптырау.

— ?

— Ә мин синең турыңда уйладым.

— Әй, ташла әле,— ди ул игътибарсыз гына кулын селтәп,— бүген без яңа пьеса укыдык. Кешенең бәеклеге турында...

Өч кырлы журнал өстәлендә кечкенә лампадан зәңгәр якты төшеп тора. Гәүһәр белән без шул өстәл янында җайлап кына үткәннәр турында, театр һәм әдәбият турында, дус-ишләр, таныш-белешләр турында гәп корабыз. Сөйләшер сүзебез дә күп икән, ни әйтсәң дә, хезмәт юлын бер еллардарак башлап җибәргән замандашлар бит.

# СӘЙФ САРАИНЫҢ ЯҢА ӘСӘРЛӘРЕ

Идел буе төрки шагыйре Сәйф Сараи[1] моңарчы безгә «Гөлестан бит-төрки» кульъязмасындагы әсәрләре белән генә мәгълүм иде. 1965 елда үзбәк галиме Насрулла Дәүранов әдипнең яңа әсәрләрен таба һәм аларның бер өлешен матбугатта игълан итә[2].

Үзбәк әдәбиятына караган борынгы кульъязмалар белән танышып йөргәндә ул Үзбәкстан ССРның Коканд районы Ленин исемендәге колхоз члены Камалхан Солтанова «Ядгярнамә» исемле бер кульъязма китап очрата. Аның бабаларыннан берсе унсигезенче йөздә Гарәбстанга хаҗ сәфәренә барган икән. Шунда аңа бу китапны ниндидер сәүдәгәр бүләк иткән.

«Ядгярнамә» — урта кул форматтагы, 12 битле җыентык. Әдәби текстлар юка ефәк кәгазьгә «сулс» почеркы белән язылган. Диакретик билгеләр, ягъни хәрәкәләр аз куелган. Китапның тышлыгы юк, шулай да текстлар әйбәт сакланган.

Кульъязма китап Әбүл ибне Кадыйр дигән мөсафирның кереш сүзе белән ачыла. Бу кеше үзенең Мисырга килүе һәм анда «Ядгярнамә» исемле әлеге кульъязманы төзүе хакында яза. Кереш сүздән соң Туглый Хуҗа һәм Мәүлана Исхак Харәзмиләрнең берәр газәле, Мәүлана Әхмәд Үргәнҗинең өч шигъри парчасы килә. Бу шагыйрьләрнең өчесе дә Алтын Урдадан чыккан кешеләр. Алар С. Сараи белән бер чорда яшиләр. Туглый Хуҗа һәм Мәүлана Исхак исемнәре безгә Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана торган «Гөлестан бит-төрки» кульъязмасы буенча да таныш иде.

«Ядгярнамә»нең 4—12 битләрен С. Сараи әсәрләре алып тора. Алар арасында шагыйрьнең өч дүртьюллык шигыре, ике икеюллыгы һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» исемле дастаны бар. Н. Дәүранов, нинди мәгълүматларга таянып булгандыр, «Ядгярнамә»нең язылу вакытын 1398 елга нисбәт итә. Әмма кульъязманың орфографиясе ул әйткән чорга түгел, ә мәмлүкләр дәверенең соңгы чорындагы язуларга охшаган. «Ядгярнамә» текстларындагы аерым тел үзенчәлекләре дә шул фикерне куәтли. Мәгълүм булганча, С. Сараи әсәрләренең нигезендә кыпчак теле ята[3]. Ә Н. Дәүранов тапкан кульъязмада төрки телләрнең көньяк группасы өчен хас аерым элементлар очрый («ул», «шул» алмашлыкларын «у», «шу» рәвешендә бирү, сүз башында т/д, к/г авазларының чиратлашуы һ. б.). Безнең уебызча, бу элементларның күпчелеге я китапны төзүче, я аны күчерүче тарафыннан кертелгән булырга тиеш. Чөнки әлеге элементлар кульъязмада даими сакланмый. Шуңа күрә без, кульъязма 1398 елда төзелгән очракта да, унбишенче йөзнең икенче яртысында яки тагын да соңрак ул кем тарафыннандыр кабат күчерелмәде микән, дигән караштa торабыз.

---

[1] Әдипнең исеме төрле кульъязмаларда төрлечә язылган. Без аны «Гөлестан бит-төрки»дәгечә Сәйф дип алабыз.

[2] Н. Даврон. Сайфи Саройининг «Сухайл ва Гулдурсун» достони. Үзбәк телендә. «Узбек тили ва адабиёти» журналы. 1968 ел. 2 сан. 61—64 битләр; Н. А. Давронов. Сайфи Сарои. Автореферат кандидатской диссертации. Рус телендә. Ташкент. 1968 ел.

[3] Ә. Нәҗипнең «XIV йөз шагыйре Сәйф Сараи һәм аның заманы» исемле мәкаләсендә бу хакта тулырак мәгълүмат бирелә. («Совет әдәбияты» журналы. 1957 ел. 4 сан. 92—99 битләр).

Сәйф Сараи әсәрләре журнал укучыларына «Ядгярнамә»нең Казан университетындагы фотокүчермәсе нигезендә тәкъдим ителә [1]. Текстларны матбугатка хәзерләү барышында без, гамәлдәге татар графикасы мөмкинлекләреннән чыгып, кульязмадагы сүзләрнең һәм гыйбарәләрнең язылу рәвешен сакларга тырыштык. «Я», «ю» хәрефләрен таркатып кулландык (йа, йә, йу, йү), изафәт кушымчалары җәяләр эчендә күрсәтелде [2].

С. Сараи әсәрләре моннан алты гасырлар элек иҗат ителгән. Бу вакыт эчендә безнең сөйләм һәм әдәби телебездә күп кенә үзгәрешләр барлыкка килде. Шул сәбәпле, шагыйрь әсәрләрендәге аерым сүзләр, гыйбарәләр һәм грамматик формалар бүгенге укучыга аңлашылып та җитмәскә мөмкин. Моны истә тотып, без текстларның хәзерге телгә тәрҗемәсен биреп баруны кирәк таптык.

## Сәйфи Сараи әбйатедин

(Сәйф Сараи шигырьләреннән)

Үсүб тофрагым үзрә нәйзәләр, бән эвдин айрылдым,
Вәтандин биннишан улдым дә, үзгә йорткә әврелдем.
Ничук миңа фәләк җәүр әйладе, кандай гөнаһым вар!!
Илаһа, әйлә кәм җәүрең, бән илгә садик ул ирдем.

### ХӘЗЕРГЕ ТЕЛГӘ ТӘРҖЕМӘСЕ:

Туфрагым өстендә сөңгеләр үскәч (ягъни сугышлар булгач),
мин өемнән аерылдым,
Ватаннан мәхрүм булдым да башка илгә (ил кешесенә) әверелдем.
Язмыш миңа күпме газап китерде, нинди гөнаһым бар!!
Илаһым, кимет җәбереңне, мин илгә тугрылыклы ул идем.

* * *

Камышлы йорт бәнем тувган илемиде,
Белең: горбәтгә киптергән — белемиде.
Килеб улдым Сәрайда шейр фидае,
Сәрайның шагире — илнең гидае.

### ТӘРҖЕМӘСЕ:

Камышлы йорт (ягъни авыл, кала) минем туган илем иде,
Белегез: башка җиргә (мине) китергән — белем иде.
Килеп, булдым Сарайда [3] шигърият корбаны (ягъни поэзиягә чын
күңелдән бирелгән кеше),
Сарайның шагыйре — илнең фәкыйре.

* * *

Хәбәрсезмен у(л) дөнйа җәннәтедин,
Үвермен йөз илемнең рәхмәтедин.
Инанмас булгусы — дарелвәфайә,
Йаруглык бәһрәсен татмак кәфайә.

---

[1] Бу фотокүчермәне 1970 елда Н. Дәүранов профессор Х. Госманга биргән иде.
[2] Шулай ук «у», «шу» алмашлыклары янына җәяләр эчендә «л» хәрефе өстәлде.
[3] Сарай — Алтын Урда дәүләтенең башкаласы.

ТӘРҖЕМӘСЕ:

Исем китми теге дөнья җәннәтенә,
Ризамын мин илемнең рәхмәтенә.
Ышанмаган нәрсәм — «тугрылык йорты» [теге дөнья],—
Якты дөньяда тору миңа җитә.

* * *

Сачур дан ризык өчсн йиргә икүнче,
Аның бар икмәгедин — дөрр, илинҗе.

ТӘРҖЕМӘСЕ:

Чәчәр орлык ризык өчен җиргә игенче,
Аның бар икканеннән энҗе, күңеллелек туа [хасил була].

## СӨҺӘЙЛ ВӘ ГӨЛДЕРСЕН

Имәс әфсанә, чын ошбу битилмеш,
Бу чын, әфсанә дик, гыйшкдә ителмеш.
Әйтим аглабан дәврем җәфасын,
Бер ирнең кыйссасы — әхчи вәфасын.
Тимур Үргәнҗә тартыб килде ләшкәр,
Күрүб күз күр булуб, калды колак кәр.
Кузутты җәнг белән галәмдә туфан,
Акытты су тикин йир үзрә күп кан.
Икенче әвләре йакылды утга,
Бодай саврулды, тофраг булды ботка.
Үлүб катты сугушдә Тохтәмеш хан,
Тирик айрылды тувгандән тувышкан.
Сөһәйл әлефне илттеләр әсиргә,
Һәммә калды булуб гаҗиз бу сиргә.
Сипаһилар килалмай калды чарә,
Фәкать калдырды бу гамь дилдә йарә.
Сөһәйл хөсне ирүр Йосыфдин гали,
Әтәр мат алмәне йөзенең алы.
Бийүк әрдәмләре бар, сүзе ширин,
Булур гашыйк аны күргәндә Ширин.
Вәли җәүр ташы йагыб башы үзрә,
Итебти башыны хәм кашы үзрә.
Бүҗә йуктур золымкарләрдә фәрва,
Кимә монгайсын эстәб дәрдә дәва.
Фәкать халене күргәнләр итүр аһ,
Очар әтрафдә кошлар дәрдә һәмраһ.
Булуб мөтриб гөлестанләрдә болбыл,
Килур мең тәрле нәгъмә берлә голгол.
Башын икмеш йитеб алтун башаклэр,
Башакләрне иқинчеләр машакләр.
Йигар дан ип өчен шундән икүнче,
Ирүр бар икмәгедин — дөрр, илинҗе.
Агачләрдә шәкәр тикин йимешләр,
Бу йирне илләре очмах димешләр.
Сөһәйл шул йул үзрә бармәкдә гамьгин,
Севүнче карә кийгән, күзе нәмгин.
Уның күңлендә сулгунлык һәмишә,
Күренмәс уңә гөлзар вә нә мишә.

## СӨҺӘЙЛНЕҢ ЧӘҺДӘ ЙАТМЫШЫ

Пайу илкен итеб зынҗыр белән бәнд,
Агачны дә аңа итделәр пабәнд.
Вә аны ташләделәр кәттә чаһгә,
Сәрә асмай алар гуш аһу-вагә.
Гөнәш дөнйа йөзендин чаһгә батты,
Өзелгән гөл тикин тофракдә йатты.
У[л] йатгән чаһ эчә йук шөглән нур,
Үләнгә мәс, терегә ирде бер гүр.
Вәликин әрдәме бар монда үлмәс,
Кавиләргә һич анда курку булмәс,
Фәләк әйланмәсилә дәүр йитгай,
Гадаләт орлыгыдин бәхт битгай.

## СӨҺӘЙЛНЕҢ ТӨШ КҮРМЕШЕ

Газаб эчендә йатыб зинданда Сөһәйл
Итәрди һарганидә уйкуны мәйл.
Күрүб уйкудә һәм куркулы төшдән
Калурди айрилиб һәр дәмдә һушдән.
Бу төшдә бер пәри багдә йөрармеш,
Йөреб баг эчрә у[л] гөлләр тирармеш.
Дийүб аңа Сөһәйл: «Ни гөл тирурсән! —
Үзең гөлрәндә күргай гөл ирурсән.
Нидүр затың: пәриму, йа адәм зад! —
Миңа әйт адыңы даим итәй йад.
Шөкерлар итайин аплага мең бар,
Ки йиткүрде миңа син тик гөнәш йар».
Җәваб көтде булуб у[л] гыйшкара мәст,
Вәли тәкъдир булуб тиз бирмәде дәст.
Газаль тик селкенеб качты пәривәш,
Сөһәйл күңленә ташлап кәттә атәш.
Сөһәйл йөрде пәри качкан сәригә,
Йиталмай күргәне — рөхсаре маһгә,
Йыкылды йөгрүбан пай үзрә чаһгә.
Уйаныб белде шундә төш иканен
Вә сиздә батканын, әндүһ тиканен.

## ШАҺ КЫЗЫ ГӨЛДЕРСЕННЕҢ КҮРГАНЕ ВӘ УНЫ СЕВИБ КАЛГАНЫН БӘЙАНЫ

Үлән үзрә корылган хәймәдә шаһ
Зәфәрдән шад улуб йатмышди агаһ.
Бар ирде шаһ кызы Гөлдерсен аты,
Тилиң эврелмәс әйтмага сыйфаты.
Имәс гөл йөзе Гөлдерсендән артык,
Аның күңлендә гыйшк тиңиздән артык.
Итүрди фасл[е] гөл сәйри хийабан
Ничә мәхрәмләре берлә хираман.
Шу[л] ан килтерделәр чаһгә Сөһәйлне,
Гөлдерсен багубан тухтатты сәйлне.
Сөһәйлне күрдейү әйләнде бер дик,
Гәнәш гәрдендә йөргән мисл[е] йир тик.
Үзен гөл белде, болбыл Сөһәйлне,
Аны севдейү тәслим итде мәйлне.
Вә[һ] ни чалә кыйын: болбыл кафәсдә,
Кирәк гөл гончәсе азад нәфәсдә.

Севәр болбыл гөлен, гөл болбылын һәм
Ничун гөл әйласен болбыл күзен нәм.
Гилеб Гөлдерсен гүңленә бу сүзләр,
Гичеб гөнләр ки, буңа чарә эзләр.
У[л] эзләб чарә, йахшы чарә тапты:
Салыб эченә гурың ипи йапты.
Ипине эстәде пасбангә бирмәк,
Кичен барыб Сөһәйлне улды күрмәк.

## ГӨЛДЕРСЕННЕҢ ЧАҺГӘ ТӨШЕБ СӨҺӘЙЛ БЕРЛӘН СҮЗЛАШГАНЕ

Кичен булгач барыб пасбангә утру,
Үзен хаһшен айатте анда утру.
Ипи йииб асрагач бир андә пасбан,
Чаһ эчрә бакты тиз хөршид[е] табан.
Ни күрсен: ким булуб тофрагдә бихаль,
Сөһәйл йатур ташалмыш йанлы гөл ал.
Корыб Гөлдерсен агләб[е] халигә йөз,
Чаһ эчрә керде, куйды йөзенә йөз.
Сөһәйл башын кутареб күрде кызны.
Кол ирмәс пад[и]шаһ диб сиздe үзне.
Үңендә төшдәген күргангә у[л] шад.
Әләм ташы сыныб, дил булды азад.
Алар йөз куйушыб бер-бер йөзенә,
Озак бакыштилар бер-бер күзенә.
Гөлдерсен әйтте аңа: мин фидайың.
Сөһәйл аңа: улдум гидайың.
Синеңсез бәңа галәмдүр карангу,
Үлүм дә салмагай безләргә голгу.
Әгәр мең җаным улсә — сиңа тартук,
Булурму дуҫту йарлигъ шундән артук.

## СӨҺӘЙЛ БЕЛӘН ГӨЛДЕРСЕННЕ[Ң] ЧАҺДӘН ЧЫКЫБ КАЧКАНЛӘРЕ БӘЙАНЫ

Бу кич сингәйү миңа килде бер киз,—
Диде Сөһәйлгә Гөлдерсен торыб тиз,—
Чыкыб чаһдин озакләргә качайлик,
Бу йирдә агламай күңүл ачайлик.
Сөһәйл кийде торыб әрват комашын,
Чыкарсә, кемсә йук чаһдин у[л] башын.
Алар куйды икесе йул сәре пай,
Бакыб торгандә йулга зәр сачеб ай.
Берекеб китде гашыйклар озакга.
Эленмай йул узә куйган тозакга.
Алар күп йөреде, сәхрага керде,
Гөнашдин сәхра үзрә дузәх ирде.
Йук ирде су, йимәккә анда икмәк,
Әгәр булгандә һәм акчасы ләк-ләк.
Очыб килмәс иде кошлар бу йиргә,
Табылмас ирде су төшнә һәр иргә.
Йыкылды төшнә Гөлдерсен ачындин,
Күмәк кемдин килүр, чүл эчрә кемдин!!
Сөһәйл барды тапарга суга, дангә,
Вали дәрман биралмай калды җангә.
У[л] йалгуз сәхра эчрә калды йалгуз,
Булуб төшнә күрүб калган тик айолдыз.

Миңа йәхшы,— диде,— йар берлә үлмәк,
Нә лазем гамь белән дөнйадә калмәк.
Шу[л] сүзне әйтде, тигъ орды үзигә,—
Күренмәй калды киң галәм күзигә.
Сөһәйл әһыдин шу[л] дәм купты буран,
Аның тик кем, бозылды чәрх[е] дәүран.
Аләр үзрә түкүлде, күмде тофраг,
Бу сирне тәнһа сәхра белде кубраг.
Аңа килде шәрәф мәрд үлмагендин,
Нә килгай ирде куркуб калмагендин.
Улурму севге һәм бел шундан артук,
Ки иккесе килур җаныны тартук.
Хатын — садыйк, аны севгел, газиз ир,
Һәр агыр эшдә һәм даим сине дир.
Уңа дуст бул, уны севгел, күңел бир,
Аның сүз бәһредин гәүһәрләрен тир.
Килеб күңлемә Мәҗнүн, Ләйли йады,
Дәфатер өстенә сүз силе йагды.
Улур бу биттигем тарихгә йадгарь,
Бу йадгаремдә йалган йук вә чын бар.
Битиген намәне илләр укугай,
Сөһәйлнең таврихене тазә белгай.
Илаһа, асрагин Сәйфи Сәрайың,
Хәлас әйлаб золымдин киң сәрайың.
Йите йөз токсән алты нәүрүз айы,
Хәтем итде моны Сәйфи Сәрайи.

* * *

Каләм [әләм] тиңизегә батмә, и Сәйфи,
Төшмәсен кулыңдан әлефлекең, Сәйфи.

ТӘРҖЕМӘСЕ:

## Сөһәйл вә Гөлдерсен

Бу язма бер хыял җимеше түгелдер,
Ике гашыйк турында, булган эш бер.
Дәвернең сөйлим аглап бер җәфасын,
Бер ирнең кыйссасын, газап-хафасын.
Тимерләнг Үргәнечкә яу китергәч,
Колак тонды, ә күзләр булды күрмәс.
Сугыштан купты бар галәмдә туфан,
Агызды, су кебек, җир өстенә кан.
Игенче өйләрен яндырды утта,
Бодай тапталды, туфрак булды ботка.
Үлеп калды [1] сугышта Туктамыш хан,
Туганнан аерылып калды туышкан.
Сөһәйл — гаскәр башы әсир ителде.
Бу хәл һәр кемгә зур кайгы китерде.

---

[1] Төгәлсезлек киткән булса кирәк. Чынлыкта Алтын Урда ханы Туктамыш 1406/1407 елда һәлак була.

Сугышчылар кылалмый калды чара,
Бу кайгы булды бар күңелгә яра.
Йосыфтан да егет матур чырайлы,
Йөзендә балкыйдыр алманың алы.
Гаҗәп сыйфатлары бар, сүзе татлы,
Гашыйк итәр Шириндәй пәри-затны.
Ләкин язмыш ташы төшеп башына,
Башын салган егет гаме кашына[1].
Залимнардан рәхим-шәфкатьме тапсын,
Моңын кемгә сөйләп, эчен бушатсын!
Моны күргәннәр аһ итә, елаша.
Очар кошлар аның хәлен сораша.
Гөлестан җырчысы — былбыл тыналмый,
Өзеп моңлы итеп сайрый да сайрый.
Башын игән тулып алтын башаклар,
Башакларны җыярга җитте чаклар.
Игәр илгә дип ашлык гел игенче,
Аның бар иккәне — бәхет һәм энҗе!
Агачларда үсәр татлы җимешләр...
Бу җирне бик дөрес оҗмах димешләр.
Сөһәйл юлдан бара, йөзе ваемлы,
Кара көйгән җаны, күзләре дымлы.
Аның күңеле боек, йөзендә яшьләр,
Күренми күзенә гөлләр, агачлар...

## СӨҺӘЙЛНЕҢ ЧОКЫРДА ЯТУЫ

Аяк-кулы аның чылбыр богауда,
Кадакланган баганасы да янда.
Төшерделәр тирән зинданга аны,—
Колакка кермәде һич аһ вә зары:
Кояш дөнья йөзеннән җиргә батты,
Өзелгән гөл кара туфракка ятты.
Күренмидер чокырда яктылык-нур,
Үлек черер урын бу, җанлыга — гүр.
Ләкин чын ир-егет һич монда үлмәс,
Батыр җаннарга бер дә курку килмәс.
Бу дөнья әйләнеп, вакыт килер бер,
Гаделлек орлыгы чәчәк бирер бер!

## СӨҺӘЙЛНЕҢ ТӨШ КҮРҮЕ

Сөһәйл зинданда. Бик кыйналды җаны,
Хәле китеп, йокысы килде аның.
Йокыда күрдеге дәһшәтле төштән
Югалтты ул исен, еш язды һуштан.
Бусында бер пәри кызы күренде:
Җыя-җыя чәчәкләр багда йөрде.
Сөһәйл әйтте: «Нигә гөлләр җыясың!
Үзең — гөл, кайсы гөл тиңдәш сиңа соң!
Затың кем, әйт, пәриме я адәм-зат!
Атыңны әйт миңа, мәңге итим яд.
Кылам аллага мин мең-мең шөкерләр,
Миңа биргән өчен кояш кебек яр».

---

[1] Кашына — янына, башына кайгы төшкән дигән мәгънәдә.

Җавап көтте, гыйшыктан мас булып ул,
Ә тәкъдир чыкты тиз бирмәс булып кул:
Гүзәл кыз чапты да күздән югалды,
Сөһәйл җанын кабызды — утка салды.
Сеһәйл чапты төшеп сылу эзенә,
Җитәм дип ай кебек пәри кызына.
Җиталмый ай чырайлы мисле хурга,
Йөгергәндә барып төште чокырга.
Уянып белде шунда төш икәнен,
Сагыш уты йөрәгенә тигәнен.

## ШАҺ КЫЗЫ ГӨЛДЕРСЕННЕҢ АНЫ КҮРҮЕ ҺӘМ ГАШЫЙК БУЛУЫ ТУРЫНДА

Чирәмдә шаһ, гүзәл чатыр эчендә,
Җиһүдән шат, масайган үз көченә.
Бар иде шаһ кызы Гөлдерсен атлы,
Тел әйләнмәс: гаҗәп сылу сыйфатлы.
Табылмас гөл бу Гөлдерсеннән артык,
Йөрәгендә гыйшык диңгездән артык.
Сәер итеп утырганда багында,
Нинә яраннары берлән янында,
Китерделәр чокырга дип батырны,
Күреп кыз әмерен әйтте: бар да тынды.
Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли[1].
Сөһәйлне — былбыл, үзен — гөл санады,
Сөйде, тагын күрергә булды аны.
Ләкин читлектә бит былбыл, ни чара!
Чәчәк тә ихтыярсыз шул, бичара.
Сөяр былбыл гөлен, гөл былбылын гел,
Күзен яшьле итәрме һич аның гөл!!
Килә кыз күңеленә кинәт бу сүзләр,
Үтә көннәр — моңа чара ул эзләр...
Һәм эзләп шундый яхшы чара тапты:
Савытка салды икмәк, дару якты;
Аны сакчыга ул бирергә булды,
Сөһәйл — ярын шулай күрергә булды.

## ГӨЛДЕРСЕННЕҢ ЧОКЫРГА ТӨШЕП СӨҺӘЙЛ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮЕ

Кичен сакчы янына кыз йөгерде,
Теләген әйтте аңа, нанны бирде.
Йокыга чумды ашап сакчы ашын.
Карады кыз чокырдагы кояшын.
Ни күрсен күзләре: туфракта шул чак
Ята аунап Сөһәйл, ал гөлгә охшап.
Елап бу халенә аның гүзәл кыз,
Янына килде, куйды йөзенә йөз.

---

[1] Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен Н. Коперник (1473—1543), Д. Бруно (1548—1600) кебек галимнәр ачкан диган караш яшәп килә. Ләкин моның 14 йөздә язылган әдәби әсәргә килеп керүе галәм турындагы материалистик карашларның Шәрыкта тагын да иртәрәк таралуына өстәмә бер дәлил булып тора.

Сөһәйл башын күтәрде — күрде аны,
Әсирдән патшага әверелде җаны!
Өенендә тоштәгеи күргәнгә ул шат,
Сынык күңеле сагыштан булды азат.
Алар куешты шунда йөзгә йөзне,
Алалмыйча юнәлтеп күзгә күзне.
Вә Гөлдерсен диде: «Сиңа фидамын!»
Сөһәйл аңа: «Ә мин — синең гидаең.
Әгәр син булмасаң — галәм караңгы.
Үлем дә куркыталмас безне мәңге.
Җаным мең булса да — сиңа, сөйгән яр!
Шушы дуслыктан артык җирдә ни бар!!

## СӨҺӘЙЛ БЕЛӘН ГӨЛДЕРСЕННЕҢ ЧОКЫРДАН ЧЫГЫП КАЧУЛАРЫ

— Бу кич сиңа вә миңа килде бер киз[1],—
Диде Сөһәйлгә Гөлдерсен, торып тиз,—
Чокырдан без чыгып ерак качаек,
Бу җирдә, агламый, күңел ачаек.
Сөһәйл киде торып кызлар киемен.
Чокырдан карады — юк иде бер кем.
Алар икәү аяк атлады юлга,
Тиргәне алтын ай күмгәндә нурга.
Икәүләп китте гашыйклар еракка,
Эләкми юлдагы корган тозакка.
Юлыкты сахрага ике адашкан,—
Җәһәннәмдәй иде сахра кояштан.
Юк анда су һәм икмәк алларында,
Мәгәр булса да акча яннарында.
Очып килмәс иде кошлар бу җиргә.
Табылмас бер йотым аһ орган иргә...
Сусап егылды ач Гөлдерсен анда.
Бу чүлдә кем бирер ярдәм аларга!!
Сөһәйл азык, сусын эзләп юл алды:
Яры җан биргәнен күрми дә калды...
Сөһәйл шул буш далада калды ялгыз,
Бу хәлне күрде тик ай һәм дә йолдыз.
— Миңа кирәк,— диде,— яр берлә үлмәк,
Газаплар берлә калмак кемгә кирәк!! —
Шулай дип орды ул хәнҗәр үзенә:
Күренми калды киң галәм күзенә...
Сөһәйл аһ итте,— купты ком бураны,
Каралтып күк йөзен япты тузаны.
Алар өстен күмеп комнар өелде...
Бу хәлне бары тик бер сахра күрде.
Сөһәйл ирләрчә үлде, куркусыз — шәп!
Ни хәл итәр идең гәр калса йомшап!
Булыр микән сөю моннан да көчле,—
Ике корбан хәяттан бергә күчте:..

Хатын — дустыр, газиз ир, син сөеп дәш,
Авыр чакларда бергә ул, чын иптәш.
Дусы бул син аның, күңел биреп сөй,
Акыл-киңәшләрен — җәүһәрләрен җый.

[1] Киз — бу урында җайлы вакыт мәгънәсендә.

Килеп күңелгә Мәҗнүн, Ләйлә яды,
Бу сүзләрем кәгазь өстенә яуды.
Булыр бу сүзләрем тарихка ядкарь.
Аларның ялганы юк, бар да хаклар.
Минем язмамны укыр барлык илләр,
Сөһәйл вакыйгасен шуннан белерләр.
Бу Сәйфи Сараины, тәңре, кызган,
Фани дөньяңны коткар син золымнан.
Җиде йөз туксан алты[1], нәүрүз ае,
Тәгәлләде моны Сәйфи Сараи.

* * *

Сагышлар диңгезенә кермә, Сәйфи,
Беренчелекне бер дә бирмә, Сәйфи.

* * *

Моны җитмеш беренчедә, алыстан
Якын телгә күчерде Н. Арслан[2].
Әман, тәкъсир! Каты күңелле булма,
Маһирлекне үзеңчә дәгъва кылма,
Кабул ит, мин — фәкыйрь алдыңда зари,
Ерактагы бабам Сәйфи Сараи.

* * *

Сәйф Сараиның яңа табылган әсәрләре әдипнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүдә мөһим чыганак булып тора. Моңа кадәр аның туган җире Сарай шәһәренә нисбәт ителеп йөртелә иде. Хәзер инде без әдипнең Камышлыда[3] туып, белем алыр өчен Сарайга килүен һәм бирсдә шагыйрь булып танылуын беләбез. «Үсүб тофрагым...» дип башланган дүртьюллык әдипнең Мисырга китү сәбәпләрен ачыклауга да яктылык сирпи. С. Сараи үз Ватанын ирекле көннән ташлап китмәгән икән. Шигырьдән күренгәнчә, бу хәлне ул бик авыр кичерә:

**Ничук миңа фәләк җәүр әйладе, кандай гонаһым вар!!**
**Илаһа, әйлә кәм җәүрең, бән илгә садик ул ирдем.**

Бу юллардагы уй-кичерешләрнең табигыйлегенә, эчкерсезлегенә һәм реальлегенә ышанмау мөмкин түгел. Шагыйрь туган иленнән аерылып, нинди генә кыен хәлләргә төшсә дә, дәрвишлеккә бирелми, дөньявилыгын саклап кала. Аның өчен, теге «дөнйа җәннәте»ннән бигрәк, җирдәге якты тормыш кыйммәт. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны (1394) нәкъ менә шуның бер матур мисалы булып тора. Авторның игътибары, беренче чиратта, дәвер җәфасына юнәлгән. Мәгълүм булганча, 14 йөзнең 80—90 еллары — Аксак Тимер походларының иң көчәйгән чоры. Бу дәвернең алдынгы кешеләре

---

[1] Миладн 1394 елга туры килә.

[2] Сәйф Сараиның моннан биш йөз сиксән еллар чамасы элек язылган бу поэмасын хәзерге заман татар теленә күчергәндә, мин аның ритмикасын, үз рифмаларын мөмкин кадәр сакларга тырыштым. Сүзен-сүзгә, юлын-юлга күчергән академик тәрҗемәгә караганда, болай күчерү борынгы шагыйрьләребезне җанлырак гәүдәләндерергә ярдәм итәр дип уйладым.— Н. Арсланов.

[3] Әмма хәзергә моның кайсы Камышлы булуын кистереп әйтү кыен. Чөнки бу исемдәге авыл-калалар Идел буенда гына да берничә. Аларның берсе, мәсәлән, хәзерге Камышин тирәсендә урнашкан була. Камышлы (Kamyschly) исемле бу шәһәр Б. Шпулер китабындагы (Die Goldene Horde, 1965. Wiesbaden) Алтын Урда картасына да төшерелгән. Шулай ук бу кала Куйбышев өлкә музееның тарих бүлегендәге Урта гасырлар картасында да бар.

тиран политикасына каршы көрәшүне үзләренең намус эшләре итеп карыйлар: мәшһүр галим Мөхәммәд әл-Бәззази (1344—1424), мәсәлән, шушы елларда Аксак Тимернең явызлыгын фаш итеп чыгышлар ясый. Әхмәт Үргәнҗи бу тиранны «башсыз», «кан эчүче» дип атый, аны халык үче белән куркыта. С. Сараи үз дастанының баштагы юлларында ук Аксак Тимернең җир өстендә «су тикин» каннар агызуын, туганнарны бер-берсеннән аерылырга мәҗбүр итүен сурәтли. Сөһәйл белән Гөлдерсеннең һәлакәте дә нәкъ әнә шул золым-гаделсезлекләр аркасында туган бер күренеш булып кабул ителә. Бу ике геройның трагедиясе укучы күңелендә вәхши политика уздыручыларга карата нәфрәт тойгысы уята.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында С. Сараи үз чорының актуаль мәсьәләләрен чагылдыра. Бу хәл әсәрнең эчтәлегенә дә тәэсирсез калмаган. Традицион багышлаулардан азат булуы, тормышчан күренешләрнең чагылуы, дини мотивларга урын бирелмәве белән дастан урта гасырлар Шәрык әдәбиятында үзенчәлекле урынны алып тора. Сөһәйлне, мәсәлән, Гөлдерсен берничә фантастик көчләр ярдәмендә дә түгел, ә үзенең тәвәккәллеге, кыюлыгы белән коткара. Гомумән, Сөһәйл белән Гөлдерсен вакыйгасе Шәрыктә киң таралган Ләйлә-Мәҗнүн, Фәрхад-Ширин, Гөл-Нәүрүз кебек мәхәббәт тарихларыннан үзенең тормышчанлыгы белән аерылып тора.

Аерым фактлар дастан сюжетының реаль җирлеге булу ихтималлыгына да ишарә ясыйлар. Беренчедән, автор үзе бу хәлнең «чын» иконлеген кат-кат телгә ала. Икенчедән, халык телендә «Сөһәйл вә Гөлдерсен» сюжетына охшашлы легендалар яши. Аларда егет — Туктамыш хан улы, ә кыз Аксак Тимер кызы дип күрсәтелә. Шунысы мөһим: Чиләбе өлкәсендәге мәшһүр «Тамерлан манарасы»[1] да бу легендаларга бәйләнешле. Легенда мәгълүматларына караганда, Аксак Тимер сугышчылары хәзерге Тамерлан станциясе тирәсендә егет белән кызны куып җитәләр. Тигезсез сугышта егет һәлак була. Кыз исә үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтерә. Ахырдан Аксак Тимер шул урынга манара кордыра. 1889 елда Э. Ю. Петри җитәкчелегендә уздырылган археологик тикшеренүләр дә манара төбендә хатын-кыз күмелгәнлеген расллады. Кыскасы, С. Сараиның үз әсәренә сюжет итеп билгеле бер тормыш вакыйгасен алуы бик ихтимал. Әмма Аксак Тимер кызы һәм Туктамыш улы хакында язма тарихи чыганаклардан өстәмә дәлилләр тапмыйча, бу мәсьәләгә катгый җавап бирүе мөмкин түгел. Кызганычка каршы, әлегә андый мәгълүматларның табылганы юк. Шулай ук әсәр сюжетының тарихи нигезен ачыклауда Гөлдерсен исеме белән бәйләнешле башка характердагы легендаларның яшәве дә өстәмә кыенлык тудыра.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанындагы сүзләрнең, гыйбарәләрнең, гропларның һәм грамматик формаларның төп өлеше бүгенге сөйләм һәм язма телебездә, диалектларда иркен кулланыла. Мәсәлән, «ипи» сүзе борынгы язма истәлекләрдә һәм күп кенә төрки телләрдә күзгә ташланмый. Ә инде татар теле өчен хас булган бу сүзгә С. Сараи берничә мәртәбә мөрәҗәгать итә. «Тартук»[2] сүзе белән дә шундый ук хәл: кыз белән егетнең үзара мөнәсәбәтен ачуда, аларның бер-берсенә тугрылыгын тагын да калку күрсәтүдә шагыйрь бу терминнан оста файдалана. Кыскасы, шул чор тормышы белән тыгыз бәйләнештә туып, гуманистик тенденцияләрне алга сөргән «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны — урта гасыр төрки-татар әдәбиятында күренекле урынны алырга лаек әсәр.

«Ядгярнамә» кулъязмасындагы С. Сараи әсәрләре шагыйрьнең тормыш һәм иҗатын өйрәнү өчен генә түгел, гомумән, элекке әдәбиятыбызны, тарихыбызны, телебезне тикшерү өчен дә әһәмиятле чыганак булып тора.

**Хатип МИННЕГУЛОВ,**
**Казан дәүләт университеты укытучысы.**

---

[1] Бу манара һәм аның тарихы хакында күптән түгел «Правда» газетасында (29 сентябрь, 1971 ел) Л. Палиевскаяның «Башня Тимерлана» дигән кызыклы мәкаләсе басылып чыкты.

[2] Уралдагы кайбер татар төбәкләрендә туй чыгымнары өчен егет ягыннан бирелә торган бүләкне дә «тартук» диләр.

Солтанморат Акбиев

# МӘДӘНИ БЕРГӘЛЕК

*Татар һәм кумык мәдәниятләренең үзара бәйләнешенә карата*

Кавказ таулары белән чал Каспий диңгезе арасындагы матур җирләргә Дагстан Автономияле Совет Социалистик республикасы урнашкан. Барлык совет халкы белән бергә, Дагстан хезмәт ияләре дә тугызынчы бишьеллык хөрмәтенә удар хезмәт вахтасына бастылар, алар өр-яңа промышленность предприятиеләре, электр станцияләре төзиләр, торак йортлар салалар, киң басуларны һәм көтүлекләрне сугару өчен елгаларны буалар. Артык зур булмаган бер республикада кулга-кул тотынышып дистәләрчә милләт вәкилләре яши. Дагстан республикасы эшчәннәренең күп меңләгән армиясе составында 180 мең кешелек кумык халкы да бар.

Кумыклар бик борынгы заманнардан бирле Дагстанның тау һәм диңгез буйларындагы җирләрендә гомер иткәннәр. Алар яшәгән җирләр аркылы, мәшһүр Дербент капкасы аша Көнчыгыштан Көнбатышка зур кәрван юллары үткән. Ул юллар кумыкларны бер Кавказ халыклары белән генә түгел, ә бәлки Россия һәм башка илләрдә яшәүче күп кенә башка халыклар белән дә бәйләнешкә керткән. Кумык һәм татар халкы арасындагы дуслык элемтәләренең дә башы ерак үткәннәргә барып тоташа.

Бу мәкаләдә исә без әлеге дуслыкның соңгырак этабына тукталырга уйлыйбыз. XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөзнең башларында татар һәм кумык мәдәниятләре, аерым алганда әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләр ничегрәк үсә? Максатыбыз — әнә шуларны ачыклау.

Татар мәдәниятенең уңай йогынтысы барыннан да бигрәк кумык телендә милли матбугат барлыкка килүдә ачык күренә. Билгеле булганча, кумыкча беренче китап Мөхәммәт-әфәнде Османов тарафыннан 1883 елда Петербургта басыла. Ул «Нугай һәм кумык җырлары җыентыгы» исемле китап була. Шул ук авторның «Нәсихәт» исемле икенче китабы 1899 елда Казанда чыга. Шул вакыттан башлап кумык телендәге китаплар 1903 елга кадәр күбрәк Казанда басылып килә.

Ике халык арасындагы элемтәләрне ныгытуга хезмәт иткән чыганакларның тагын берсе Казанның уку йортлары була. XIX йөзнең ахырларында күп кенә дагстан яшьләре, белем дәрәҗәләрен тагын да күтәрү максаты белән, Россия шәһәрләренә һәм Якын Көнчыгыш илләренә китәләр. Кумыклар да, бигрәк тә аларның алдынгырак фикерле вәкилләре, Казан губернасы шәһәрләренә, Идел буена юл тоталар һәм

шул төбәкләрнең иҗтимагый-политик тормышына катнаша башлыйлар.

Кумыклар арасыннан чыккан иҗат кешеләрен тәрбияләүдә Казанның һәм алдынгы татар интеллигенциясенең роле аеруча зур. XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән күренекле кумык шагыйре һәм мәгърифәтче Мөхәммәт-әфәнде Османов (1840—1904) нәкъ менә шундый тәрбия алган кешеләрнең берсе була. Туган авылы Аксайда башлангыч белем алганнан соң ул, Казанда басылган фәнни хезмәтләр ярдәмендә Шәрык әдәбиятын һәм төрки телләрне өйрәнә. Бу өлкәдә билгеле бер уңышка ирешкәч, 1871 елда Петербургка килә һәм пайтәхет университетының Шәрык факультетында төрки-татар телләре буенча укытучы булып эшли. Бираедә ул Х. Фәезхановны алыштыра. Рус телен һәм рус мәдәниятен, шулай ук Шәрык әдәбиятын тирән үзләштергән белгеч буларак, ул профессорларның, укытучылар һәм студентларның тирән ихтирамын казана. Университет җитәкчелеге тарафыннан аңа бирелгән характеристикалар шуны раслый. Шәрыкне өйрәнүче күренекле галим Веселовский аның укытучылык эшчәнлегенә югары бәя биреп, түбәндәге җылы сүзләрне яза: «Үз фәнен тирәнтен һәм нигезле үзләштергәнлектән, Османов күренекле лектор иде һәм факультетта ул үзе турында якты истәлек калдырды»[1].

М. Османов Петербург университетында профессор Березин, доцент Гиргасс, Казан университетының элекке деканы А. Казембек кебек алдынгы карашлы галимнәр белән бергә эшли. Шулар йогынтысында аның мәгърифәтчелек карашлары формалаша. Ул Казан һәм Петербург типографияләрендә кумык телендә дәреслекләр, фольклор җыентыклары бастыра башлый.

Кумык прозасына нигез салучы күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Нухай Батырморзаевның дөньяга карашы формалашуда революцион-демократик татар интеллигенциясе хәлиткеч роль уйный. Аның иҗтимагый-сәяси карашлары турыдан-туры татар язучылары йогынтысында формалашты дисәк, бу һич тә арттыру булмас, дип уйлыйм.

Нухай Батырморзаев шулай ук Аксай авылында туа (1864—1919). Хезмәт юлын мәдрәсәдә укытучы булып башлый. Ләкин аның бу эше авыл байларына, мулла-монтагайларга ошамый, алар арасында ризасызлык тудыра. Алар белән тынышa алмаган, алар кубызына биергә теләмәгән Нухай укытучылык эшен ташларга һәм эш эзләп читкә чыгып китәргә мәҗбүр була.

Эш һәм бәхет эзләп Россиянең төрле шәһәрләренә агылган халык ташкынына ияреп, ул Дербент, Баку, Астрахань, Казан якларын урап чыга. Михнәт чигеп, кайгы-хәсрәт эчендә яшәүче халык арасында булу аның көрәшче буларак формалашуын, сыйнфый аңы үсүен тизләтә.

Казанда ул Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал һәм башка революцион демократлар белән аралаша, аларның иҗаты белән якыннан таныша. Демократик татар язучыларын Н. Батырморзаев зур ихтирам белән искә ала. «Төрле кимсетүләргә һәм эзәрлекләүләргә дә карамастан, үз халкы өчен сокланргыч әсәрләр тудырган»[2] Габдулла Тукай турында ул аеруча югары фикердә була.

Нухай Батырморзаев кумык проза әдәбиятын тудыру һәм милли мәдәниятне үстерү юлында искиткеч зур эшләр башкара. Ул «Бәхетсез Хабиибат» (1910), «Даут һәм Ләйлә» (1912), «Һарун белән Зөбәйдә яки бәхетсез Җанбикә» (1914) кебек талантлы повестьлар иҗат итә. Аның уңай геройлары шул чорның алдынгы фикерләрен, прогрессив идеяләрен яклап көрәшәләр. «Бәхетсез Хабиибат» повестендагы адвокат Габделкәрим, «Даут һәм Ләйлә»дәге Даут, «Һарун белән Зөбәйдә»дәге Һарун — әнә шундыйлар. Һарунны татар егете Гайнетдин белән ныклы дуслык җепләре бәйли. Гайнетдиннең якын булышлыгы белән, ул Казандагы типографияләрнең берсенә эшкә урнаша һәм эшчеләр арасында зур хөрмәт казана. Югарыда саналып үтелгән әдәби геройлар мисалында без кумык халкы вәкилләренә татарлар арасындагы алдынгы карашларның уңай йогынты ясавын күрәбез. Н. Батырморзаев белән якыннан аралашып яшәгән кешеләрнең сөйләвенә караганда, ул татар әдәбиятын бик яраткан, татар әдәбияты үрнәкләрен кумык теленә тәрҗемә итү эшенә зур игътибар биргән. Кызганычка каршы, аның тәрҗемәләренең әлегә хәтле табылганы юк.

---

[1] Биографический словарь профессоров и преподавателей Петербургского Университета. Рус телендә. II том, 1898 ел. 80 бит.

[2] «Танг чолпан» («Таң йолдызы») журналы. 1917 ел. 2 сан.

Кумык мөхитенә Көнбатыш һәм Шәрык әдәбияты үрнәкләре нигездә татар теле аша үтеп керә. Тарихи документлар шул турыда сөйли. Кумык мәгърифәтчесе Абусуфьян Акаевның (1870—1931) иҗат эшчәнлеге әнә шул фикерне раслый.

Дагстанның башка мәдәният әһелләре кебек үк, А. Акаев та башлангыч белемне мәчет каршындагы авыл мәктәбендә ала. Аннан үзлегеннән укып, филология, философия кебек фәннәрне үзләштерә. Ул үз чорының энциклопедист галиме була. Казанның культура эшлеклеләре аны Дагстан профессоры дип йөртәләр[1]. А. Акаев үзенең бөтен белем байлыгын туган халкына багышлый.

Дини-схоластик мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшләренең торышы искиткеч түбән була. А. Акаев кумык мәктәпләрендәге тәртипләрне үзгәртү юлларын эзли. Бу мәсьәләдә ул Казан уку йортларында тупланган тәҗрибәгә таяна. XX йөз башыннан Казанда һәм кайбер башка шәһәрләрдә укулар яңа ысул белән алып барыла башлый. Татар балаларына, дин сабакларыннан тыш, тарих, география, математика кебек дөньяви фәннәр өйрәтелә башлый. Казанга килгәч, Акаев татар мәгърифәтчеләре белән элемтәгә керә, әлеге яңа мәктәпләрдәге укыту методикасы һәм ул мәктәпләр өчен программалар төзү тәртибе белән таныша. Туган авылына кайткач, ул анда ике класслы мәктәп ача һәм балаларны татар мәктәпләре ысулы белән укытырга тотына. Уку-укыту эшчәнлеген дәвам итү белән бергә, ул башка төрле җәмәгать эшләре дә алып бара. Бүтән халыкларның иҗат интеллигенциясе тәҗрибәсенә таянып, Акаев дагстанлыларны караңгылыкка һәм томаналыкка каршы көрәшкә чакыра. «Дагстанлыларны якты юлга чыгару өчен,— дип яза ул,— безгә үз ана телләребездә китаплар бастырырга кирәк»[2]. Әлеге программасын тормышка ашыру йөзеннән, ялкынлы мәгърифәтче әдәбият буенча дәреслекләр, тарих, география, арифметика, грамматика фәннәре буенча уку китаплары чыгара башлый.

А. Акаевның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге дә кумык һәм татар халыклары арасындагы әдәби мөнәсәбәтләрнең якты бер үрнәге булып тора. Татар әдәбиятындагы «Таһир һәм Зөһрә» (1908), «Йосыф һәм Зөләйха» (1910) кебек әсәрләрне кумык теленә нәкъ менә ул тәрҗемә итә.

Татар мәгърифәтчеләре үрнәгендә, Абусуфьян телара сүзлекләр төзи. Төрле календарьлар да («Гиччи рузнама», «Уллу рузнама») аның тарафыннан языла. Ул китап-календарьларны төзегәндә, А. Акаев татар телендә чыккан охшаш басмалардан файдалана.

Үз китапларын язганда татар әдәбияты материалларыннан файдалануын ул һич тә инкарь итми. 1913 елда басылган «Къылыкъ китаб» («Книга о нравственности») дигән хезмәтенә язган сүз башында шундый юллар бар:

«Әдәплелекнең һәркемгә кирәклеген аңлап, без «Къылыкъ китаб» чыгарырга булдык, аның өчен Казанда басылган шундый ук китаптан файдаландык. Материалның бер өлеше башка китаплардан да алынды». Һәр китабының сүз башында А. Акаев укучыларны кумык мәдәниятен үстерү өчен көрәшергә чакыра. Бу мәсьәләдә якын туганнарыбыз Казан татарларыннан үрнәк алыйк, ди. Шул рәвешле, милли культураның үсүен һәм төрле халыклар арасында интернациональ элемтәләрнең ныгуын яклап чыга.

Кумык һәм татар халыкларының мәдәни бәйләнешләре турында сөйләгәндә, күренекле дагстан коммунисты Зәйналабид Батырморзаевның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге үзенә аерым урын алып тора. Нухай Батырморзаевның улы Зәйналабид Батырморзаев кечкенәдән үк белемгә омтылучан малай була. Мәчет каршындагы мәктәпләр генә аның укуга булган теләген канәгатьләндерә алмый. Ундүрт яшендә ул Астраханьга чыгып китә һәм анда сигезьеллык шәһәр мәктәбенә укырга керә. Астраханьда бергә яшәгән иптәше Вәли Вәликаев истәлекләренә караганда, Зәйналабид башка укучылар арасында киң эрудицияле һәм кыю фикерле булуы белән аерылып торган.

Астраханьда З. Батырморзаев татар зыялылары, татар әдипләре белән дуслаша. Татар язучыларының кайбер әсәрләрен кумык теленә тәрҗемә итә. Мәсәлән, Г. Камалның Зәйналабид тарафыннан тәрҗемә ителгән «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасы 1917—1918 елларда кумык театры сәхнәсендә зур уңыш белән бара. Аннан

[1] А. Акаев. Гиччи рузнама (12 еллык календарь). 1912 ел. Кереш мәкалә.
[2] А. Акаев. Юз йыллыкъ тынч рузнама. 1905 ел.

кергән табыш — культура-агарту эшләренә тотыла [1].

Зәйналабид татар телендә шигырьләр дә яза. «Татарча язган шигырьләренең берсендә,— дип билгеләп үтә С. Алиев,— Батырморзаев романтик татар шагыйре Сәгыйть Сүнчәләйне тәнкыйтьли» [2]. Тикшеренүченең фикеренә карагаңда, З. Батырморзаевның татар телендә язылган шигырьләре биш йөз юлдан артыграк булган. Зәйналабид Батырморзаевның татар телендә язган «Даниялбек» һәм «Муллаларга каршы» исемле драматик әсәрләрен исә Дагстан тамашачылары яратып кабул итәләр.

З. Батырморзаевның ул чорда Оренбургта татар телендә чыгып килгән «Вакыт» газетасы редакторы исеменә язылган хаты сакланган. Бу хат шулай ук З. Батырморзаевның татар культурасы эшлекләләре белән нык элемтәдә торганлыгын раслый. З. Батырморзаев үзенең бу хатында газета һәм журнал чыгару турындагы уй-теләкләре белән уртаклаша.

Унҗиде яшьлек егетнең ул вакытта Оренбургта яшәгән һәм «Вакыт» газетасына язышкан әтисе Нухайга язган хаты да зур кызыксыну уята. Ул хатында Зәйналабид изелгән халыклар бәхете өчен көрәш юлына баскан әтисенең язмышы өчен борчыла һәм шул ук вакытта аның белән чиксез горурлана.

Иялэшкән җирдән аерылу кыен булса да, университетка керү теләге белән, Батырморзаев Казанга килергә карар итә. В. И. Ульянов, Н. Е. Федосеев кебек куркусыз көрәшчеләр тәрбияләгән Казанга килү белән, Зәйналабид демократик рухлы яшьләр арасына керә. Татар яшьләренең социал-демократик идеяләре йогынтысы астында ул татар телендә чыга торган бер газетага мәкалә яза. Мәкалә капиталистлар, чиновниклар строена каршы юнәлдерелгән була. Аның авторының кем икәнлеген бик тиз белеп алалар. Зәйналабид, эзәрлекләүләрдән качып, туган ягына кайтып китәргә мәҗбүр була.

Татар яшьләренең прогрессив идеяләре аңа зур йогынты ясый. Хасавюрт шәһәрендәге реаль училищеда укыта башлагач, ул анда Шәрык әдәбияты, төрки филологиясе буенча лекцияләр укый, укучыларга революцион татар яшьләренең тормышлары һәм эшчәнлекләре турында сөйли. З. Батырморзаев «Танг чолпан» исемле әдәби түгәрәк оештыра. Аның членнары хезмәт ияләре алдында караңгылыкка һәм торгынлыкка каршы көрәшкә өндәгән әсәрләр укыйлар.

Егерменче гасыр башында, илдә барган иҗтимагый-политик хәрәкәт тәэсирендә, Дагстан шәһәрләрендә һәм авылларында культура-агарту оешмалары барлыкка килә. Әмма алар бер-берләреннән аерылган хәлдә яшиләр. Шуңа күрә 1917 елның язында ул оешмалар Дагстан агитацион-агарту бюросына берләштерелә. З. Батырморзаев шул бюроның члены итеп сайлана. Анда эшләү белән бергә, 1917 елның июль аеннан башлап ул әлеге бюроның органы булган иҗтимагый-политик, әдәби-иллюстратив «Танг чолпан» («Таң йолдызы») журналын редакцияли. Ә бер елдан соң аны «Эшче халык» исемендә чыга торган большевистик газетаның редакторы итеп билгеләләр. Әлеге журнал һәм газета өчен кирәк булган шрифтны ул, татар дуслары булышлыгы белән табып, Казаннан алып кайта. Бу басма органнарда Дагстан прогрессив интеллигенциясенең революцион-демократик омтылышлары үзенең якты чагылышын таба. Ул чорның актуаль проблемаларын яктырту буенча «Танг чолпан» журналы һәм «Эшче халык» газетасы татар демократик газеталары һәм журналлары белән тыгыз элемтәдә тора. Моны раслау өчен аларны татар телендә чыга торган кайбер газета-журналлар белән чагыштырып үтү дә җитә. Казанда басылган «Азат» газетасы, мәсәлән, түбәндәге программ белдерү белән чыга: «Газета, үзенең исеменә тугрылыклы буларак, азатлыкның чәчәк атуы өчен көрәш алып барачак, изү, хокуксызлык, түбәнсетү һәм халыкның артталыгы белән беркайчан да килешмәячәк, барлык милләтләргә тигез хокук бирелүен яклап көрәшәчәк». Редакция мәгарифне, һөнәр һәм белемнәрне киң таратуга һәрьяклап булышлык күрсәтергә, уку йортларына реформа үткәрүдә ярдәм итәргә вәгъдә бирә.

Кумык телендә чыккан «Танг чолпан» журналы һәм «Эшче халык» газетасы да шул ук мәсьәләләрне дикарлек күтәрә. «Азат» газетасы изүгә, хокуксызлыкка, түбәнсетүгә һәм халыкның артталыгына каршы көрәшкә чакырса, «Эшче халык» газетасы «Барлык изелгән массаларның проле-

---

[1] Партархив Дагобкома КПСС. 2370 фонд. 5 тасвирлама. 160 саклану берәмлеге. 130 бит.

[2] «Ленин юлы» газетасы. 1969 ел. 143 сан.

тарийлары, берләшегез!» дигән лозунг белән чыга.

Татар һәм кумык телләрендәге басма органнарның исемнәре үк бу халыкларның тыгыз мәдәни элемтәләре турында сөйли. Кумык телендә чыккан беренче прогрессив журналның «Танг чолпан» дип аталуын без инде әйтеп үткән идек. Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты каршында бөтен Россиядәге төрки халыклар өчен чыгарылган газета да «Чулпан» дип аталган. Аны Зәйналабид Батырморзаевның Казан буенча якын иптәше, күренекле татар революционеры Мулланур Вахитов редакцияләгән. Башка төр басмаларда да без шундый ук охшашлыкны күрәбез. Егерменче гасырның башында татар телендә «Халык» исемле газета чыгарыла, кумык телендә 1918 елда чыга башлаган газетага да «Эшче халык» дигән исем бирелә.

Шулай итеп, З. Батырморзаевның һәм аның тарафыннан оештырылган басма органнарның эшчәнлегендә татар-кумык әдәбияты һәм культурасы арасындагы тыгыз бәйләнеш бик ачык гәүдәләнә.

Дагстан халыклары арасында татар әдәбиятын актив популярлаштыручыларның берсе итеп без тагын милли кумык театрына нигез салучы Тимербулат Бейбулатов (1879—1942) исемен атыйбыз. Тимербулат Бейбулатов — алдынгы Европа культурасына ия булган шагыйрь, педагог һәм драматург. Ул шулай ук төрки халыкларның әдәбиятларын кумык теленә тәрҗемә итүче булырак та билгеле. 20 елларда ул татар драматургы Фәтхи Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә» пьесасын тәрҗемә итә һәм аны Дагстан театрларында куя. Галиәсгар Камалның З. Батырморзаев тарафыннан тәрҗемә ителгән «Безнең шәһәрнең серләре» спектакленең дә художество җитәкчесе Т. Бейбулатов була. Аның зур көч куеп эшләве аркасында, бу пьесалар кумык авылларында да, ерак нугай далаларында да күп тапкырлар куелалар.

* * *

Беренче кумык мәгърифәтчеләре нигез салган матур традицияләрне Совет власте елларында алардан соң килгән буын вәкилләре дәвам иттерәләр. Партия һәм хөкүмәт тарафыннан көн тәртибенә наданлыкка каршы көрәш мәсьәләсе куелу белән, кумык интеллигенциясе партиянең бу чакыруына көне-сәгате белән җавап бирә һәм яңа тормыш төзүчеләрне тәрбияләү эшенә алына. Бу юлда аларга күп төрле авырлыкларга очрарга туры килә: дәреслекләр, әдәбият, кадрлар җитешми. Ул елларда да кумык культура эшлеклеләренә татар интеллигенциясе ярдәм кулын суза: Казаннан һәм Татарстанның башка шәһәрләреннән китаплар һәм дәреслекләр җибәрелә.

Бу тема буенча материаллар эзләгәндә, безгә кумык язучыларыннан һәм җәмәгать эшлеклеләреннән язучы һәм драматург Алим-Паша Салаватов, Дагстанның атказанган укытучысы Мөхәммәт Хангишиев, республиканың халык шагыйре А. Аткай һ. б. ларның шәхси китапханәләрендә булырга туры килде. Аларның һәркайсында татар язучыларыннан Г. Тукай, М. Җәлил әсәрләре, Татарстан китап нәшриятында басылган күп санлы дәреслекләр, уку әсбаплары саклана.

Кумык халкының милли кадрларын үстерүдә татар әдәбиятының роле турында Бабаюрт авылында яшәүче Алхәмәт бабай Гамзатов безгә менә нәрсәләр сөйләде: «Миңа хәзер 75 яшь. Хәзерге көндә персональ пенсионер. Үземнең 30 ел гомеремне яраткан эшемә — яшь буынны тәрбияләүгә багышладым... Минем бала чагым михнәт эчендә үтте, шуңа күрә тиешле белемне ала алмадым... Тора-бара, дус-ишләремнең киңәше буенча, Казаннан татар телендә чыга торган газета-журналлар, тарихи һәм әдәби китаплар яздырып ала башладым. Әле дә хәтеремдә, мин аларны бер генә тапкыр түгел, әллә ничәшәр кат укып чыга торган идем. Октябрь революциясе булгач, без яңа тормыш төзергә тотындык. Партия: «Барыгыз да дәреслекләргә!» дигән чакыру ташлады. Республикада укытучылар җитми иде. Шул чагында дәүләт аларны хәзерләү буенча бер еллык курслар ачты. Тимерхан-Шурада оештырылган шундый курсларның берсенә мин дә киттем. Башта комиссия узарга кирәк иде. Комиссия членнары минем әдәбият белән азмы-күпме таныш булуымны хупладылар һәм мине шунда ук әлеге курсларга кабул иттеләр. Менә шул рәвешчә, татар әдәбияты аркасында, мин үземнең күптәнге теләгемә ирештем». Ул хәзер дә үзенең беренче ярдәмчеләрен — татар китапларын кадерләп саклый. Аларның берсен ул безгә дә бүләк итте. Бу — тарих һәм география фәннәре буенча төзелгән дәреслек иде.

Утызынчы елларда Дагстан хөкүмәте кумык интеллигенциясе вәкилләренең аң-белем дәрәҗәләрен күтәрү өчен, аларны берничә тапкыр Казанга һәм Татарстанның башка шәһәрләренә җибәрә. Татарстандагы уку йортларында алар татар һәм Европа культурасының үсеш тарихы белән танышалар, ул чорда алырга мөмкин булган фәнни белемне үзләштерәләр. Туган якларына кайткач, алар үзләренең бөтен көчләрен һәм аң-белемнәрен дагстанлыларның культурасын үстерүгә багышлыйлар. Шуның белән бергәттән, Дагстанда татар әдәбиятын һәм сәнгатен пропагандалау буенча зур эш алып баралар. Дагстанның атказанган укытучысы (күптән түгел үлде) Басыйр Сунгуровның истәлекләреннән күренгәнчә, башка дагстанлылар белән бергә Казанга ул әледән-әле килә торган булган. «Безнең арабызда,— ди Б. Сунгуров,— А. П. Салаватов еш була иде. Аның белән бергә без татар мәктәпләрендә уздырыла торган дәресләрдә катнаша, ә буш вакытларыбызда татар интеллигенциясе вәкилләре, культура эшлеклеләре белән очраша торган идек. Безнең өчен моның әһәмияте бик зур иде. Ә инде Казаннан киткәндә, без аннан үзебезнең мәктәпләребез өчен күп санлы уку әсбаплары, әдәби китаплар, типография кирәк-яраклары алып китә торган идек»[1].

Республикада чыга торган «Ленин юлы» газетасының элекке редакторы Галим Кәримов та безгә шул ук нәрсәләр турында сөйләде. «Безнең редакциягә беренче машинкалар Казаннан алып кайтылды. Татар нәшриятларының сораулары буенча, редакция аларга бездә чыккан газеталарны җибәреп торды. Үз чиратыбызда без дә алардан газета-журналлар соратып алдыра һәм алардагы аерым мәкаләләрне, татар язучыларының әдәби әсәрләрен үзебездә күчереп баса идек».

Кумык һәм татар мәдәниятләре арасындагы үзара бәйләнеш турында сөйләгәндә, гарәп шрифтыннан латинга күчү кебек катлаулы һәм четерекле мәсьәләне дә истән чыгарырга ярамый. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң, илебез халыклары үз әдәбиятларының үсешен тизләтү өчен чиксез зур мөмкинлекләр алдылар, халык массаларына фәнни белемнәрне үзләштерү өчен киң юл ачылды. Әмма аларның туган телләрендә басылып чыккан китаплар җитәрлек түгел иде. Гарәп алфавитына нигезләнгән полиграфия станокларының җитешмәве дә күп кыенлыклар тудырды. Шуңа күрә икенче шрифтка күчәргә кирәк иде. Шундый шрифт итеп латин алфавиты сайлап алына. Әмма, төрле сәбәпләр аркасында, бу эшне тормышка ашыру юлында кыенлыклар килеп чыга. Шунлыктан милли өлкәләрнең вәкилләренә бу проблема буенча күп баш ватарга туры килә. Яңа алфавитка күчү мәсьәләсен уңай хәл итү өчен, алар күп мәртәбәләр төрле киңәшмәләргә һәм конференцияләргә җыелалар. Һәм, ниһаять, бу проблема тюркологларның 1926 елның февралендә Бакуда үткәрелгән Беренче бөтенсоюз съездында хәл ителә. Съезд ябылганнан соң милли республика һәм өлкәләрнең вәкилләре, яңа алфавитка күчү мәсьәләләрен Союз күләмендә регулярлаштыру өчен, җитәкче бер үзәк төзү турында карар кабул итәләр. Комитет председателе итеп Агамали-Оглы, аның урынбасарлары итеп татарлардан Фатих Сәйфи-Казанлы, ә безнең республикабыздан Дагстан Халык Комиссарлары Советы Председателе Д. Коркмасов сайлана. Аның җитәкчелегендә 1928 елның 1 ноябрендә «Мәгариф юлы» журналының чираттагы саны яңа алфавит белән чыга.

Дагстан халыкларының милли әдәбиятына һәм сәнгатенә Россиянең алдынгы карашлы вәкилләре элек-электән сокланып караганнар. Бу сәнгать татар интеллигенциясе вәкилләре тарафыннан да югары бәяләнгән. 1929 елның 17 августында Махачкалага Татарстан язучылары, шагыйрьләре, журналистлары һәм сәнгать вәкилләре делегациясе килә. Делегация Дагстанда ике көн була һәм республиканың культурасына бәйләнешле күп кенә истәлекле урыннар белән таныша. Кунакларны республика буйлап сәяхәттә күренекле җәмәгать эшлеклеләре Савин, Аликберли, Хәйруллин һәм башкалар озатып йөри. Мәгариф Халык Комиссариатында делегация белән зур очрашу уздырыла, анда ике республика арасындагы культура бәйләнешләрен тагын да үстерү турында сөйләшүләр алып барыла. Шуннан соң озак та үтми, А. П. Салаватов, Б. Сунгуров, К. Әскәров һәм башкалар әдәбият алып кайту максаты белән Казанга юл тоталар.

Илебездә социализм төзелеше үсә һәм җәмгыятебезнең материаль-техник базасы ныгый барган саен, әчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли мәдәният-

---

[1] «Ленин юлы» газетасы. 1971 ел. 26 гыйнварь саны.

ләрнең үсеше дә киңрәк колач ала. Бу үсешне кумык һәм татар халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнешләре мисалында да ачык күрергә була. Без күреп үттек, М. Османов, Н. Батырморзаев, А. Акаев, Т. Бейбулатов кумык әдәбиятын һәм сәнгатен тудыруга һәм үстерүгә үзләреннән зур өлеш кертәләр. Аларның эшен кумык культурасының А. П. Салаватов, А. В. Сөләйманов, А. Аткай, Г. Аджиев шикелле вәкилләре дәвам иттерәләр. Соңгыларының әдәбият һәм сәнгать мәйданына килеп, тиз арада үсеп, күтәрелеп китүләрендә, рус классик әдәбияты һәм халык иҗаты традицияләре белән беррәттән, татар әдәбиятының, татар китапларының да зур өлеше бар. «Минем әнием,— дип искә ала халык шагыйре А. Аткай,— Сызраньда татар мәктәпләрендә укыган. Ул аннан күп кенә татар язучыларының һәм шагыйрьләренең китапларын алып кайта торган булган һәм аларны бүгенге көнгә кадәр кадерләп саклаган. Бала чакта минем беренче укыган китапларым әни алып кайткан нәкъ шул китаплар булды. Шуңа күрә дә мин Г. Тукай шигырьләрен, Г. Камал әсәрләрен аеруча якын күрәм». А. Аткай хәзер дә татар галимнәре һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләре белән даими язышып тора.

Халык шагыйре Ә. Аджиев иҗатында да прогрессив татар әдәбиятының шифалы йогынтысын тоябыз. Үз иҗатында ул күренекле сүз осталарының иң матур традицияләрен чагылдыра.

Әнвәр Аджиев 1914 елда Хасавюрт районының Костек авылында туа. 1932 елда Аксайдагы урта мәктәпне тәмамлап, район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Шул ук елны аның беренче шигыре басылып чыга. Хәзерге көндә исә ул республикабызда гына түгел, үзәк нәшриятларда да басылып чыккан күп санлы җыентыкларның авторы.

Ә. Аджиев — интернационалист шагыйрь. Кумык укучысы А. С. Пушкин, Т. Шевченко, К. Хетагуров, Лопе де Вега, С. Стальский, Р. Гамзатов әсәрләре белән Ә. Аджиев тәрҗемәләре аша таныша.

Татар шагыйрьләрен Әнвәр аеруча якын итә. Аның үзенең сөйләвенә караганда, егерменче елларда эш эзләп аның туган авылына татарлар киләләр һәм шунда төпләнеп калалар. Шул чорда Костек мәктәбендә Зөләйхә һәм Мөхәммәт Акчуриннар укытучы булып эшли. Татарлар белән кечкенәдән үк аралашкан малай аларның телен өйрәнә. Шагыйрьнең бүгенге көндә дә татар газеталарын һәм журналларын яздырып алуы бер дә гаҗәп түгел. «Казан утлары» исә аның күп еллык һәм даими юлдашы. Реалистик татар әдәбиятына гашыйк Әнвәр 40 елларда ук инде аның иң яхшы үрнәкләрен үз ана теленә тәрҗемә итә. Аның укучылар арасында киң таралган «Кайсар Калабузаров» исемле поэмасының язылуы шул чорга туры килә. Үзенең бу әсәрен язганда шагыйрь Г. Тукайның «Өйләнү — түгел сөйләнү» шигырен нигез итеп ала.

1966 елда илебез халыклары татар әдәбиятының күренекле ике вәкиленең бәйрәмен — Г. Тукайның 80, М. Җәлилнең 60 еллыгын билгеләп үттеләр. Юбилей көннәрдә Ә. Аджиев бу шагыйрьләрнең күп кенә әсәрләрен кумык теленә тәрҗемә итте.

Күрәсез, тугандаш ике халык арасындагы дуслык элемтәләре бик күптән килә, һәм вакытлар узган саен, ул элемтәләр ныгый, тирәнәя, үсә бара.

Татар интеллигенциясенә рәхмәт йөзеннән, шуны әйтеп үтәргә кирәк: кумык халкының әдәби мирасы, кульъязма хәлендәме ул, яисә китап булып басылганмы, Татарстан китапханәләрендә тулырак саклана. Шуңа күрә, үз әдәбиятыбызның тарихына караган материаллар эзләп, без еш кына Казан китапханәләренә, Казан архивларына мөрәҗәгать итәбез.

Менә, беренче карашка, әллә ни әһәмиятле дә тоелмаган кечкенә генә бер факт. Әмма ул халыклар арасындагы мәдәни бәйләнешләрне өйрәнүче галимнәргә ифрат күп нәрсә турында сөйли.

1971 елның язында В. И. Ленин исемендәге Дагстан Дәүләт университетының дагстан халыклары әдәбиятлары кафедрасы Казан архивыннан «Шура» журналларының кайбер саннарын сората. Һәм аның 1910 елгы 18 санында Солтан Сәлимгәрәй Җантуринның түбәндәге хәбәре урнаштырылган икән: «Мен Кисловодск Кавказияде турагъан вакътиде къумукълу Девлет Шайых Али-эфендини уланы Ибрагим-бекни архивендин къол языв бир осги китап тапдым. Бу китапны язылгъан заманы 1291 йылны магъарам айны 13 гюню деп белгиленгән. Тек китапны кил язгъаны белгили тюгюл. О китапны тили къазакъ (къыргъыз) тилге да геле. Ибрагим эфенди огъар ногъай тил болса ярай деп ерай. Сизге шо китапдан бир бетни гечюруп йиберемен:

«Эр хазнасы — эсги сөз, эр ширагъы — эки сөз. Яхшы гергенин айтор, яман бергенин айтор. Яхшы булан сейлансанг, аслам жавгъар тегюлюр; булан сейласанг, атанг ананг сегюлюр. Эки ямандан яхшы тугъса — тенги болмас; эки яман яхшыдан тугъса — эмми болмас. Яхши къатун — гюндюз байрам гече той; яман къатун — гече пикир, гюндюз ой. Кеп тургъан гюл сасыр, кеп сейлаган адасыр.

Яхшыны досту кеп олур, яманны хысы кеп улур. Яхшы булан сейпасанг — балгъа шекер къатгъандай, яман булан сейсанг итге сюек атгъандай»[1].

Бу хәбәр Дагстан галимнәрен уйланырга мәҗбүр итте. Нинди китап булыр бу? Кулъязманың датасын ничек исәпләргә? Тикшеренүче С. М. Алиев, мәсәлән, «Әгәр 1291 елны һиҗрәт буенча исәпләсәң, бу 1873 елга туры килә. Ул чагында китапны М. Э. Османов язган булуы ихтимал»[2],— ди. Ләкин бу китапны әле беркемнең дә таба алганы юк. Әгәр 1291 ел һиҗрәт буенча исәпләнсә? Ул чагында ничек? Ачышмы бу, әллә кулъязма авторының хата җибәрүе генәме? Киләчәктә җентекләп тикшерүләр бу сорауларга бәлки дөрес җавап бирерләр.

Татар-кумык әдәбиятларының үзара бәйләнешләрен күрсәткән фактларның барысы да бу проблеманы яктыртуның актуаль икәнлеген искәртә. Аны киләчәктә җентекләбрәк тикшергәндә тугандаш ике халыкның тарихына кагылышлы тагын да кызыклырак мәгълүматлар ачылуына һичбер шик юк.

Башта ук әйтеп үткәнебезчә, без бу мәкаләбездә кумык-татар әдәбиятлары һәм культурасы арасындагы бәйләнешнең кайбер якларына гына тукталдык. Совет власте елларында тугандаш бу ике халыкның әдәбиятлары арасындагы бәйләнешнең торган саен үсә, ныгый баруын киңрәк яктырту проблемасы үзенең тикшеренүчесен көтә.

**Махачкала, 1971 ел.**

[1] «Шура» журналы 1910 ел. 18 сан. 16 бит.

[2] «Ленин юлы» газетасы. 1971 ел. 18 май саны.

Равил Фәйзуллин

# ҮР АРТЫНДА ЯҢА ҮРЛӘР БАР

*Татар шагыйрьләренең 1971 елдагы иҗатлары турында*

Бер шагыйрь болай дигән: кешеләрнең үзләренә караганда аларның җырлары яхшырак, матуррак. Бу, мөгаен, дөрестер. Кеше җырга, дөньялыкта кылганына, ирешкәненә естәп, тормышка ашмаган хыял-шатлыкларын, иң газиз хисләрен, иң яшерен серләрен дә өсти шул. Чөнки кеше җырга, аның зурлыгына, бөеклегенә ышана. Җыр — мәңгелек юлдаш. Кешеләр белән җыр-шигырь дә дәверләр үткән, утлар-сулар кичкән, зәңгәр күк катларына менгән, шахталарга төшкән, данлы яки мәсхәрәле вакыйгалар шаһите булган. Гади халык җырны үзенчә юлдаш иткән, хөкемдарлар аны үзенчәрәк иш иткән, табигый, җыр-шигырьне тудыручы шагыйрьләрнең үзләренә дә караш төрле дәвердә төрлечәрәк булган. Берәүләр шагыйрьләрне зур көч ияләре дип таныган, берәүләр, хезмәтләрен җитдигә санамыйча, аларга сабыйларына карагандай, көлемсерәбрәк караган, берәүләр аларны күккә күтәргән, берәүләр үч алган...

Бүген дә һәммә кеше шигырьгә бер төрлерәк карый, аңлый һәм бәяли дип уйламыйм. Ләкин шигъриятнең, гомумән, әдәбиятның җәмгыятьтәге зур роле хәзер һәркемгә ачык, ул — зарури ихтыяҗ. Реалистик сүз сәнгатенең иҗтимагый тормыштагы олы урыны бездә элек-электән традицияләр белән раслап киленгән һәм бүгенге сәясәт белән дә ныгытылган. Дөрес, төрле контингент халык арасында, кайчак хәтта сәнгатьнең үз кешеләре арасында да, бүгенге шигърият һәм шагыйрьләр турында сайрак, берьяклырак фикер йөртүчеләр очраштыргалый. Хәер, бусы инде кешенең тормышка карашына, эрудициясенә, эстетик зәвыгына һәм интеллектуаль дәрәҗәсенә бәйле. Шигъриятне белү — аны тудыручы халыкның үткән һәм бүгенге рухи тормышын нечкәләбрәк белү дигән сүз ул. Беләсең, өйрәнәсең, аңлыйсың икән — бик күркәм, белмисең икән, син халык күңелендәге нюансларны, тирбәнешләрне, тойгыларны тулы итеп белә алмаячаксың. Әлбәттә, бөтен кеше дә шигырьне бер дәрәҗәдә яратырга, аңларга тиеш, шигъриятне тирән тойган зат, һичшиксез, бәхетле, аерым бер дәрәҗәле дип ракларга җыенмыйбыз. Шигырьләрнең бер ишләре кешене исәпкә төшерергә, гамьсез рәхәтлеген җуйдырырга, күңел кылларын авырттырырлык чиертеп сагышландырырга, борчырга да мөмкин. Ләкин шунысы анык, намуслы шагыйрьнең, намуслы талантның иҗаты һәрчак про-

грессив кешелеккә хезмәт иткән, кешенең кешелеген арттырган, аны рухи чистарткан, яктылыкка, алдынгы иҗтимагый идеалларга өндәп килгән. Дөрес, скрипканың үзе белән стенага кадак кагарга тырышу файдасыз. Әмма скрипканы чиертә белгәндә, кадак та кагылырга, яу да күтәрелергә мөмкин. Беркатлы диерләрме, хисчән, тәэсирләнүчән диерләрме, әмма мин, барыбер, шигъриятнең тылсымлы кодрәтенә, тормышыбызның алга баруына ярдәм итәрлек зур көч булуына нык ышанып, борынгы һәм мәңге яшь булган бу нәфис сәнгатьнең торган саен кешеләр күңелендә күбрәк урын алачагына шикләнмим. Чөнки тормыш үзе шигъриятле, табигать, мәңгелек хәрәкәт, мәхәббәт, идеаллар шигъриятле. Һәркемнең күңелендә җыр-шигырьгә урын бар, һәркем үзенчә — очкын гына сал — шагыйрь бит! Заманалар үтәр, мөгаен, бүгенге калын романнар юкарыр, яңа жанрлар туар, бүгенгеләре нык үзгәрер, ә җыр-шигырь исә, хис һәм фикернең иң кыска, тапкыр, йөгерек, үзгә ритмлы формасы буларак, жанрлар арасында, чагыштырмача, тотрыклы булып, кешеләргә һәр даим зарури кирәк, сүз сәнгатенең иң нәфис төре булып кала бирер. Шигырьгә карата шушы карашымнан, инануымнан, ышануымнан чыгып, үткән елда татар шагыйрьләре тарафыннан иҗат ителгән шигырьләр турында сүз әйтергә җөрьәт итәм.

1971 елның нинди тарихи вакыйгаларны эченә алганы һәркайсыбызга мәгълүм. XX гасырның киеренке бер елы булды ул. Дөньяның кайбер илләре экономик һәм политик яктан ныгыды, кайберләре кризис кичерде, континентларның төрле почмакларында теге яки бу масштабта сугышлар дәвам итте, кайбер дәүләтләрнең үз эчендә каты кан коюлар булды, кайбер халыклар бәйсезлек яулап алды. Халыкара хәл никадәр генә катлаулы, четерекле булмасын, барыбер, үткән ел коммунистик идеяләрнең җир шарындагы барлык илләргә, барлык халыкларга йогынтысы арткан бер ел булды. Үткән XXIV съездның колачы һәм аның дөньякүләм алган бәһасе моңа ачык дәлил. Җәен үзебезнең илкүләм съездыбыз булып үтте. Совет язучыларының кылган эшләре, бурычлары, киләчәктә эшлисе эшләре турында эшлекле сөйләшү булды, барыр маяклар ачыкланды. Шуңа өстәп республикабызның халык хуҗалыгы хәлләрен, экономик һәм культура тормышын күз алдыннан кичерсәк, үткән елның безнең бөтенебездә матур эз калдыруына инанырбыз. Язучыларыбыз, аерым алганда шагыйрьләребезнең, иҗаты да заманның төп проблемаларыннан, ил алдына куелган бурычлардан аерылгысыз. Ил сулышы — әдипләр сулышы. Ил һәм халык язмышы — әсәрләрдәге геройлар язмышы. Халыкның һәм заманның улы һәм шул ук вакытта чын интернационалист булу — безнең язучыларның, шагыйрьләрнең төп мәсләге, төп тоткан юлы, эшләренең асыл эчтәлеге. Татар әдәбиятының барлыгын һәм зурлыгын бөтендөньяга таныткан Тукай, Җәлилләр традициясе, аларның көрәшчән рухы бүген дә яңа буыннар иҗатында уңышлы дәвам иттерелә. Әдәбиятыбызны киңрәк аренада танытуда шагыйрьләр, мөгаен, киләчәктә дә иң алгы раттә булырлардыр. Мин моны, прозабызның уңышлы үсүен таныган хәлдә, поэзиябезнең бүгенге торышын ассызыклап әйтүем, аның теләсә кайсы халык алдында йөз кызартмаслык әсәрләре барлыгын һәм булачагына, бүгенге шагыйрьләрнең көченә, потенциаль мөмкинлекләренә ышанып әйтүем.

Иң әүвәл басылып чыккан шигырь китапларының күләме турында. СССР язучылар союзында член булып торган татар шагыйрьләренең саны 40 ка җитә. Үткән ел нәшриятның зурлар редакциясе 30 табак чамасы яңа шигырьләр, 80 табак чамасы элек язылган шигырьләрне кабат басып чыгарды. (Мәгълүмат тематик план буенча алынды, эш процессында, табигый, теге яки бу якка беркадәр үзгәреш булырга мөмкин.) Табаклар чагыштырмасы яңа, оригиналь әсәрләр файдасына түгеллеге ачык күренә. 30 табак ул күп түгел. Кардәш халыкларның поэзия буенча чыгарган китапларын күз алдына китерсәк, чагыштырсак, бу бик аз. Бу күләм, асылда, зуррак бер китап дигән сүз. Әлбәттә, күзәтү ясарга алынган кеше өчен, «Казан утлары», «Азат хатын», «Чаян», «Ялкын» журналларында һәм «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталарында басылган шигырьләр һәммәсе тупланганч, байтак кебек күренергә мөмкин. Ләкин ят күз белән читтән карaганда, бер еллык басылып чыккан поэзия әйтерлек күп түгел. Дөрес, олырак яшьтәге бер төркем шагыйрьләрнең сайланма шигырьләр сыйфатында чагыштырмача күләмле китаплары чыкты. Бу — Н. Арсланов, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Г. Афзал, З. Нури, Ә. Маликов, Г. Латыйп, Ә. Баянов сайланмалары һәм һ. Такташ, Ә. Исхак, С. Хәкимнәрнең рус

телендә чыккан китаплары. Боларның байтагы юбилейлар уңае белән чыгарылды. Бу китаплар — шагыйрьләрнең 30 яки 20 еллык иҗатларын чагылдырган басмалар, димәк, әлеге авторларның иң әйбәт китаплары дигән сүз. Һәрхәлдә, танылган шагыйрьләрнең тулырак басмалары укучылар кулына ирешү күңелле хәл. Бу китапларның авторлары кичерерләр дип уйлыйм, минем аларга тәфсилләп тукталырга мөмкинлегем юк. Ихтимал, аларны берьюлы дәррәү анализлап чыгарга көчем дә җитмәс, чөнки бу әдипләрнең күбесе, иҗатларын чорларга бүлеп, аерым тикшерелергә лаек. Бу очракта әдәбият белгечләре ярдәмгә килерләр дип уйлыйм.

Минем максатым үткән елда язылган поэзия әсәрләрен анализлау булганга күрә, мин фәкать яңа әсәрләргә генә, анда да, поэзиябез үсеше тенденцияләрен, андагы сыйфати үзгәрешләрне характерлый торган шигъри әсәрләргә генә тукталырга булдым.

Сүзне өлкән шагыйребез С. Хәкимнән башлыйсы килә. Үткән ел әдәби җәмәгатьчелек зур күтәренкелек белән, бәйрәм рәвешендә, аның 60 еллыгын билгеләп үтте. Була шундый юбилейлар яки юбилярлар, алар турында тантаналы кичәдә сөйләгән чыгышларны бүтән җирдә кабатлап булмый. Ничектер, уңайсыз, дөреслеккә туры килеп бетми. Ә менә С. Хәким иҗаты турында юбилей кичәсендә сөйләгән докладны яки чыгышларны, анда әйтелгән фикерләрне биредә дә рәхәтләнеп китереп үтәргә мөмкин. Моңа беркем дә гаҗәпләнмәс, күпсенмәс яки кызармас, гайре табигый дип санамас. Күрәсең, чын талант турында сүз кайда да бер. Талант ул талант инде. Андый әдипнең үз мәктәбе бар, үз шәкертләре бар. Сибгат Хәким дә — әнә шундый бәхетле язмышлы шагыйрьләрнең берсе. Бу очракта Сибгат Хәкимне, олы шагыйрь яки илнең олы бүләкләренә лаек, хезмәте зур әдип булудан бигрәк, 1971 елда актив эшләгән шагыйрь буларак, беренчеләрдән телгә алам. Ул үткән ел яшьләрчә бер зур дәрт белән гаҗәп бер мәгънәгә ия әсәрләр язды, «Казан утлары»нда зур бер шигъри цикл һәм поэма чыгарды. Моннан тыш, байтак публицистик мәкаләләр һәм, ниһаять, «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле проза белән язылган истәлек язмасы укучылар кулына барып иреште. «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы үткән елда басылган иң уңышлы поэтик әсәрләрнең берсе. Ул Тукайга багышланган. Уйлану рәвешендә язылган, бер караганда, шагыйрьнең тормыш чорларын гына чагылдырган бу поэма үткәнгә карый сыман, асылда, ул — киләчәк турында, илнең, телнең, әдәбиятның киләчәге турында. Халыкның талантлы уллары турында, аларның рухи дөньядагы урыннары, язмышлары, батырлык һәм намусларына тугрылык дәрәҗәләре турында.

**Өем тыныч, Аккош күле тыныч,**
**Тыныч түгел нигә бу җаным!**
**Чорны чорга якын куеп карыйм,**
**Вөҗданына аның — вөҗданым.**
**Өч гомерен аның яшәп җирдә**
**Чагыштырыр эшем бармы соң!**
**Җырны җырга якын куеп карыйм,**
**Намусына аның — намусым.**

Шагыйрь нинди генә авыр чорда һәм нинди авыр хәлдә дә Тукай кебек бөек затны биргән халыкның рухи көч чыганагын эзли, шуны таба, горурлана, бүгенгесенә сөенә, тормыштагы аерым кимчелекләр өчен борчыла, ваемсызларны кисәтә.

Халык, Тукай, без, үткән, хәзерге, киләчәк. Менә поэманы колонналар кебек тотып тора торган категория-төшенчәләр. Шагыйрь, ил улы булып, намуслы шагыйрь булып, бик күп нәрсәне эченә алган бу сүзләрнең үзара бәйләнешләрен һәм эчке мәгънәләрен эзли. С. Хәким үз гомерендә Тукайга багышлап тулы бер поэмалар циклы иҗат итте. Бу поэмаларга карап аның шагыйрь буларак үсеш эволюциясен чамаларга мөмкин. «Кырыгынчы бүлмә» белән «Шагыйрьнең бала чагы» һәм «Пар атлар арасында аерма зур. Аерма шунда—хәзергеләре камилрәк, тирәнрәк. Әлбәттә, һәр әсәрне, иң әүвәл, язылган вакыты, чоры күзлегеннән карап бәяләү зарур. Әгәр кайчан да булса Тукай турында төрле әдипләр тарафыннан иҗат ителгән әсәрләрне бөртекләп җыйнап, томлап чыгарсалар, бу поэма алар арасында күренекле урын алыр дип ышанам. «Казан утлары»ның беренче санында чыккан зур шигъри

циклы да эдипнең актив эшләве турында сөйли. «Күңелдә юылмаган эзләр» исемле истәлек-язма турында фикеремне матбугатта белдергән идем инде. Өстәп әйтәсе килгән шул: беренчедән, бөек җиңүне тәэмин иткән солдатларның гади бөеклеген, авторның материалына тугры мөнәсәбәтен күрдек, әсәр ышандыра, дулкынландыра, сугышка нәфрәт, Ватанга мәхәббәт тәрбияли; икенчедән, осталык, фикерләрне җыйнак һәм поэтик бирә белү ягыннан бик озын язарга яратучы кайбер прозаик иптәшләргә гыйбрәт алырлык нәрсәләр бар кебек бу әсәрдә. Шагыйрьнең соңгы поэмасында «Вакыт, йомгакларга вакыт» кебек сүзләр очраштыргалады. Йомгакларга кайсы вакыт яхшырактыр, анысын әйтүе кыен. Әмма бер нәрсә анык — хәзерге вакыт Сибгат ага өчен хаким шагыйрь булган вакыт, халыкның аннан олы сүз көткән вакыт, аның һәммәбез өчен дә бик кирәк вакыты. Чөнки «үр артында яңа үрләр бар», Гыйльметдин куйган тәрәзәле өйләргә, таң нурлары белән бергә, рухи яктылыкны да әле бик күп иңдерәселәр бар.

Баштук, ахры, күзгә чалындым мин:
— Яшь,— диделәр,— яңа! — диделәр...
Ә картайгач: — Бу яшәгән саен
Гел яшәрә бара! — диделәр.

Таныдылар чынлап илле яшьтә,
Зурладылар фәкать алтмышта...
Бераүләргә ул да насыйп түгел,
Мин бик риза мондый язмышка.

Бу юллар икенче бер өлкән шагыйребез Н. Арслановның «Мин бик риза» дигән шигыреннән китерелде. 30 да булмаганнан, ихтимал, 50 дә дә шагыйрь чыкмас. Шагыйрь һәрчак шагыйрь. Биеклекләр генә төрле. Нури ага 20 дә дә, 40 та да шагыйрь булган, ләкин зур шагыйрь итеп үзен соңгы ун елда танытты. Шигърияттә үз биеклеген сызды. Шагыйрьдәге яңарышны шигъриятебездәге бер күркәм, шактый сирәк очрый торган күренеш дип кабул итәргә кирәк. Шагыйрьнең осталыгы, тематик диапазоны, үзгә аһәңе турында үткән елда «Казан утлары»нда чыккан ике зур шигырь циклларына карап хөкем йөртеп була.

Читтә каламыни Ил җанлы ир —
Шагыйрь урыны — алгы сафларда!
Алгы сафта барган кешеләрнең
Рухы төшми авыр чакларда.

Илне олылау, рух күтәренкелеге, тормышны, яшәүне сөю — шагыйрь иҗатының эчтәлеген билгеләүче төп сыйфатлар. Ул — гашыйк шагыйрь. Мәхәббәт шигырьләрен Н. Арсланов кебек, аныңча дәрт белән, рәтен белеп язган шагыйрь, белмим, арабызда тагын кем бар икән? Мәхәббәт турында шактый күп языла һәм язабыз. Кайчак башны югалтып язабыз, кайчак сыкранабыз, шыңшыйбыз. Нури аганың бүтәнчәрәк, аның егетләрчәрәк чыга: сөйгәнен дә данлый, зурлый белер, үзен дә төшермәс, горур торыр, шунда ук кеше булып дөньяда яшәүнең олылыгын да раслар. Яшәргә өндәү, кеше булырга, ышанырга, гадел булырга өндәү һәм укучылар күңелендә мәгълүм бер дәрәҗәдә шуңа ирешү — бу шагыйрьлек. Шагыйрьнең хәтта элегик строфаларында да арысланлыгы уянып китә.

И кыска гомер — дөньяга
бер карап алу гына.
Алышыр идем җәннәтен
Дөньяның тамугына.

Шәрык шигърияте шәп үзләштергән, төрки телләрнең нечкәлекләрен белгән шагыйрь оста тәрҗемәче буларак та яхшы сүз белән искә алынырга лаек. Тугандаш халыкларның байтак шигырь җәүһәрләре белән без үз телебездә аның тәрҗемәләре

өшә таныша алдык. Н. Арсланов — үткән елда актив эшләгән шагыйрьләрнең берсе. Аның «Партияле кеше диләр мине», «Язгы тамчылар», «Мәрцишор», «Сагышларым», «Далаларым» кебек шигырьләре 1971 елның иң яхшы әсәрләре рәтендә саналырга хаклы.

С. Хәким һәм Н. Арсланов. Бу ике әдипне, иҗатлары белән бер-берсеннән шактый ук аерылып торган ике шагыйрьнең исемнәрен рәттән китереп үтүем — аларның ел дәвамында актив иҗат итүләре өчен генә түгел, зур һәм бик кирәк бер уртак сыйфатлары өчен дә. Ул сыйфат — аларның яшьләргә якын була алуларында, кирәк чакта алардан өйрәнә дә алуларында. Яхшы өлкән шагыйрьләрнең яшьләргә йогынтысы, яшьләрнең алардан өйрәнүе табигый. Ә менә өлкәннәрнең яшьләр дәртен, тыелгысыз хисен, фикерләү стилен, индивидуальлеген нечкә тоеп, аларны үз рухларына өсти алуы — бу — егетлек, бу — яшәрә алу, киң күңелле була алу дигән сүз. Кызганычка каршы, бу һәркемнән булмый. Я чыккан китаплар саны, я тәкәбберлек, я еллар комачаулый... Иҗатлары белән яшьләрне сокландырырлык, шул ук вакытта алардан да өйрәнә алучы өлкән шагыйрьләрдән мин шушы ике генә исемне атый алам: С. Хәким, Н. Арсланов.

Әдәбиятка 30 нчы елларда ук килеп, поэзиябезгә 40 еллап хезмәт итүче өлкән буын шагыйрьләренең яңа әсәрләрен аеруча зур игътибар белән укыйсың. Осталыкларының серенә төшенәсе, шагыйрьнең теге яки бу теманы менә бүген ни өчен актуаль итеп алуын беләсе, фикер тирәнлеген ачыклыйсы, идея-художество кыйммәтен үзеңчә бәялисе килә. Ветеран шагыйрьләребезнең берсе Хәсән ага Туфанның «Кармәт эскизлары» исемендәге шигырьләр циклын әнә шундый уйлар белән, кызыксынып укыдым. Бу шигырьләр шагыйрьнең моннан 55 ел элек аерылган туган җиренә — туган авылына кайтып зиярәт кылу тәэсирләре нәтиҗәсе. Кармәт кайчандыр зәңгәр сәдәпле киндер күлмәк кигән егетне озаткан булса, хәзер чал чәчле, дөньяның төрле җил-давылларын кичкән, олы шагыйрьне каршы ала. Дулкынландыргыч очрашу! Әйе, авыл үзгәргән, кешеләр үзгәргән. Бу үзгәрешләр шагыйрь күңеленә дә күчә. Үзгәрешләрнең яхшы якларын күреп, ул балалар кебек куана. Шагыйрьгә шулай ук яшьлеген хәтерләткән урыннар бик газиз, ул аларны эзли. Урманнарга бара, яланнарга чыга, чардуганнарга барып баш ия, каеннарга, талларга дәшә, йолдызларга сүз ката. Чагыштыра, уйлана, хыяллана, шагыйрьләр турында да, аларның тормыштагы хакыйкый бәяләре турында хәтереннән чыгармый. «Әдипләр-шагыйрьләр гомере — илдәге гомуми милек ул», «Матур булса да торган җир, сагындыра туган җир» дигән җырдагы сыман, туган җирнең газизлеге, аның бер рухи таяныч ноктасы, кешенең кешелеген арттыру чыганагы икәнлеге турында бу шигырьләр циклы. Әнә якташ шахтерларын искә алып шагыйрь нәрсә ди:

Кайтканнар Геркулес кебекләр,
Ахырда тәп йортка кайтканнар.
«Кыямәт көнгәчә»... дип кенә
Зиратта йокларга ятканнар.

Икенче бер җирдә шагыйрь болай ди:

Әллүле, бәллүле талларым! —
Тиккә дә тибрәлгән тирәгем! —
Нәкъ сезнең шикелле әле дә
Җилсез дә тибрәнә йөрәгем.

. . . . . . . . . . . . . .

Йомасы идем мин, якташлар,
Күзләрне мәңгегә йомасы...
Коткарды илемнең, җиремнең,
Тирәкнең, талымның догасы.

Тулаем алганда, бу шигырьләр күңелдә якты гына эз калдыра. Шулай да без шагыйрьнең бик яхшы шигырьләрен байтак укыганга күрә, беркадәр чагыштыра да алабыздыр, бу — Хәсән ага өчен гадәти цикл.

Акыл белән аллага тиң кеше
Табар микән тәкать үзендә!
Төкәнмәсме аның сабыр көче
Иң җаваплы
Авыр мизгелдә
Кагылмаска
Актык бер теймәгә!..
Ана кочагыдай шушы җирне
Ай шикелле үле итмәскә,
Үзе тапкан үлем көче белән
Үз башына үзе җитмәскә
Акыл табармы ул!..

Бу юллар икенче бер өлкән шагыйребез Шәйхи ага Маннур шигыреннән. Аның ел ахырында журналда басылган шигырьләре әйбәт тәэсир калдырды. Алар — уйлану, борчылу шигырьләре. Уйлар зур, чөнки кешелекнең уе, гаме зур. Замана, Галәм, Табигать тагы — кеше һәм аның кылган гамәле, мәхәббәт, шагыйрьнең шәхесе — шигырьләр менә шул турыда. Бик йөгерек укылмасалар да, шактый төшле шигырьләр алар. Өлкән шагыйрьләрнең без — яшьләр өчен бер гомум гыйбрәтле ягы бар: алар үз шигырьләрендә гомумән, иҗатларында, артык үгет-нәсихәтләмичә генә, яшәүнең бәхет икәнлеген, бар нужасы, бар авырлыгы белән яшьлекнең гүзәл икәнен, гомумән, гомернең газиз икәнлеген искәртеп торалар. Без игътибар итмәгән, яки гамьсез караган әйберләрнең, күренешләрнең кеше өчен күркәм якларын ачып бирәләр. Вакытның кадерен белергә, җай белән ашыгырга, ил куанырлык эшләр эшләргә өндиләр.

«Казан утлары»нда «Чирмешән якларында» исемле шигъри романның икенче кисәгеннән өзекләр басылды. Салих ага Батталның бу әсәре төрле елларда, төрле күләмдә, чәчелебрәк басылды. Болай басылу роман турында фикерне үз вакытында җыйнап әйтергә беркадәр комачаулады да шикелле. Әсәрнең беренче кисәге аерым китап булып чыккач та аның турында аерым рецензия-мәкаләләр күзгә чалынмады диярлек. Ә тулаем алганда, әсәр кызык, гыйбрәтле, татар поэзиясендә шигырь белән язылган беренче роман, заманында шактый шаулаган «Олы юл буйлап» кебек эпик пландагы зур әсәр. Миңа калса, «Чирмешән якларында» идея-эчтәлек ягыннан да, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да уңай бәягә лаек әсәр. Романда авылның революция алды һәм аннан соңгы еллардагы хәле, төрле сыйнфый катлаулар, алар арасындагы киеренке мөнәсәбәт, җир кешесенең, гади крестьяннарның аңы уяну, яңа тормыш төзү омтылышлары сурәтләнә. Форма ягыннан әсәр гадәти халык җырлары үлчәве — 8╳7 белән язылган. Ул йөгерек укыла, җиңел аңлашыла. Әмма бу җиңеллек авыр процесс нәтиҗәсе. 8—10 сүздән генә торган куплетларга чор сулышын өрү, геройларны җанлы итеп бирә алу, вакыйгалар барышының нечкә нюансларын ача алу һәм шуның барысын йөгерек формада укучыларга җиткерә алу — җиңел түгел. Яшь шагыйрьләргә бу җәһәттән романда өйрәнер, гыйбрәт алыр нәрсә күп. Әсәргә әдәби җәмәгатьчелек тиешле бәясен бирер дип ышанам. Хәзинәдәге байлыкның, кемнеке генә булса да, реаль кыйммәте танылырга тиеш.

Үткән елда актив иҗат итүчеләрнең берсе — шагыйрь Г. Афзал. 50 еллыгы уңае белән бу шагыйрь турында фикерләремне әйтеп, матбугатта мәкалә белән чыккан идем, хәзер аларны кабатлап тормыйм. Шуны гына искәртеп үтәсе килә, 50—60 елларда Г. Афзал үзен юморист, сатирик, шагыйрь итеп танытса, 70 елларда ул үзен үзенчәлекле лирик һәм публицистик шагыйрь итеп тә күрсәтте. Әлбәттә, бер бөтен шагыйрьнең иҗатын алып чорларга кырт кисеп карау формальрәк эш булыр, шулай да лирик-фәлсәфи юнәлештәге шигырьләре аның соңгы еллардагы иҗатының йөзен билгеләде. Соңгы елларда язылган байтак лирик, публицистик шигырьләре, җырлары бу фикернең дөреслеген раслый.

Без урта буын дип йөрткән, ә яшьләрә белән инде уртадан узып бара торган буын соңгы 5—6 ел эчендә нык активлашты. Берәүгә дә сер түгел, беркадәр элегрәк алар турында «тәүфыйклы, йомшак» буын дигәнрәк фикер йөри иде. Үсыз

тетен булмый дигәндәй, мондый фикернең тууына нигез дә бар иде шикелле. Чыннан да ир уртасы булып килгән бу буынның байтак вәкилләре шактый вакыт тормышның иң алгы сызыгында ук булмадылар, җәмәгать эшләренә бик агылыгып тормадылар. һәрберсе диярлек ялгызаграк һәм тынычрак юл сайлап, иҗатларында да таулашлар актармый, давыллар чыгармый, яшеннәр уйнатмый гына, спай гына, беркадәр үз-үзләренә сокланып, алсу таңнарда, чыклы сукмакларда сандугачлар җырын тыңлап, сөйгән ярлары белән бик озак әйләнгәләп йөрделәр... Әлбәттә, аларның һәрберсе ихлас күңелдән, шактый ук үҗәтлек белән иҗат итте, әдәбиятта үз йөзен табарга, үз урынын дауларга тырышты. Иҗатың белән үз-үзеңә һәйкәл куярга тырышу, бәлки, әйбәт омтылыштыр, ләкин ул һәйкәлләрне кая куярга соң? Аның өчен мәйдан кирәк, җирлек кирәк, халык кирәк. Бәхеткә каршы, аларның билләре сыеграк бу чор үтте инде. Ниһаять, ирлек чоры килде, чын мәгънәсендә өлгерү чоры килде. Бу буынның озаграк өлгерүендә, әлбәттә, объектив (сугыш, авыр еллар, белем җитенкерәмәү, вакытында тиешле әдәби тәрбия күрмәү) һәм субъектив сәбәпләр бар иде. Ниһаять, алар гәүдәләрен турайттылар, тормыштагы җаваплылыкны һәм табигый миссияләрен тоеп, дөньяга хуҗаларча карый башладылар. Дөнья киң икән! Нужа күрү дөнья күрү белән тәңгәл ук килеп бетми икән! Эш күп икән, кирәк күп икән. Моннан мең ел элеккеге тарих белән сөйләшергә, аңлашырга кирәк, Мефистофельләр белән бәхәсләшергә һәм җиңәргә, туган җирдәге өч аршин җирнең бәясен ачыкларга, югалган яшьлекне эзләргә, яшьләй сугыш утында чыныккан фронтовиклар турында сөйләргә, хәзинәләр табарга, тагын бик күп, бик күп эшләр башкарырга кирәк икән.

**Артык имин көн кичермим микән! —**
**Булды шулай уйлап пошканым.**
**Кагылмый күк чорның тыгыз җиле,**
**Юк та бугай хәтта дошманым!..**

**Туры сүзне ярып әйткән идем,**
**Җайланды да китте тормышлар —**
**Минем дә бар шәхси дошманнарым,**
**Явып кына тора орышлар!**

Ш. Галиевнең бу юллары урта буындагы эчке сыйфатый үзгәрешне беркадәр ача сыман. Әдәбиятның чисталыгы, рухи ныклыгы өчен көрәшкәндә, табигый, гел «песәем» диеп кенә тормаслар, ят күз белән караганнар да булыр, кеше җаны өчен көрәш заманында орышлар да булыр.

Шулай да үткән ел урта буынның, шагыйрьләргә караганда, проза өлкәсендә эшләүче өлеше активрак булды шикелле. һәрхәлдә, басылган әсәрләр, чыккан әсәрләр буенча шулай күренә. Х. Камал, Ә. Баян, Р. Гөрәй, С. Сөләймановаларның яңа шигъри әсәрләре күренмәде диярлек, яки бик аз күренде. Боларның күбесе бүтән жанрларда көч сынадылар, берәүләре, күрәсең, яңа зуррак әсәрләр өстендә эшләгәннәрдер. Чагыштырмача актив эшләгән, аерым шигырь цикллары бастырган иптәшләрдән И. Юзеев, Ш. Галиев, М. Шабаевлар булды.

**Әмер булсын иде, шигырьне тик**
**Ташка гына чокып язарга...**
**Буш сүз тезүчеләр бетәр иде!**
**һай, бер шуны сынап карарга!**

*(Ш. Галиев)*

Бу буын инде хәзер сүзнең кыйммәтен, дөньяның тозын белә, дуслык-иптәшлекнең, кылган эшләрнең чын бәһасен белә.

**Юк, мин яши алмыйм алай:**
**Күккә карап ятып,**
**Ялган алла ясап,**

**Сүзгә үрә катып...**
**Үзем — утлар ягам,**
**Үзем — дөрлим, янам.**

*(И. Юзеев)*



Табигать. Машина. Алар арасындагы мөнәсәбәт. Тирәнрәк уйласаң, машина да, әлбәттә, табигать җимеше. Ләкин кешегә машинаның хуҗасы һәм шул ук вакытта табигатьнең игелекле баласы була алу җиңел түгел. Марс Шабаевның «Җикән камыш» дигән исем астында оялап бирелгән шигырьләре Кешенең табигать улы булганын, булырга тиеш икәнлеген искәртә. Кешенең физик яшәве өчен тәгаен кирәк табигый шартлар турында дөньякүләм борчылу-исәп арткан заманда мондый шигырьләрнең кирәге икеләтә зур. Бу җәһәттән М. Шабаевның «Салда сәяхәт» исемле китабы да игътибарга лаек.

Роберт Әхмәтҗанов. Холкы белән дә, иҗаты белән дә үзенчәлекле шагыйрь. Аның артык үзенчәлеге, капризлылыгы каләмдәш иптәшләренә гел сөенеч генә китерми, кайчак сәерсендерә, кәефне дә җибәргәли. Ләкин ул — тумыштан шагыйрь, тәгал поэтик күремгә, нечкә тоемга ия шагыйрь. 60 еллар башында күпләрне өметләндереп, матур башлаган шагыйрь юл башындагы иҗади темпны тота алмады шикелле. 15 еллап гомер узды. Шагыйрь байтак китап чыгарды, яхшы шигырьләр, җырлар, поэмалар язды, эшләде... Әмма ул күбрәк эшли ала һәм эшләргә тиеш иде. Тиеш дип әйтәм, чөнки талант — ул халык байлыгы. Шагыйрьнең язганнарын ихтирам иткән һәм талантлы дип санаган хәлдә, миңа калса, аның үзен чолгап алган мохиткә, кешеләргә киң күңелле дустанә карашы җитенкерәми шикелле. Мин язганнарына карыйм, диапазонын чамалыйм, бер характерлы як: аның темалары я бик интим, я бик космик. Бүгенге яшәешебезгә — үзебезнең шатлык-нужаларга, әдәби процесска, хәл иясе теге яки бу мәсьәләләргә Роберт беркадәр битараф шикелле. Каян килә ул битарафлык, күзәтүчән караш? Тормышның вак-төягеннән өстен санавымы ул, үзен-үзе артык яратумы? Мин киләчәк өчен сәламәт акыл белән, борчылып яшәүче шагыйрьләр яклы. Роберт дөрес аңласын, бу әйтүләр аның талантына ышанудан, аны һәм тормышта, һәм шигърьдә көрәшче-гражданин шагыйрь итеп күрәсе килүдән. Робертның күңелгә кереп калган шундый юллары бар:

**Беләсең, бик тигез салмадык эзне дә,**
**Без дә бит бу җирнең баласы —**
**Еллар сагынып безне дә!**

Әйе, еллар безне күбрәк яхшы яктан сагынсыннар иде!

1971 елда М. Садри, М. Хөсәен, С. Шакир, чагыштырмача яшьрәкләрдән Е. Уткин, Б. Рафиков, П. Апушев иптәшләрнең дә шигырь китаплары чыкты. Бу җыентыкларга тәфсилләп тукталмавымның сәбәбе шунда — алар миңа, кызганычка каршы, шигъриятебезнең бүгенге үсешен характерлый алырлык яки авторларның үз иҗатларына карата яңа сүз әйтерлек материал бирмәделәр. Бу китаплар — авторларның чираттагы гадәти басмалары.

Үткән елда чыккан эреле-ваклы барлык шигъри әсәрләрне барлап чыккач, шундый бер нәтиҗәгә киләсең: С. Хәким, Н. Арслан кебек өлкән буын тудырган яхшы әсәрләр белән рәттән, 65 елларда күтәрелеп чыккан шагыйрьләр бик актив иҗат иткән икән. Яңа әсәрләрнең саны ягыннан һәм сыйфатлары ягыннан караганда да үткән ел шигырь оркестрында иң үзәк урынны алып алар торалар дисәм дә ялгышмыймдыр. Мин моны Р. Харисов, Р. Мингалимов, Ш. Мәхмүдов, Г. Рәхим, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов һәм тагын башка кайбер иптәшләрнең китапларын, басылган әсәрләрен күз алдында тотып әйтәм. Бер елны тары, икенче елны бодай уңа дигәндәй, урта буын шагыйрьләренә караганда, 1971 ел яшьләр иҗаты өчен аеруча уңышлы булды.

Р. Харисов — үткән елда иң актив иҗат иткән шагыйрьләрнең берсе. Ул «Казан утлары» журналында ике зур шигырь бәйләме чыгарды. «Ак сөлге» дигән китабы

укучыларга барып иреште. «Кеше» ораториясе туды, сүзләрен Р. Харисов язды. Кылган эш, башкарылган хезмәт икеләнебрәк караучыларга, өнәбрәк бетермәүчеләргә үзе үк җавап. Ренат — инициативалы һәм күп эшли торган иптәш. Язганнары арасында табигый, төрлеләре бар: бериш шигырьләре бөтен кешегә диярлек ошый, беришләре аерым контингент кешеләргә ошый, яки бөтенләй ошамый. Минемчә, моның сәбәбе ике нәрсәдә. Беренчедән, авторның кайбер очракта чын мәгънәсендә халыкчан итеп, гади итеп язмавында, икенчедән, бертөрлерәк вәзенгә һәм аңлауга күнеккән бериш укучыларның шагыйрь белән бергә иҗади процесска карнашып җитә алмавында. Ренатның шигырьләрен яратырга, яратмаска мөмкин, ләкин аларны инкарь итү, танымау мөмкин түгел. «Казан утлары» һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкалә авторлары (Ш. Әхмәдуллин һәм Ә. Баянов) асылда аның иҗатына уңай бәя бирделәр. Моннан бер-ике ел элек Р. Харисовның тәнкыйть мәкаләләрен укып: «Их, ул тәнкыйтьче булып китсен иде!» диючеләр бар иде. Шагыйрьме, тәнкыйтьчеме яхшы — әйтә алмыйм, тик шунысы хак — тәнкыйть, беренче чиратта, акылдан килә, шигырь, иң әүвәл, хистән, дулкынланудан килә. Бер үк кешегә бер үк вакытта икесе дә бугу авырдыр. Чыннан да, Р. Харисовның элегрәк язган шигырьләрендә бу авырлыкны тоярга була иде. Шигырьләр дөрес, фикри үсеш ягыннан да, шигырь техникасының кануннары саклану ягыннан да, ә үзләре ничектер салкынрак. Шагыйрь танылсын өчен, аның дөньясы, фикер агышы, күз һәм тагын күңел күзе күргән күренешләр, детальләр халыктагы дөнья белән, фикер агышы белән, шул күренеш, детальләр белән тәңгәл килү кирәк. Бөтенләй үк тәңгәл булсаң да син бөтенләй «эрисең», сине танымаячаклар, бик артык аерылсаң да халык кабул итеп җиткерми. Ниндидер идеал аралык, «чүт-чүт» аерымлык кирәк. Бу, әлбәттә, бөтенебезгә дә карый, шул исәптән Ренатка да. Ренатның соңгы шигырьләре аның бу «чүт-чүт»не тою сәләтенең үсә төшүен күрсәтте. Ул, үз индивидуальлеген дә саклап, тыгыз фикерле, укуы, әйтелеше, кабул ителүе ягыннан да аңлаешлы байтак шигырьләр тудырды. «Ак сәлге» китабына кергән «Татарстаным минем», «Синең йөрәгең тибә», «Йола», «Агыйдел тугайларында», «Өянке», «Карама яру» һ. б. шигырьләре шундыйлардан. Ренат Харисов шигырьләрне махсус бер темага оялап язарга ярата. Фатих Кәримгә багышланган шигырьләр, «Яфраклар», «Яралар» циклы. Композицион яктан алар һәрберсе күп бүлекләрдән торган фәлсәфи поэмалар кебек. С. Хәким Р. Харисов һәм тагын кайбер башка иптәшләр турында мондыйрак фикер әйткән иде: «Кура җиләген учта шундый итеп сыгасың, коры түбе генә кала, алар да материалның фәлсәфәсен шулай сыгып чыгаралар шикелле». Болай эшләү, бәлкем, начар түгелдер. Ләкин көч күпме дә, учында нәрсә? Кура җиләгенең суын чыгарып булыр, ә без кайчак учка имән чикләвеге куябыз да кысабыз, су да, сок та чыкмый... Теоретик һәм практик яктан дөньядагы бөтен нәрсә турында да язарга була. Гөл чәчәге турында да, икмәк турында да, хирург кулындагы канлы мамык турында да. Кайсын сайлап уңышка ирешеп була, анысын һәркем үзе карар. Бу — һәр шагыйрьнең этик, эстетик принципларыннан килә. Ә, безнеңчә, халык күңеле кабул итәрлек предметлар, күренешләр, уй-хисләр тирәсендә йөреп иҗат иткәндә отышлырак чыгачак. Гомумән алганда, Р. Харисов үсештә, яңа әсәрләре зурга өмет бағларга мөмкинлек бирә. Журналда чыккан шигырьләр циклы һәм «Ак сәлге» китабы 1971 елда чыккан иң яхшы китаплар рәтендә торырлык.

Шагыйрь Ш. Мәхмүдов «Көтелмәгән очрашулар» исемле китап чыгарды. Кемнәргәдер көтелгән, кемнәр өчен көтелмәгән булгандыр бу очрашу, әмма күңелдә матур эз калдыра торган очрашу бу. Ш. Мәхмүдов — әдәбиятта яңа кеше түгел. Ул моңа кадәр Мәскәү, Уфа нәшриятларында 4—5 китап чыгарган иде инде. «Көтелмәгән очрашулар» — Казанда басылган икенче китабы. Бу китап, минемчә, авторның моңа кадәр чыккан китаплары арасында иң яхшысы. Шагыйрь зур фәлсәфи категорияләр белән эш йөртә, тематик киң диапазонда иҗат итә. Йорт, Җир, Ватан, Вакыт, Буыннар... Аеруча яхшы шигырьләреннән «Балбаннар», «Бар шундыйлар», «Ике тол», «Мәрхүм абзыйга элегия», «Күлмәк», «Ольшан зиратында», «Күз» һ. б. Китапны төзү культурасы да күзгә ташлана. (Безнең кайбер авторлар китапның композицион төзелешенә игътибар итеп бетермиләр.) «Прага дәфтәре» циклында да күңелгә хуш килерлек шигырьләр байтак. Шәкли ягы да классик шигырьләренекеннән аерылаː үзгә рифмалар, үзгә ритм. Беренче укып баккан кешегә башта сәеррәк тә тәэсир

итәргә мөмкин. Ләкин болар формалистик экспериментлар түгел, ә телнең табигый әйләнмәләре. Мин авторның кечкенә генә бер шигырен мисал итеп китерергә телим. Бу шигырь авторның үзе һәм аның язу манерасы турында фикер әйтергә, көчле һәм йомшак ягын чамаларга мөмкинлек бирер дип уйлыйм.

Яшь тә түгел, артык алай карт та,
шулай да, ярты гомер артта —
яшьлек юлләрлеге, гөнаһлар
күптән инде сәер кунаклар
(алар белән өзелгән ара!).
Чуарланмый әйберләр төсе,
үз урынында ак белән кара;
(әгәр әрнү булса йөрәктә,
ул тик күк күкрәве еракта;)
бизмәннәр чайкалмый, дөнья нык,
көнгә караш-фикерләр анык,
дошманга тупас эндәшмим,
куштанга җәймим кочак...
Кыскасы, кинде бугай балигълык,
гүзәл әйберләр тудырыр чак.

«Дошманга тупас эндәшмим»... Мин мондый позиция белән килешмим. Н. Хикмәтнең шәкертләреннән берсе булган шагыйрьгә, үз укытучысының мондый сүзләрен янәдән хәтеренә төшерәсе килә:

Әгәр мин янмыймын икән,
Әгәр син янмыйсың икән,
Әгәр ул да янмый икән,
Караңгыны кем таратыр!

Шагыйрьнең шигыреннән бер юл алып кына аның иҗади позициясен билгеләү мөмкин түгел, диярләр. Килешәм. Шагыйрь шәхесе һәм аның иҗат лабораториясе катлаулы нәрсә. Рухи каршылыклар, үзең теләмичә үк үз-үзеңә каршы килүләрне әдәби тормышта байтак күрсәтергә мөмкин. Ш. Мәхмүдовның барлык китапларын һәм бу соңгысын күздән кичергәч, миндә шундыйрак фикер калды: ул шактый оригиналь шәхес, талантлы, зур фәлсәфи категорияләргә, гомумиләштерүләргә омтылучан шагыйрь, аның сизгер тою һәм чама хисе бар. Тормыштагы бихисап төрлелектән мәгънә әйттерерлек, детальләр сайларлык художниклык күзе бар, теле бар, зур тәҗрибәсе бар... Ләкин күп очракта язганына авторның үз мөнәсәбәте юк. Ул тегә яки бу трагик ситуацияне күрсәтә, сөйли, ачып сала... Ләкин үз шәхси мөнәсәбәтен әйтми. Авторның казанышымы бу? Укучыга ышануымы, мөнәсәбәтләрне үзең белдерт диюеме? Хакимлегеме, әллә бәркәдәр куркаклыгымы? Әллә әйберләрнең, күренешләрнең эчке мәгънәләрен ачу үзе мөнәсәбәтме? Нәтиҗәләр ясарга ашыкмыйк. Һәрхәлдә, безгә дә, авторга да бу юнәлештә уйлану комачау итмәстер. Ш. Мәхмүдов — көнчыгыш, төрки, Европа шигъриятен яхшы белгән, заманында әдәби институтларда укыткан, зур эрудициягә ия кеше. Гаҗәп, шул кешенең мәкаләләре, рецензияләре, чыгышлары белән безнең әдәби хәрәкәттә катнашканы юк. Ә ул әдәби тәнкыйть, бигрәк тә шигырь өлкәсендә зур һәм кирәкле эш башкара алыр иде.

Ел ахырында гына, 1971 ел китабы булып калыйм дигәндәй, Рөстәм Мингалимовның «Алкын су» исемле җыентыгы чыкты. Бу китап күңелдә яхшы тәэсир калдырды, һәм анда, чыннан да, көнләшеп укырлык шәп шигырьләр күп. Бу басманың тагын бер күркәм ягы шунда: китап тулысы белән диярлек өр-яңа шигырьләрдән, 1971 елда язылган шигырьләрдән тора. Күпләр әле «Алкын су» белән танышырга өлгермәгәннәрдер, укып чыккач шагыйрьне аңларлар, тиешенчә бәяләрләр. Төрле китаплар чыга, арада язучыны яки шагыйрьне танытa торганнары була. Рөстәмнең бу китабы, миңа калса, моңа кадәр чыкканнары арасында иң яхшысы, 1971 елдагы шигырь

китаплары арасында да иң яхшыларының берседер. Ни өчен җылы сүз әйтәм, шагыйрьнең битараф булмавы, алган темаларның тормышчан һәм җитдилеге һәм, ниһаять, ирләргә хас сабырлык һәм саллылык белән язуы. Бу китапка кергән шигырьләрне тел, сурәтләү чаралары һәм тышкы фактура ягыннан карап та шагыйрьнең камилләшә баруын күрергә мөмкин. Шигырьне укыгач, шундый тәэсир кала: шагыйрь үзенең көчен калку итеп күрсәтергә тырышмый, эффектлы чаралар эзләми кебек, ә көч барыбер күренә, нечкәлек һәм ныклык барыбер тоела. Дөньяда бәхетлеләр күп. Һәркем үзенчә бәхетсез, һәркем үзенчә бәхетле. Шагыйрь дә өлешенә тигән үз бәхете турында сөйли, ышандырырлык итеп сөйли:

**Минем бәхетем — Җиргә килүемдә,**
**Минем бәхетем — бөтен бәхетсезне,**
**Бөтен бәхетлене сөюемдә.**

Китапка шулай ук инде матбугатта уңай бәя алган «Минем дәүләт» исемле поэмасы да кергән. Рөстәмнең барлык шигырьләре дә бер дәрәҗәдә яхшы дигән мөһер сугарга җыенмыйм. Әмма «Алкын су» — шагыйрьнең үсешен күрсәтә торган, шигъриятебезнең бүгенге таләпләренә җавап бирерлек китап.

Г. Зәйнашева яңа шигырьләр, җырлар китабын «Җырлап яшик!» дип атаган. Җырлап яшәргә өндәве очраклы түгел, шагыйрәнең моңа хакы бар, аның халык яратып кабул иткән җырлары күп. Бу китапта да күңелгә хуш килерлек җырлары бар. «Очрашу җыры», «Иң кадерле сүз», «Күрешербез» — болар инде көйгә салынган, илгә таралган җырлар. «Аулагөйләр», «Ана йөрәге», «Ничә кышы килде гомеремнең», «Акбүз атым», «Тик бер тамчы кирәк» шигырьләре дә матур тәэсир калдыра. Тулаем алганда, шагыйрәнең бу китабын хуплаган, тематик яктан үз мөмкинлекләрен белеп, чама-хисен тоеп эш итүен, самимилеген, халыкчанлыгын таныган хәлдә, кайбер шигырьләрендә сиздерә торган примитивлыктан, «нинди матур брошка белән бизәлгән күк күкрәге» кебек зәвыксыз строфалардан котылуын телибез. Хатын-кыз шагыйрәләребездән үткән ел актив эшләгәннәр рәтендә К. Булатова һәм башлап язучы Ф. Гыйззәтуллиналарның да исемнәрен атап әйтәсе килә. Болар икесе дә нефть районнарында чыныгу алган шагыйрәләр. Кларaның үткән ел аерым китабы чыкмаса да безгә, Әлмәт бүлегенә, тапшырган һәм вакытлы матбугатта чыккан шигырьләре белән хөкем иткәндә, 1971 ел аның өчен шактый бәрәкәтле ел булды. Әлмәт районының Кәшер урта мәктәбендә татар әдәбиятын бик яхшы итеп укытуын әйтеп узу да артык булмас. Ул оештырган әдәбият түгәрәге гөрләп эшли, өметле яшь каләмнәр үсеп килә, Клара укыткан мәктәпне тәмамлаган укучылар әдәби профильдәге вузларга килә торалар. Гомумән, яшьләр иҗатына кучкәнче, инде бернічә китап чыгарган, исемнәре укучыларга таныш булган К. Мостафин, Ф. Шәфигуллин иптәшләрнең дә «Казан утлары» журналында чыккан уңышлы шигырьләрен әйтеп узу дөрес булыр.

Хәзер яшь һәм башлап язучылар иҗаты турында бернічә сүз. Алар бездә шактый. Йөзләп башлап язучының туксанлабы шигырь яза. Шуңа күрә аларның бөтен язганнарын, иҗади юл башларының бөтен индивидуаль үзенчәлекләрен, уй-теләкләрен, гадәт-холыкларын белеп, потенциаль мөмкинлекләрен чамалап бетерү ифрат кыен. Кыенлык тагын шунда, бу зур төркемдә, чын мәгънәсендә яшь һәм күзгә күренеп, янып торган талантлар белән бергә, инде байтактан язып килүче, бик үк яшь булмаган, иҗатлары белән дә һәммә кешене сокландырырлык дәрәҗәдә кабынып китә алмаган, әмма әдәби хәрәкәттә һәм, гомумән, әдәбият өчен кирәк, шигъриятта мәгълүм бер урын тоткан иптәшләр шактый. Кемнәр соң бу зур төркемдә? Болар — З. Маликов, М. Әгъләмов, Е. Уткин, Н. Мадьяров, Р. Вәлиев, Х. Әюпов, Т. Камалиев, Ш. Маннапов, К. Сибгатуллин, Д. Сирай, Н. Хисамов, Ә. Рәшитов, А. Сәләхетдинов, И. Беляев, З. Гомәрова, Э. Мостафин, П. Апушев, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Хәлиуллина, А. Вергазов, С. Гәрәева, Р. Закиров, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, М. Галиев, З. Насыйбуллин, Р. Вәлиева, Х. Халиков, М. Газизов, Б. Сөләйманов, Ә. Гаязов, Ә. Синегулов, А. Хәлим, Ә. Исхаков, Р. Вәлиуллин, Р. Бәшәров, Р. Низамиев, И. Ганиева, Х. Хөснуллин, Э. Шәрифуллина, З. Мансуров, С. Шәйдуллин, Р. Идиятуллин, Р. Риян, Х. Гатин, Ә. Гайнуллин, М. Садыйков, Р. Фазлыев, Ф. Шиһапова, Ә. Сәйфетдинов, В. Туктарова —

Менә 50 дән артык исем. Яшьрәкләр хисабына исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин. Югарыда санаганнарның бөтенесе аерым мөстәкыйль китап чыгарган (кайберләре хәтта 3—4 китап авторы) яки «Беренче карлыгачлар»да табаклап шигырь бастырган иптәшләр. Бу — үзе бер армия. Әдәбиятның, аерым алганда шигъриятнең, дәвамчылары булган бу көчнең зур булуы, әлбәттә, сөендерә. Шул ук вакытта иҗатларына тиешле ярдәм күрсәтү һәм юнәлеш бирү ягыннан, Язучылар союзы идарәсенә, консультация бүлегенә, гомумән, бөтен язучылар коллективына зур җаваплылык өсти. Кемнәргә таянабыз һәм аларны тәрбия итүдә күпме көч сарыф итәбез, киләчәк шуңа бәйле.

Үткән ел яшьләрдән кемнәр аеруча актив эшләде соң? Беренчеләрдән итеп Зөлфәт Маликов исемен әйтер идем. Аның, ниһаять, беренче мөстәкыйль китабы — «Язмышлар ярында» җыентыгы дөнья күрде. «Казан утлары»нда ике мәртәбә күләмле шигырьләр циклы басылып чыкты. Х. Туфан яшь шагыйрьнең беренче китабына язган кереш сүзендә болай дигән иде: «Поэзиянең нинди җитди, җаваплы миссия икәнен күңеле белән тойган, аңлаган бу яшь егет тормышны малайларча түгел, ә ирләрчә фикер йөртеп күзәтә белә». Зөлфәтнең шигырьләре өлкән шагыйрь әйткән фикерләрне раслый, хәер-фатихасын аклый, ышаныч уята. Шигырьләрендә кайбер каршылыклы фикерләр, кабатлаулар, формалашу чорына хас беркатлылык чалымнары булса да, мин Зөлфәтнең бөтен язганнарын диярлек шигырь дип таныйм һәм аның сәләтенә, киләчәгенә ышанып карыйм. Кем генә ни генә әйтсә дә, поэзиябездә үз тавышы булган, Язучылар союзы гаиләсендә торырлык, перспективалы, Зөлфәт дигән яшь шагыйрь бар. Бу — иң мөһиме. Аның иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең уңай фикере, «Казан утлары» журналының махсус бүләгенә лаек булуы да фикеремә куәт булса кирәк. Шул ук вакытта мин Зөлфәтнең чынлап өлгерүен, чынлап формалашуын, үзе актарасы чирәмне, үзе менәсе тауны тизрәк табуын теләр идем. Поэзиядәге үз миссиясен ул никадәр тизрәк аңласа, төшенсә, аңа шул кадәр яхшырак булыр. Зөлфәт бер шигырендә: «Сугар өчен син тимернең зәгыйфьрәк җирен — йөрәк турын таба бел генә», ди. Шуның сыман, аның үзенә дә көчне кая юнәлтәсен, шигырь көче белән кая сугасын төгәл белү бик кирәк. Миңа калса, кайчак Зөлфәт көчен үзе хәл итә алмаслык, яки бүгенге әдәби ихтыяҗыбыз өчен алай ук зарур булмаган, яки үзе белмәгән нәрсәләргә дә сарыф итә кебек. Атакага баручы рота, Хемингуэй үлеме, Кабан күлендә йодрык сугышы... Без төрлелек һәм тематик диапазонның киңлеге ягында, шулай да, үзең белгән нәрсәләр турында язуга ни җитә! Кайчак миңа Зөлфәт 20—30 йортлык авылда батыр булып калган егет төсле. Биленә таянып офык фонында баскан, бөтенесен егар кебек... Ләкин дөнья зур! Әллә нинди пәһлеваннар бар, әллә нинди көчләр бар. Кызганычка каршы, көчнең дә коесы төкәнмәс түгел. Зөлфәт инде зур тормышта да, шигъриятта да малай түгел, үзенең реаль мөмкинлекләре турында һәм булган сәләтен кирәккә файдалану юнәлешендә уйланыр дип уйлыйм. Һәрхәлдә, аңа ышаныйк, ул үсештә.

Зөлфәтнең яшьтәше Разил Вәлиевнең дә «Зәңгәр кабырчыклар» исемле беренче китабы дөнья күрде. «Поэзияне яратам. Дөньяның үзе төсле катлаулы да, кешеләргә аңлаешлы да итеп язасы килә». Болары — авторның моннан берничә ел элек матбугатта язып чыккан сүзләре. Мәскәүдәге Әдәбият институтын тәмамлап килүче яшь шагыйрьнең беренче китабын кызыксынып укыдык: мәркәз мәктәпләре, язучылары, шагыйрьләре белән аралашу безнең егеткә ничек тәэсир иткән икән, поэзиябезнә баетырлык табышлары бармы? Китап болай кызык, төрле, яңа хисләр, бизәкләр бар. Автор үзенчәлекле, әмма бу үзенчәлек байтак укучыда, соклану белән бергә, сәерсенү тойгысы да уятырга мөмкин. Яшь авторның беренче китабында, «Әнкәйгә хат», «Дисбе», «Казан поезды», «Авылда туй» кебек яхшы шигырьләре белән берррәттән, гражданин-мин булып җитмәгән «мин»нең үтә интим тойгы-хисләрен чагылдырган шигырьләр кирәгеннән артык урын алган кебек. Кайчак автор укучыга тәкәбберрәк карап: шуны да аңламыйсыңмыни? — дип әйтә сыман. Шагыйрь белән укучы арасында тулы аңлашу булмаса, һәр ике якка да кыен. Бу мөнәсәбәтнең дустанә булуы өчен ике генә юл бар: әгәр син көчле талант икән, дөньяны җәлеп ит тә, кешеләрне үзең белән иярт, күтәр, шуңа көчең юк икән, киң катлам укучылар ихтыяҗлары, зәвыклары белән исәпләш.

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Я дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Я булмаса үзем үзгәрәм.

Аңламыйлар җилне зәңгәр дисәң,
Тормышыбыз — сабан туй дисәң.
Һәр нәрсәгә минем үз атамам:
Айны кояш диям теләсәм.

Мөгаен, Разилнең үзенә күбрәк үзгәрергә туры килмәгәе. Минемчә, ул яхшы якка, халыкчан якка, ил-халык язмышын кайгыртучы шагыйрьләр ягына үзгәрәчәк. Аның сугышчан холкы, ил сөяр, ирек сөяр табигате, әдәбиятка кайнар мәхәббәте, нык омтылышы бар.

М. Әгъләмов 1968 елның ахырында «Еракка китеп кара» исемле шигырьләр циклы белән үзен зур мөмкинлекләргә ия шагыйрь итеп күрсәткән иде. Күпләр аны шунда танып, яратып калдылар. Шуннан соң өч елдан артык гомер үтте, кечерәк кенә булса да китабы чыкты, берничә тапкыр бәйләм-бәйләм шигырь бастырды. 1971 елда чыккан шигырьләре дә уңышлы цикллар белән рәттән саналырга лаек. Шулай да Мөдәррис турында уемны әйтми китә алмыйм. Кемгә ничектер, миңа калса, Мөдәррис «Еракка китеп кара»сыннан узып китә алмый кебек әле. Хәзер бастырган шигырьләренең күбесе моннан 4—5 ел элек язылган әйберләр. Бүгенге көндә ул нәрсәләр яза? Нинди уйлар белән яна, нинди коллективта кайный? Ахыр чиктә без иҗат кешесен аның язган әсәрләренең кыйммәтенә карап бәяләргә тиешбез. Ләкин бер хакыйкать бар: шәхес нинди генә сәләтле булмасын, әгәр ул бүгенге иҗтимагый тормышка кендеге белән берекми икән, аның тиз сүнүе бар.

Гомумән, соңгы өч-дүрт ел эчендә әдәбиятка килүче бу яшь буын, көндәлек иҗтимагый тормышта, әдәби хәрәкәттә, җәмәгать эшләрендә катнашулары ягыннан 65 еллар тирәсендә күтәрелеп чыккан буыннан күпкә кайтышрак, пассиврак. Әдәби җәмәгатьчелекне беркадәр өметләндергән, яшьләре белән Тукай яшенә җитеп килә торган бу сәләтле буын вәкилләренең теге яки бу мәсьәлә буенча ни матбугатта, ни җыелышларда борчылып, я сөенеп үзләренең теләк-уйларын белдергән чакларын хәтерләмим. Хәзер коеп куйган шагыйрь генә булып булмый, заман бүтән, максатлар бүтән. Вакыттан, Заманнан өстен хаким була алмыйбыз, без фәкать я актив, я пассив булып шушы Заманда, тормышта катнаша гына алабыз. Шагыйрьләр, әлбәттә, матурлык җырчысы. Ләкин нинди матурлык? Гомум абстракт матурлык күп, кешелек дөньясы аны безгә чиксез күп дәрәҗәдә мирас итеп калдырган, китапханәләрдә, храмнарда алар белән танышу өчен генә дә йөз гомер җитмәс. Без шушы гомуми кешелек тудырган рухи хәзинәгә шушы замандагы, шушы җирлектәге социаль эчтәлекле, тормышның алга барышына ярдәм итәрлек үзебез тудырган конкрет матурлык өстәргә тиешбез. Бу миссияне үтәүне иҗтимагый тормышның үзәгендә кайнаудан тыш күз алдына да китереп булмый. Тагын шуны да әйтәсе килә: кайбер яшь шагыйрьләр, даһи шәхесләрнең, даһи әдипләрнең иҗтимагый бөек эшләреннән, кылган хезмәт батырлыкларыннан гыйбрәт алудан бигрәк, аларның тышкы, яшәештәге кайбер сәерлекләрен үзләрендә булдырырга тырышалар. Ләкин бер нәрсәне генә онытталар: Маяковскийның сары кофтасы сиңа зуррак булырга да мөмкин бит әле! Иң әүвәл эш, иң әүвәл хезмәт! Некрасов әйтмешли, шагыйрь булу-булмау ихтыярың, ә гражданин булырга бөтенебез бурычлыбыз.

Үткән ел актив иҗат итеп, вакытлы матбугатта матур тәэсир калдырырлык шигырь бәйләмнәре бастырган К. Сибгатуллин, З. Насыйбуллин, Х. Әюпов, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, М. Галиев һ. б. иптәшләрнең дә исемнәрен уңай яктан искә алып үтәсе килә.

Нәшрият берничә ел рәттән яшь шагыйрьләр иҗатын «Беренче карлыгачлар» дип исемләнгән коллектив җыентыкларда бастыруны практикага кертеп карады. Яхшы ният белән башланган бу эшнең уңай һәм кире яклары булды. Уңайлыгы шунда: байтак иптәшләр бер дәррәү басылып алдылар. Ләкин тормыш үзе искәртеп тора, шагыйрьләрне 10 ләп, 15 ләп, сериялап поэзия күгенә очыртып булмый. Коллектив

жыентык уңае белән талантлылар да, урта кул иптәшләр дә бер үлчәүгә, бер хәлгә куелды. Берәр елдан сәләтле иптәш аерым китап чыгарса, аннан күрел, инде тартып-сузып «Беренче карлыгачлар»га кергән иптәш тә, минекен дә аерым китап итеп чыгарыгыз дип, шул ук чыккан шигырьләренә бераз өстәп, нәширләр өстәленә китереп салды. Асылда әле иптәш әдәбиятка кереп җитмәгән, «Карлыгачлар»ы әле сатылып бетмәгән, инде кабат басыла булып чыга. Бу кәгазь аз дип әйтергә ярата торган нәшрият файдасына түгел. Менә бер мисал. Яшь автор Данис Хәбибуллинның бер үк шигырьләре диярлек 1965 елны «Дуслык» күмәк җыентыгында, 1968 елны «Беренче карлыгачлар»да, 1971 елны «Беренче адымнар» дип аталган китапларда чыккан. Уннарча елга сузылган нинди «беренче адымнар» бу? Яки бүтәнрәк мисал: яхшы шигырьләре байтак булган Рәшит Әхмәтҗанов нәни генә беренче китабын 1962 елда ук чыгарган иде, аннан соң ун ел буена коллектив җыентыклар, карлыгачлар зонасын үтә алмый йөрде, гәрчә авторның кулга тотарлык мөстәкыйль җыентыгын ике-өч ел элек үк чыгарып була иде. Соңгы елларда үзенең иҗтимагый әһәмияте булган, фикри яктан саллы, халыкчан шигырьләре белән актив күренә һәм танылa бара торган К. Сибгатуллин белән дә шундый ук хәл: 1969 елда ук «Беренче карлыгачлар»да чыкты, тагын коллектив җыентыкта чыгару планлаштырылган. Нигә аерым китап итеп чыгарылмый? Шуңа охшаш мисалларны тагын китерергә мөмкин. Әйтәсе килгән шул: әгәр яшь шагыйрь сәләтле, перспективалы икән, әсәрләрен әдәби җәмәгатьчелек хуплый икән, бер дә курыкмыйча аерым китабын чыгарырга кирәк. Бүлгәләп йөртүдән автор да, укучы да, ахыр чиктә нәшрият үзе дә отмый.

Әдәби журналыбызның беренче санында тәнкыйтьче Р. Мостафинның «Җаваплылык хисе» дигән исем астында яшь шагыйрьләр иҗаты турында уйланулары чыкты. Бу төпле һәм тирән эчтәлекле мәкалә бүгенге яшь көчләр хакында гына түгел, ә бәлки соңгы 20 ел эчендә татар шигъриятенә килгән буыннарның төп асыл сыйфатлары, үзенчәлекләре турында да. Тәнкыйтьче әдәбиятка 65 елларда килгән шагыйрьләр турында аеруча киң туктала, аларның иҗатын анализлый, индивидуаль йөзләрен ачыклый һәм бу төркем шагыйрьләрнең чагыштырмача тиз һәм куәтле рәвештә күтәрелеп чыга алуларының сәбәбен, нигезен аңлата. Аның шигърияттәге үзгәрешләрне бәяләве белән, яңарышны тудырган тарихи социаль сәбәпләрне күрсәтүе белән килешкән хәлдә, минем аның бер фикерен дәвам итәсем, булдыра алсам, ачыклабрак та китәсем килә. Тәнкыйтьче болай ди: «Рус һәм күп милләтле бөтен совет әдәбиятында 50 елларның икенче яртысында һәм 60 еллар башында барган процесслар безнең яшь поэзиябезгә дә йогынты ясамый калмады... Рус поэзиясендә шул чорда ук хасыйл булган көчле поэтик дулкын безнең әдәбиятка бары тик 7—8 елдан соң гына килеп җитте...» Шунда ук: «Барыннан да бигрәк аны (яшь поэзияне — Р. Ф.) туендырып торган туфрак баеды, традицияләр киңәйде», ди. Болар һәммәсе дөрес, бәхәсләшер нәрсә юк та кебек. Әмма яңарыш, күтәрелешнең төп нигезе, фәлән елдан соң килеп җиткән йогынтылы җилдән бигрәк, **үз җирлегебездәге үзгәрешләрдә,** тәнкыйтьче әйткәнчә, **традицияләр киңәюендә, классик мираска мөнәсәбәт үзгәрүдә, гасырлар буе чарланып килгән шигъри культураның югары булуында, заман сулышын сизгер тоярлык кешеләре булуында.** Яңгыраш еракларлан, дастаннардан ук килә. Әйтик, Евтушенко, Вознесенский, Рождественскийларның М. Әгъләмовка яки Р. Мингалимовка, яисә Рәшит Әхмәтҗановка сизелерлек йогынтылары булгандыр дип уйламыйм. Чөнки безнең шагыйрьләрнең үзләренең матур исемнәре бар, йөзләре кызармаслык сәләтләре бар. Ә инде Мәскәүдәге бик модалы һәм популяр бер төркем шагыйрьнең иҗатына килгәндә, аларның XX гасыр тудырган бөтен мөмкинлекләрдән файдалануларын, материаль һәм рухи хәлләрен исәпкә алып, реалист булып карасак, мин аларны уртача язалар дип саныйм. Хәзер милли әдәбиятлар шул кадәр үсте, хәзер алар үзләре Совет әдәбияты хәзинәсенә сизелерлек өлеш кертәләр, әдәби үсешнең кайбер тенденцияләрен билгелиләр. Йогынтылар күп кырлыга әйләнде хәзер.

Менә без үткән елда чыккан байтак әсәрләргә, байтак авторларга тукталдык, мөнәсәбәтне, теләкләрне белдердек. Күзәтү рәвешендә конкрет авторлар, конкрет әсәрләр турындагы фикерләрдән соң, табигый, гомумирәк сораулар туарга мөмкин. Шигърият бүтән жанрлар нисбәтендә нинди хәлдә? Үсеш нинди юнәлешләрдә бара, потенциаль мөмкинлекләре ничек, хәл итәсе нинди проблемалар бар?..

Сүземне йомгаклау алдыннан, соңгы еллар шигърияте материалларыннан чыгып, шул хактагы фикерләрем белән уртаклашмакчы, кайбер нәтиҗәләр ясамакчы булам **Беренче** — татар әдәбиятында шигырь сугышчан позициясен ныгытты, аның рухи тормышта йогынты офыгы киңәйде. Хәзер бездә теләсә нинди телдә, дөньяның теләсә кайсы почмагында бастырып чыгарырлык, сөйләрлек, йөз кызартмаслык шигъри әсәрләр бар һәм алар гомум хәзинәгә өстәлеп тора. **Икенче** — татар поэзиясенең төп асыл сыйфатлары булып аның гражданлыгы, тормышчанлыгы, халыкчанлыгы саналып килә, һәм бу сыйфатлар соңгы еллар әсәрләрендә тагы да үстерелде. Тукай, Такташ, Җәлил, Кәримнәр традициясе яңа эчтәлектә, яңа төсмерләрдә, яңа формаларда дәвам итте. Ил һәм халык язмышы — поэзиябезнең үзәгендә. Тормышыбыздагыча, шигъриятебез интернациональ эчтәлекле. Тагын бер зур казанышыбыз — идея чатаклыклары булмау, чит идеология коткысына бирелмәү. Татар шагыйрьләренең, гомумән, язучыларының бу яктан ил йөзен кызартканнары юк.

Тәнкыйтьче Р. Мостафин әйткәнчә, үткән буыннарның әхлакый тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү, халыкның тарихи барыштагы урынын һәм ролен аңларга тырышу артты, рухи хәзинәләрне тарихи чагыштырып карау көчәйде. Шигырь тематик киңәйде, фикри яктан тирәнәйде. Яңа образларга баеды. Шигърияттәге бүгенге яшь кеше образы бармы, дигән сорауга, мин, бар, дип җавап бирер идем. Ул, әлбәттә, Такташның 30 еллардагы Алсулары, Зөбәйдәләре түгел, хәтта теләгәндә дә ул алар була алмас иде. Аның каравы, үткән, бүгенге, киләчәк турында, ил, халык, дөнья язмышы турында аек уйлый алучы җитди яшь кеше образы бар, бүгенге көн герое була алырлык лирик «мин» бар. Ул ачышлар ясый, калалар төзи. Мефистофельләр белән бәхәсләшә, җиңә. Бу яшь кешенең исәбе, гаме зур.

Шагыйрь бар икән, шигырьдә шәхес, кеше бар дигән сүз. Бездә шагыйрьләрнең өлкәне дә, яше дә бар, димәк, шигырьдә дә тулы канлы бүгенге кеше бар! Юкса, поэзиянең тормышта тәрбияви роле артмас, күпләр өчен ул ихтыяҗга әверелмәс иде. **Өченче** — шигырьдә фикер һәм хисне укучыга җиткерү формалары төрлеләнде. Кешеләрнең интеллектуаль дәрәҗәсе күтәрелү, шәхесләрнең кабатланмас төрлелеге, информация заманында төрле фикерләү рәвешләре белән аралашу, ахыр чиктә кешенең төрлелеккә омтылучан табигый халәте сәнгатьтә дә яңа сурәтләү чаралары, яңа формалар таләп итә. Шунысы характерлы, бу яңа формалар традицияләр нигезендә үсә. Яңарак формаларда эшләүче шагыйрьләр классик мәгънәдәге формаларда да уңышлы иҗат итәләр. Эзләнүләр, кемнәрдер уйлаганча, классик формада эш итә алмаганнан түгел, бәлки, традицион рәвештә эшли һәм бик яхшы эшли алып, формаларны төрләндерергә, баетырга тырышудан. Кыскасы, үсеш, төрләнү, баю күз алдында.

Шул ук вакытта, үсешне таныган хәлдә, шигърият алдында хәл итәсе мәсьәләләр, проблемалар, бурычлар да байтак. Минемчә, аларның кайберләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: **шигърияттәге булган хәзинәләрне, классик җәүһәрләрне һәм бүгенге яхшы әсәрләрне гомумсовет әдәбиятына, казаныш итеп, зур өлеш итеп күрсәтә, җиткерә алмыйбыз, кирәк дәрәҗәдә демонстрацияли алмыйбыз.** Бу беренче чиратта тәрҗемә эшенә карый. Икенче бер җитешсезлегебез — **заманга ияреп җитә алмавыбызда, оперативлык җитмәүдә, вакытны, форсатны ычкындыруда.** Вакыйгалар узгач, су тонгач кына язарга яратабыз. Халкыбызның фидакарь хезмәте, республиканың уникаль казанышлары әсәрләребездә үз вакытында тиешле чагылыш табып җиткерми. Өченчесе — **бүгенге совет һәм дөнья әдәбиятлары белән бәйләнешебезнең тиешле дәрәҗәдә булмавы.** Хәзер бер генә халыкның әдәбияты да фәкать үз кабыгында гына яши һәм үсә алмый. Еш һәм эшлекле аралашу — зарури. Күп милләтле совет әдәбиятының максаты, идеалы, темалары, хәл итәсе мәсьәләләре уртак. Шуңа да теге яки бу халык әдәбиятында мәгълүм бер проблеманың ничек хәл ителгәнен, нинди чаралар ярдәмендә югары эстетик кыйммәткә, яңгырашка ирешкәнен өйрәнү безнең өчен бик кулай һәм кирәк. Дүртенчедән — **халтура шигырьләре әдәби продукциянең сизелерлек өлешен тәшкил итүен дәвам итә.** Күрәсең, ак белән караны, чын белән ялганны тәгаен аерып җиткерә алмыйбыз. Бу очракта таякның бер башы редакцияләрдә утыручы әдәби хезмәткәрләргә дә төшә. Бастыручы булгач, язучысы табылыр. Без күп вакыт билчәннең үзен сүгәбез, аны үстерүчеләрне онытып җибәрәбез. Әлбәттә, халтура белән көрәшү җиңел түгел. Кыенлык шунда, кәсепче теманың ак-

туалена ябыша, сәясәттәге һәрбер үзгәрештән максималь файда алып калырга тырыша.

Кәсепчеләрнең кайчан да булса эзе дә калмас дип уйламыйм, ләкин, аңа карап, алар белән көрәшүне дә туктатырга ярамый. Күрәсең, зур темаларны халтурщиклардан саклый да белергә кирәк. Практик яктан моны талантларга игътибарны көчәйтү, аларның гражданлык тойгыларын үстерүдә ярдәм итү, ышану, социаль заказлар бирү, җәмәгать эшләренә активрак тарту белән эшләп булачак. Сүз талантларга таянырга кирәклек турында, аларны халык интересын чагылдыра торган әдипләр итеп тәрбияләү турында. Бу мәсьәләгә карата КПСС Үзәк Комитетының әдәби тәнкыйть турындагы мәгълүм карары, СССР язучылар союзы V съездының резолюцияләре безгә кулланма булып торырга тиеш.

Сүземнең ахырында шигырь китапларын нәшер итү һәм аларны тарату мәсьәләсенә тукталасы килә. Парадокс хәл: шигърият үсә дибез, ә тиражлар кими бара. Борчылырлык нәрсә бу. Моннан 4—5 ел элек китаплар 8—10 мең данә чыга иде. Хәзер уртача 3 мең данә. Хикмәт шигъриятка ихтыяҗ кимүдән түгел, әлбәттә. Сәбәпләрнең берсе китап пропагандасы эшенең йомшак булуында, китап сатуда әзлекле бер тәртип булмауда. Нәшриятның яхшы китапларны тиешле күләмдә, тиешле полиграфик югарылыкта чыгармавында. Аерым күргәзмәләр өчен чыгарылган басмаларны исәпкә алмаганда, көндәлек чыга торган китаплар шактый зәвыксыз булып дөнья күрәләр. Шигырь — нечкә, нәзакәтле жанр. Дөрес, соңгы елларда «Шагыйрь китапханәсе» сериясеннән классик һәм өлкән буын шагыйрьләрнең чагыштырмача канәгатьләнерлек басмалары дөнья күрде. Бу — бик яхшы. Шулай да бүтән басмаларны да югары художестволы һәм күзне иркәләрлек итеп чыгарырга кирәк. Һәр китап — нәшриятның очырган баласы ул. Китап язмышы. Без аның язмышын күп чак күздән югалтабыз. Очырабыз, онытабыз. Тулаем алганда, бездә китап сату, китапны пропагандалау эше начар тора. Республиканың үз районнарында яки читтәрәк әдәби атналыкларда, очрашуларда булган язучыларның китап сату оешмаларыннан канәгать булып кайтканнары юк диярлек. Нәшриятның да, Язучылар союзы оешмасы каршындагы пропаганда бюросының эше дә бу юнәлештә канәгатьләнерлек түгел. Гомумән, әдәби китаплар аша эстетик тәрбия итү, китап пропагандалау эше — эшлекле сөйләшүне сорый торган зур мәсьәләләрнең берсе. Зур булуы шунда, сүз киң халык массаларын, бигрәк тә яшь буынны художество чаралары белән коммунистик рухта тәрбия итү турында бара.

# ТУГАН ЯК ЯМЕ

Республикабыз хезмәт иярләре даһи юлбашчыбыз фәрманы белән үзләренә автономия бирелүгә ярты гасыр тулу вакыйгасен 1970 елда тантана белән бәйрәм иттеләр. 50 яшь. Кеше гомере белән исәпләгәндә, бу — зирәклеккә ирешү чоры, тарих өчен бу бик аз вакыт, диңгездән бер тамчы гына. Әмма әһәмияте ягыннан караганда, бу илле еллык — гасырларга торырлык.

Партиябезнең В. И. Ленин васыять иткән милли политикасын эзлекле итеп тормышка ашыруы нәтиҗәсендә, илебездәге барлык тугандаш халыкларның эчкерсез ярдәме белән безнең Татарстаныбыз иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә алга таба могҗизалы сикереш ясады. Кем идек тә кем булдык? Туган ягыбызның бүгенге йөзе турында уйланганда алга ирексездән шушы сорау килеп баса. Кыйшаеп беткән өйләрдә зиннәт дип саналган керосин лампасы — һәм бөтен Союзда чыгарыла торган нефтьнең өчтән бер өлеше чамасын бирүче менә дигән промыселлар. «Сабын патшалыгы» (элекке юл күрсәткечләрдә Казан шулай дип аталган) — һәм республиканың данын күтәргән күп төрле продукция: самолетлар, төгәл приборлар, каучук, кинопленка, полиэтилен, бик катлаулы модификаторлар. Актерларның ишаннар ләгънәтенә дучар булган бердәнбер профессиональ труппасы һәм хәзерге заман сәнгатенең иң югары биеклекләре: театр, опера, музыка, рәсем сәнгате...

Шушы гаять зур казанышларны конкрет мисаллар һәм язмышлар аша ачу, азат хезмәтнең кодрәтен күрсәтү, патриот һәм интернационалист сыйфатларын үзендә туплаган совет кешеләренең фидакарьлеген гәүдәләндерү, ирешелгән уңышларның чыганакларын ачып бирү, кыскасы, ленинчыл милли политиканың тантанасын пропагандалау җәһәтеннән соңгы елларда галимнәребез дә, язучы һәм журналистларыбыз да иҗат активлыкларын арттыра төштеләр. Илебез һәм республикабыз халыклары тормышында зур вакыйга булган истәлекле юбилейлар да моңа зур этәргеч ясады. Әлеге уңай белән киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәрдәй байтак китаплар дөнья күрде. Алар арасында Гариф Ахунов һәм Марсель Зариповның «И кадерле туган як» исемле хезмәте дә бар. Сүзебез шул китап хакында.

Татарстанның узганын һәм бүгенгесен тоемлы итеп күз алдына китереп бастыру өчен авторлар сәяхәт алымын файдаланганнар. Публицистика дөньяга килгән чордан башлап кулланыла ул алым. Бу — әлеге алымның колачы киң булудан, кирәк чакта, хәрби термин белән әйтсәк, маневр ясый алуыннан киләдер. Чөнки ул алым (авторы үзе яза торган объектны биш бармактай белгәндә, фантазиясе бай һәм йөгерек булганда, билгеле) бик күп язмышлардан һәм фактлардан иң кирәклеләрен, иң үзенчәлеклеләрен сайлап алырга, узганга да, бүгенгә дә, киләчәккә дә кыю караш ташларга мөмкинлек бирә. Бу — бер. Икенчедән, сәяхәт алымыннан файдаланганда, автор үзе сурәтли торган вакыйгаларга, язмышларга, фактларга актив мөнәсәбәтен күрсәтә ала. Өченчедән, укучылар автор белән бергә сәяхәт кылгандай булалар. Гүя укучылар — кызыксынучан экскурсантлар, ә автор — күпне белүче, туган төбәген яратучы киң күңелле гид. Әйтерсең лә ул экскурсантлар белән эчкерсез әңгәмә корып җибәргән. Укучылар авторны һәрчак янәшәсендә итеп тоялар. Бу, әлбәттә, әсәрнең эмоциональ тәэсир көчен арттырып җибәрә. Ләкин хикмәт сәяхәт алымын сайлауда түгел (аны Г. Ахунов үзе дә, Ә. Маликов, А. Сәләхетдинов һ. б. республикабыз турында китаплар язганда кулландылар инде), ә кемнең ничек сәяхәт итүен-

дә, кайнап торган тормышыбызның берсен-нән-берсе бай рухи дөньялы кешеләрнең кайсысын сайлап алып, аларны ничек гәү-дәләндерү осталыгында, икенче төрле әйткәндә, объектив чынбарлыкның субъек-тив яктан ничек чагылдырылуында.

Баштан ук әйтеп куйыйк: авторларның республикабыз буйлап аның үткәненә, бү-генгесенә, өлешчә киләчәгенә сәяхәте уңышлы чыккан. Алар югарыда сүз алып барылган форманың бай мөмкинлекләрен максатка юнәлешле итеп оста файдаланган-нар, сәяхәт вакытында киң катлау укучы-ларда зур кызыксыну уятырлык мөһим ва-кыйгалар, фактлар, гыйбрәтле язмышлар «күрә» алганнар һәм күргәннәрен мавык-тырырлык итеп сөйләп бирә белгәннәр. Хәзерге заманның нинди генә камил транс-портында — һава корабындамы, тиз йөреш-ле поездларды, М. Девятаев йөртә торган «Метеор»дамы — хәрәкәт итмәсеннәр, дил-бегә һәрвакыт авторлар кулында.

Иң мөһиме: язмаларда авторларыбыз-ның туган ягыбызны, аның кешеләрен яхшы белүләре, аларны ихлас яратулары тоелып тора. Шул ук вакытта алар мәгълүм факт-ларга, вакыйгаларга, кешеләрнең язмышла-рына үзләренчә якын килгәннәр, аларны үзләренә генә хас алымнар белән гәүдә-ләндереп гомумиләштерүләр ясаганнар.

Күзгә бәрелеп тормаган җепләр белән бер-беренә бәйле очеркларны берләштер-гән бу китапның бер үзенчәлеге шунда, авторлар — республикабыз тормышының кайсы өлкәсен генә алмасыннар — нигездә, хосусыйдан гомумига бару алымын кулла-нып эш иткәннәр. Хосусый дигәнебез — аерым фактлар, вакыйгалар, күренешләр, кеше язмышлары; гомуми дигәнебез — иҗ-тимагый тормышның теге яки бу тармагын-да Татарстан ирешкән казанышлар, иртәгә ул яулаячак яңа үрләр. Әлеге принципны эзлекле үткәрү очеркларны конкрет һәм тоемлы иткән, чынбарлыкны образлар аша сурәтләргә мөмкинлек биргән. Бу исә ки-тапны буш сүзлелектән, коры шапырыну-лардан коткарып калган, аның дәлиллелеген, ышандыру көчен арттырган, кызыксынып укыла торган иткән.

Китаптагы очеркларга герой итеп алын-ган кешеләрнең хезмәт иляренең төрле катлаулары өчен типик булулары «Ир яз-мышы — ил язмышы» дигән хакыйкатьне конкрет мисалларда ачарга булышкан. Шуңа күрә әсәрдә сурәтләнгән аерым яз-мышлар барысы бергә халык язмышы бу-лып күз алдына килеп баса.

«И кадерле туган як» китабы «Елгалар-ның елгасы» исемле очерк белән ачыла. Мәгърур Идел-ана турында ул. Бу очраклы түгелдер, мөгаен. Хикмәт Идел-ананың иле-без, республикабыз язмышында гаять зур урын тотуында, барлык тарихи вакыйгалар-ның чал шаһите булуында гына да түгел. Безнеңчә, бу очракта Идел-ана Туган ил образына да ишарә сыман. Ул үзенә күп санлы инешләрнең суын җыйган, «балала-рын багучы ана кебек, меңләгән авыл, йөз-ләгән калаларга, олы һәм вак елгаларга сулыш биргән». Илебездә яшәүче милләт-ләр һәм халыкларның язмышын хәтерләтә бу деталь. Алар да бит бер йөрәктән су-лыш алып яшиләр. Илебез, Идел-ана ши-келле, йөзләгән милләт һәм халыкларга яшәү сулышы бирә (Идел-ана булмаса, вак һәм олы елгалар корып бетәрләр иде). Үз чиратында Ватаныбыз да, Идел-ана кебек, тугандаш республикалардан көч һәм куәт ала (күп санлы елга-инешләр булмаса, Идел-ана да булмас иде, булса да — хәзер-ге кебек мәгърур булмас иде). Татарстан да Идел-анадан туена һәм аңа үзенең мул суын бүләк итә торган бер ашкын елга бу-лып аңлашыла. Республика язмышы ил яз-мышы белән аерылгысыз. Шагыйрь әйт-мешли, «без туган бер җепкә бергә тер-кәлеп».

Туган якның кадере, аның бүгенге бә-хете турында тәпле сүз сөйләргә җыенган-да, аның данлы узганына, каһарманнары-ның язмышларына күз ташламыйча, тарих-ка экскурслар ясамыйча мөмкин түгел. Ки-чәгедән башка бүгенгене, бүгенгедән баш-ка иртәгәне аңлавы кыен.

Һәр халыкның, һәр илнең бай тарихы, бигрәк тә аның социаль һәм милли азат-лык өчен көрәшкә керткән өлеше, фида-карь революционерларының якты гомер-ләре яшь буында патриотизм һәм милли горурлык хисләре тәрбияләргә ярдәм итә.

Илебездәге башка тугандаш республи-калар кебек үк, безнең Татарстан да рево-люцион традицияләргә бай, «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгезгә», «кул җитмәс йолдызга» тиң батырлары бар аның.

Без сүз алып бара торган китапның нәкъ менә тагын бер үзенчәлеге шунда, аның авторлары бу традицияләргә кайта-кайта мөрәҗәгать итәләр, кичәгене һәм бүгенге-не бер җепкә бәйләп алып баралар, буын-нарның дәвамчанлыгын ачып бирергә ом-тылалар. Революцион традицияләр дә ае-

рым кешеләрнең язмышлары аша гәүдәләнәләр.

Авторлар туган ягыбызның азатлыгы өчен көрәшкә тугандаш милләтләрнең алдынгы уллары һәм кызлары керткән гаять зур өлешне дә онытмыйлар, аны басым ясап күрсәтәләр. В. И. Ленинның олы бәясенә лаек булган беренче марксист Н. Е. Федосеев, рухи яктан Казанда туган А. М. Горький, республикабызны сыйнфый дошманнардан азат итү өчен җанын фида кылган атаклы комиссар Н. Г. Маркин турындагы очерклар, шулай ук бүтән язмалар әнә шуны раслый. Димәк, патриотизм һәм милли горурлык тойгылары интернационализм рухы белән сугарыла. Нәтиҗәдә, патриотизм һәм интернационализм диалектик бердәмлектә ачыла. Бу исә тарихи чынбарлыкка тугрылыкны тәэмин итә.

Китапта тасвирланган бүгенге чынбарлыкка тарих сулышы самими килеп керә. Моның төп сәбәпләреннән берсе тарихи вакыйгаларга һәм язмышларга тукталганда авторларның сәяхәт алымыннан читкә китмәүләрендәдер, күрәсең. Ирек өчен көрәш вакыйгалары, азатлык өчен гомерләрен биргән баһадирлар халык күңелендә якты эз калдырганнар. Ул аларның истәлеген, исемнәрен шәһәр мәйданнарына, урамнарына, йортларга, парсходларга биреп мәңгеләштерә барган. Авторлар, әнә шундый изге урыннарга дә сәяхәт кылып, тарих белән бүгенге көн арасына табигый күпер салуга ирешкәннәр.

Менә Россия халыкларының кайгы-хәсрәтен гасырлар буена үзенә җыеп саклаган Себер тракты. Моннан декабристларны сөргенгә куганнар. 1833 елны Казанга Пугачев вакыйгаларын өйрәнергә дип килгән А. С. Пушкин Себер трактына күзләрен талдырып озак карап торган. Казан аркылы А. И. Герценны Пермьгә озатканнар. Аннары Россия крестьяннарын балта алырга чакырган Чернышевскийның, народоволецларның, патшага каршы күтәрелгән эшчеләр, крестьяннарның Себер китәр чаклары җиткән... Кыскасы, мондый сәяхәт маршрутлары байтак җыела бу китапта.

Авторлар республикабызның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген бәян иткәндә әледән-әле бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинга әйләнеп кайталар. Бу, әлбәттә, аның данлы якташыбыз булуыннан гына, Татарстанда аның якты истәлеген саклаучы изге урыннарның күплегеннән генә килмидер. Хикмәт изелгән халыкларның бөек дусты, иң зур интернационалист В. И. Ленинның Татарстан язмышында хәлиткеч урын тотуында, аның мәңге үлмәс идеяләренең, гадел милли политикасының тантана итүендәдер. «Безнең иң якты легендабыз — ул Ленин,— дип язалар авторлар.— Кичәге хакыйкать, бүгенге тантана һәм республикабызның киләчәк көне». Зирәк юлбашчыбыз һәм бөек якташыбызның якты образы аңа махсус багышланган очеркларда гына түгел, ә китаптагы барлык язмаларда да кызыл җеп булып сузылып бара. Әйтерсең авторлар бер очтан В. И. Ленинга аның васыятьләренең чынга әверелә килүе турында исәп-хисап та бирә баралар.

Авторлар В. И. Ленин образының, аның идеяләренең кешеләр язмышында яшәвен тәфсилле итеп сурәтлиләр. Алар бу очракта да башта алган принциптан — тарихны һәм бүгенгене кешеләр язмышы аша күрсәтү принцибыннан читкә тайпылмыйлар. «Тормыш китабы» исемле очеркта аерата ачык күренә бу. 13 яшендә чагында ук «бөтен дөнья социалистик революциясенең бөек юлбашчысы белән күңеленнән килешкәнлеген» белдереп В. И. Ленинга хат язган, хәсрәт-сагышын бушаткан, бүгенге һәм иртәгәге көнгә булган ышаныч-өметләрен әйткән, ә хәзер Тәтештә яшәүче пенсионер Тихон Ильич Курков турында ул. Үз авылында беренче комсомол ячейкасы секретаре булган, аннары югары белем алып Мәскәүдә «Сельхозгиз»да редактор булып эшләгән, Бөек Ватан сугышын иңендә күтәрешкән, удан соң балалар йортында, партия райкомында, мәктәптә тәрбия эшләре алып барган Тихон Ильич юлбашчы белән «килешкәнен» гомер буе күңел түреннән үткәреп яши. Бөек Ленин, Данко йөрәгедәй, аның тормышын һәм күңелен яктыртып бара.

В. И. Ленин Т. И. Курковның гына түгел, башка очерк геройлары язмышында да хәлиткеч роль уйнаган, аларны революция, социализм эше өчен фидакарь көрәшкә һәм хезмәткә рухландырган, алар һәр нәрсәдә аңар охшарга тырышып яшәгәннәр. Ялкынлы революционер Мулланур Вахитов та, шул ук Николай Маркин да, грузчиктан атаклы галим булып җитешкән профессор Гыйлем Камай да, башка бик күпләр дә... Авторлар шушы олы идеяне тормышчан детальләрдә, гадәти ситуацияләрдә ачып бирәләр.

Китапның зур өлешен, табигый ки, Татарстанның Совет власте елларында яулаган казанышларын, экономика, культура

һәм кешеләрнең үсешен чагылдыра торган очерклар бирелгән.

Бу хактагы олы сүзне авторлар республикабызның нефть якларына сәяхәттән башлыйлар. Чөнки Татарстанның бүгенге индустриаль йөзен нефть промышленносте билгели. Мәгълүм булганча, безнең республикада 1971 елда скважиналардан бер миллиард тонна нефть алынды. Хәзер «кара алтын» осталары, ел саен 100 миллион тоннадан артыграк нефть биреп, бу тармакта ил буенча беренчелекне үз кулларында тоталар. Мондый могҗизаның сере нәрсәдә? Бу сорауга китапның «Нефть хәзинәсе» дигән бүлегеннән җавап табасың. Дөньяда моңарчы тиңдәше булмаган әлеге могҗизаның сере, әлбәттә, социалистик стройның куәтендә, өстенлегендә, партиянең һәм дәүләтнең милли республикалардагы җитештерүче көчләрне үстерү турында туктаусыз кайгыртуында. Икенче сер — илебездә яшәүче халыкларның бөек дуслыгы, олы эшләрне үзара ярдәмләшеп башкарулары. «Рәхмәт осталарга — украиннарга, әзербәйҗаннарга, башкорт күршеләргә,— диелә бу җәһәттән.— Алар уңайлы җылы урыннарыннан кубып, безнең Идел буйларына, Кама ярларына килеп, татар егетләрен нефть чыгару кебек зур һәм катлаулы эшләргә өйрәтеп киттеләр». Өйрәтү белән генә чикләнмәделәр, дип өстик үзебездән, аларның байтагы Татарстанны икенче туган йорты итеп торып калды, хәзер дә фидакарь хезмәт үрнәкләре күрсәтә. Әлеге китапта чагылдырылмаса да, тагын шуны әйтик: җир маен үзләштергәндә бөтен ил Татарстанга кадрлар белән генә түгел, җиһазлар, техника, хәзерге фән-техника казанышлары белән дә бар җәһәттән ярдәм күрсәтте. Өченче сер — һәрвакыт яңалыкка омтылучы төрле милләт нефтьчеләренең хезмәт батырлыгы, патриотлыгы. Менә бу серне ачып бирүгә авторлар аеруча игътибар итәләр һәм, әлбәттә инде, кеше язмышлары аша. Совет кешеләренең фидакарьлеге, патриот һәм интернационалист булулары атаклы нефтьчеләр, Социалистик Хезмәт Геройлары М. Гыймазов, К. Вәлиев һәм гади шофер П. Савин образлары аркылы ачыла.

Авторлар Татарстан хезмәт ияләренең интернациональ бурычларын үтәүләрен күрсәтеп бик дөрес эшлиләр. Бәйрәм ашы — кара-каршы дигәндәй, хәзер республикабыз нефтьчеләре илебезнең яңа «кара алтын» районнарында үз дусларын җир маен чыгару серләренә өйрәтәләр. Себердә, Маңгышлакта, Белоруссиядә промыселлар үсеп, ныгып бара — анда тоташ таныш фамилияләр: Тимченко — Себердә, бездә чыныккан егет, атаклы вышка төзү остасы; Дамир Нурисламов — Маңгышлакта скважиналар бораулый, бездә канат ныгыткан, искитмәле рекордлар куйган егет; Травин белән Чернозубов Лена буйларын, кембрий нефтен актаралар — шулай ук Татарстан нефте үстергән егетләр... Саный башласаң, дүрт йөзгә тула алар.

Татарстан нефте илебез чикләрен үтеп чыкты. Ул атаклы «Дуслык» трассасы аша тугандаш социалистик илләргә — Венгриягә, Германия Демократик Республикасына, Польша һәм Чехословакиягә ага. Әлеге үткәргеч — тарихта булмаган бөек дуслык, туганлык артериясе ул. Социализм илләре халыкларының: немец, поляк, чех, рус, украин, татарларның — төрле телләрдә сөйләшә һәм дуслык телендә аңлаша торган халыкларның иҗат җимеше. Социалистик дуслык илләре арасындагы интеграциянең бер күркәм күренеше булган «Дуслык» артериясе турында сөйләгәндә, авторларның аны капитал дөньясындагы «хезмәттәшлек»кә капма-каршы куюлары бик урынлы. Капитализм дөньясында бер илнең икенче илгә яхшы ният белән ярдәм кулы сузуы мөмкин булмаган хәл. «Ярдәм» дигәнең анда көчленең көчсезне кабалага эләктерүенә, монополистларның кесәсен калынайтуга хезмәт итә.

Безнең республика «кара алтын» белән генә дан тотмый, билгеле. Ул башка республикаларга электр энергиясе, төгәл приборлар, мех, химия продукциясе чыгара. «Татарстанда эшләнде» дигән маркалы товарларны дөньяның иң ерак базарларында, алтмыш төрле илдә очратырга була. Шагыйрь әйтмешли, «хәзер аңа дөнья базарында зур дәүләтләр бирә сәламен».

Ярты гасыр эчендә республиканың продукция җитештерүе 300 мәртәбә артты. Бүгенге Татарстан бер көн эчендә Казан губернасы ел буена җитештергән продукциямне бирә.

Татарстан — химия промышленносте олы адымнар белән үсеш алган төбәк. Шуңа күрәдер, зур химия гигантлары сәяхәт маршрутыннан читтә кала алмаган, әлбәттә. Китапта язылганча, Казан — илебездә «каучук плантацияләрен» булдырган, ягъни ясалма каучук җитештерүне үзләштергән дүртенче шәһәр. Германиядән, Америка Кушма Штатларыннан элегрәк үзләштергән ул аны. Безнең синтетик каучук заводыбыз

1936 елны эшкә кереште. Немецлар каучук житештерүне бездән бер елга соң, америкалылар икенче бөтен дөнья сугышы вакытында гына көйләп җибәрә алдылар. Татарстанның тагын бер данлы елъязмасы — химия биографиясе әнә шулай башланды. Хәзер Казан органик синтез заводы, Түбән Кама нефть химиясе комбинаты кебек гигантлар үсеп чыкты. Авторлар бу өлкәне тасвир иткәндә дә, кызыклы публицистик алымнар тапканнар. Мәсәлән, алар Аксак Тимергә бәйле риваятькә мөрәҗәгать иткәннәр. Җиңелмәс илбасар Әзербәйҗан җиренә поход белән бара. Әмма ул анда һәркайда янып торган утлардан өркеп качып китә. Мәңгелек ут үзәнендә зәңгәр газ янган икән. Аны җен чыгарган, имеш.

Авторлар нәкъ менә «җенне» куркуларе һәм тотып караулары турында язалар. Түбән Кама нефть химиясе комбинатында эшләнгән изопрен каучугы кисәге була бу. Гайрәтле Аксак Тимер куркып качкан мәңгелек уттан ясалган могҗиза. Азат хезмәт кешеләре әнә шулай куркыныч «җенне» кулга ияләштергәннәр. Тормышта явызлык түгел, мәкер түгел, кеше акылы, кеше хезмәте гел җиңә бара.

Республикабызга сәяхәт ясаганда ничек инде атаклы КамАЗны читләтеп үтәсең! Авторлар да аңа сугылып узганнар. Нәтиҗәдә, бу гигант төзелеш турында язма иҗат ителгән. Әлбәттә, республикабызның экономикасында һәм социаль тормышында гаять зур роль уйнаячак бу гигант хакында тәфсиллерәк сөйләргә бик кирәк иде. Күрәсең, китап язылганда материаллар җитәрлек булмаган.

Китапта шулай ук республикабыз промышленностеның бүтән тармакларына караган предприятиеләр турында да очерклар урнаштырылган. Алар арасында кетгут заводына багышланганы аерылып тора. Гадәттә, журналистлар теге яки бу продукцияне җитештерүнең технологиясенә сугылсалар, язмалар да гади укучы аңламастай катлаулы, коры һәм эчпошыргыч була. Әлеге очеркны укыгач, оста публицистлар технологиягә дә җан бирә алалар икән дигән тәэсир туа. Авторлар сарык эчәгеннән йөрәк тегә торган җепләрнең ничек эшләнүен мавыктыргыч итеп, укучының белемен арттыра торган итеп сурәтләп биргәннәр.

Татарстан, промышленность куәтле үскән республика булу белән бергә, мул ашлык, көр мал-туар төбәге дә. «Авыл сукмаклары буйлап» дигән бүлек республикабызның авыл хуҗалыгы үсешен күрсәтүгә багышланган. Авторлар, табигый ки, крестьян ирке өчен көрәшкә күтәрелгән чорларга, аларның батырларына да күз ташлаганнар. Алар, мәсәлән, Бездна вакыйгасен һәм Антон Петровны җанландырганнар.

Кеше алар истәлегенә ихтирам белән җир өстенә һәйкәлләр куя. Әмма һәйкәлләрнең иң яхшысы — һәлак булганнарның юлын дәвам иттерү. Антон Петровка иң зур һәйкәл — элекке Бездна авылы, хәзерге Антоновка. Кайчандыр атсыз мужик тилмергән җирдә үсеп чыккан совхоз. Мәңләгән крестьян гаиләсенең таза тормышы.

Андыйлар бер Антоновка гына түгел. Бәхет барлык авылларга да килде. Авторлар авылның бүгенге йөзен, аның кешеләренең рухи дөньясын күрсәтер өчен иң алга киткәнен дә яки артта калганын да түгел, ә «нык тәртип белән үргә күтәрелүче урта кул хуҗалык»ны — Әгерҗе районының Пушкин исемендәге колхозын алганнар һәм бүгенге көнгә хас үзгәрешләрне тасвир иткәннәр, шул нигездә гомумиләштерү ясаганнар.

Авторлар авылның киләчәгенә дә караш ташлаганнар. Киләчәк исә бүген туа. Шуның бер күркәм үрнәге булып Шәпше агрошәһәрчеге күтәрелеп килә. Катлы-катлы таш пулатлар, мәктәп, ашханә, көнкүреш йорты, балалар комбинаты... Хәер, Шәпше турында сөйләүнең хаҗәте юк, ул әлеге китапта тәэсирле сурәтләнгән. Шулай да авторлар, башта ук алган принципка турылыклы булып, аерым кешеләрнең образлары аша бүгенге колхозчы яки совхоз эшчесенең рухи дөньясын да ачып бирсәләр, сәяхәттән туган тәэсир тагын да тулырак булыр иде.

Китапның «Матурлык дөньясына сәяхәт» дип исемләнгән бүлегендә республикабызның культура өлкәсендәге уңышлары яктыртыла. Авторлар бу бүлеккә дә оригиналь алым тапканнар. Шартлы рәвештә контраст алымы дип атар идек без аны. Казан губернаторы М. В. Стрижевский 1912 елны язган бер хатында: «Россиядә, киң мәгънәсендә алганда, татарларның... үз культуралары юк һәм булуы мөмкин дә түгел»,— ди. Ләкин шул чорда халык шагыйре Г. Тукай: «Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйларына сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга... яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайрәләргә мохтаҗ»,— дип

язып чыга. Бу — ике дөнья бәхәсе. Авторлар нәкъ менә шушы олы бәхәснең кем файдасына хәл ителүен конкрет мисалларда, культура эшлеклеләренең язмышлары аша дәлиллиләр. «Бу карашларның кайсы дөрес, кайсы гадел һәм яшәргә хаклы икәнлеген революция ачыклап бирде»,— дип язалар авторлар. Татарстанда әдәбият гөрләп үсә, зур колачлы профессиональ музыка туа, рәссамнар яңадан-яңа әсәрләре белән халык алдында имтихан тоталар. Татарстан театрлары илебезнең иң ерак почмакларында тамашачының ихтирамын яулый баралар. Гомумиләштерелгән бу фикерләр Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое М. Җәлил, артистлар — Татарстанның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты И. Шакиров, республиканың атказанган артисткасы Р. Билалова язмышлары аша конкрет гәүдәләнеш таба. Алар — хезмәт кешеләре семьясында туып, совет чынбарлыгында әдәбият һәм сәнгать белән шөгыльләнергә, талантларының ачылып, үсеп китүенә мөмкинлек алган кешеләр. Аларның язмышы — сәнгатебез язмышы.

Сәяхәтне авторлар Татарстанның алтын туе тантанасында төгәллиләр. Бәйрәм зур, табын мул. Авторлар моның чыганагын ачып бирәләр. Бу — илебез халыкларының бер-берсенә дусларча, эчкерсез ярдәме нәтиҗәсе. Бу — Коммунистлар партиясенең, Совет дәүләтенең зирәк милли политикасы нәтиҗәсе. Бу — безгә бөек Ленин васыять итеп калдырганнарның чынга ашуы. Кырларда иген үстерәбезме, елгаларда саллар агызабызмы, химкомбинатлар төзибезме, җиде кат җир астыннан нефть чыгарабызмы — һәрвакыт дусларның кайгыртучан җылы кулын сизеп торабыз. Без күп милләтле, бертуганнардай тату, зур һәм дус семьяда яшибез. Шуңа күрә безнең эшләребез көннән-көн алга бара. Дуслык һәм туганлык хисе — совет халыкларының иң зур могҗизасы!

Г. Ахунов һәм М. Зарипов республикабызның бүгенгесен тасвир иткәндә буржуаз дөнья белән дә бәхәсләшеп алалар, аның әшәкелегенә совет чынбарлыгын каршы куялар. Андый чакта очерклар идеологик яктан үткенләнеп китә, казанышларыбыз янә дә калкурак күренә. Их, дип куясың андый урыннарны укыганда, авторлар ленинчыл милли политиканы фальсификацияләүче хәзерге буржуа ялчыларына да тәнкыйть утын юнәлдерсәләр, аларның «аргументлары»н сүтсәләр, ничек шәп буласы! Көнбатыштагы «советологлар» Татарстан адресына да бик күп пычрак яла яудыралар бит. Аларны фаш итә бару — ифрат кирәкле эш. Хәер, бу — әлеге китап авторларына гына түгел, башка публицистларга да кагыла.

Күрәсез, китапка ясалган искәрмәләр нигездә теләкләргә кайтып кала. Бу мавыктыргыч сәяхәтләрен тагын да дәвам иттерсеннәр, туган ягыбызның яңадан-яңа үзенчәлекләрен ачсыннар иде.

Ә хәзергә аларның сәяхәте тәмам. Инде китап үзе сәяхәткә чыгып китте. Аның да сәяхәт маршрутлары күп һәм мавыктыргыч. Бу очракта без авторларның «Без Казаннан, Иделдән» дигән исем белән «Тугандаш Россия семьясында» сериясендә «Советская Россия» нәшриятында русча дөнья күргән 30 мең тиражлы китабын да күздә тотабыз. Нигездә әлеге китаплар бер үк очерклардан төзелгән. Әмма аермалар да байтак. Мәскәүдә чыккан китапның Бөтенсоюз укучысына юлланган булуын исәпкә алсак, бу аңлашыла да.

Саф әдәби тел белән, үзенчәлекле публицистик алымнар кулланып язылган бу китапларның сәяхәте дә уңышлы узар. Ул укучыларда туган як өчен, янә дә шагыйрь сүзләрен кулланcак, «барлык-барлык парламентларда сөйләрдәй» горурлык хисен, туган илгә мәхәббәт тойгысын көчәйтергә ярдәм итәр, ә идеология фронты хезмәткәрләре өчен пропаганда һәм агитация эшендә файдалы кулланма булыр. Әлеге китапларның СССР төзелүнең 50 еллыгын бәйрәм итү алдыннан дөнья күрүе дә бик вакытлы.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ.**

# ДӨНЬЯМ КЫЗЫКСЫНДЫРСА...

Р. Харисның «Ак сөлге» исемле яңа җыентыгын[1] укып чыккач, андагы шигырьләрне элегрәк язганнары белән чагыштыра, янәшә куеп карый башладым. Шагыйрь тәүге әсәрләренә хас тотрыклы сыйфатларга, үз эчке табигатенә турылыклы кала алганмы? Бер күтәрелгән үрендә таптанмыймы? Йөрәк кылларын тибрәтә, укучыларны уйландыра алырлык шигырьләре күпме?

Икеләнми әйтергә була, шагыйрь яшьлегендә тапкан ачышларына, форма һәм калып өлкәсендәге тәҗрибәләренә турылыклы калган. Ул элеккечә үк тар мәйданда төгәлләнгән тыгыз фикер әйтергә омтыла, лирик парчалары кыска һәм җыйнаклар. Әйтерсең лә аңа берничә минутлык регламент бирелгән дә, ул, рәиснең каш җыеруын көтеп тормастан, шул вакыт аралыгында күңелендә туган фикерләрен әйтеп калырга ашыга. Тыгызлык, детальне сайлап ала белү һәм афористик яңгырашлы, күп сыйдырышлы нәтиҗәгә омтылу да шуның белән аңлатыла. Сөйләм теле интонациясеннән үсеп чыккан җөмләләр, ачык һәм кискен буяулар аның фикерләү рәвешенә тәңгәл килеп тора. Җыентык белән танышкач туган беренче тәэсирләр әнә шундый.

Инде «Ак сөлге»не авторның «Кайтаваз» исемле китабы белән башка еллардан чагыштыра башлагач, сыйфат үсеше дә күренә. Шагыйрьнең беренче китабында таркаулык, «йолкып алу», юлда очраган һәр теманы «йотып барырга» омтылу үзен нык сиздерсә, хәзер ул теманы, образны эзләпсайлап ала. Бер үк шәхескә, бер үк проблемага багышланган әсәрләрне циклларга, шигъри бәйләмнәргә җыйнау да шул хакта сөйли.

Җыентыктагы иң отышлы, «йөрәк кылларын тибрәтә» алырлык иң уңышлы әсәрләр туган илгә, аның ямьле-тәмле табигатенә, шул хозурлыкның, байлыкның бердәнбер хуҗасы булган кешене олылауга багышланган. «Дөньям кызыксындырса...», «Яфрак» исемле шигъри бәйләмнәр шундыйлар.

«Дөньям кызыксындырса...» дигән бәйләмнең исеме беренче карашка лирик геройның интим кичерешләре, мәхәббәт-сагышы, шатлык-кайгысы, кыскасы, рухи дөньясы турында сөйләүне вәгъдә итә, шуңа әзерли кебек. Ә шагыйрь исә сүзне Татарстанга, икмәккә, табигать ямен дан җырлаудан башлап китә. Алга таба лирик геройның интим дөньясы да өзелмәс җепләр аша шул изге төшенчәләргә барып тоташа:

> Син безне тудырдың, үстердең.
> Тик сиңа бурычлы мәңге без.
> Юк бит ул тагын бер синдәй җир —
> Язың — яз!
> Җәең — җәй!
> Көзең — көз!
>
> («*Татарстаным минем*»)

Шигырьдәге шәхси интонация публицистик ялкын белән кушыла, лирик геройның эчке кичерешләре киңәеп, иркенәеп китә, башка меңләгән шәхесләрнең сөенечкөенечләренә килеп кушыла.

Р. Харис туган илне публицистик аһәң ярдәмендә данлау белән генә чикләнми. Шигырьдән шигырьгә бу мәхәббәтнең конкрет эчтәлеге ачыла бара. Туган ил — иң олы һәм туры хаким, бөек һәм гали хакыйкать. Шагыйрь оптимизмының нигезен-

[1] Р. Харис. Ак сөлге. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1971 ел.

дә дә туган илнең мәңгелегенә ышаныч ята:

Җирдән туган нәрсә
Үтерә алмый Җирне.
Тамуг йоткан атом төше,
Барлык атом төшен тоткан кеше...
Барысы да,
Барысы да Җир баласы...

Җирдән туган нәрсә
Үтерә алмый Җирне —
Җиргә
Мәңге исән каласы!!!

*(«Ышаныч»)*

Берише әсәрләрендә шагыйрь туган илебезнең бүгенге халәтен чал тарих бизмәненә салып карый, дөресрәге, хәзергече үткән белән чагыштырып сурәтли. «Укыйм, җырлыйм...» исемле шигырьдә хәзерге төшенчәләрне тарихи ассоциацияләр аша гәүдәләндерүнең уңышлы алымы табылган. Шигырьдән күренгәнчә, «Татарстан» «дастан» сүзе белән рифмалашуга сорап тора икән. Дастан исә — халык тарихының шигъриләштерелгән елъязмасы. Аның үзәк герое — халык улы Алып батыр:

Уйлыйм:
— Дастан!
Күз алдыма
Алып батыр күтәрелә
Тарихтан, астан...

Һәр дәвер дастанны үзенчә үзгәртә, аңа үз хикмәтләрен өсти. Алып батырлар дастаны хәзер ни хәлендә? Аның дәвамы бармы? Бар икән:

Дәвамы аның Татарстан...
Татарстан — яңа дастан.

Шагыйрь кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт турында күп уйлана. Табигать образы аша кеше кичерешләрен тасвирлауга багышланган уңышлы шигырьләр китапта аз түгел: «Коела яшел яфрак...», «Яфракларың — гәрәбә...», «Җир — чәчәк»,— дигәч...», «Яктылык тәме», «Өянке» һ. б. Соңгысында, мәсәлән, яшәргә омтылыштан да көчлерәк хис юк дөньяда, ул үлемнән, вәхшилектән өстен дигән фәлсәфи фикер уздырыла. Шигырь ике планлы булуы, динамикалы сюжеты, психологик киңлеккә омтылуы белән дә үзенчәлекле. Шул ук темага тартылып торган «Яфрак» шигыре — Р. Харис поэзиясе өчен иң характерлы әсәр. Ул сәнгатьчә шартлылыкка, хыял итүгә корылган. Лирик герой олы дөньяны аның аерым кисәкләре, сызыклары аша таный. Хәер, бу әсәрдә тышкы эффектка да өлеш чыгарылган. «Агачта иң көчле нәрсә — иң көчкенә нәрсә. Ул — яфрак», ди шигыйрь. Алдарак бу метафорик силлогизмның мәгънәсе ачыклана төшә. Билгеле, яфрак тамырдан башка яши алмый. Шул ук вакытта, яфрак үсмәсә, тамырның да, кәүсәнең дә кыйммәте югала. Ахырдан автор бу чагыштыруны кеше тормышына күчерә: «Мин — яфрак. Тормышны мин агач итеп күрәм». Димәк, кеше табигатьнең яфрагы да, тамыры да булып чыга. Бу шигырьдән күренгәнчә, Р. Харис метафорага киң таяна. Шуннан башка ул, бәлки, шагыйрь булудан ук туктар иде. «Яфрак» шигыре «агач — күккә төбәлгән елга» дигән метафора белән башланып китә. Алдарак шагыйрь бу метафораның мәгънәсен ачыклый, аны җирдәге тереклек һәм кеше белән бәйли. Ш. Әхмәдуллин «Казан утлары» журналында басылган «Уйланырга кирәк...» исемле рецензиясендә әлеге метафора белән килешми. «Агач — күккә төбәлгән елга», дип эндәшүгә каршы гади укучылар керфек тә какмаячаклар», ди ул. Бәлки, бу метафора бик үк уңышлы түгелдер. Тик миңа рецензентның аргументы сәер тоелды. Кем ул «гади укучы»? Бары натуралистик сәнгатькә табынган примитив укучымы? Әллә башка кешеме? Бәлки, укучы, керфек кагаргамы, юкмы икән, дип уйланып тормастан, шигырьне тулысынча укып чыгар һәм төплерәк бәя бирер! Р. Харис әсәрнең эстетик ләззәтен бирьюлы ачып салмый. Ул укучысыннан баш ватуны, шигырьнең эченә үтүне, структурасына керүне, Ш. Әхмәдуллин әйткәнчә, уйлануны таләп итә.

Соңгы елларда поэзиянең халыкчан, милли нигезләре турында сөйләшүләр күп булды. Бирегә иң кыены — халыкчанлык белән милли бизәкләр, традицион образлар һәм борынгыдан килгән йолалар арасындагы дөрес мөнәсәбәт булдыру. Хәзерге поэзия аларны ничек һәм нинди күләмдә шигырьдә эретә ала? Р. Харис та бу мәсьәләгә җавап эзли. «Йола» шигырендә ул халкыбызның аңына һәм рухына сеңгән уңай йолаларны сакларга өнди:

Һәр яңа гаилә өешу
Йоланы яңадан яңарта.
Күрсен халыкның өмете
Һаман да яшидер аңарда.

Шагыйрь халык йоласын кеше күзенә артык чалынмаган гадәти детальләрдә эзли. «Чулпы», «Ак сөлге» шул юлда туган әсәрләр.

Ак сөлге — татар кешесенең даими юлдашы. Ул сабан туйларында, беләкләргә куәт биреп, билгә ята, яшьләрнең туен бизи, ир-егетләрне көрәшкә озатып җилферди, хәләл канны сөртә... Үзәк шигъри образ, үзенең шигъри һәм семантик функциясен һәръяклап ачып, олы фикергә алып килә:

Син бит үзең дә халкымның
Күңеле төсе —
Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.

Ак сөлге образы поэзиядә еш очрый. Ләкин бу традицион образга таянып, халык күңеле, халык характеры турында шундый зур фикергә алып килгән шигырьне мин хәтерләмим. Күренә ки, аерым детальләр аша гомумиләштерелгән фикергә алып килү юлында эзләнүләр кызыклы ачышларга китерергә мөмкин икән.

Җыентыкта татар халкының батыр улларына, тарихи шәхесләргә, поэзиябезнең якты йолдызларына багышланган әсәрләр дә әһәмиятле урын алган. Халкыбызның батыр улы һәм талантлы шагыйре Фатих Кәрим истәлегенә багышланган цикл кызыклы эшләнгән. Автор өлкән әдипнең иҗатына тулы бәя бирүгә дә, аның тормыш юлын ачыклауга да дәгъва итми. «Синең йөрәгең тибә...» циклында ул үзен һәм башка бик күпләрне борчыган ике сорауга җавап эзли. Беренчесен Фатих Кәримне каһарманлыкка һәм соңгы чиктә үлемсезлеккә алып килгән илаһи көчнең серен, чыганагын ачарга омтылу дияр идем. Бу проблема «Фатих Кәрим...» шигырендә куела:

Җәлил үлде...
Син...
Мулланур,
Үлде Шамил Усманов...
Беләм, беләм —
Үлеп була
Үлемнән өстен калып.

Үлемне идеаллаштыру юк биредә. Киресенчә, шагыйрь «ничек үләргә кирәген өйрәнергә килмәдем», ди. Героизм исә совет кешесе характерының эчке бер хасияте итеп карала. Ф. Кәримне үлемсезлек ярларына алып чыккан көч бу шигырьдә генә ачылып җитми әле. «Өченче ядрә» шигырен укыйбыз:

Үз тәнеңдә яра ярамыни?..
Сызлаулары бары үзеңә.
Кеше ярасыннан гомер буе
Сызлануга ничек түзәргә?

Кеше ярасыннан сызлануга ничек түзәргә? Бик гади һәм уңышлы әйтелгән. Бу юллар Ф. Кәримгә дә, авторның үзенә дә карый. Ике тапкыр яраланган Фатих Кәримне «кеше ярасы», ил ярасы өченче ядрәгә каршы атакага күтәрә дә инде. Бәйләмне бәйләм иткән икенче үзәк мотив — халыкны шундый олы йөрәкле улларыннан мәхрүм иткән иҗтимагый явызлыкны фаш итү, аны хурлык баганасына терәү. «Төкерәм мин бу дотларга...», «Кипарислар», «Юл буенда дотлар кала...», «Төш» шигырьләрендә автор, гуманизм һәм кешелеклелек байрагын югары күтәреп, фашизмга каршы көрәшә. «Төш» шигыре өстә аталган кардәшләреннән эчке егәре һәм символик юнәлеше белән аерылып тора. «Төш» шигырендәге кебек композиция Р. Харисның күпчелек әсәрләренә хас. Ул вакыйганы, образны, теге яки бу күренешне үстереп килә-килә дә, иң соңгы юлларда сюжет үсешенә көтелмәгәнрәк юнәлеш биреп куярга ярата. Шигырьләренең бетеме еш кына афористик яңгырашлы, төгәл һәм кискен була. Әйтик, «Төкерәм мин бу дотларга...» шигырендә ул дошман дотлары, үзенең аларга мөнәсәбәте турында сөйли дә, вакыйга-кичереш үсешен түбәндәгечә тәгәлләп куя:

Дошман дотыннан дошманның
Йөрәгенә атармын!

«Юл буенда дотлар кала...», «Аның кабере янында уйланулар», «Өченче ядрә» шигырьләренең дә композициясе шундый ук. Кыскасы, Р. Харис шигырьнең нигезе итеп тормыштагы гади фактны ала да, шуңа таянып, киңрәк йомгак ясарга, фактның фәлсәфәсен, сүлен «сыгып чыгарырга» омтыла.

Нәби Дәүли әдәби ел йомгакларына багышланган докладында Фатих Кәрим турындагы шигъри циклга уңай бәя бирде. Ләкин шул ук вакытта ул Р. Харисның Мулланур Вахитовка багышланган әсәрен «юкка чыгарып» ташлады. «Яшь шагыйрь Ренат Харисовның, яңа форма эзләп, каш куям дип күз чыгарган чаклары да булды,— диде докладчы. Бигрәк тә Мулланур Вахитов турында язылган шигырьләре ми-

һәм чәчләремне үрә торгызган иде». Чынында Н. Дәүли мактаган «Синең йөрәгең тибә...» шул ук «Мулланур» әсәреннән үсеп чыккан цикл. Шул ук күзәтүчәнлек, үзенчәлекле сюжет һәм шундый ук ачык метафора. Нәби Дәүлинең «Мулланур»ны кабул итмәвенең сере алдагы юлларда тулырак ачыла. Ул болай ди: «...Элегрәк елларда бер төркем яшьләр поэзиядә «новаторлык» белән шактый озак газапландылар. Аларның баскычлап та, «аткырылып-тоткырлап» та, «ак шигырь», «зәңгәр шигырь» итеп язган тәҗрибәләре еш күренгәләде». Бу бәхәс күптәннән килә. Биредә аңа кирәшеп торуның хаҗәте юк. Тик шуны гына искәртәсе килә: яшьләрне форма өлкәсендәге эзләнүләрдән тыярга, аларга үз эзләгыңны, үз тәҗрибәңне көчләп тагарга тырышу поэзияне баетмаячак. Эзләнүләр, экспериментлар аша үз юлын табарга тырышкан шагыйрьне ниндидер әзер калыпларга буйсындырырга тырышу поэзия үсеше өчен бигрәк тә зарарлы. Хәзер «шакмак-такмаклары» үз урынына куелган шома шигырь белән генә укучыны канәгатьләндереп булмый. Эчтәлек һәм тирәнлек таләп ителә.

Әлбәттә, Р. Харисның барлык язганнары да камил сәнгать әсәре дип уйларга ярамый. Мондый нәтиҗә таләпчән шагыйрь һәм тәнкыйтьче булган Ренатның үзенә дә көферлек булып тоелыр иде. Шәйхи Маннурның «Кеше, исәнме!» мәкаләсендә әйтелгән тәнкыйть сүзләрендә дә хаклык бар. Тик өлкән әдип безнең бүгенге поэзиягә, хәзерге кеше фикерләвенә хас үзенчәлекләрне исәпкә алмыйча, таррак аспекттан чыгып караш ташлый. Бу хәл яшьләр поэзиясен бер яклырак аңлауга алып килгән.

...Р. Харисның неологизмнарга, башка фәннәрдән алынган терминнарга мәхәббәте зур. Үтә яңачалык «Мин — галәм» поэмасын кабул итүне кыенлаштыра. Шул поэма үнае белән, шагыйрь иҗатына хас бер күренешкә игътибарны юнәлтәсе килә. Алдарак күргәнебезчә, аны тарих, батырлык үзенә җәлеп итә. Шагыйрь романтиканы һәм илһамына канат бирерлек идеал геройны эзләп еш кына үткәнгә борылып карый. «Мулланур», «Салават һәйкәле белән саубуллашу» (анда: «кеше булып калу белән алла була алу — бер» шикелле матур юллар бар) әсәрләре, Фатих Кәримгә багышланган шигъри бәйләм — моның ачык мисалы. Шуның янына Дәрдмәнд турындагы циклны да өстәп булыр иде. Тарихи образларга мөрәҗәгать итүдә, әлбәттә, бернинди зарарлы нәрсә юк. Киресенчә, ул мактаулы күренеш. Шулай да заман темасы — поэзиянең җаны дигән хакыйкатьне истән чыгарырга ярамый. «Мин — галәм» поэмасы чор темасына багышланган. Ләкин Ренат бу әсәрендә яшьләр поэзиясенә хас бер кимчелектән котыла алмаган. Бүгенге романтика турында сүз чыктымы, яшьләр шигъри телескопларын күккә юнәлтәләр. Поэзиянең йолдызстаны — кеше йөрәге, аның җирдәге тормышы, хезмәте читтә кала. Хикмәт темада гына да түгел. Р. Харис традицион темада да үз кыйбласын таба белә. «Мин — галәм» поэмасында исә кеше тонык чыккан. Каләменә риторика чүбе урала. Башка әсәрләрендә дә бүгенге заман кешесе сәнгатьчә камиллеге ягыннан тарихи шәхесләр белән ярыша алмый. Хәер, бу житешсезлек яшьләр поэзиясенә гомумән хас нәрсә. Олы эпик әсәрләрнең бөтенләй диярлек язылмавы да шул хакта сөйли. Замандашыбызның тулы канлы образын Р. Харис кебек өметле яшьләр тудырырга тиеш тә инде.

Теләсә нинди шагыйрь иҗатындагы шикелле, Р. Харис китабында тиешле ноктага тимичә «читкә» киткән әсәрләр дә бар. Минемчә, «Ике шагыйрь» әсәре Ф. Кәримнең портретына да, Шиллерның әдәби сурәтчәсенә дә яңалык өстәми. «Тисен, ди, ядрә йөрәккә...» исемле шигырьнең нигезенә салынган үз-үзеңне корбан итү идеясе белән дә килешүе кыен. Шагыйрь уенча, кеше үлемнән куркырга тиеш түгел, чөнки бөек идея исән кала. Батыр, бөек идеалларны, башкалар бәхетен яклап, һәлак булырга да мөмкин. Ләкин марксизм теләсә нинди «кешелекле идеядән», зур өмет һәм якты хыялдан Кешенең үзен югарырак бәяли. Алдынгы идея үзе кеше тормышына акыллы юнәлеш бирү максаты белән хәрәкәткә китерелә. Кеше һәм кешелек юкка чыккач, идеянең (ул нинди генә алдынгы һәм прогрессив булмасын) гамәли файдасы калмый. «Киң ачыйк» шигырендәге «җиде ят»ны күңелләрдә аунатырга («дусишләр дә, җиде ят та күңелләрнең болынында рәхәтләнеп аунасын») чакырган лозунг та соклану тойгысы уятмады. «Үкенү җыры», «Юлда» шигырьләрендә фрагментлык, фикернең хикмәтен ачып җиткермәү үзен сиздерә.

Күренә ки, Р. Харис һәр шигырендә дә ачыш ясамый. Ләкин аның күпчелек әсәрләрендә поэзия сулышы, эзләнү рухы, сәнгать эзе сизелә. Форма калыбы, иҗек

саны турында баш ватмыйча, эчтәлекнең табигый агышына ирек биргәндә ул кызыклы уңышларга юлыга. Р. Харис чорның динамикалы һәм омтылышлы хәрәкәтенә лаеклы шигъри юллар эзли. Ул — традицион бизмәннәргә сыешып бетми торганрак шагыйрь. Фразалары, үлчәүләргә баш бирмичә, «тырпаеп» тора, прозаизмнары халык җырының музыкаль иҗегендә тәрбияләнгән колакны тырнап уза. Моның сәбәбе ачык: шагыйрь, ритмика гармониясеннән бигрәк, фикер гармониясенә омтыла. Фикер гармониясе логик эзлеклелекне, эзмә-эз үсешне таләп итә. Логика алга чыккан очракларда хис кыерсытыла, шигырь мәкаль-әйтем дидактикасына тартыла. Менә шул төр поэзиянең бер үрнәге:

Кылыч тотар өчен
Кирәк Алып көче.

Байрак тотар өчен
Кирәк халык көче!

Кылыч җиңсен өчен
Кирәк хаклык көче.

Байрак җиңсен өчен
Кирәк пакьлек көче!

(*«Кылыч тотар өчен...»*)

Р. Харис иҗаты турында тәнкыйть сүзе күп әйтелә. Фикерләр төрле. Берәүләр аны хискә караганда фәлсәфи фикергә өстенлек бирүче салкын, рационалист, дидактик шагыйрь, диләр (мәсәлән, Шәйхи Маннур), икенчеләре аны катлаулы язуда, шигъри дисциплинаны бозуда гаеплиләр (Нәби Дәүли), өченчеләре «гади укучы» белән эркетәләр (Ш. Әхмәдуллин), дүртенчеләре аның шигырьләрендә Дәрдмәндне кабатлау табалар (К. Латыйп), бишенчеләре шагыйрь иҗатында татар поэзиясенең матур традицияләренең яңача үсешен, эволюциясен күрәләр (Сибгат Хәким) һ. б. Кыскасы, берәүләр аның шигъри тәҗрибәләренә югары бәя бирәләр, икенчеләре бөтенләй кабул итмиләр. Шунысы кызыклы, офыкта битарафлар бөтенләй күренми. Ул барысын да уйландыра, шатландыра яисә «чәчләрен үрә торгыза». Шагыйрь өчен бу күңелле нәрсә. «Ак сөлге» китабын да «салкын каты», битараф хис белән укучылар булмас дип уйлыйм.

**ТӘЛГАТ ГАЛИУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

**Нурихан Фәттах**

# ТАРИХ БИТЛӘРЕН АКТАРГАНДА

«Әтил суы ака торур» романы басылып чыккач та редакциягә һәм шулай ук минем үз исемемә укучылардан хатлар килә башлады. Элекке тәҗрибәдән чыгып шуны әйтергә була: мондый хатларны күбесенчә яшьләр яза. Аларны гадәттә әдәби әсәрдәге теге-бу геройның соңгы язмышы кызыксындыра. Укучылар: фәлән кыз белән фәлән егет кавыштылар микән, фәлән кеше бүгенге көндә кайда яши икән? кебегрәк сораулар биреп, авторны еш кына аптырашта калдыралар.

Бу юлы миңа андый хатлар килмәде. Бу юлы килгән хат авторларының күпчелеген романдагы аерым геройларның язмышы түгел, бәлки башка нәрсә — халкыбызның бай тарихы һәм шул тарихның романда ничек чагылуы мәсьәләсе кызыксындыра. Укучылар татар халкының борынгы тарихына нигезләнеп язылган әсәр тууына үзләренең сөенечләрен белдерәләр, татар әдәбиятына, татар язучыларына зур иҗади уңыш телиләр. Бу бигрәк тә Уфадан язган Р. С. Якупов, Ульяновск өлкәсе, Малыклы районы, Сантимер авылыннан язган Шәфигуллин Сәлим, Татарстанның Столбище авылыннан язган З. Х. Гайнетдинов иптәшләрнең хатларында ачык чагыла.

Укучы хатлары арасында башкачарак эчтәлеклеләре дә очрый. Ташкентта яшәүче Мидхәт Якупов, мәсәлән, романны укыганнан соң туган тәэсирләрен, уй-фикерләрен уртаклашу белән генә чикләнми, бәлки әсәрдә сурәтләнгән чорга, геройларга тарихи яктан кызыклы гына күзәтүләр дә ясый. Хатның һәрбер сүзендә, һәрбер юлында Мидхәт Якупов иптәшнең борынгы тарихны, аерым алганда төрки халыклар тарихын, яхшы ук тирән белүе сизелеп тора.

Ә менә икенче бер иптәш — Шиһапов Разак — романга карата хат кына да түгел, утыз бер биттән торган бөтен бер рецензия язып җибәргән! Шиһапов Разак Татарстанның Шөгер авылында яши. Үзе язганча, ул «гади колхозчы, Ватан сугышы инвалиды». Шиһапов иптәш үзенең рецензиясендә романдагы теге-бу детальнең тарихи фактларга туры килүе-килмәвенә игътибар итә. Эзләнә торгач ул үзенчә күп кенә хаталар, төгәлсезлекләр таба. Ләкин, әйтергә кирәк, Шиһапов иптәшнең тарихи мәгълүматлары берьяклырак. Тарих турында фикер йөрткәндә ул үзе дә шактый хаталар, төгәлсезлекләр җибәрә. Мәсәлән, Алмыш ханның мең кеше сыйдырышлы тирмәсе булуына Шиһапов Разак иптәш шик белдерә. «...Бу очракта... тирмәнең кеше ышанмаслык зур булуы дөреслеккә дә туры килми. Яңа Казан циркы зурлыгындагы тирмә төзү өчен Алмыш ханга хәзерге заман күтәрү краннары кирәк булыр иде», дип яза рецензент үзенең хатында.

Мондый сүзләрне язудан элек, Шиһапов иптәш ибне Фазланның юл язмаларын җентекләп карап чыкса, әлбәттә, яхшы булыр иде. Ни өчен дигәндә, гарәп битекчесе язмаларында ачыктан-ачык: мең кеше сыйдырышлы, диелгән. Әллә соң ибне Фазлан ялгышты яисә ялганлады микән? Юк, ялганламас та, ялгышмас та. Ибне Фазланга фәндә ышаныч бик зур. Ибче Фазлан язмаларында гына түгел, башка чыганакларда да элекке замандагы зур-зур тирмәләр турында мәгълүматлар сакланып калган. Гомумән, хан тирмәләренең бик зур булуы тарихчылар арасында бәхәс тудырмый, ягъни бу — исбат ителгән мәсьәлә. Иптәш Шиһаповның менә шундыйрак башка тәнкыйть фикерләренә дә җавап биреп булган булыр иде, ләкин, урын тарлыктан, сүзне озынга җибәрәсем килми.

Миңа килгән укучы хатлары арасында берсе аерым игътибарга лаек. Бу хатны Казан дәүләт университеты студентлары язган. Егерме кеше исеменнән хатка Җ. Әхметова, Г. Моратов, Т. Госманова, Р. Фәизов, М. Хәйруллин, З. Ибраһимова, Р. Рамазанова иптәшләр кул куйганнар. Хат

авторлары берничә сорау белән мөрәҗәгать иткәннәр. Хәзер мин студентларның шул сорауларына җавап бирергә тырышып карыйм.

**Беренче сорауларында** укучылар «романны язарга рухландырган беренче этәргеч» белән кызыксыналар.

«Беренче этәргеч» турында мин озак кына баш ваттым, үткән көннәрне искә төшереп карадым, ләкин шулай да бу «беренче этәргеч»не ачык кына итеп күз алдына китерә алмадым. «Этәргеч»ләр күп булды кебек. Шуларның берсе, әлбәттә, китап булгандыр. Хәзерге заман темасына язучыга барыннан да элек бүгенге тормыш тәэсир итсә, тарихи темага язучыга китап, язма әдәбият тәэсир итә дисәк, ялгыш булмас дип уйлыйм. Тарих бит ул үзе китап. Йөз еллык, мең еллык тарихлар — төрле халыкларның үткәннәре йөз битлек, мең битлек китапларга тупланган, һәм алар, ягъни «тарихлар» шул катлам-катлам кәгазь «кирпеч»ләрдә буыннардан буыннарга ирешә баралар.

Ләкин алдан ук искәртеп куясы килә: мин беркайчан да тарихи романнар уку белән мавыкмадым һәм тарихка мәхәббәт уянуда тарихи романнарның бернинди роле булмады диярга мөмкин. Миңа бик нык тәэсир иткән беренче тарихи китап «Кабус намә» булды, ахрысы. «Кабус намә» XI гасырда яшәгән чын кешенең чын язмалары. Икенче китап итеп мин Усама ибне Мункызның «Үгет-нәсихәт китабы»н («Книга назидания») күрсәтә алам. Усама ибне Мункыз, Сүрия гарәбе, тәре сугышлары вакытында яшәгән, бик күп сугышларда катнашкан, күп батырлыклар күрсәткән һәм менә шуларның барысы турында үзенең хикәяләрен язып калдырган. Мункыз китабында төркиләр турында да күп кенә гүзәл язмалар бар.

Миндә тарихи әсәр язу теләге тудырган өченче китап итеп «Исландия сагалары»н атап әйтәсем килә. Исландиянең борынгы төркиләргә берниңди катнашы юк диярга була, һәм «сага»ларда тасвирланган тормыш, гореф-гадәтләр дә күчмә төркиләр яисә гарәпләр, фарсылар тормышына бөтенләй охшамаган. Ләкин бу «сага»ларның һәм югарыда телгә алынган тарихи язмаларның бер уртаклыгы бар, ул да булса — реализм.

Әйтәсе килгәнем шул: миңа үткән заманның үз кешеләре язып калдырган чын фактлар, чын вакыйгалар «беренче этәргеч»ләрнең берсе булды.

Бу урында мин атаклы ибне Фазлан язмаларын укуымны һәм үземнең 1957 елда Болгар хәрабәләрен казуда катнашуымны да искә алмасам, «беренче этәргеч»ләр мәсьәләсе тулы булмас дип уйлыйм. Ибнә Фазлан язмаларын уку, өйрәнү, ятлау һәм җирдән казып алынган болгар әйберләрен — гап-гади чүлмәк ватыкларын, кирпечләрне, чуен, бакыр, тимер калдыкларын үз кулларың белән тотып карау — болар барысы да, әлбәттә, беренче, иң беренче этәргечләр булгандыр. Болары күреп, тотып була торган «этәргеч»ләр. Ләкин «этәргечләр»нең күреп, тотып булмый торганы да бар. Анысы — мәхәббәт. Туган халкыма, туган телемә, культурама чиксез мәхәббәт тойгысы. Бу тойгы булмаганда гомумән бер нәрсә дә иҗат итеп булмый. Бу тойгы беренче дә, икенче дә түгел, ул — төп этәргеч, даими этәргеч.

**Икенче сорау:** «Әсәрне язганда нинди чыганаклар ярдәм итте?»

Иң беренче чыганак әлбәттә, ибне Фазлан язмалары булды. Моннан тыш борынгы Болгарга, аның күршеләренә караган башка хезмәтләр белән танышып чыктым. Тарихи әсәрләрне өйрәнү өстенә, билгеле, телгә, әдәбиятка, фольклорга, сәнгатькә караган хезмәтләргә дә күз ташларга туры килде.

Тарихи романнарны язганда борынгы үткәнебезгә нинди күз белән карау бик тә мөһим. Бу очракта безгә, совет язучыларына, марксизм-ленинизм тәгълиматы ярдәм итә.

**Өченче сорау:** «Сезнеңчә, татар тарихына багышланган кыйммәтле гыйльми хезмәт кем тарафыннан язылган һәм ул нинди хезмәт?»

Татар тарихына, төрки халыклар тарихына багышланган хезмәтләр чиксез күп. Төркиләр тарихын өйрәнү тарихы үзе генә дә кимендә ике гасырны эченә ала. Бездә, мәсәлән, төрки халыкларның тарихын, телен, әдәбиятын тикшерү белән шөгыльләнә торган дистәләрчә фәнни үзәкләр эшли. Мәскәүдә, Ленинградта һәм башка шәһәрләрдә ел саен төрки халыклар тарихына багышланган фәнни хезмәтләр чыга. Безнең илнең галимнәре исә төрки халыкларны өйрәнүнең иң алдынгы сафында булдылар һәм бүген дә беренчелек, һичшиксез, совет фәне кулында. Монда бөтен дөньяга атаклы В. В. Радлов белән В. В. Бартольдны искә төшерү дә җитә.

Тюркология шулай ук башка илләрдә дә шактый алга киткән. Германия, Төркия, Англия, Франция, Польша, Финляндия, Венгрия, Дания, Австрия, Америка, Япония һәм башка ил галимнәре дә төркиләрнең (димәк, татарларның да) үткәне турындагы фәнгә зур өлеш керттеләр. Мәсәлән, тиңдәшсез ибне Фазлан язмаларын табуда, фәнни тәрҗемә итүдә, аңлатуда, таратуда руслар, немецлар, инглизләр, французлар, еврейләр, гарәпләр, ираннар, терекләр, татарлар һ. б. бик күпләр катнашкан.

Күрәсез, «татар халкы тарихына багышланган кыйммәтле гыйльми хезмәтнең» кайсын булса да берсен аерып күрсәтү бик кыен.

Соңгы елларда басылып чыккан һәм турыдан-туры безгә караган хезмәтләрдән М. Г. Сәфәргалиевнең «Распад Золотой Орды» («Алтын Урданың таркалуы»), Һ. В. Юсуповның «Введение в болгаро-татарскую эпиграфику» («Болгар-татар эпиграфикасына кереш»), А. Х. Халиковның В. Ф. Генинг белән бергә язган «Ранние болгары на Волге» («Идел буендагы беренче болгарлар») дип аталган хезмәтләрен күрсәтеп китәргә була. Казан галимнәре тарафыннан язылган һәм 1967 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» («Урта Идел һәм Урал буе татарлары») диган хезмәт аеруча

игътибарга лаек. Татар халкының тарихына, этнографиясенә, фольклорына, сәнгатенә багышланган бу энциклопедик хезмәт моңарчы басылган башка җыентыклардан бик нык аерылып тора. Бу Казан Тел-әдәбият һәм тарих институтының соңгы еллардагы зур казанышы, тик шунысы кызганыч, әлегә кадәр бу кыйммәтле китап татарча чыкмаган.

**Дүртенче сорау:** «Татар халкының тагын кайсы сәхифәләре әдәби гәүдәләндерүне көтә?»

Бу турыда мин күп итеп, озын итеп сөйли алыр идем. Татар әдәбияты өчен татар тарихы ул беркем аягы басмаган иксез-чиксез карурман кебек. Дөрес, бу карурманга аяк басарга тырышып караучылар булмады түгел, һәм минем әлеге романым да шул тырышып карауның бер мисалы булып тора. Тик шулай да мондый берән-сәрән әсәрләр генә безне, әлбәттә, канәгатьләндерә алмый. Безгә чын-чынлап тарихи роман жанрын тудырырга кирәк. Моның өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Бүгеннән алып берьюлы унлап язучы бары тарихи жанрда гына яза башласа да, беркайчан да бездә тема һәм материал кытлыгы булмас иде. Менә шундый бай ул татар тарихы, төркиләр тарихы!

Татар тарихы дигәндә мин хәзерге Татарстан территориясендә яшәгән татарларның үткәнен генә күз алдына китермим. Татарларның, казакъ, үзбәкләрнең, кыргыз, башкорт, төркмән, кумык һәм башка төркиләрнең борынгы тарихы һәм культура байлыклары күп очракта уртак. Бу уртаклык кайчандыр күчмә булган һәм төрле тарихи шартларда үзара аралашып беткән төрки халыклар тарихының бер үзенчәлеге булып тора.

Мәсьәләгә менә шул күзлектән караганда, татар халкының тарихы, әйтик, Болгар яисә Казан тирәсе белән генә чикләнми. Бик борынгы гуннарның да, Алтай төрекләренең дә, хазарларның, угызларның, бәҗәнәкләрнең дә бүгенге татарга күпмедер катнашы бар. Борынгы болгарлар, кыпчаклар исә турыдан-туры безнең бабаларыбыз булып исәпләнелә. Ләкин шул ук вакытта алар безнең генә бабаларыбыз да түгел. Димәк, тарихка мөрәҗәгать иткәндә, боларның барысын да истә тотарга кирәк.

Шулай да тарихның кайсы сәхифәләре әдәбиятта яктыртылуны көтеп ята соң? Минемчә, монда тәртеп күрсәтү урынсыз булыр иде. Язучыны кайсы чор, кайсы вакыйга, кайсы факт рухландыра, ул шуның турында яза ала. Әйтик, әлеге ибне Фазлан язмаларына нигезләнеп, Болгар турында яңадан өч-дүрт роман язарга мөмкин. Яисә шул ук болгарларның монгол яуларына каршы сугышларын искә төшерегез. Дөрес, бу хакта материал күп сакланмаган, ләкин гомумән монгол яулары турында ярдәмче әдәбиятның исәбе-хисабы юк. Мәсәлән, шул чорның атаклы шәхесе Бачман үзе генә ни тора! Монголларга баш имәгән һәм илбасарларга каршы туктаусыз көрәш алып барган бу кыпчак батыры турында гарәп, фарсы тарихчылары гына түгел, Иделдән әллә кайда ерактагы кытайлар да бик яхшы белгәннәр һәм менә шул белгәннәрен үзләренең тарих китапларына теркәп калдырганнар. Бүгенге көндә Бачман безнең тарихи романнарның, сәхнә әсәрләренең, сынлы сәнгатьнең иң яраткан героена әверелсә, бик яхшы булыр иде.

Яки менә исемнәре тарихта сакланып калган башка шәхесләрне — Колгалине, Сәйф Сараины, Мөхәммәдъярны алыгыз. Тарихи романнарга лаеклы кешеләр түгелмени болар? Әлбәттә, лаеклы! Тик аларны тарихи әсәр геройлары итеп сурәтләү өчен язучыдан кыюлык, тәвәккәллек һәм тирән белем сорала.

**Бишенче сорау:** «Романны язганда нинди кыенлыклар кичердегез?»

Романны язганда кыенлык кына түгел, чын-чынлап тәмуг газаплары кичерергә туры килде. Ләкин минем хәзер ул турыда сүз кузгатасым килми, аннары ул иҗат газаплары турында бер-ике сүз белән сөйләп тә булмый. Кичергән газапларның, кыенлыкларның кайберләрен бары искә төшереп китәргә генә мөмкин.

Язган вакытта миңа дәими рәвештә диярлек белемсезлек кыенлыгын татырга туры килде. Еш кына иң гади нәрсәдә каләмем төртелеп туктап калды дә, шул «гади» нәрсәнең төбенә төшәргә тырышып, китаплар актарырга кирәк булды. Мәсәлән, болгарларда һәм гомумән төркиләрдә байрак булуы мәгълүм нәрсә. Ләкин ул байраклар нинди төстә, нинди формада булган соң? Миңа бит «байрак» дип кенә котылырга ярамый, миңа аның төсен, рәвешен сурәтләргә кирәк. Укыган китапларда мин бу хакта берни очратмадым. Таныш белгечләрдән сораштыру да нәтиҗә бирмәде. Дөрес, монголларның ап байрагы, Мисыр мәмлүкләренең (кыпчакларның) яшел байрагы хакында мин болай да белә идем. Әмма борынгы болгарлар өчен ап, яшел төсләрнең туры килүен-килмәвен мин берничек тә хәл итә алмадым. Төрки халыкларда байрак һәм штандарт мәсьәләсенә багышланган махсус мәкаләне миңа бары роман журналда басылып чыккач кына укырга туры килде.

Моннан тыш тел мәсьәләсен алып карыйк. Минем өчен бу, ягъни тел мәсьәләсе, иң кыеннарның кыены булды. Мин болай фикер йөрттем: әсәрдә вакыйга 920 елларда бара. Димәк, бу чорда болгарлар әле гарәпләр белән дә, фарсылар белән дә ныклап аралашмаганнар. Димәк, болгарларның теле чагыштырмача саф төрки булырга тиеш. Болгар теле төркинең ниндирәге булгандыр — хәзерге чувашныкы кебегеме, әллә башкасымы — мәсьәлә анда түгел. Төп мәсьәлә шунда: болгар теле — төрки, төркинең дә гарәп-фарсы белән чупләнмәгәне. Шулай булгач, чорны дөрес итеп күз алдына бастыру өчен мин дә шундый чупләнмәгән төрки белән язарга тиеш түгелмени?!

Ләкин бүгенге әдәби тел байлыгы яисә минем үз тел байлыгым ярдәмендә генә мондый эшне башкарып чыгу мөмкин түгел. Монда инде миңа борынгы төрки тел-

не һәм шулай ук хәзерге заман төрки телләрне өйрәнүдән башка чара калмады. Әйтергә кирәк, ул вакытта әле «Древнетюркский словарь» («Борынгы төрки телләр сүзлеге») чыкмаган иде, һәм мин бер ел буе диярлек В. В. Радловның сигез китаптан торган «Төрки телләр сүзлеге»н, Мәхмүд Кашгари сүзлеген, С. Е. Малов һ. б. сүзлекләрен, башка әдәби-тарихи чыганакларны күздән кичердем. Алай гына да түгел, аерым темалар буенча (әйтик, төзелеш, административ, хәрби, медицина, мифология һ. б. буенча) үзем өчен мин кечкенә-кечкенә махсус сүзлекләр төзедем. Һәм шул ук вакытта мин галимнәр «библиографик аппарат» дип атый торган нәрсә дә булдырдым.

**Алтынчы сорауларында** студентлар роман авторының иҗат планнары белән кызыксыналар.

Мин үземнең яза торган яисә язылачак әсәрләрем турында алдан шауларга яратмыйм. Газета-журнал битләрендә: фәлән вакытка фәлән нәрсә тәгәллим, дип алдан әйтеп куюу ул меңләгән укучылар алдында, халык алдында вәгъдә бирү белән бер. Ә бит вәгъдә биргәч, һичшиксез, аны үтәргә кирәк!

Шулай да мин ул сорауга да җавап бирергә тиешмен. Иҗат планнарым минем бик зур. Киләчәктә дә мин төрки халыкларның, аеруча үз халкымның, төрле чор тарихын өйрәнүгә багышларга уйлыйм. Өйрәнгәч, әлбәттә, романнар язармын дип өметләнәм.

Болгар турындагы беренче романнан соң мин гуннар белән җенләнә башладым.

Тарихта төрки халыклар турында булган иң беренче чыганаклар менә шул гуннарга карый. Шулай итеп, мин үземнең киләчәк әсәремдә төрки халыкларның документлар белән расланган иң беренче тарихи чорын күрсәтергә уйлыйм. Бу инде Болгар да, Казан ханлыгы да, Алтын Урда да түгел. Болары — монда, үз җиребездә; вакыт арасы да якын. Мин тасвирлаячак гуннар исә миңа таныш булмаган территориядә моннан ике мең ике йөз еллар элек яшәгәннәр. Күршеләре — борынгы кытайлар, монгол, маньчжурлар, иран халыклары, кыпчаклар, кыргызлар... Малчылык белән шөгыльләнүче күчмә халык. Ярым кыргый, сугышчан халык. Нәкъ Бөек Кытай стенасы салынган еллар. Цянь империясенең таркалуы, Хань империясе белән гуннарның, я үләм, я калам дип, канга батып сугышкан еллары. Гуннарның атаклы юлбашчысы (кытайча) Модэ Шаньюйның рәхимсез көрәштә җиңеп чыккан һәм үз халкын мәңге үлемнән, эзсез югалудан саклап калган еллары...

Әйе, безнең халыкның бик ерак тамырлары менә шул канлы елларга барып тоташкан.

Искиткеч кызык тема. Төн йокыларын калдыра торган, материалның ифрат дәрәҗәдә катлаулы, ят һәм авыр булуын да онытгыра торган тема.

Хәзергә мин бары менә шуларны гына әйтә алам. Тагын шунысын да әйтергә була: роман «Сызгыра торган уклар» дип аталачак (исеме бар!). Сызгыра алырмы ул, юкмы һәм кайчан сызгырып җибәрер — анысын әлегә үзем дә белмим.

## Колхөсәен Хөсәен оглы

# ХИКӘЯЛӘР

*(«Нәни дусларга» циклыннан)*

## Тыныч йокла балам



Әнкәй, әнкәй дим, син йокламыйсыңмыни әле?

— Юк әле, кызым, минә дәфтәрләр тикшерәсем бар.

— Иртәгә тикшерсәң ярамыймыни? Минем үземә генә йоклавы күңелсез. Син дә ят.

— Юк әле, кызым, ята алмыйм. Дәфтәрләрне бүген тикшерергә тиешмен. Иртәгә аларны балаларга кайтарам — нинди билгеләр алганлыкларын күрсеннәр.

— Алайса, хәерле төн, әнкәй.

— Тыныч йокла, балам.

Кыз башын мендәргә салды, йокылы күзләре белән озак кына әнисенә карап ятты. Әнисе башын дәфтәрләр өстенә игән, күзләре дәфтәрдәге саннар өстендә йөреп тора.

* * *

— Әнкәй, әнкәй дим!

— Нәрсә бар, кызым? Миңа комачаулыйсың син!.. Я, я, ярый, иренеңне турсайтма. Ни кирәк?

— Әнкәй, син үзеңнең укучыларыңа икеле куясыңмы?

— Куйгалыйм.

— Мин синең беркемгә дә икеле куймавыңны телим.

— Икеле кую миңа гына бәйле түгел бит ул.

— Тагы кемгә бәйле?

— Укучының үзенә, белеменә бәйле.

— Юк инде, әнкәй, син икеле куймаска сүз бир. Бирәсеңме?

— Яхшы, кызым. Йокла инде... Сиңа йокларга вакыт...

— Ярый, әнкәй, хәерле төн!

— Тыныч йокла, балам!

* * *

— Әнкәй, син ятмадыңмыни әле?

— Юк әле, кызым. Ә син ник уяндың?.. Күзеңә якты төшәме әллә?

— Юк, әнкәй! Мин синең дә ятканыңны көтәм.

— Мин әле дәфтәрләрнең яртысын гына тикшердем.

— Кая, карыйм әле,— дип, кыз кәҗә бәтие кебек тып итеп идәнгә сикереп төште дә әнисе янына килде. Дәфтәр битенә күз салды. Кызыл кара белән куелган «2» не күреп, иренен турсайтты.

— Икеле куймаска сүз биргән идең бит?!

— Кызым, бу эшкә «2»дән дә артык билге куеп булмый.

— Хәзер инде ул бала нишләячәк? Җылаячакмы? Әти-әнисе аны ачуланачак, иптәшләре алдында аңа оят булачак.

— Менә кара, кызым. Мин аның бөтен ялгышын төзәттем. Ул бүтән икеле алмасын өчен мин аның белән дәрестән соң өстәмә рәвештә шөгыльләнәчәкмен. Я, бар инде, ят, йокла.

Кыз теләр-теләмәс кенә урынына барып ятты.

— Әнкәй, миңа мәктәпкә барырга тагы алты ай да уникe көн калдымы әле?

— Әйе, кызым, йокла инде

— Мин укырга кергәч бер дә «икеле» алмам, яме.

— Әлбәттә, кызым. Син бишкә генә укырга тиешсең.

— Аннары...— дип кыз сүзен башлады да тотлыгып калды, шикләнебрәк әнисенә карады.— Әнкәй, сиңа бер нәрсә әйтсәм, миннән көлмәссеңме?

— Юк, кызым, көлмәм.

— Әтиең белән ант итәм диген.

— Әтиең белән ант итәм,— диде әнисе, елмаеп.

— Мин синең кебек укытучы булгач, беркемгә дә «икеле» куймам, яме.

— Бик әйбәт, кызым. Укучыларың гел яхшыга гына укысыннар, «икеле» куярга туры килмәсен сиңа.

— Әһе. Хәерле төн, әнкәй!

— Тыныч йокла, балам!..

## Егетләрчә...



Бир дим, бир!..

— Бирмим!

— Алайса, талап алам. Сорагач та кире кайтарам дип сүз биргәнеңне оныттыңмы? Егетләрчә сүз бирдең.

— Егетләрчә сүз бирмәдем мин.

— Бирдең, егетләрчә, дидең.

— Димәдем!

— Кемгә әйтәм мин: бир! — дип, җиде яшьлек Орхан ачуы килеп, үзеннән ике яшь ярымга кече энесе Илшатка ташланды.

Илшат, әлбәттә, эшнең болай буласын белә иде. Ул учындагы кургаш солдатны тагы да ныграк кыса төшеп, Орхан кулыннан ычкынырга тырышты. Тик озак карышырга көче җитмәде. Орхан Илшатны идәнгә егып, өстенә менеп атланды да аның учын каерып ачарга кереште. Шул вакыт Илшат чырылдап кычкырып җибәрде. Әти-әнисе килеп якласын дип, кыенга килгән чакларда аның шулай кычкыра торган гадәте бар.

Янәшә бүлмәнең ишеге ачык иде. Ризван малайларының тарткалашуларын ишетеп торды. Кечкенәсенең чырылдаган тавышы ишетелгәч, түзмәде.

— Хәзер үк икегез дә минем янга килегез, тиз булыгыз! — дип кычкырды.

Орхан, теләмәсә дә, Илшатны ычкындырып, торып басты һәм курка-курка гына әтисе янына китте.

— Ә Илшат әфәнде нигә килми?

Орхан:

— Белмим,— дип җилкәсен сикертте.

Күрше бүлмәдән Илшатның:

— Киләм мин, әти, киләм! — дигәне ишетелде.

Чайкала-чайкала, ишектән Илшат килеп керде. Орханнан бер читкәрәк барып басты да зур кара күзләрен әтисенә төбәде. Уң кулын ул һаман да йомарлаган, теге кургаш солдатны абыйсына бирергә җыенмавы күренеп тора иде.

— Нәрсә өчен талаштыгыз сез анда? — дип, кырыс кына тавыш белән сорады әтиләре.

Орхан:

— Әти, беләсеңме, ул...— дип әйтә башлаган иде, әтисе:

— Беләм, барысын да ишетеп тордым,— дип, аның сүзен бүлде. Илшатка таба борылып: — Бу ни хәл, тагы хәрәмләшә башладыңмы? — диде.

— Юк,— диде Илшат кыюсыз гына.

— Ничек «юк»? Син егетләрчә сүз биргәнсең бит.

— Мин егетләрчә сүз бирмәдем! — дип әйтеп салды Илшат.

— Ничек дип сүз бирдең соң?

— Болай гына.

Ризван көлеп җибәрүдән көчкә тыелып калды. Орхан янә энесеннән зарланырга керешге. Әтисе аны тынычландырып, Илшатка:

— Ярый алайса, син хәзер миңа — ир кешегә ир кеше буларак әйт: абыеңнан уенчыкны алганда ничек дип сүз бирдең?

Илшат башта елмаеп куйды, аннары кызарынды, шулай да җавап бирмәде. Аның елтырап торган хәйләкәр күзләреннән әтисе «егетләрчә» дигән мәгънәне аңлады.

— Аңлашылды... барысы да аңлашылды,— дип, Ризван малае янына килде.— Илшат, кеше бер вакытта да үзенең вәгъдәсен онытырга тиеш түгел. Син егетләрчә сүз биргәнсең икән, сүзеңдә егетләрчә торырга да тиешсең. Югыйсә, моннан ары синең сүзеңә берәү дә ышанмас. Яле, уенчыкны кайтарып бир...

Илшат ризасызланып кашларын җыерды, мышный-мышный, кургаш солдатны абыйсының аяк астына ташлады. Орхан уенчыкны алырга иелгәч, әтисе:

— Туктап тор әле! — диде.— Илшат, уенчыкны абыеңнан ничек алган булсаң, шулай кайтарып бир.

Илшат, теләр-теләмәс кенә иелеп, уенчыкны идәннән алды, кургаш солдатны беренче тапкыр күргән кебек караштыргалаган булды да абыйсына сузды.

— Менә хәзер син егетләрчә эшләдең! — диде әтисе.

## Югалган кәҗә



Фикрәт Мәхбүбә апасын бик ярата. Апасы аннан дүрт яшькә дәүрәк, өченче класста укый инде.

Бер көнне кич, Мәхбүбә дәресләрен хәзерләп утырганда, Фикрәт аның янына килде дә:

— Карале, шәп бит! — дип, апасына таба кулын сузды. Фикрәтнең учында озын сакаллы, кәкре мөгезле кечкенә генә уенчык кәҗә бар иде. Фикрәт бармагын кәҗәнең мөгезенә тидерүгә, кәҗә сәлам биргән кебек башын селкеде.

— Кем бирде моны сиңа? — дип сорады Мәхбүбә.

— Таптым.

— Бир әле, карыйм!

— Юк! Үзем тапкан — үземнеке.
— Тапсаң соң! Бир әле, карыйм да кайтарам.
Фикрәт уенчыкны апасына бирде. Мәхбүбә аны игътибар белән әйбәтләп карады, кәҗәнең колакларын күргәч, уенчыкның каян килгәнлеген аңлады.
Бу кәҗә күрше кызы Миная уенчыгы иде. Минаяның апасы Мәхбүбә белән бер класста укый. Мәхбүбә иптәш кызы янына гел кереп йөри, бергәләп дәрес тә хәзерлиләр иде.
Моннан берничә көн элек Миная таш кәҗәне кулыннан төшереп җибәреп, аның бер колагын сындырган иде. Апасы белән Мәхбүбә кәҗәнең колагын ябыштырып биргәч, кыз тынычланып еламас булган иде.
Мәхбүбә аны кызганып: «И мескен Миная, кәҗәсен югалткач тагын елагандыр инде,— дип уйлап куйды. Моны энесенә дә әйтте һәм:
— Иртәгә кәҗәне Минаяга кертеп бирерсең, ишеттеңме? — диде.
Фикрәт риза булмыйча иренен турсайтты.
— Димәк, сүземне тыңламыйсың?
— Мин берни белмим, мин кәҗәне җирдән таптым! Минеке ул.
— Синеке түгел, син аны тапкансың гына. Шулай булгач, син аны кайтарып бирергә тиешсең. Бирмәсәң, Минаяны әнисе ачуланыр, аңа бүтән уенчык алмас.
Фикрәт киреләнеп җилкәсен генә җыерды.
— Минем ни эшем бар?! Мин аны җирдән таптым. Минеке ул. Мин берни белмим...
Диванда ял иткән әтиләре боларның сөйләшкәнен ишетеп ята иде. Ул хатынын чакырып алып, аның колагына шыпырт кына нидер әйтте. Әниләре баш какты да чыгып китте. Әтиләре диваннан торып, малайның яраткан уенчыгы Буратиноны яшереп куйды.
Бераздан әниләре кайтып, Фикрәттән «Буратиноң кайда?» — дип сорады. Фикрәт уенчыкларын саклый торган тартмасы янына йөгерде, Буратиноны тапмагач, борчыла башлады. Барысы да Фикрәтнең уенчыгын эзләшкән булдылар, ләкин Буратиноны таба алмадылар.
Фикрәтнең күзләренә мөлдерәп яшь тулды, малай, менә-менә елап җибәрердәй булып, лыш-лыш борын тарта башлады. Ә әнисе аны ачуланырга кереште:
— Эшмени инде шул, я? Алган бер нәрсәне югалтып бара. Моннан ары сиңа уенчык алмыйм,— диде.
Фикрәт үкереп елап җибәрде.
Шул чакны әтисе кинәт кенә:
— Таптым, таптым, менә ул, диванда ята икән,— дип кычкырды.
Фикрәт әтисе янына йөгереп барды, Буратиноны тартып алып күкрәгенә кысты. Йөзе яктырып, күзләре очкынланып китте.
Шуннан соң әтисе, улына ишетелерлек итеп, хатыны белән кызына:
— Менә бит югалган уенчыгын тапса, нинди шатлана кеше. Әгәр мин уенчыкны тапмаган булсам, Фикрәт, мөгаен, төшләрендә күргән булыр иде аны. Ә хәзер әнә ничек шатланды!..— диде.
Шул вакыт Фикрәт Мәхбүбә апасы кулында теге кәҗәне күреп алды. Шатлыгы шундук юкка чыкты. Малай уңайсызланып башын читкә борды.
Әтисе-әнисе дә, апасы да Фикрәткә кәҗә хакында бүтән бер сүз әйтмәделәр. Ә малай иртәгәсе көн җиткәнен түземсезләнеп көтә иде инде.

# Саран



Билалның ике кызы, бер малае бар. Өлкән кызы Сөенче икенче класска күчте. Малае Сурхай биш яшендә. Кечкенә кызы Тәранәгә ике яшь тулды.

Билал эштән соң гына кайта, балалары белән сөйләшергә, шөгыльләнергә ял көннәрендә генә вакыт таба.

Бер якшәмбе көнне Билал улы Сурхайның арифметиканы ни чама белүен тикшерергә булды. Аңа мондый бер мәсьәлә бирде:

— Сурхай, менә синең биш алмаң бар, ди. Икесен Сөенче апаңа, берсен Тәранәгә бирсәң, үзеңдә ничә алмаң кала? — диде.

Малай уйлап та тормыйча:

— Биш! — дип җавап кайтарды.

Әтисе башта бу җавапка гаҗәпләнде, аннары кәефе үк китте. Кушу-алу гамәлен улы яхшы белә дип уйлый иде Билал.

— Улым, син иң элек әйбәтләп уйла, аннары җавап бирерсең. Дөрес әйтмәдең. Биш алма калмый.

— Кала!

— Ничек калсын инде? — диде Билал, ачуы килә башлап.— Менә тыңлап тор әле: синең биш алмаң бар, икесен Сөенче апаңа бирәсең, берсен — Тәранәгә. Үзеңдә ничә алма кала?

— Биш!

— Бу ни хикмәт?! Әллә аңгырамы син!..

Билалның ачуы чыкты: әйтерсең аның каршында малае түгел, әйтерсең кыйммәтле вазаны ваткан мәче тора иде.

Иренең ачуланганын күреп, малайның әнисе дә сүзгә кушылды:

— Аңгыра түгел ул, Билал. Ни...

— Нәрсә «ни»? Син аның ничек җавап биргәнен ишетмисеңмени?

— Тынычлан әле, Билал,— дип, әнисе малайга таба борылды.— Улым, Сөенче апаңның биш алмасы бар. Әгәр икесен сиңа, берсен Тәранәгә бирсә, аның үзенә ничә алма кала?

— Ике,— диде Сурхай тиз генә.

Билал шаккатып кашларын күтәрде.

— Ни хикмәт бу?! Мин дә шуны ук сорадым ич!.. Нинди аермасы бар?

— Аермасы шул: Сурхай апасы белән сеңелесенә үтерсәң дә берни бирми, ә аларда бирәр әйбер күрсә, үзе сорап ала. Мондый малайны кем дип атыйсың инде? Аңгыра дипме, әллә...

— Саран дип атыйм мин аны, саран! — диде Билал, ризасыз бер кыяфәттә башын чайкап.

Әзербайҗанчадан
Х. ЯХИН тәрҗемәсе.

Фатих Хөсни

# ЦИКЛОН

хикәя

Шәһәрдә без, аллага шөкер, бер-беребезне белмибез дә. Ә менә җәйге айларда, атна башында, шимбә азагында дигәндәй, ишәктәй күтәренеп һәм, өстәвенә, хатынның кешегә ишеттермичә генә әрләгән шелтәләрен тыңлап бакчага чаба башлагач, бигрәк тә җәйге ялларыбыз да бер тирәдәрәк туры килсә, момент дуслашып китәбез. Минеке — аныкы, аныкы — минеке. (Дөрес, мин үзем, үзара гына әйткәндә, минеке — аныкы булуга караганда, аныкы — минеке булганны яратарак төшәм — нишләтәсең, бармак үзеңә кәкре!) Югыйсә, бакчаларыбыз да рәттән түгел, әллә ни уртак сүзләребез дә юк, ә менә шулай, бер-беребезгә сагыз булып ябышканбыз. Җәйге айлар турында сүз бара, зинһар, кышкы айлар белән һәм, гомумән, дөнья-ахирәт белән бутамагыз. Хәер, бакча дусы булу өчен әллә ни зур һиммәт тә кирәкми. Теге я бу агачны ничек, кайчан күчереп утырту хәерле икәнлеге турында тәҗрибә алышсаң, аннары тагы күп акча чыгармыйча гына тирес табу юлларын бер-береңә өйрәтешсәң, шуларга ук өстәп я ул, я син кыстыра килгәнне шау-шусыз гына бүлешеп салышсаң — бакча дуслыгының фундаменты менә шул.

«Фундамент» дигәннән искә төште, әлеге шул Бәкер дус турында әйтүем, әкәмәт нык итеп, кирпечтән һәм бетоннан катырып салды ул фундаментны. Аннан да бигрәк, базны бер тамаша коеп куйды. Стеналары тоташ кирпечтән, варенье банкалары, тозлаган кыяр, помидор савытлары кую өчен куышлар калдырган, ул куышларның стеналары цементтан, базның идәне шулай ук цементтан. Һава кереп-чыгып торсын өчен ян-яннарына түгәрәк амбразуралар чыгарган, бер сүз белән әйткәндә, баз түгел, крепость. Кызыгы тагы шунда: өч җәй буена ныгыткан шул «крепость»-нигезгә, цементтан-кирпечтән катырган шул базы өстенә калдык-постык фанер кисәкләреннән әтмәлләнгән, кәҗә оясы хәтле генә өен бастырды да куйды бу. Сүз чыга кайчакта. Үенын-чынын бергә кушып әйтәсең:

— Синең, Бәкер дус, базың өеңә караганда мең тапкыр яхшырак, килгән кунагыңны өеңә үткәрмә, тот та базыңа яп та куй, тавышы да чыкмас, чыкса да, кешегә ишетелмәс.

— Бу да бер резон, минем башка андый шәп идея килгәне юк иде әле,— ди Бәкер, авыз чите белән генә көлгәндәй итеп. Һәм шундук үтә җитди тонга күчеп ялгап алып китә: — Бакча өчен, җиләк-җимеш кую өчен баз ул, малай, латинчалап әйткәндә, альфа и омега... Калганы барысы да вакытлы чара. Әле минем башта хыяллар йөри.

Һәм ул, көе шәп чак туры килсә и шунда беррәттән син кыстырып алып барганны салып та җибәргән булса, китә инде аннары хыялларын бушатып: кайдан ул нинди мал кулга төшерәчәк. Әлеге ныклы фундамент өстенә нинди вилла бастырып куячак. Ике катлы гына түгел, мансардасы белән өч катлы. Мансардасында бала-чага, икенче катында чакыру буенча килгән кунаклары, аскы катында хатыны белән үзе, тагын да астарак, ягъни әлеге теге мактаулы базына, без биргән акылдан файдаланып, чакырмыйча килгән кункаларны ябып куячак. Өч катлы бу пыяла вилла өстендә, төн булса бөтен тирәюньгә аллы-зәңгәрле нурларын чәчеп, алты лампалы алты шар янячак. Янә килеп, ул шарлардан да өстәрәк, җил уңаена канатларын җилпеп, буяулы калай әтәч әйләнеп торачак.

— Менә шулай тора эшләр, авыз җырырга ашыкма,— дип куя ул иң ахырдан, синең каршы төшәчәгеңне әллә кайдан белеп торгандай.

Шулай да аның тормышка ашмастай бу хыялыннан көлмичә калып булмый, кайчагында җеп очларын яшерергә тырышып кына сорау бирәсең:

— Кара әле, Бәкер дус, нишләп әле син үзең аскы катта калып, кунагыңны үтә дә почетлы урынга — өске катка ук менгездең? Соңыннан берәр файдасы тиярдәй адәм түгелдер бит?

— Тешеңне ыржайтма,— ди ул, синең бу соравың астында качып яткан чәнечкеле кинаяне шундук сизеп алып,— үзем аста калып, кунакны югары үрләтүнең янә бер резоны бар: кунактан элек торып, өйдән качып китү өчен эшләнә бу. Йокысы тәмам туйгач, соң гына уяна бу кунак дигәнең, як-ягына карана, сорашып, көтеп карый, һич тә булмаса, балконга чыгып, югарыдагы калай әтәчкә сокланган була, әмма ләкин юк хуҗа, сызган хуҗа. Көтеп-көтеп тә хуҗаның кайтып җиткәнен көтеп ала алмагач, нишләсен, бичара, җилкәнне китү ягына бормыйча хәле юк.

Әнә шундый бер кеше инде ул минем бакча күршесе, минем Бәкер дус. Хыяллануны да булдыра, көлгәнне дә аңлый, үзе дә көлә белә, шулай кирәк саный икән, чакырып китергән кунагыннан качып китү юлларын да таба. Дөресрәге, көтмәгәндә башына килеп төшкән бер бәлагә хәтле шундый уңган кеше иде. Ә ул бәла аны берьюлы имгәтеп, канат-каурыйларын каерып алып киткәндәй итте.

Ә бу болай булды: атна буена җелекләрне киптерерлек кызу көннәр торганнан соң, көтмәгәндә-уйламаганда, Идел аръягыннан, туп-туры Зөя тирәләреннән кара-кучкыллы болыт күренде. Кинәт күренүендә үк бер шом бар иде аның — гомере буена халык алдына чыгып сыңар бер сүз әйтмәгән адәм трибунага менеп басса, шулай шомланам мин, ни ычкынмас ул мокытның авызыннан... Шулай чыкты болыт, шулай күтәрелә, өскә килә... Шомлы, яшелле-зәңгәрле, әллә ниткән тересәкләре, кабарган мыеклары бар, әйтерсең без сүз берләшеп бакчаларыбызда юри корткыч бөҗәкләр үрчетеп ятканбыз да шуның өчен безнең башка орырга килә. Аннары бер мәл дөньяны тынлык басты, ничектер, бугазны киптерә торган тынлык. Хәер, бусыннан мин алай курыкмадым, кипсә тагын, чылата торганның алып

куйганы бар иде. Гөнаһ шомлыгы түгел диген, нәкъ шул мәлдә минем бакча башыннан Бәкер дус узып бара. Бүтән вакытта үзем башлап өйгә кунак чакырмый торган мин күчәннең теле әйләнеп куймасынмы:

— Кара әле, Бәкер малай, болыт чыгып тора, әкәмәт болыт... Мондый чакта ахыры хәерле булсын дисәң, бер әмәле бар инде барлыкка да...

Болай чорнап әйтүнең кирәге дә булмаган икән, Бәкерем-тишек түбә шундук чамалап алды:

— Әллә синең алып килгәнең бармы? Соңыннан хатыныңның каһәре сугар дип тә курыкмыйсыңмы?

Юха җылан ул Бәкер, адәм түгел, мине кай яктан чеметергә икәнен белә, янәсе, мин — алып куйганым булса да, андый мәсьәләдә хатынның рөхсәтеннән башка кыл да кыймылдата алмый торган куркак бер мәхлук. Җен ачуларым чыкты аның бу сүзенә и шунда, минем җенне йолкып алган кебек, безнең өстебездән генә көтүче чыбыркысыдай сузылып һәм чыжылдап хәтәр җил дулап узды.

— Аен, цвай... минем базда закусканың әгъләсе вә әүләсе бар,— дигәнен генә ишетеп калдым Бәкернең, үзе юк иде инде. Әйтерсең әлеге ыргып узган җил үзе белән аны да урап алып китте. Бактың исә, бу әле сузылып каравы гына булган икән «көтүче чыбыркысының». Аның болганасы, болгатасы, чыжлыйсы, шартлыйсы минутлары алдарак булган икән. Кинәт көнне караңгылык басты, бер үк вакытта тузгып җил купты, кемнәрнеңдер беседка түбәсен йолкып алып минем помидорлар өстенә китереп атты, кайдандыр баласына чырылдап кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелеп калды, агачлар сынганы, тирес яшереп куйган полиэтилин кисәкләренең очканы, буш ләгәннәр зыңгылдавы — барысы-барысы бергә буталып, дөнья бер мәл акылыннан шашты. Мин, әлбәттә, артык күзәтер чамамны югалттым, Бәкер дус та онытылды, яшермим, тирес валчыклары, буш ләгәннәр, полиэтилин кисәкләре белән бергә, ахрысы, минем котым да очып киткән булса кирәк.

Бу «пәри туе» күпме дәвам иткәндер, күземне ачып җибәргәндә, мин әле исән, бер ялгызым өемнең почмагында сеңеп утырам, имеш. Тиз генә башымнан: Ә бүтәннәр? Ә хатыным-Газизәбануым кайда?» — дигән сорау узды, ләкин шундук өнемә килдем: бүген мин, күрәчәккә каршыдыр инде, бакчага ялгызым гына киләсе иткән идем. Кем белгән, бәлки баягынак Бәкер алдында куштанлык күрсәтеп, аны сыйларга ниятләвем дә шуннан килеп туган бер шомлык булгандыр.

Бер өнгә килгәч, ул факыр да искә төште: ник болай озаклады? Закускага дип кенә киткән кеше ич! Бу «пәри туе»ннан исән-сау котылып калуым галәмәтедер инде, минем күңелем изгелек белән тулган иде ул минутта. Бәкер дусны алып килергә дип үзем киттем.

Барсам, ни күзләрем белән күрим: Бәкернең әлеге теге фанер кисәкләреннән генә оештырылган «вакытлы» кетәген давыл очырып алып киткән, тик таштан, бетоннан катырган нигезе һәм аның нәкъ уртасында тешсез авыз кебек базы гына кара янып тора иде. Давыл узганда, ахрысы, ул шунда булып калгандыр, базының капкачы ачык, эчтән нинди дә булса тавыш-тын ишетелми иде. Бер мәл шикләнә калдым, тизрәк баз авызына иелеп кычкырдым:

— Син андамы, Бәкер? «Аен, цвай» дип кенә киткән кеше, панимаешь.

Шактый вакыт тавыш-өн ишетелмичә торды һәм, тәмам аптырап калганда гына, баз авызында тегенең пеләш башы ялтырап күренде. Беравык телен әйләндереп сүзен әйтә алмыйча азапланды бу. Күз-

ләре, саташкан кешенекедәй, берсе чәршәмбегә, икенчесе дүшәмбегә карый иде.

— Син нәрсә? Онытты̆ң мәллә нәрсәгә дип киткәнеңне? Өең кайда соң синең?

Бичараны ничек тә тизрәк өненә китерү нияте белән, бер-бер артлы сораулар яудырырга тотындым. Хәтсез вакыттан соң гына, анда да баздан чыгарга һич ашыкмыйча, котсыз бер тавыш белән:

— Син кем? — дип эндәште бу миңа.

Менә сиңа мә! Дус дип йөргән кешем, хыяллары белән бүлешүче, гел минем хатыным юк чакны туры китереп йөрүче и хәзинәңдә булганны бүлешеп кабучы җан дусың күзгә карап, нәрсә, ди?! «Син кем?» имеш. Төрле яклап яңадан сораулар яудыра торгач, ниһаять, пеләшенә шапылдатып сугып куйды бу. Беләм мин аның бу гадәтен: «сукин сын, мин дә бар ич әле бу дөньяда!» дигән сүзе иде бу аның. Ләкин бу — иске киемдә ябышып калган иске төймә генә булып чыкты.

— Ә кайда «әгълә вә әүлә» закускаң? — дигән сорауны куйгач, ул тәмам өнгә килде, озак көттермичә һәм бу юлы инде бөтенләй ачык итеп, солдат-дневальный рота командирына рапорт биргәндәге ачыклык белән әйтте миңа:

— Юк, туган, больше миннән андый эшләр белән булашуны көтмә. Исән калганым өчен шөкер, өй белән бергә башны очырып алып китмәгәч, больше авызга алмаска ант иттем. Тәүбә-әстәгъфирулла, карчыклар әйтмешли.

Шулай итеп шул, берничә минут эчендә котырып узган бу циклонның Бәкер дуска файдасы тиде — шуннан бирле аракыга иренен дә тидерми. Әгәр, әйтик, шундый циклоннар ешрак һәм хатыннары өйдә юклыктан файдаланып берсе икенчесендә әледән-әле кунак булырга ярата торган бүтән ирләр башыннан да уйнап узса? Миңа әйтүләре бар: «Кара әле, шайтан колы, Бәкер дусыңны котыртучы син үзең ич. Әгәр шул циклон синең башыңны да очырып алып киткән булса?» — диюләре мөмкин. Узсын. Миңа да, бәлки, файдасы тияр. Мин кешедән киммени?

*Сентябрь, 1971.*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## «КАЗАН УТЛАРЫ» БӘЙРӘМЕ УҢАЕ БЕЛӘН

Билгеле булганча, шушы елның май аенда «Казан утлары» журналының чыга башлавына 50 ел тулды. Республикабыз хезмәт ияләре бу олы бәйрәмне күтәп алдылар, тантаналы шартларда билгеләп уздылар.

Бәйрәмгә кадәр берничә ай буе Татарстанның төрле районнарында «Казан утлары»на багышланган конференцияләр, әдәби кичәләр үткәрелеп килде. Шундый кичәләрнең берсе 11 февральдә Лениногорск районының Муса Җәлил исемендәге колхозында булды. Журналның баш редакторы Г. Ахунов кичәдә катнашучыларны журналның эш планнары, редакция портфелендәге зур күләмле яңа әсәрләр белән таныштырды, укучыларның күп санлы сорауларына җавап бирде. Журнал авторларыннан Ш. Бикчурин «Каты токым» романыннан өзекләр, Җ. Рәхим яңа хикәясен, Р. Вәлиуллин шигырьләрен укыды.

Лениногорск музыка педагогия училищесы укытучыларыннан яшь композитор Ф. Хөснуллин, җырчы Ф. Юсупов, студентлардан К. Вәлиуллина, Э. Латыйпова, З. Әхмәтҗанова Татарстан композиторларының төрле елларда «Казан утлары» журналында басылган җырларын башкардылар.

* * *

«Казан утлары» журналына багышланган тагын бер кичә 14 февральдә Лениногорск шәһәренең 5 нче урта мәктәбендә үткәрелде. Кичәдә язучылардан Г. Ахунов, Ш. Бикчурин, яшь язучылардан А. Хәсәнов, Җ. Рәхимов, Р. Вәлиуллиннар катнашты.

Г. Ахунов шулай ук КПССның Лениногорск шәһәр комитетында булды, редакция, радио, «Союзпечать» хезмәткәрләре белән очрашып сөйләште.

## КИТАП СӨЮЧЕЛӘР ҖАВАБЫ

1971 елда Украинада чыга торган «Рабочая газета» редакциясе үзенең күп санлы укучыларына «Сезнең иң яраткан язучыларыгыз кемнәр?» дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән иде. Газета редакциясенә алты меңнән артык җавап килгән. Украина китап сөючеләренең кайсы язучыларның әсәрләрен яратып укыганы түбәндәге таблицадан ачык күренә.

## РУС ӘДӘБИЯТЫ

| | |
|---|---|
| Михаил Шолохов | — 1 180 тавыш |
| Константин Симонов | — 450 » |
| Вадим Кожевников | — 200 » |
| Борис Полевой | — 180 » |
| Георгий Марков | — 160 » |

## СССР ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

| | |
|---|---|
| Чыңгыз Айтматов | — 1 830 тавыш |
| Рәсүл Гамзатов | — 1 260 » |
| Эдуардс Межелайтис | — 930 » |
| Берды Кербабаев | — 560 » |
| Габдрахман Әпсәләмов | — 400 » |

## НЕПАЛДА — ТАТАРСТАН ТУРЫНДА

«Советлар иле» журналының Непалда чыккан узган елгы бер саны тулысы белән диярлек Совет Татарстанына багышланган.

Журнал Максим Горький һәм Габдулла Тукай исемендәге премияләр лауреаты, шагыйрь С. Хәкимнең «Барысы да халкым йөзендә» дигән публицистик мәкаләсе белән ачылып китә. Журналда киң бер сәхифә республикабызның Ленин исеме белән бәйле урыннарына багышланган.

КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре, КПСС Үзәк Комитеты члены Ф. Табеевның «Бөек көч» дигән зур мәкаләсе халкыбызның коммунистлар партиясе житәкчелегендә XXIV съезд карарларын үнышлы рәвештә тормышка ашыруы турында сөйли. Татарстан Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев үзенең журналга биргән интервьюсында республикабызның тормышын, татар халкының совет чорындагы зур уңышларын яктырта. Бу журналдан шулай ук безнең Кама буенда барган гигант автозавод төзелеше, нефть районнарыбыздагы зур эшләр турында укырга да, төрле фоторәсемнәрдән андагы хезмәт алдынгыларын, яңа шәһәр, яңа төзелеш панорамаларын күрергә дә мөмкин. Монда татар авылы үсешенең яңа перспективалары турында да мәкалә бар.

Республикабызның Культура министры Б. Гыйззәтуллин «Совет Татарстаны культурасы» дигән мәкаләсендә татар халкының сәнгате, театры, гомумән, культура казанышлары турында тулы мәгълүмат бирә.

Непал укучыларына шулай ук язучы М. Рәфыйковның «Шарлама» исемле хикәясе, халкыбызның мәкальләре һәм мәзәкләре такъдим ителгән.



*Берлинда «Муса Җәлил» бригадасы членнары.*

## ДУСЛЫК ҖЕПЛӘРЕ НЫГЫЙ

Язучы Р. Мостафинның Германия Демократик Республикасында булган чагында Муса Җәлил исемен йөртүче бригада членнары белән очрашуы матбугатта хәбәр ителгән иде инде. Берлин шәһәренең тормозлар эшләп чыгаручы «Берлинер Бремзенверк» заводында оешкан һәм өч мәртәбә Социалистик хезмәт бригадасы дигән мактаулы исемгә лаек булган бу коллектив Татарстан язучылары белән дусларча элемтәдә тора. Әле күптән түгел генә «Муса Җәлил» бригадасы членнары Р. Мостафин исеменә үзләренең күмәк фоторәсемнәрен һәм истәлекле бүләк җибәргәннәр иде.

## ФЕДИН БӘЙРӘМЕ

СССР Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое, академик Константин Александрович Фединга 80 яшь тулу уңае белән СССР Язучылар союзында 24 февральдә үткәрелгән тантаналы мәҗлестә катнашырга республикабыз язучылары һәм укучылары сәламе белән Зәки Нури барды. Билгеле булганча, К. Федин— безнең барыбызга да аеруча таныш булган олы якташыбыз Ул Саратов шәһәрендә туа, Ватан сугышы елларында тагын бик күп рус язучылары белән бергә Казанда була һәм Чистайда тора, анда бик күп әдәби чыгышлар ясый, хәзер бөтен дөньяга билгеле кайбер әсәрләренең планнарын уйлый, аерым өлешләрен яза. Бу дуслыкта конкрет бер шигърият бар, аның эшлекле эчтәлеге зур. Шуна күрә Зәки Нуриның бәйрәмнән кыска бер шигъри репортажы да безнең бу информациягә өлеш итеп теркәлә:

**Төбәп карап, якты-тирән күзләр**
**Аңлаттылар күңел уйларын —**
**Сагына иңән Казан каласын ул,**
**Сагына иңән Кама буйларын.**
**Ә Чистайны кат-кат искә алды:**
**Мин бит анда булдым кат-кат, дип,**
**Йөрде кебек әсәр геройларым**
**Урамнарын аның таптап,— дип.**
**Бүләгенә Казан кызларының —**
**Мәскәүләргә килгән чәчкәнә**
**Карап торды — гүя карагандай**
**Таныш кырдан җыйган чәчәккә.**
**Китаплары барды бу бәйрәмгә**
**Камал, Тукай, Җәлил, Такташның.**
**Бик күпләрнең кайнар хисе барды**
**Бәйрәменә олы якташның!**

Мәҗлестә илебездәге әдәбият, сәнгать һәм фән оешмаларыннан, партия, совет, комсомол һәм профсоюзның җитәкче органнарыннан, нәшриятлардан, газеталар һәм журналлар редакцияләреннән, чит ил язучыларыннан вәкилләр катнашты.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ТӘНКЫЙТЬ

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры партия оешмасының ачык җыелышында театр җитәкчеләре, артистлар, режиссерлар, художниклар, язучылар, театр белгечләре КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы» карары яктылыгында иҗат коллективы һәм театр тәнкыйте алдында торган бурычлар хакында фикер алыштылар. Докладчы — театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов һәм фикер алышуда катнашучылар Үзәк Комитет карарын бердәм яклауларын белдерделәр һәм театр тәнкыйтен тагын да яхшырту чаралары турында сөйләделәр. Җыелыш тикшерелгән мәсьәлә буенча конкрет карар кабул итте.

* * *

Татарстан композиторлар союзының чираттагы партия җыелышы да музыка тәнкыйтен һәм музыка белгечләре, композитор-

лар алдында торган бурычларны тикшерүгә багышланган иде. Җыелышта чыгыш ясаган музыка белгечләре Й. Исәнбәт, Ф. Бикчурина, З. Хәйруллина, Я. Гиршман, З. Сәйдәшева, Г. Кантор, Г. Калашкина, З. Мулюкова, композиторлар Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, Р. Еникеев, Казан дәүләт консерваториясе доценты К. Гыйззәтов музыка тәнкыйтен үстерү буенча фикерләрен әйттеләр. Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## УКУЧЫЛАР ФИКЕРЕ

Узган ел «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе «Газета турында укучы» дигән исем астында анкета урнаштырган иде. Редакциягә 600 дән артык җавап килде. Бу җаваплардан Б. Камаловның «Кышкы яңгыр», Ф. Шәфигуллинның «Ликандо» хикәяләре, Зөлфәтнең «Әни», «Коммунист йөрәге турында баллада» шигырьләре, Ә. Хәйретдиновның шагыйрь Ф. Яруллин сүзләренә язылган «Иң гүзәл кеше икәнсез» дигән җыры, М. Рәфыйков, М. Насыйбуллин, Р. Хисмәтуллин очерклары укучылар күңеленә аеруча хуш килгәнлеге мәгълүм булды.

## КУЛЬТУРА РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

Март аенда М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында республикабыз культура работникларының IV съезды булды. Съездны КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев ачты.

ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Хәсәнов КПССның XXIV съезды, КПСС Үзәк Комитетының «Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүнең 50 еллыгына хәзерләү турында»гы карарларын үтәү буенча культура работникларының бурычлары турында доклад белән чыкты.

Фикер алышуларда РСФСР культура министры урынбасары Е. Милов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншина, ТАССР композиторлар союзы идарәсе председателе, СССР халык артисты Н. Җиһанов, язучы Г. Ахунов һәм башка иптәшләр катнашты.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев чыгыш ясады. Съезд эшендә шулай ук ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. Усманов катнашты.

## ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучыларының март аенда үткәрелгән ачык партия җыелышында иҗат секцияләренең эше тикшерелде. Җыелышта доклад белән Язучылар союзының җаваплы секретаре, шагыйрь Р. Харис чыкты. Фикер алышуларда Г. Кашшаф, А. Гыйниятуллина, М. Хәмитов, Н. Бабенко, З. Шаһиморатов, М. Мазунов, Г. Сабитов, В. Юдин, һәм башка иптәшләр катнаштылар. Җыелыш иҗат секцияләренең эшен тагын да яхшырту турында карар кабул итте.

## ДАИМИ СЕМИНАРДА

Татарстан культура эшлеклеләренең КПСС өлкә комитеты каршында оештырылган даими семинарының чираттагы занятиесендә М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының «Кияүләр» (Хәй Вахит либреттосы, Сара Садыйкова һәм Рәшит Гобәйдуллин музыкасы) спектакле турында фикер алыштылар. Язучылар Х. Туфан, Р. Ишморатова, музыка белгече З. Хәйруллина, артистлар Ф. Насретдинов, Й. Гыйззәтуллин, В. Шәрипова, композитор Ә. Бакиров, художник Э. Гельмс, сәнгать белгечләре Б. Гыйззәт, Х. Гобәйдуллин спектакльгә карата үзләренең фикерләрен һәм тәкъдимнәрен әйттеләр.

Мәскәүдән килгән сәнгать белгече И. Мартынов традиция һәм заманчалык турында доклад белән чыкты. КПСС өлкә комитетының лекторлар группасы җитәкчесе, философия фәннәре кандидаты А. Калаганов атеистик пропаганданың кайбер актуаль мәсьәләләре турында сөйләде. Семинар занятиесен КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. Мусин алып барды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән Татарстан язучылар союзының пропаганда бүлеге язучылар белән очрашу кичәләре уздыра. Шундый очрашуларның берсе Куйбышев шәһәрендә уздырылды. Бу очрашуга С. Сөләйманова, Х. Сарьян, Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Мингалимов, М. Газар, Л. Хәмидуллин катнашты. Алар В. И. Ленин исемендәге металлурглар заводы цехларында һәм культура сараенда, Дзержинский исемендәге культура сараенда, «Звезда» клубында укучылар белән очраштылар.

* * *

Татарстан язучылар союзы тарафыннан Баулы районында үткәрелгән әдәби очрашуларга С. Шәкүров, М. Хәбибуллин, М. Хәмитов, Ф. Мансуров, Рәшит Әхмәтҗанов һәм нәфис сүз остасы М. Шиһапов катнашты.

* * *

Тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре Г. Кашшаф, Р. Мостафин, филология фәннәре докторы, профессор И. Нуруллин, шагыйрь Р. Харис Казанның «Теплоконтроль» заводы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары белән очрашып, әдәби тәнкыйть алдында торган мөһим бурычлар һәм әдәби тәнкыйтьнең максаты турында тирән эчтәлекле зур сөйләшү алып бардылар. Бу очрашу телевидениедән дә күрсәтелде.

* * *

Казан шәһәре культура сарайларында «Казан язы» исеме белән барган әдәби-музыкаль кичәләрне халык бик җылы кабул итте. Кичәләргә иң актив катнашкан язучылар — Г. Минский, Г. Ахунов, Б. Камалов, С. Шәкуров, М. Маликова, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, артистлардан — Г. Рәхимкулов, Ф. Сөләйманова, Р. Ильясов һәм нәфис сүз остасы М. Шиһапов булды.

* * *

Казан дәүләт педагогия институтының тулай торагында яшь шагыйрьләр һәм прозаиклар Р. Вәлиев, Ф. Сафин, Р. Миңнуллин, Р. Низамиев, Р. Бәшәров һәм башкалар студентлар белән очрашып, яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Яшь шагыйрьләр Р. Вәлиев, Ф. Сафин, Ә. Гадел, журналист Р. Хисмәтуллин Түбән Кама районы авылларында чыгышлар ясадылар.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БЮРОСЫНДА

30 март көнне Татарстан язучылар союзының консультация бюросында яшь язучы Касыйм Нигъмәтуллин иҗаты буенча индивидуаль семинар үткәрелде. Семинар җитәкчеләре Х. Сарьян, Р. Мингалимов, Г. Рәхим яшь язучының нәсерләрен, лирик парчаларын укып тикшерделәр, авторга киңәшләр бирделәр һәм уңышлы әсәрләрен «Идел» альманахына тәкъдим иттеләр.

## Шәриф ага Саттаров

**Быел, 14 мартта, озак авырудан соң, карт язучы, педагог, журналист һәм персональ пенсионер Шәриф ага Саттаров вафат булды.**

**Ш. Саттаров 1887 елның 10 маенда Оренбургның Сагыйть бистәсендә туа. 1909 елда Казандагы «Учительская школа»ны тәмамлагач, татар мәдрәсәләрендә рус теле укыта, үзенең әсәрләре белән матбугатта катнаша башлый.**

**Революциягә кадәр аның «Азатлык корбаннары», «Бәхетсез татар кызы» кебек сәхнә әсәрләре басылып чыга һәм сәхнәләрдә куела.**

**Бу әсәрләрдә шул заманның кара көчләре, кадимчеләре, динчеләре тәнкыйть ителә.**

**Ш. Саттаровның хезмәт ияләрен аң-белемгә өндәгән әдәби-педагогик эшчәнлеге, билгеле, полиция игътибарыннан читтә калмый: ул кулга алына, төрмәгә утыртыла. Төрмәдән чыккач, полиция күзәтүеннән үзен яшерү теләге белән, 1913 елда Астраханьга килеп педагоглык эшен дәвам иттерә.**

**Шәриф ага Саттаров Бөек Октябрь революциясен шатланып каршы ала һәм аның беренче көннәреннән үк совет мәгариф эшләрендә актив катнаша. «Халык мәгарифе» журналының җаваплы редакторы була. 1925 елда Мәскәүгә күчкәннән соң, Ш. Саттаров Кызыл Армия Политидарәсе тапшыруы буенча татар кызылармеецлары өчен дәреслекләр, РСФСРдагы татар мәктәпләре өчен уку китаплары, кулланмалар яза.**

**Шәриф ага Саттаров 1950 елдан бирле Татарстанның Зеленодольск шәһәрендә илебездә барган тарихи вакыйгалар белән рухланып яшәде. Ленин партиясенә багышлап «Зөһрә йолдыз» исемле яңа пьеса язды.**


**Карт язучы, талантлы педагог һәм журналист Шәриф аганың якты хатирәсе дуслары күңелендә озак сакланыр.**


БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘРЕ.

# АКЧАРЛАКЛАР

ХӨСНУЛ ВӘЛИУЛЛИН көе

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ җыры






Кораб китте зур юлларга, еракларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.

Мәхәббәтне ала алмый бер упкын да,
Хыянәтне күтәралмый бер дулкын да.
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Кавышуны вәгъдә итә пар канатлар.

Сөйгән ярым китеп барды кулын болгап,
Кайтыр микән тагын миңа юллар урап!
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар.

*Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның 8 нче санында

Аяз Гыйләҗевнең «Урталыкта» һәм Рәисә Ишморатованың «Милиция лейтенанты» дигән повестьлары басыла.

Шигърият дусларына Сибгат Хәким, Мөдәррис Әгъләмов, Фәнис Яруллин шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Барлас Камаловның «Ул һаман да солдат», Валентина Гудкованың «Профессор Мөштәри» дигән очеркларын, А. Халиковның «Дунай Болгарстаны — безнең кардәшләребез иле» дигән мәкаләсен һ. б. материалларны укырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210